www.kazanutlary.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ
ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Рашат НИЗАМИ. Безнең Тукай. *Шигырь.* ....3
Марат ӘМИРХАНОВ. Зиннәтулла хәзрәт. *Бәян.* ....4
Рәниф ШӘРИПОВ. Эт урамы. *Поэма.* ....20
Кәрим КАРА. Депрессия. *Фәлсәфи повесть.* ....24
Халисә МӨДӘРРИСОВА. Галәмнәргә чаклы агыла. *Шигырьләр.* ....53
Дилбәр БУЛАТОВА. Соң түгел! *Повесть.* ....57

*Җәһәт тәнкыйть:* сәхифәне Дания ЗАҺИДУЛЛИНА алып бара. ....96
Айдар ХӘЛИМ. Читтә. *Хикәя.* ....97
Рәсимә ГАРИФУЛЛИНА. Ай нурында энҗе яна. *Шигырьләр.* ....113

*100нче бит:* Рухия АХУНҖАНОВА. Тукайның «Туган тел»е. ....100

ЯҢА ИСЕМНӘР

Алинә ГАЛИЕВА. Киләчәккә атап. *Фантастик хикәя. (М.Закирның кереш сүзе белән).* ....117

ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕНӘ КАНДИДАТЛАР

Әхәт ГАФФАР. Киләчәктән кайтып килешли. *Хикәя.* ....133
Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА. «Кеше бәясен халкы билгели...». *Очерк.* ....137

*Кардәш халыклар әдәбияты:* Якут риваятьләре. (*Мөдәррис ВӘЛИЕВ тәрҗемәсе).* ....144

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Фоат ГАЛИМУЛЛИН. Гафур Коләхмәтовка ике төрле караш. ....154

*Юбилейлар*: Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ. Әдәбиятыбызның әмир-ханнарыннан берсе. ....158

ТУКАЙ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

Рифә РАХМАН. Тормышыма Тукай килеп керде... ....164

*Дин һәм тормыш:* Харис хәзрәт САЛИХҖАН. Шагыйрьнең Коръәнгә мөнәсәбәте. ....168

*Тормыш язган хикәяләр:* Вакыйф НУРИЕВ. Мостаев җыры. *Хикәяләр.* ....175

ЮМОР ҺӘМ САТИРА

«Афәрин, тагын әйт!». Рабит БАТУЛЛА тупламасыннан. ....178
Ислам ӘХМӘТҖАНОВ. Әйткән сүз... ....180
Разил ВӘЛИЕВ. Синең язмыш язга охшаган. ....181

Сәфәрләр, очрашулар, тәэсирләр... ....182

АК ҖИЛКӘН

Ләйсән САФИНА, Резедә СӘЕТГӘРӘЕВА, Рима ФӘРРАХОВА *шигырьләре.* ....186
Юлия ДӘҮЛИКАМОВА. Беләзек. *Хикәя.* ....188

«Казан утлары» архивыннан. ....142
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

татмедиа

Гамәлгә куючы –
«Татмедиа»
акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР –*

**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Рәдиф Җамалетдинов**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Зиннур Мансуров**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Вакыйф Нуриев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Данил Салихов**
**Айрат Сибагатуллин**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Илсур Һадиуллин**
**Рәфикъ Юныс**

---

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Фәнил Гыйләҗев, Айсылу Имамиева, Камил Кәримов, Ләйсән Солтанова.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Наил Кадыйров.**
*Сайт мөхәррире:* **Рәзилә Хәйретдинова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Люция Сөләйманова** (баш бухгалтер).

---

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип һәм проза бүлеге – 222-09-83 (өст. 1613)*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1266), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
: **Факс** – (843) *222-09-83 (өст.1612).*
: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 30.03.2018, график буенча 30.03.2018.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ Е-761. Тираж 4100.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекслар: 73210 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен), П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), 16262 (Татарстаннан читтәге юридик затлар өчен), П2368 (Татарстандагы юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2018 ел

Рашат
Низами

## БЕЗНЕҢ ТУКАЙ

Чәчәкләрне, ачы җимешләрне
Меңләп табам шигъри түтәлдән...
Чандыр гына, ябык кына Тукай
Татар йөген күпме күтәргән!

Шагыйрьлекнең юлын сайлый белгән,
Җир-күкләрнең исен китәреп.
Әле дә булса Тукай, Атлант кебек,
Милләт йөген бара этәреп.

Кергән Тукай Казан урамына,
Көткән дошман, көткән дуслары.
Шигырь уты белән айкаган ул
Державаның салкын бозларын.

...Вакытларны бергә тоташтырып,
Ява карлар, яңгыр тамчылый.
Бара Тукай Яшәү урамыннан –
Кочак җәеп еллар каршылый.

Казан өсләрендә дөрли кояш,
Ул – шагыйрьне күргән утчәчәк.
Дәверләрне ерып бара Тукай,
Һәм каршылый Аны киләчәк.

Тукай күләгәсен каплый алмый
Җил-бураннар, яшен, яңгырлар.
Ә мөкатдәс моңлы сазы аның
Гасырларда мәңге яңгырар!



Марат
Әмирханов

# ЗИННӘТУЛЛА ХӘЗРӘТ

БӘЯН

*Картларның иң яхшы күңеллесе*
*булган бабабыз...*
Габдулла Тукай

Ничәнче көн инде иртәләрен күктә өч кояш пәйда була. Бу – кырлач галәмәте. Хак, кырлач-кырлач инде ул, җиргә төшкәнче төкерек туңарлык зәмһәрир салкыннары белән әнә шулай күкләрне дә үз хөкеменә ала.

Кырлачта җиде җилән кигәнче, бер тун ки, ди. Кече Сасна зиратына адашкан кыр куяны эзеннән ялгызы кар ерып кергән мосафир бу киңәшкә колак салмагандыр, мөгаен. Җиләнен җилән түгел, әмма утырма якалы сырмасын да энәдән-җептән генә чыккан дип әйтеп булмый, шактый таушалган. Аның каравы, йон муен капламасы калын күренә. Билбавы да мулдан, ике-өч кат уралган.

Хәер, мосафирның күктәге өч катлы кояшта да, җилеккә үтәрдәй бозлы суыкта да гаме юк иде ахрысы. Намазлык вазифасын үтәүче тире кисәгенә тезләнгән дә тораташтай каткан хәлдә оеган, фәкать иреннәре генә селкенгәли.

– И Раббым, каберләребездән кубарылып, мәхшәр мәйданына җыелганда, йөзләребезне ай кебек якты кылып, гамәл дәфтәрләребезне уң тарафларыбыздан бирелүне барчабызга да насыйп ит. Нечкәлектә чиктән тыш булган сират күперен мәшәкатьсез үтеп, җәннәткә керүне җөмләбезгә насыйп ит. Амин! Раббым, Синең турылыклы колбикәң, минем дөньялыктагы кызым мәрхүмә Бибимәмдүдә абыстайның барча гөнаһларын ярлыкасаң иде, ихлас савапларыңны ирештерсәң иде, авыр туфракларын җиңеләйтсәң иде...

Мосафир – Өчиле авылы имам-хатибы Зиннәтулла хәзрәт иде. Ул шулай һәр гыйнварда, озын юлны якын итеп, моннан биш ел элек вафат булган баш баласының каберен зиярәт кылырга килә. Әүвәл авыл мулласы Мөхәммәтшакир йортына кагылып, хәл-әхвәл белешә. Элекке кияве аны ихластан кабул итә, эчкерсез хөрмәт күрсәтә. Бүген дә:

Марат ӘМИРХАНОВ (1933) – *прозаик; «Таш һәйкәл», «Тәкъдир», «И кылган догам минем», «Дөя муены» һ.б. китаплар авторы. Журнал укучыларына ул тарихи темага язылган «Үрбәт ханәкә гыйшкы», «Гәүһәршад», «Әлвидаг» романнары белән таныш. Казанда яши.*

– Мактап йөрисең икән, хәзрәт, табынның әзер вакытына туры килдең, әйдә, түргә уз, – дип каршы алды.

– Рәхмәт, абызагай, башта Аллаһы каршындагы бурычыбызны үтик, дога кылыйк, – диде Зиннәтулла, – аннан сезнең рөхсәт илә тәһарәт алырмын, чәйләп торырга вакытым тар, кышкы көн чыбыркы сабыннан да кыскарак бит ул, күз йомганчы үтә дә китә.

– Аштан зур булып булмый инде, хәзрәт. Бу чатнама суыкта интегеп йөрмәсәң дә ярар, кунып китәрсең.

Зиннәтулла каш астыннан гына өй хуҗасына күз төшереп алды да әйтте:

– Ризыгым биштәремдә, җан асрарга миңа бер телем кипкән икмәк тә җитә. Үзеңә дә билгеле, мин бит тәмледән-тәмле ашау, мал-мөлкәт артыннан кумыйм. Раббыбыз ризалыгына яшим, барча гамәлләрем дә Раббыбызга багышлана.

* * *

...Зиннәтулла тагын юлга кузгалды. Үзе яраткан Кышкар мәдрәсәсенә еш бара ул. Авылга килеп җиткәндә, көнне сындырып җибәргән иде инде. Күк томандай аксыл сыек болыт белән капланган. Ялкау гына кар энҗеләре төшкәли. Дымык. Тыныч. Табигать нииндидер илаһи вә самими хозурлык кочагында йокыга талган.

Зиннәтулла туры мәдрәсәгә юнәлде. Ул монда сукмакны суытмый, туган йортына кайткандай кайта. Әйе, кайта. Ул шушы мәдрәсәдә гыйлем алды.

Кышкар мәдрәсәсе Казан арты мәдрәсәләре арасында иң атаклылардан санала. Менә ике гасыр инде югары белекле дин әһелләре хәзерли. Шәкертләре белән дә, мөгаллимнәре белән дә дан тота. Зиннәтулла әле күптән түгел генә, мөхтәрият үтенече буенча, Сәгыйт бине Ибраһим әл-Кышкарый мөдәрриснең «Көррият әл-арыз» («Җир шары») исемле әсәре күчермәсен төгәлләде. Бүген аны мөдир, мөхтәрәм Габделхәбир хәзрәткә тапшырачак. Күренә ки, мәдрәсәдә рәсми төстә дөньяви фәннәр укытылмаса да, анда Кышкар Сәгыйт хәзрәт кебек күренекле гыйлем ияләре бер каршылыксыз шәкертләргә гаммави аң-белем бирә.

Зиннәтулла шәкерт вакытта, борынгы әдәбиятка мөкиббән булып, Фирдәүсинең «Шаһнамә», Низаминың «Ләйлә вә Мәҗнүн», Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф», Котбның «Хөсрәү вә Ширин» әсәрләрен ятлап та йөргән иде. Үзенә ошаган аерым-аерым өзекләрен, билгеле. Алай гынамы, шулар тәэсирендә үзе дә яшертен генә каләм тибрәткәли башлады.

Әүвәл башлап сорасагыз,
Ни адәм пәйгамбәрләр үткән дөньядан?
Айдай-көндәй балкыган
Гайшә белән Фатыйма,
Алар да үткән дөньядан...

Гадәттәгечә, Зиннәтулла төнне шәкертләр янында үткәрде. Күптәннән килә торган бу дәвамлы очрашуларны монда көтеп алалар. Ник дисәң, аңардан мөдәррисләргә бирергә җөрьәт итмәгән теләсә-нинди катлаулы сорауга да җавап алып була. Ә сораулар күп. Русиядә 1905 елда кабынып киткән инкыйлаб сүз иреге, матбугат иреге алып килде, авызларны ачты. Бер-бер артлы гәҗит-журналлар чыга башлады. Инкыйлаб шулай ук дини мәктәпләрнең еллар дәвамында тораташ булып каткан кадими укыту ысулларын да чатнатып җибәрде, заман таләпләренә якынайтты.

Җәт-җәт кенә самавыр шаулаттылар. Һәрберсе хәзинәсендә булган ризыкны табынга тездe. Ит, бәрәңге, тоз, кемдәдер шикәр кисәге дә табылды хәтта. Аны бик зурлап, кунак алдына куйдылар...

Үзенә генә хас моң белән моңланган самавыр тавышына хозурлана-хозурлана, бер тын сөйләшмичә генә чәй эчтеләр. Күзләр, блүдә кырыена сыенып кына, мосафир хәзрәтне күзәтә, әңгәмәгә фатиха бирүен көтә.

Ниһаять, ул чынаягын читкәрәк этәрде. Бу ым иде: «Әйдәгез, рәхим итегез».

Әүвәл тарих, аерым алганда, Куликово кыры орышы, Мамай морза турында гәп корып алдылар.

– Болар узгандагы хәлләр, аларны инде кире кайтара алмыйсың, мине, шәхсән, хәзерге вазгыять күбрәк кызыксындыра, – дип, кара тут йөзле, калын иренле, юантык шәкерт әңгәмәнең юнәлешен үзгәртеп җибәрде.

– Бик мәслихәт, – диде Зиннәтулла, – үзем дә дамелла Хөббетдин кайчан кузгалыр икән, дип уйлап кына куйган идем, бәрәкалла, котлыйм, бүген-иртәгә хәлфә чапаны кияргә торасың икән, Ходай тел ачкычлары бирсен.

– Җәнабе гали, гаепкә алмасагыз, янә бер сөалем бар иде, – дип, Хөббетдин олы ихтирам белән хәзрәтнең чабуыннан үбеп алды.

– Үзеңә хәмед, миңа куаныч, рәхим ит.

– Җаек каласында нәшер ителгән «Әлгасрел җәдит» мәҗмугасында бер яшь шагыйрьнең «Сорыкортларга» дип исемләнгән бик усал шигыре тәкъдим ителә.

> Аристократ-сорыкортлар, калын корсак, кечек башлар;
> Ашыйлар соң бирән булган кешеләр, ну гаҗәп, ай-яй!
>
> – Тәвәккәл, бик тәвәккәл.
> – Шагыйрь үзенең исемен дә яшерми.
>
> Яза күрмә, җитәр, артык, Тукаев, вастрок (төртмә. – *ред.*) бар бит;
> Куярлар астырып дарга, ятып тор бер дә кузгалмай.

– Ә сөалең, карием, нидән гыйбарәт? – дип, Зиннәтулла хәлфәгә карап бакты.

Хөббетдин кәләпүшен батырыбрак куйды да:

– Хәзрәт, бу Тукай атлы шагыйрьне сезнең оныгыгыз, диләр, шул дөресме? – диде.

Зиннәтулланың барча күзәнәкләре мөлдерәмә сагыш белән тулды. Ләкин ул аны шәкертләргә сиздермәде, бер йотым чәй эчеп куйды да:

– Әйе, ул минем оныгым, – диде.

* * *

Ул, Бибимәмдүдә вафат булып, гүргә кергәннән соң, Габдуллаҗанны алырга Кече Саснага үзе барды.

Хак, акыл яшьтә түгел, акыл – башта. Орчык буе, күзгә чебештәй юка гәүдәле оныгы аны тапкырлыгы, үткен теле белән шаккатырды. Сүзне кесәдән эзләми, үлчәп-нитеп тә тормый, күзеңә бәреп әйтә. Хәтта: «Улым, сиңа ничә яшь соң әле?» – дип сорарга мәҗбүр булды.

Малай ваемсыз гына кулын селтәп алды да:

– Яшь бара, бабакай, дүрт тулып китте бит, – диде.

Сулар ага,
Көннәр – төнгә,
Төннәр көнгә ялгана.
Гомерләр шулай уза.

– Бәрәкалла-машалла, хәтерең әйбәт икән, улым, бу робагыйны әниең өйрәткәндер, мөгаен, әһле гыйлем иясе иде мәрхүмә, кызыл сүзгә ифрат маһир иде, – дип, Зиннәтулла оныгын үзенәрәк елыштырды.

– Нинди робагый, бабакай, бу тезмәләр тик торганда, шап, үзләреннән-үзләре телгә килә, – диде Габдуллаҗан.

Карга карыйм – ак җәймә,
Юлга карыйм – ал тасма.
Ак җәймә дә ал тасма,
Бабкай белән Габдулла,
Өченчебез күк бия,
Их, матур соң көн, дия.

Авызына Хозыр төкергән бу баланың, дип уйлап куйды Зиннәтулла, балалыктан да бик иртә сикергән. Җәтим тайдан юрга чыгар, җәтим баладан ага чыгар, ди, бирсен Ходай.

– Сөбханалла, сөбханалла...

– Әй, бабакай, – дип дәвам итте малай, – әниемнең белмәгәне юк иде, аның белән шигырьләр әйтешеп, җырлар җырлашып күңел ача идек. Биергә дә өйрәтте.

Бие, бие, Хәйбулла,
Биегән кеше бай була...

Габдуллаҗанның тавышы киселеп китте.

– Бабакай, һич аңламыйм, нигә Ходай миңа каныкты икән, ә? – дип, башын Зиннәтуллага таба чөйде. Җавап көтмичә, шундук фикерен дә шәрехләде. – Әтиемне хәтерләмим, ул үлгәндә, бик кечкенә булганмын, әнием яшәргә тиеш иде әле. Әүлия иде бит, мин әниемне бик-бик ярата идем. Мин әниемне бик-бик сагынам, бабакай...

Зиннәтулла керфекләренә кунган яшь бөртекләрен кул аркасы белән сыпырып төшерде дә әйтте:

– Улым, без, бәндәләр, Аллаһының коллары. Аның һәр гамәлен, иман китереп, «Әлхәмдүлиллаһ», дип хупларга гына бурычлы. Аллаһы Тәгалә – юкны бар итүче дә, барны юк итүче дә. Гыйлем эсти башлагач, син боларның барысын да аңларсың әле.

Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун.

Ат кинәт кенә пошкырып җибәрде, йөрешен дә акрынайтты. Зиннәтулла ялт-йолт карангалап алды: әллә бия бүреләр исен сизеп алдымы? Алла сакласын, юл аулак, кеше-мазар күренми, ташланырга да күп сорамаслар.

Тирә-як ап-ак юрган ябылгандай иде. Тын. Чана табаны астындагы кар шыгырдавы гына күңелне ярсытып-ярсытып ала. Борчылырга сәбәп юк. Пошкыру да атның табигый халәте генә булган, күрәсең.

Тынлыкны Габдуллаҗан бозды.

– Бабакай, синең күгәрченнәрең арасында мин янә чәүкә буламмы инде? – дип, Зиннәтулланы янә тетрәндерде.

– Әстәгъфирулла, тәүбә-тәүбә, диген, син минем кызым Бибимәмдүдәмнең бәгыреннән өзелеп төшкән җимеш бит. Апаларың, абый-энеләрең дә ипле балалар: Бибисаҗидә, Гандәлип, Гөлчәһрә... Кәшфелкәбир абыең исә синнән бер генә ел алдан туган бала. Әниеңнең вафатына багышлап бер шигырь дә чыгарган идем әле. Тыңлап кара, ни диярсең икән?

Нурлы газизем кызымның төрбәседер бу мәзар,
Әйләмеш назик вөҗүден хак дәүре рузекяр.
Исеме Бибимәмдүдәдер гаилә ирде гаян,
Дыңлап ирде тәшкилә вәгазь мөсагыл һәм мәган.
Ни сәбәптер, и Ходая, ризкы аз, гомере тәмам.
Күрмәдем күзем туйганчы, улды бәңа кальбәнам.
Даре михнәт, даре хәсрәт, даре залим бу мәкам,
Шунда мәхбүбә мөрәссагы дөрне кылды инкыйдам...

– Миңа, бабакай, мондагы күп сүзләр аңлашылмый, – диде Габдуллаҗан, – ә аһәңе колакка ятышлы. Бабакай, син дә бик кайгырасың инде...

Зиннәтулла аңа җөмләсен төгәлләргә ирек бирмәде, бүлде.

– Улым, күрәсеңме, алда – Өчилебез. Шөкер, исән-имин кайтып җиттек, – диде.

Габдуллаҗан батырып кигән бүреген маңгаена калкытыбрак куйды. Пәрдәсен ачып җибәргәндәй, җиһан яктырып китте. Офык читенә кунаклаган челтәр болытлар инде алсу төскә кергән. Авыл үзе күренми дә диярлек, ә мәчете әллә каян балкып утыра. Әйтерсең лә таулар хозурына төшеп баручы кояшның бар мәрхәмәте, барча нур-шәфкате шунда сыенган.

– Бабакай, кара, кояш манарага кунаклаган, – диде Габдуллаҗан, – нинди күркәм мәчет.

«Улым, мәчет әле ул, илаһи вә изге бина булу беләң беррәттән, мәхәлләне мәхәллә итеп тотучы үзәк тә, җиргә сеңеп беткән татар авылларының йорт-кураларын күккә күтәрүче тылсымлы бизәк тә», дип уйлап куйды Зиннәтулла.

– Ахшам вакыты җитә, улым, ашыгыйк, безне көтәләрдер.

* * *

Өчиле, дип авыз суын корытса да, Зиннәтулла монда килмешәк кенә. Чал Чулман җирендә дөньяга аваз салган инсан ул. Нәсел-нәсәбе әле дә шул тарафларда көн күрә. Үзе дә ярата иде Чулман-йортны, каядыр читкә чыгып китү турындагы фикер уена да кереп карамый иде. Ә менә бабасы Әмирхан хәзрәтнең нияте бөтенләй башка булган икән. Беркөнне буй җиткереп килүче оныгын дәшеп алды да карарын ирештерде.

– Улым, чын-чынлап гыйлем эстәр вакытың җитте, иң абруйлы мәдрәсәләр Казан төбәгендә, юлга әзерлән, – диде.

Атасы Зәйнелбәшир аны иң борынгылардан сакланган таныклы Кышкар мәдрәсәсенә китереп урнаштырды. Күңел биреп, тырышып укыды Чулман егете. Ләкин чит җиргә авыррак ияләште. Мәдрәсәне тәмамлаганнан соң, әзерлекле вә төпле шәкерт икәнен исәпкә алып, Кушлавыч авылына мәзин итеп тәкъдим ителгәндә дә төпләнү-төпләнмәү мәсьәләсен тәгаен хәл итмәгән иде әле. Шуңа күрә башлы-күзле булырга да ашыкмады, утыз дүрт яшенә җиткәнче буйдак егет күлмәген салмады.

Озакка сузылыр идеме бу утраксызлык, юкмы, төгәл генә әйтүе кыен. Әмма көтмәгәндә әлеге билгесезлеккә бер вакыйга киртә куймасынмы.

Җомга көн иде. Җомга азанын ул аеруча дәртләнеп, ниндидер ашкынулы рухи күтәренкелек белән әйтә.

Әйтә. «Азан әйтү» җөмләсе халык телендә киң кулланылышта йөрсә дә, шәхсән, ул үзе аны кабул итеп бетерми. Чөнки Азан – илаһи аваз, Аллаһы авазы. Мәзин бары бу тылсымлы авазны аһәңе аша диндәшләренә җиткерә генә. Әйтми, җиткерә.

– Аллаһу әкбәр. Аллаһу әкбәр...

Зиннәтулланың тавышы ярты юлда абынып китте. Күзләре күрше йортның капка төбендә йотылып азан тыңлаучы бер тәкъва затны шәйләп алган иде.

Йөрәге кагып куйды, тәне буйлап ниндидер аңлаешсыз дулкын йөгереп узды.

Сынына караганда, тыңлаучы хатын-кыз җәмәгатеннән буласы. Гәүдәсе төз, мәһабәт... Һич тә бу йортта гомер кичерүче Шәрифә карчыкка охшамаган.

– Әстәгъфирулла... тәүбә-тәүбә...

Зиннәтулла азанны көч-хәл белән ерып чыкты. Бу тамаша аны тәмам җилкендергән иде. Манарадан төшүгә, дәрәҗәмә зыян килер дип тормады, карчыкны сагалап көтеп алды да ачыктан-ачык сорады.

– Абыстай, кунагың бар икән, кайсы авылдан килде? – диде.

– Сәрдәдән, мәзин, Сәрдәдән, туганнан туган Камилә сеңлем, бигрәкләр дә акыллы бала. Үзе бал калагына гына салып йотардай чибәр, ашка-суга бик оста, тегүгә-чигүгә дә дигәндәй...

– Сөбханалла...

– Ә-ә, онытып та торам икән, мәзин, кортка кешенең хәтере ярты сапламнан да кимрәк бит аның, – дип, Шәрифә карчык сөйләнүендә булды, – ул синең Азан әйтүеңә мөкиббән, мәзин, шулкадәрләр дә аһәңле, шулкадәрләр дә ашкындыра, күңелең белән җиде кат күккә, Аллаһы катына иңгәндәй буласың, ди.

– Мондый фәрештәдәй гүзәл туташны яучылар бик бимазалыйдыр инде, абыстай.

– Әйтмә дә инде, мәзин, һич тынгы бирмиләр, Камилә генә сайлана. Шул сайлануы аркасында егермесе дә узып китте, әнәтрәк. Ник дигәндә, атасы үсендерә, кызыма үз тиңе булсын, ди.

Зиннәтулла да тәвәккәлләде. Кыз сорарга үзе барды. Тиздән туй булды, буйдаклыкка, ниһаять, чик куелды.

Бер килгәч, килә бит ул, шул ук елны Өчиле авылы мәхәлләсенә имам урынын тәкъдим иттеләр. Муллалыкка указ алды, йорт-җир җиткерде. Шөкер, яратышып, бер-берсен ихтирам итешеп гомер иттеләр. Бакыйга гына бик иртә китеп барды Камилә, нибары ун гына ел яшәп калдылар. Кызлары Бибимәмдүдә тач анасы иде. Озынчарак йөзле, сызылып киткән кара кыйгач кашлы, матур кылыч борынлы, төскә-биткә чибәр, матур буй-сынлы шагыйранә мөлаем зат иде. Икесе дә юк инде, җир куенында. Өй алдындагы бакчада үз куллары белән утырткан юкә агачы гына, бу кадерле мәрхүмәләрен яд итеп, һәр язны шау чәчәккә күмелә.

* * *

Ачлык капчык астырыр, ди. Бу язмыш Зиннәтулла хәзрәтне дә читләтеп узмады. Ул моңарчы да очны очка ялгап кына бара иде. Аның буш вакытын китап, гыйлем, суфичылык, дини багланышларга сарыф итүен, хуҗалык алып бару, йорт-җир тоту, мал-туар асрау мәнфәгатьләренә битараф булуын бөтен мәхәлләә беләә. Шуңа күрә хәленә кереп, сәдаканы да мулрак бирергә

тырышалар иде. Хәлбуки, Өчиле – ярлы авыл. Җирләре аз, уңдырышсыз. Урман-болыннары да чамалы.

Чүп өстенә чүмәлә, Идел буенда 1890 елда башланган коточкыч корылык аннан соңгы елларда да дәвам итте. Чәчелгән иген буынга да сикерә алмыйча саргаеп катты. Борынгы заманнардан килгән йоланы тотып, җиргә орлык белән бергә йомырка оны чәчүнең дә, карга боткаларына чыгуның да, яңгыр теләп, үзара су сибешүләрнең дә файдасы тимәде.

Корылык барча үсемлекләргә дә кырау булып төште: җиләк-җимешләр төкәнде, алабута, балтырган, кычыткан, җуа, кузгалак ише яшел азык табыны да саекты. Ризык табу чиктән тыш авырайды. Юллар теләнчеләр белән тулды.

Алар арасында Зиннәтулла хәзрәт тә бар. Тик аны хәер эстәүчегә санамыйлар. Ник дисәң, ул – тирә-яктагы иң күрекле дин әһелләренең берсе, элек-электән юл кешесе, мосафир. Дин тәгълиматын, пәйгамбәрләрнең тәрҗемәи хәлен халык телендә гади һәм аңлаешлы итеп аннан да тәфсиллерәк шәрехләүче юк.

Ни кызганыч, хәзерендә ул да хакыйкатән теләнче иде инде. Хәллеләрдән саналган Наласаякларына да тамак хәстәре китерде. Чырайлар элеккечә ачык. Әйе, чырай ачык, ә бирер әйберләре юк.

– И, мулла бабай, синең белән актык телем ипиебезне дә бик теләп бүлешер идек тә соң, буралар тәмам коргаксыды, – диде аңа бер танышы, – үзебез дә ачлы-туклы.

Ярый әле, бер балыкчы табышыннан өлеш чыгарды.

Өчилегә көтү алдыннан гына кайтып җитте. Капка төбендә аны, күзләрен мөлдерәтеп, алты бала каршы алды.

– Әти кайтты, әти кайтты, әти!

Балалар аны шау-гөр килеп, сырып алды.

Зиннәтулла һәрберсенең башыннан сыйпады, бер яшьлек төпчеге Шәмсемөнирне кулына ук алды.

Бу төркемдә Габдуллаҗан күренми иде. Ул Бибисаҗидәгә карап алды. Чөнки Саснадан кайтуга:

– Кызым, Габдуллаҗанга күз-колак булуны сиңа тапшырам, үзең дә ярты җәтим, әлхәмдүлиллаһ, уртак тел табарсыз, – дигән иде.

Бибисаҗидә бу карашны аңлады.

– Әни Габдуллаҗанны кәҗәбезне эзләргә җибәрде, – диде.

Ул арада Габдуллаҗан үзе дә күренде. Бер кулы белән сакалбайны мөгезеннән эләктергән, икенчесендә – тал чыбыгы. Сыдырып-сыдырып та алгалый. Җорланып та куя.

Кәҗә йөри түтәл белән,
Тыеп булмый киртә белән.

Зиннәтулла онытын күзеннән кичерде. Ябык, эченнән энә үтәрлек. Җанын сакларлыгы да калмаган бит баланың. Аллам сакласын, ул-бу булганчы, бер-бер чарасын күрергә кирәк.

Шундый карарга килде Зиннәтулла һәм шул ук кичне Гыйльфан ямщикны дәшеп алды да ниятенә килгән үтенечен җиткерде.

– Күрше, син Казанга еш йөрисең, бер баруыңда, зинһар өчен, оныгым Габдуллаҗанны да утыртып алып бар әле, бәлкем, берәр мәрхәмәт иясе асрамага алыр, – диде, – хәлемне үзең дә күреп торасың, ул бала өчен бик

хәстәләнәм. Үземнекеләр дә ишле, берсе китсә, икенчесе кала дигәндәй, ә Габдуллаҗан өзелсә, нәселе корый.

– Хәзрәт, атасы мәрхүм Мөхәммәтгариф имамның туганнары бар түгелме соң, бәлки...

Зиннәтулла кулын гына селтәде.

– Шакирҗан шайтаннан да ярлырак, икенче энесе Зариф каядыр читкә китеп олакты, Бибигазизә үзе кеше чутында яши. Апасы Фаиза абыстай бар-барын, тик аның да кулы бәйле, үз балалары өстенә җәмәгате Җәләлетдин мулла ягыннан берничә ятимне сыендырганнар, өйләрендә алма төшәрлек тә урын юк, ди.

– Синең сүзне тыңламый ярамый инде, хәзрәт, – диде Гыйльфан, – җомгадан соң тәвәккәлләрбез, теләктә булыгыз.

– Амин!

* * *

Казанда мәрхәмәт иясе табылды. Габдуллаҗанны Печән базарыннан читекче Мөхәммәтвәли белән калфакчы Газизә үз өйләренә алып кайттылар. Зиннәтулла бик шатланды. Күп тә үтми, үзе дә асрамадагы, Габдуллаҗанның ата бер, ана башка апасы Бибигазизә туташтан күңелле хәбәр дә килеп ирешге. Яңа әти-әнисе Габдуллаҗанны ихластан үз иткәннәр икән. Ашау-эчү, киемсалым мулдан, ди. Габдуллаҗанның өстендә һәрчак ак күлмәк, җиңсез кара камзул белән килешле чалбар, башында бизәкле кәләпүш, ди.

Рәхәткә чыккан Габдуллаҗан!

Хак, сабыр соңында носрат бар, михнәт соңында рәхәт бар, кайгы соңында шатлык бар. Тик язмыштан гына узмыш юк. Кыш үтеп, дөньялар яшәргәч, ямщик Гыйльфан Габдуллаҗанны Печән базарыннан, арбасына утыртып, янә Өчилегә алып кайтты. Мөхәммәтвәли һөнәрченең сәламәтлеге какшап киткән икән. Шакирҗанга сылтаучылар да булды. Кул астына керә башлагач, энемне үземә алачакмын, иманасы да тияр, дип, Казанга сүз җибәргән, имеш.

Зиннәтулла бу имеш-мимешләргә колак салмады. Булганы булган, Ходай шулай язган, күрәсең, җан биргәнгә җүн бирер, дип, күңеленнән барысы белән ризалашты, оныгын тынычлыкта калдырды. Җәмәгате Латыйфа абыстай чәпчи башлаган иде дә бик тиз авызын япты.

– Абыстай, ир – баш, хатын – муен, мин нәрсә әйтсәм, шул булыр, – диде.

Бабасының бу кырыслыгы Габдуллаҗанның тормышына үзгәреш китермәде. Элеккечә артык кашык рәтендә йөрде, кагу-сугулардан да азат түгел иде. Тик ул авызына кан килсә дә түкерми торган түзем вә горур бала. Берәүгә дә баш имәс, күз яшен дә күрсәтмәс. «Ходай орган нәмәстә, кешечә җылый да белмисең бит син», – дип, үткәндә-сүткәндә, үги әбисе еш кына чеметкәләп тә алгалый иде.

Габдуллаҗанны әлеге тормыштан бу юлы Нәфисә ханым тартып чыгарды.

Нәфисә – анасы Бибимәмдүдәнең якын дусты, ахирәте иде. Кечкенәдән бергә уйнап үстеләр. Хәзерендә – Кырлай авылы килене. Туган авылына кайтканда, ул Зиннәтулла хәзрәтнең хәлен белә, яшьлек дусты рухына багышлап, сәдака биреп чыга иде. Әлеге керүендә, чыра гына булып калган Габдуллаҗанны күргәч, йөрәге бик нык әрнеде. Кырлайда әле яңа гына бердәнбер малайлары үлгән, таза тормышлы Сәгъдетдин абзыйларга, уллыкка алырга теләсәләр, Өчиледә бер ятим ир бала барлыгын әйтте. Алар бу тәкъдимне бик хуп күрде.

Тәүге килүләрендә Зиннәтулла оныгын бирмәде. Кырлайлылар барыбер ниятләреннән чигенмәде, ике көннән янә бусаганы атлап керделәр.

– Адәмнең көне адәмнән, хәзрәт, – диде Сәгъдетдин, басынкы, ышанычлы тавышын сузыбрак, – оныгыңны эшкә өйрәтермен, укытырмын да, мулла нәселе дигән дәрәҗәсенә лаеклы итеп тәрбияләргә тырышырмын.

– Сәгъдетдин абзый – авылыбызның бик тә абруйлы кешесе, – дип, Нәфисә дә сүзгә кушылды, – Кырлай ерак җир түгел ләбаса, кайткалап йөрим ич, Габдуллаҗанны да ияртеләрмен, күрешеп торырсыз, шулай бит, Сәгъдетдин абзый?

– Шулай булмыйча теге, шулай, килен, шулай, безнең тарафтан каршылык булмас.

Зиннәтулланың иңсәләре калтыранып китте, озак кына бер ноктага текәлеп торды. Аннан соң:

– Бер дә җибәрмәс идем дә, дөньясы шулай бит, – дип, ниһаять, фатихасын бирде.

Нәфисә вәгъдәле булды. Өчиле сукмагына үлән үстермәделәр. Габдуллаҗан да бабаларына бик теләп кайта иде. Ул хәзер җиргә нык басып йөри. Шулай булмыйча, озын чуклы яшел-кызгылт хәтфә кәләпүш, яшел хәтфә белән кырлап тегелгән камзул Өчиле малайларының төшенә дә кермидер, мөгаен.

– Мин хәзер абыстайга сабакка йөрим, – дип шатлыгын уртаклашты бер кайтуында, – укый да, яза да беләм, барысыннан да уздырам, берсе дә миңа җитми.

Бу яңалык Зиннәтулланы бик сөендерде: «Сөбханалла, куандырдың, улым», – диде.

– Бәетләр дә чыгара башладым, – дип мактануында булды Габдуллаҗан, – ул авылда Хөрмәтулла исемле бер агай бар. Шул, бакчама керә, дип, күршесенең тавыкларын пыран-заран китергән: кайсының аягын сындырган, кайсының канатын каерган. Халык бик шаулашты. Олырак малайлар, син телмәр, җыруга да остасың, шул абзыйны камчылап, көлкеле бәет чыгар әле диделәр. Һәм чыгардым да:

Җәнҗалчы Хөрмәтулла
Кыя күрше тавыгын.
Гөнаһ дип тә тормый,
Ләгънәт тә аңа тубыктан,
Саламторхан каһарман.

Кичкырын бәетемне әлеге егет кәмәшләре урам буйлап такмаклап йөргән.

Хөрмәтулла агай таң белән безгә килеп җиткән дә әтигә әйткән:

– Сәгъдулла, улыңны тый, минем турыда такмак чыгарып йөрмәсен, тагын ишетсәм, билләһи, аягын сугып сындырам, – дигән.

– Үзеңнекен сындырганчы тай моннан, – дигән әтием.

– Әтиеңне яратасың ахры, – диде Зиннәтулла, көнләшү катыш кызыксыну белән.

– Әтиемне дә, әниемне дә, апайларымны да – барысын да, барысын да яратам, – диде Габдуллаҗан, аннан бабасына карап өстәде, – мин сине дә яратам, ә дөресе, иң яраткан кешем – Саҗидә апаем.

Шушы кайтуыннан соң Габдуллаҗан югалды. Аңа янә яшәү урынын, гаиләсен үзгәртергә туры килде. Әлегесендә әтисе ягындагы туганнарының кулы уйнады. Фаиза абыстай Җаек каласында төпләнгән сеңлесе Газизә ханымга, кияве Галиәсгар сәүдәгәргә мөрәҗәгать хаты язды. Алар, уллары вафат булып, малайсыз калганнар иде. Эшне тиз тоттылар. Габдуллаҗан

1894 елның көзеннән җизнәсе Госмановның ике катлы зур таш йортында яши башлады.

Бу хәлләрне Зиннәтуллага әйтеп тормадылар, киңәшләшмәделәр дә, кирәк санамадылар, күрәсең.

* * *

Зиннәтулла, гадәтенчә, китап-дәфтәрләрен өстәл өстенә салды да, күзлеген киеп, кулына каләмен тотты. Бу көннәрдә «Туктамыш хан» дастанын күчереп язу белән мәшгуль иде. Өлкәнәюе сәбәпле, мосафирлыкны ташлаганнан соң, үзенең күп вакытын ныклап торып язу-сызу эшләренә багышлады ул. Шөкер, комачаулаучы юк. Кара өйнең бер почмагын үзенә бүлеп алды да көнен шунда уздыра.

Хәзерендә ул гади бер мәчет карты. Муллалыкны улы Кәшфелкәбиргә тапшырды. Шуның белән вакыт кысынкылыгы да бетте. Аллаһыга мең рәхмәт, гомер дә, сәламәтлек тә бирде, җитмеш сигез яшьтә дә үзен әйбәт хис итә. Карт кеше тузган кием кебек – каян тартсаң, шуннан ертыла, дигән мәкаль аңа кагылмый.

Бүген исә каләме әйтерсең лә бозга катып калды. Кәгазьгә әле бер кәлимә-сүз төшермәде. Ул – уйлар әсирлегендә. Моның сәбәбе дә бик җитди иде. Аңа оныгы Габдуллаҗанның Казанга кайтуы турында хәбәр җиткерделәр. Солдатка каралу мәшәкатьләреннән соң, туган-үскән якларыннан да урап китмәкче, имеш.

Аерылышканнарына да шактый вакыт шул инде.

Унөч ел!

Шушы унөч елны ул энә өстендә үткәргәндәй үткәрде. Ник дисәң, оныгы алдында үзен үтә дә гаепле саный иде. Соңгы вакытта төшенә дә керә башлады. Гел бер халәт-кыяфәттә. Баштанаяк озын кара хөлләгә төренгән, төмсә чырай, кинәле күз. Үзе ләм-мим. Карашы гына киртәдән чыккан, үткен пәкедәй кыеп алырга тора.

Тәү кемгә кайтыр Габдуллаҗан, бабасынамы, бүтәннәргәме? Менә шунда ачыклана да инде үпкә тоту-тотмавы. Мәктүпләрендә ул аны өстен куя иде куюын.

Зиннәтулла оныгының соңгы хатын кулына алды. Үзенә кагылышлы өзеген кычкырып укыды: «Сез ки... картларның иң яхшы күңеллесе булган бабабыз Зиннәтуллага, хөрмәтле һәм кадерле әбигә... бик күптин-күп сәламнәребезне җибәреп ирештердем».

Зиннәтулланың юравы рас килмәде. Габдуллаҗан иң әүвәл Кушлавычка сугылды. Сыкраныбрак булса да, ул оныгының бу гамәлен хуплады. Ни әйтсәң дә, Кушлавычта җиһанга аваз салган бала ич ул. Кушлавыч – аның кендек каны тамган изге җир.

* * *

Габдуллаҗан, Кушлавычта берничә көн кунак булганнан соң, Югары Масрага, Фаиза апайларына килде.

Җизнәсе Җәләлетдин хәзрәт аның кыяфәтен хуп күрмәде, дәһригә чыгарды. Исәнлек-саулык белешүгә үк чәнчеп аласы итте.

– Хәзер шәкертләр чәч алдырмыймыни, урыс пубына әйләнеп беткәнсең бит, – диде, җитү чәчен ошатмыйча. Кыска кәзәкиенә, балагы төшерелгән

озын тар чалбарына, балтырыннан тотып кия торган шнурсыз резиналы ботинкасына да бәйләнергә исәбе бар иде дә, хәләле ботыннан чеметеп алды: «Тсс!» – янәсе...

– Тсс...

Габдуллаҗанның мондый тузан кунып беткән кадими дин әһелләрен күргәне бар иде инде, исе китмәде, ияк астыннан гына елмайгандай итте дә:

– Хәзрәт-җизни, мин бит хәзер шәкерт түгел, шагыйрь, – диде, – китаплар язам, сезгә дә бүләк итәрмен.

– Безнең китабыбыз – Коръән-Кәрим, башкасы намуафыйк, – дип, Җәләлетдин каенишенең ниятенә шундук киртә салды.

– Күзләребез дә күрми, – дип өстәде Фаиза абыстай, акланганДай.

Картлар картлар инде, тискәрелеккә ясап куйган кебек. Ә авылның яшьләрен ошатты Габдуллаҗан. Дәрткә дәрман алып, яңалыкка омтылалар икән, мәчет күләгәсендә басылып яшәмиләр. Уйныйлар да, җырлыйлар да, биеләр дә...

Югыйсә, Югары Масра Өчиле кебек үк аз җирле ярлы авыллардан санала. Шулай да халык югалып калмаган, җаен тапкан, көзен барлы-юклы игеннәрен җыеп алу белән, читкә – Җаек, Агыйдел-Чулман тарафларына чыгып китәләр икән. Кем нәрсәгә маһир, кайсы итек баса, кайсы тегү тегә, кайберләре кырык тартмачы булып сату итә...

Йөргән таш шомара бит ул, масралылар да дөнья күреп, тәҗрибә туплап, иң мөһиме, ирек дигән тылсымлы һава тәмен татып, җәсарәт алып кайталар. Хикмәт тә нәкъ менә шул канатсыз акчарлакларда икән.

Хәйран калырлык хәл, Кушлавычта әле агач яфраклары да коелып бетмәгән иде, ә Масрада кешеләр инде бүрек кигән. Көзге көнне керәле дә чыгалы, дип бик дөрес әйткәннәр. Ара-тирә кар да төшкәли. Халык каз өмәсенә тотынган. Көн дә бәйрәм, көн дә туй, көн дә уен, көн дә сый.

Өмә чираты Җәләлетдиннәр күршесенә дә килеп җитте. Көнозын ыгы-зыгы. Каз йолкучы кызлар инде, әнә, ишегалдына чыкты, гөрләшепме-гөрләшәләр. Берсе бөтерчекнең бөтерчеге, бер басасы урынга биш баса. Чибәр дә, каһәр. Түп-түгәрәк ап-ак йөзле, кап-кара күзле, чем-кара кашлы, йомырка күмәчедәй пешкән. Габдуллаҗанның үткен карашы хәтта кыска-кыска гына итләч бармакларын да абайлап алды. Тач, шәкертләр хыялындагы матурлык өлгесе.

Чибәркәй кунак егетенең посып кына читән аша үзен күзәтүен сизеп алган иде булса кирәк, шундук такмагын да очырды.

Аргы яктан берәү килә –
Кара кәчтүн, ак яка;
Кара кәчтүн, ак якага
Исебез китми пука.

– Сәрбиназ, син инде бигрәк, кала егетләре нәзберек бит алар, үпкәләве бар, – дип, иптәш кызы дустын битәрләгәндәй итенде.

Абзый, сине бай, диләр,
Җиккән атың тай, диләр.
Байлык белән бик мактанма,
Кесә ягың сай, диләр.

Кызлар, көянтәләренә каз түшкәсе асып, көлешә-көлешә, инеш буена төшеп киттеләр.

Сәрбиназ өмәгә яңа гына басылган нәфис кара киез ката киеп килгән икән. Көнләшсеннәр, янәсе.

Кичтән, кипсен өченгә, аяк киемнәрен мичкә куеп калдыралар. Ә яшь килен иртән-иртүк тыштан салам көлтәсе алып керә дә, мичне бушатып, ягып та җибәрә.

Ниһаять, кызлар да уяна. Өй җылы, таба чыжылдый, кәеф күтәренке. Каз тәбикмәге дә телеңне йотарлык. Тик кызларның гына иркенләп юанырга вакыты юк, алар янә чакырулы. Иң беренче Сәрбиназ урыныннан кузгала.

Кузгалуын-кузгала, сыңар катасы гына ут булган да су булган. Идән ярыкларына кадәр капшап чыгалар, мактаулы ката гына табылмый.

– Мичне кабат җентекләбрәк карагыз әле, – ди пошаманга төшкән хуҗабикә.

Һәм килен көл арасыннан янып, чукмарга әйләнгән ката калдыгын тартып чыгармасынмы.

Бу хәбәр яшен тизлеге белән бөтен авылга тарала. Габдуллаҗанга да тәкәббер вә наян сылукайга җавап сүзе әйтү җае табыла.

Шагыйрьнең җавабы шигырь инде, әлбәттә.

Сөеп кигән кара катаң
Янды мәллә, җанашым?
Кара ката хәсрәтеннән
Тамды мәллә күз яшең?
Кара катаңның төтене
Очкан кыйбла хутына.
Раббым Аллам, кадыйр мәүлям,
Салган кайгы утына.
Кимә, җаным, пар аякка
Сыңар ката – килешми,
Һич кайгырма, бастырып ал, –
Басып бирер Земский[1].

* * *

Зиннәтулла бер очтан Мөхәммәтшакир хәзрәтнең дә хәл-әхвәлен белешеп чыкты. Җир җимертеп йөри, һич тә сиксән сигез яшь бирмәссең. Яшь кәләш ир-атны шулай дулкын өстендә тота шул ул.

Габдуллаҗан турында да сүз чыкты.

– Без, картларны, хәзер яшьләр санга сукмый, кайтканына ун көн инде, әле күзгә-башка күренгәне юк, – дип, Зиннәтулла зарланып та алды.

Мөхәммәтшакир аны хупламады.

– Турысын әйткәнгә үпкәләмә, тәкъсыйр, монда картлык-яшьлекнең бер катышы да юк, – диде, – ни чәчсәң, шуны урасың, ди халык. Менә син дә үзең чәчкәнне җыясың инде...

Ул тукталыбрак торды, әңгәмәдәше каршы төшәр, бәхәскә керер, дип фаразлаган иде. Зиннәтулла исә, балтасы суга төшкән кешедәй, башын иеп утыра бирде. Чөнки дөресе дә шулай. Үткән болытны кире кайтарып булмаган кебек, үкенүдән дә файда юк анысы. Язмышны Аллаһы Тәгалә тәгаенләгәнчә, ничек бар, шулай кабул итәргә генә кала. Хәзрәт хаклы, ул, чыннан да, үзе чәчкәнне җыя, берәүгә дә үпкә белдерә алмый.

[1] Авылның итек басучысына, зур корсаклы булганы өчен, «Земский түрә» кушаматын такканнар.

Габдуллаҗанга ул фәкать яхшылык кына тели. Исән-сау йөрсен, барыр юлларында Ходай һидаятен ачсын, эш-гамәлләре белән халыкны куандырсын, эти-әниләренең рухына турылыклы булсын.

Зиннәтулла шулай изге теләкләр белән ярты төн уртасында Өчилегә кайтып егылды. Һәрвакыттагыча, иртүк торып, намазга басты, ашап-эчеп алгач, кулъязмаларына тотынды.

Кулы ифрат җиңел иде бүген, каләме кәгазь өстендә уйнаклапмы-уйнаклый, гүя чаптар тай.

Ул, кулъязмаларны күчергәндә, үзе дә дастаннарда урын алган вакыйгалар эчендә кайный, анда сурәтләнгән каһарманнар белән бергә кылыч күтәрә, яу чаба, илчеләрне кабул итә, мәҗлесләрдә утыра, ил-мәмләкәт хакын даулый. Әле дә Туктамыш ханның үзалды сөйләмен, телдән әйтә-әйтә, кәгазьгә төшерә.

Иртән торып кош чәйсәм,
Каз мынан ку алдырган Идел-йорт,
Ат башыдай сары алтын
Сандыгымда яткан Идел-йорт...

– Афәрин, хәзрәт, әгъмале хәсәнә!

Зиннәтулла башын тавыш ягына борды. Аңа, көлеп-елмаеп, урта буйлы, ап-ак йөзле, җәдитчә киенгән ыспай егет карап тора иде.

– Әссәламегаләйкем, бабакай, сөбханалла, бик күркәм, бик мөлаем күренәсең, Ходай алга таба да хәер-фатыйхасыннан аермасын, рәхим-шәфкатеннән ташламасын.

Кәшфелкәбир имам, энесенең теләкләрен хуплап, битен сыпырып куйды.

– Амин!

Габдуллаҗан бабасын кочаклап алды. Алар шулай кочаклашкан килеш шактый ара бер-берсенең йөрәк тибешен тоеп, басып тордылар.

– Габдуллаҗан, улым, балакаем...

Зиннәтулла капыл гына таудан тәгәрәгән кар өемедәй өстенә ишелеп төшкән бу шатлык-куанычтан тәмам изрәгән, балавыз кебек йомшарган иде.

– Габдуллаҗан, улым, балакаем...

Габдуллаҗанның да күзләре чыкланмыш, алай да ул бабасыннан алданрак игә килде, барып, аның өстәл өстендәге кулъязмасын кулына алды.

– Туктамышлар, Идегәйләр, Аксак Тимерләр белән мавыгасың икән, бабакай, – диде, – ә минем баш иючеләрем бөтенләй бүтән. Пушкин, Лермонтов, Крылов, Кольцов, Толстой, Шекспир, Байрон, Петефи...

– Мин бу мөгаллимнәр арасында мәшһүр Фирдәүсиләр, Низамилар, Кол Галиләрнең исем-атларын ишетмәдем, – диде Зиннәтулла, дулкынлануын баса төшеп, – белүемчә, аларны зыялы гавам төрки әдәбиятның йолдызлары дип саный.

– Хак, бабакай, син исемнәрен телгә алган әһле каләм – шигърият бакчасының ал гөлләре. Галиҗәнап сүз алар иҗатында моң аһәңе югарылыгында күтәрелә. Өйрәнәсе дә өйрәнәсе. Ләкин...

Габдуллаҗан, сабак бирүче яшь хәлфәдәй ишекле-түрле йөрештереп алды да бабасы каршына килеп басты.

– Ләкин, бабакай, алар сурәтләгән татлы гыйшкый вакыйгалар заман ихтыяҗларыннан, халык тормышыннан бик ерак тора. Бу дөнья – хыялый

дөнья. Мине исә, барыннан да элек, туган халкымның бүгенге хәленә, киләчәгенә кагылышлы гамәлләр кызыксындыра, борчый. Сүз дә юк, милләтебезнең үткәне шанлы вә бөек. Тик дәүләтеннән коры калганнан соң, татар басынкылана, юашлана, ваемсызлана, арага көнчелек, хөсетлек, әләк, яла, монафикълык кебек залим сыйфатлар килеп керә. Татарны уятырга кирәк. Минем иҗатым нәкъ менә шул изге максатка юнәлдерелгән. Шул сәбәпле, мине күралмаучылар да бихисап. Әмма мин тоткан юлымнан тайпылмаячакмын.

Җырлап торам, торган җирем тар булса да,
Курыкмыйм, сөйгән халкым бу татар булса да;
Күкрәк биреп каршы торам, миңа милләт
Хәзерге көн мылтык-ук атар булса да...

Габдуллаҗан шигырен сәхнәдә чыгыш ясагандай шундый ихластан, шундый ашкынып сөйләде ки, бу игълан-белдерү, Зиннәтулла хәзрәтнең тавык кетәгедәй кечкенә бүлмәсенә сыеша алмыйча, горурлыгын җуя барган татар халкына кисәтүле набат булып яңгырады. Хәтта савыт-сабаларга да җан керде бугай. Чыңгыл-чыңгыл килеп, идәнгә тәгәрәштеләр.

– Бәрәкалла, улым, син инде чын шагыйрь булып җитешкәнсең икән, – диде Зиннәтулла, – кафияле сүзгә кырау юк, илһамың саекмасын, һәрдаим иҗтиһадта бул.

Сүзгә Кәшфелкәбир дә кушылды.

– Энем, Габдуллаҗан, халык сине хәзер Тукай буларак белә, ошбу исем-атны үзең уйлап таптыңмы, нәшриятлар тәкъдим иттеме? – дип сорады.

– Әйе, мин хәзер Габдулла Тукай. Хикмәт шунда: әдәбият дөньясында тәхәллүс киң таралган. Мин дә шул агымга иярдем. Чөнки Габдуллаҗан Мөхәммәтгарифов исем-аты шагыйрь өчен озын да, килешсез дә. Баксаң, әти ягыннан иң карт бабабыз Туктулы атлы булган икән. Әлеге исемнең беренче иҗегенә «ай» сүзен беркетеп куйган идем – Тукай килеп чыкты, – дип елмайды ул, уенын-чынын бергә кушып.

– Тукай – татар-төрки дөньясында мәгълүм исем, – диде Зиннәтулла, – фаразан, Бату ханның кече энесе Тукай Тимур – тарихыбызда тирән эз калдырган шәхес. Нугайларда да еш очрый бу исем.

– Бабакай, зинһар, иҗади табышыма кизәнмә, – дип көлде Габдуллаҗан, – монда син мисал иткәннәрнең бер катнашы да юк.

Әңгәмә шушы урында өзелде, ишек уемында Кәшфелкәбирнең җәмәгате Рабига абыстай күренде.

– Кара, күр боларны, кунакны сүз белән сыйлыйлар, – дип, хуҗаларны битәрләп алды, – рәхим итегез ак өйгә, табын әзер.

– Кунак килсә, өй тотәр, дияргә ярата җиңги-абыстай, – диде Габдуллаҗан, шаян гына елмаеп, – казанын да астыра, тавыгын да суйдыра.

– Алай димәле син, Габдуллаҗан, кунак төшсә, йортка җәм генә өстәлә, – диде хуҗабикә.

Әңгәмә табында да дәвам итте. Бу инде көнкүреш хәлләренә, туган-тумача хәлләренә кагылышлы әңгәмә иде.

Әүвәл Бибимәмдүдә рухына дога кылдылар.

– Мин барысын да хәтерлим, – диде Габдуллаҗан, – әниемнең җәсәден өйдән алып чыгып киткәч, җеназачылар артыннан елый-елый йөгергәнемне

дә, Мөхәммәтшакир хәзрәтнең майлы ипигә бик мулдан бал ягып сыйлавын да, хәтта ат җибәреп, Кушлавычтан Саснага алып барганнарын да...

Бераз сүзсез утырдылар. Аннан соң: «Саҗидә апайларның хәл-әхвәле ничек?» – дип белеште Габдуллаҗан.

– Көтәрнәстә матур гына яшәп яталар, балалар үстерәләр, барышып-килешеп йөрибез, – диде Рабига.

– Мин Саҗидә апаемның туенда, такмак әйтә-әйтә, ишек бавы тоткан егет кәмәше дә бит әле, – диде Габдуллаҗан, борынын чөебрәк, – шул истәлеккә «Ишек бавы» дигән шигырь дә яздым, үзләренә баргач сөйләп күрсәтермен дип торам, ошатырлар, шәт.

Ишек бавы бер алтын,
Безнең апай мең алтын...

Әле дә хәтеремдә, туйдан соң мине кияү белән кәләшнең хәлвәт катына чакырдылар. Әхмәтсафа җизнине бер карауда ошаттым. Мәһабәт кыяфәтле, зәңгәр күзле, коңгырт чәчле, ачык йөзле, җор телле. Кипкән балыктай ябык һәм шүре гәүдәле булганга, күрәсең: «Габдуллаҗан, бу дәү өй ишегеН малайлар белән җыйнаулашып, күбәүләп ачкандырсыз инде», – дип шаяртып та алды.

– Юк ла, җизни-абый, янымда бары бер дустым гына бар иде, шул булышты, – дип чынын әйттем.

Чәйләре шундый хуш исле, шундый шифалы булды ки, тәме авызымда әле дә саклана. Саҗидә апай йомшак күңелле ак фәрештә бит ул, аның изгелекләрен кабердә ятсам да онытасым юк.

– Габдуллаҗан, Өчиледә һич югы берәр ай кунак булырсың әле, һич тә аерылашасы килми, – диде Зиннәтулла, – бездә яшәп калсаң да сөенер генә идек, шулай бит, балалар?

Барысы да ризалык белдереп баш какты.

– Рәхмәт, бабакай, – диде Габдуллаҗан, – Аллаһы боерса, берсекөнгә кузгалырмын, дип торам, Саҗидә апайларда да озак юанмам, Казанда шөгыльләрем күп, эшкә урнашасы бар, нәшриятлар белән элемтәне җайлыйсы бар. Борчылмагыз, мин кайтыштырып йөрермен.

– Торыр урының бармы соң?

– Шөкер, торыр урыным да бар, бабакай. Мин бит Казанда туры «Йолдыз» гәҗите редакциясенә килдем. Анда матбугат аша якын танышым Галиәсгар Камал белән очраштык. Бик ихластан кабул иттеләр. Мәҗлесләр оештырдылар. Шунда ук «Болгар» кунакханәсендә өченче катта Кабан күленә карап тора торган бер тәрәзәле, караватъ, өстәл, урындыктан гыйбарәт җиһазлы бүлмәне миңа тәгаенләделәр. Хакы да килешле. Миңа әлегә бик җиткән.

Сагынышканнар иде, әле ут алгач та озак кына сөйләшеп-гәпләшеп утырдылар. Шулай да Зиннәтулланың тамагына сөяк булып кадалган төп сүз әле әйтелмәде. Ул аны берничә мәртәбә башларга омтылып карады-каравын, тик тел очына килеп җитүгә, төкереген йотып, янә күңел төбенә яшерде.

Билгесезлек аны эчтән кимерә иде, төнне дә керфек тә какмыйча үткәрде. Таң атуын көтеп ятты да, яктыра башлауга, өстәл янына утырып, кулъязмасына тотынды.

Габдуллаҗан ишекне ачып кергәндә, бабасы шушы мөкәйиф халәттә иде. Бераз күзәтеп торды да сәламен юллады.

– Әссәламегаләйкем, бабакай, бик иртәләгәнсең.

– Ә-ә, Габдуллаҗан, вәгаләйкемәссәлам-вәгаләйкемәссәлам.

Зиннәтулла бу юлы форсатны кулыннан ычкындырмады, күзенә бәреп:

– Улым, Габдуллаҗан, турысын гына әйт әле, син миңа нык рәнҗисеңме? – дип сорады.

– Әлхөкеме лиллия, бабакай, ничек инде мин сиңа рәнҗергә тиеш? – дип, Габдуллаҗан Зиннәтулланың аркасыннан җиңел генә сөеп куйды.

– Бик кыбырсыйм, улым, мин сине карый алмадым бит, кеше өстендә йөрттем, моннан да зур гөнаһның булуы мөмкинме соң? Тәүбә дә...

Ул ярты юлда тотлыгып калды. Габдуллаҗан шундук ярдәмгә ашыкты.

– Зинһар, бабакай, юкка тәшвишләнмә, – дип, әңгәмәне ялгап җибәрде, – минем язмыш – шагыйрьләр язмышы ул. Һәр дәкыйка – имтихан, һәр адым – сынау. «Бәкарә» сүрәсен генә хәтеребезгә төшерик. Ә анда: «Без сезне сынарбыз... үлем-китүләр белән, бакча җимешләрегезне, йөрәк җимешләрегезне алып», – диелә. Раббыбыз, күрәсең, әһле каләм бәрабәренә миңа шушы сынауларны мәгъкуль санаган. Син, бабакай, кулыңнан килгәнчә барысын да эшләргә тырыштың. Игелекләрең өчен тәшәккүрдән гаҗизмен. Соңлавым өчен үзең кичер.

Зиннәтулланың сөрлегүле гәүдәсе тураеп китте, күзләрендә очкынга охшаш дулкын кабынды.

– Әлгаязе билла, улым, Ходай үзеңә дә бәрәкәтләр бирсен, син мине тәмуг утларыннан коткардың. Аллаһының рәхмәте илә бу фани дөньядан тыныч күңел белән, чистарынып-пакьләнеп китә алам, димәк...

– Бабакай, син минем өчен иң мөшәррәф тәкъваи вә гыйльми мөрәүбәт зат. Инша алла, бакыйда да урының түрдә булыр.

– Фазыйләтен салават, улым, авызыңа бал да май.


* * *

Зиннәтулла хәзрәт калган гомерен әүвәлгечә дингә багышлады, сиксән яшендә намазлык өстендә җан тәслим кылды.

Дүрт елдан соң Габдуллаҗан да, егерме җиде ел, өч ай, унбиш көн яшәп, бабасы хозурына күчте.

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Рәниф
Шәрипов

# ЭТ УРАМЫ

ПОЭМА

*Илдә көчек булсаң бик тә ярый,*
*Тик ил өчен кирәк өрергә.*

*Зөлфәт*

Менә язып та бетердем,
Җитте бугай инде. Булды.
Язылдырып керим әле
Каләм тотып каткан кулны.
Чыгып бастым. Ә алдымда
Тыз-быз килә шаулы урам.
Күккә карыйм, җиргә карыйм,
Кулларымны селким, борам.
Кан йөреше җайга килә,
Тик язылмый әле күңел.
Нидер җитми кебек һаман,
Йөрәгем дә тыныч түгел.
Ыгы-зыгы... Беркемнең дә
Бернидә дә эше дә юк.
Ташып торган уйларымны
Сөйләрлек бер кеше дә юк.
Миллионлы мега-шәһәр,
Миллионлап ут кабыздык.
Күңелләрдә генә никтер
Караңгылык һәм ялгызлык.
Урамнарга чыксаң әгәр,
Кеше йөзе... Кеше йөзе...

Рәниф ШӘРИПОВ (1950) – *шагыйрь; «Мәңгелек сер», «Азатлык көне», «Җомга» һ.б. китаплар авторы.Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. С.Сөләйманова, Һ.Такташ һәм Г.Исхакый исемендәге әдәби премияләр лауреаты. Казанда яши.*

Чиксез төркем уртасында
Шул ук кеше, тик берүзе.
Карт-карчыклар, бала-чага...
Машиналар, машиналар...
Иртәгә көн бетәр кебек,
Нәрсә куып ашыгалар?
Унбер яшьтә биш чакрымга
Җәяүләп тә бара идек.
Шул ук гомер, шул ук вакыт,
Һаман шул бер ара инде.
Барысына өлгергәнбез –
Укырга да, уйнарга да,
Шул ук көннәр баскычында
Киләчәкне уйларга да.
Шул ук гомер. Вакыт уза.
Алдымда тик кыргый урам.
Ә мин нидер язган булам,
Имеш, ниндидер эш кырам.

...Күзем төште – ерак түгел,
Гамьле күңелемне өтеп,
Үпкәле бер әрнү белән
Карап тора урам эте.
Өметсезлек тулы күзләр...
Карый аңлап, карый белеп.
Минем йөрәк боздан түгел,
Мин дә аны аңлыйм кебек.
Кыргый, усал булырга дип,
Аңа язмыш кушкан инде.
Көн аралаш ач тамакка
Бөтен дөнья дошман инде.
Йә хуҗасы үлгән моның,
Адашыпмы тайган юлдан.
Күренә бит – ул кайчандыр
Җүнле йортта сакчы булган.
Чакырырга хуҗа кушкан
Исеме дә булган элек.
Исемен дә, нәселен дә
Булмас инде хәзер белеп.
Күпме зарын сөйләр иде.
Рәхәт күргән көне юк бит.
Аңлашырлык аңы бар, тик
Сөйләшерлек теле юк бит.
Саклагандыр хуҗасының
Йорт-җиренең әйләнәсен.
Хезмәт итү – хурлык түгел,
Тик чылбырга бәйләмәсен.
Чылбырда гомер үткәрү –
Тормыш түгел, каза бит ул,
Аңлатып булмаслык сагыш,
Озын-озак җәза бит ул.

Нишләтәсең, күпме хуҗа
Бер уйлап та карамый бит.
Яздым инде. Бәйдәге эт
Йөрәгемә ярамый бит.
Эт хуҗасыз яши алмый,
Иреге бар, кирәге юк.
Бәйдә җәнлек тотучының
Аңы, җаны, йөрәге юк.
Кирәгең юк икән инде,
Юанычмы мондый ирек?
Торырга йорт сайлар иде,
Барлык азатлыгын биреп.
Тугры эттән угры качар,
Өркетер ул юлбасарны.
Йорты барның иреге юк –
Яхшымы бу йә начармы?
Бездә шундый хуҗалар бар,
Басып кергән кисеп-суеп.
Җиребез бар, илебез юк,
Ә азатлык – чылбыр буе.
Чылбырны тарталар һаман,
Алдан түгел, син, арттан бар.
Артык озын, дип, телеңне
Кисә-кисә кыскарталар.

Кемдә кемнең эше бар соң?
Кыргый тормыш, кыргый урам...
Беркемгә дә кирәкмәгән
Урам эте карап тора.
Кем әйтер аны кыргый дип,
Күргәч безнең «тамаша»ны?
Кем әйтер аны җансыз дип,
Күзләрендә аның җаны!
Әйтә кебек рәнжү белән:
«Без бит сезгә кирәк идек.
Кирәк чакта, кыргыйлыкта,
Ни дисәң дә, терәк идек».
Карап булмый күзләренә –
Сагыш тулы тугры җанга.
Укыла тик аяусыз зар:
«Сез бит сатылгансыз анда...»
Сөйләшәбез. Җан иясе
Кеше янында йөргән бит.
Аның теле – күзләрендә,
Ә минем тел киселгән бит.
«Кайчандыр без кирәк идек,
Күпме сезне саклап йөрдек.
Без дә сатылдык бер көнне –
Бүреләргә каршы өрдек...
Сатылганга каргыш булып,
Язмыш булып кайта үче –

Без бүре дә, эт тә түгел,
Без, бары тик, хәзер күсе.
Безне беркем дә яратмый,
Без чүплектә тукланабыз.
Сатылганның нәселе юк,
Юк атасы, юк анасы.
Кайчак кыйнап үтерәләр,
Кайчак очыралар тибеп.
Ә кайчандыр үзебезгә
Тик үзебез хуҗа идек».

Башын салды тирән сулап,
Бераз тынычланды җаны.
Ул  сөйләде кебек миңа,
Мин аңладым кебек аны.
Сизәм, аның карашында
Барысы бар – ут та, боз да.
Тагын бераз карап торсам,
Кочаклашып еларбыз да.
Җитте сиңа. Кереп киттем,
Кисәк кенә кузгалдым да.
Кая гына карасам да,
Урам эте күз алдымда.
Өмет тулы күз карашы
Йөрәгемне ала телеп.
Нәрсә күреп кергәнемне
Мин әкренләп аңлыйм кебек.
Бер-беребезне без дә саттык,
Килештек тә майга, балга.
Ә киләчәк шул эт булып
Килеп басты безнең алга.
Әллә бу кич ахырымы?
Әллә инде таң алдымы?
Безгә өзгәләнгән йөрәк,
Телгәләнгән тел калдымы?
Әллә инде алдыбызда
Аяк атламаслык чикме?
Сөйләшергә тел бар әле,
Аңлашырга акыл җитми.
Мин атылып чыктым кире,
Ит кисәге тотып кулга.
Йозаклы йөк машинасы
Төтен сибеп тора юлда.
Ә читлектә урам эте
Өмет белән миңа карый.
Аяусыз чор... Кырыс дөнья...
Атып үтермәгәч ярый.
Тик шулай да өмет кала –
Урам түгел бит барыбер.
Бәлки, агу кадамаслар?
Бәлки, хуҗа да табылыр?
Этләр елый белә икән...
Яшәп булмый көлеп кенә.
Ләкин, нигә бу эт һаман
Миңа карый өмет белән?!

Юк! Җитмәде егетлегем,
Күтәрелеп булмый инде.
Йөрәк күпме сораса да,
Сатлык гамьсезлегем җиңде...
Тәнемдә дә, җанымда да
Сызлый, әрни күпме ярам.
Куркак йолкыш кебек качып,
Елый-елый кереп барам.

Дөнья матур тук тамакка,
Гамьсез тормыш боза безне.
Риза булып чылбырга да
Кистерәбез телебезне.
Кулыбызда бәхет иде,
Суга салдык та агыздык.
Яр буенда елап калды
Өметсезлек һәм ялгызлык.
Агып китеп бара хыял
Упкын авызына таба.
Битараф, буш су буеннан
Өрә-өрә этләр чаба.


Җитте-җитте. Туктыйм инде.
Бу юлы чынлап та булды.
Тагын чыгам шул урамга,
Тагын узам шул ук юлны.
Язганымда мантыйк күрмим,
Эчтәлеге дә икеле.
Бер карыйм да, «Шедевр!» дим,
Тагын карыйм – чүп шикелле.
Искә алам сугышларны,
Кавышмаган гашыйкларны...
Котылгысыз сорау туа –
Ә тормышта мантыйк бармы?
Кемгә тормыш – баллы җиләк,
Ә кемгәдер эссе таба.
Кылган эшләренә карап,
Үз мантыйгын кеше таба.
Чыгып бастым. Шул ук урын.
Мин хәтерлим бу рәсемне.
Ләкин мин бит чыгып киләм,
Белеп нәрсә күрәсемне.
Көтмәгәндә катып калдым –
Әйтерсең лә мине көтеп,

Беркая да китмәгәндәй,
Карап тора урам эте.
Шул ук җирдә, шул ук мизгел,
Шул ук дүрт-биш аршин ара.
Шул ук дөнья. Әллә зиһен,
Әллә вакыт алдан бара.
Әллә вакыт туктаган да,
Шул ук сүзләр катып калган:
«Сез бит безне ташладыгыз,
Сез бит сатылгансыз анда...»
Мин бит әле бу дөньяда...
Барысы да шул ук иде!
Вакыт туктап калган икән,
Киләчәккә юл юк инде.
Күрә белсәң, бу карашка
Күпме туры сүз язылган.
Ни булса да, бу көн хәзер
Китмәс инде күз алдымнан.
Сатылганнар яши сатып,
Ватылганнар ятып калган.
Ничә гасыр буе инде
Курку йөри безнең алдан.

Җиргә карыйм, күккә карыйм –
Өмет күрмим туган җирдә.
Ә бит Кемдер яшәү хакын
Барыбызга тигез биргән.
Кайчандыр бер җавап тотар
Тигезлекне бозган адәм.
Үз өлешең – үзеңнеке,
Калган барысы да хәрәм.
Нәрсә ул тән? Көл дә туфрак...
Мәңгелеккә калган җан бар.
Хакимнәрнең кулларында
Юып бетермәслек кан бар.
Чиксез җәза көтә аны,
Җанын – озын-озак газап.
Әле безнең исемнән ул
Хөкем итә, закон яза.
Ничек анда – беркем белми.
Барыбызда бар ул өмет –
Безнең Җирдә яшәвебез
Юкка гына түгел кебек.

Тәүбә ит тә игелек кыл,
Хәтта соңгы көнеңдә дә.
Иман билгесе – тик вөҗдан,
Монда да шул, тегендә дә.

Фәхеш тулы гаделсез Ил,
Ярдан ярга күпме ара.
Бәйләп суга салган өмет,
Инде агып китеп бара.
Китә бәхет. Алда упкын.
Бу – кыямәт көне алды.
Өреп узып китте этләр,
Берсе никтер туктап калды.
Сүнмәс өмет бу күзләрдә –
Бәлки, хуҗа да табылыр?
Туктама син... Ялгышасың...
Кереп китәм мин, барыбер.
Угрылар күп нотык сөйләр,
Дөрес булмас бер сүзе дә.
Таян бары үз көчеңә,
Ышан бары тик үзеңә!
Алда күпме тормыш әле.
Төрле якка таркала юл.
Имансызның җиһаны юк,
Тегендә дә, монда да шул.
Иман нуры кыйбла булсын
Җаныңда да, телеңдә дә.
Иман нуры – җәннәт юлы,
Монда да шул, тегендә дә.
Нинди авыр, аяусыз көн...
Сызлый, әрни күпме ярам.
Өметсезлек урамыннан
Киләчәккә кереп барам.
Ә артымда шул ук күзләр
Өтеп алды тәнне, җанны.
Мин йөгердем, тик барыбер
Канатларым дөрләп янды.
Хокуксызлар төрмәсенә
Кертеп салды безне язмыш.
Яна-яна, елый-елый,
Хәзер инде шул төрмәнең
Зиратына кереп барыш.



Кәрим
Кара

# ДЕПРЕССИЯ

ФӘЛСӘФИ ПОВЕСТЬ

Кәбир киштәдәге китапларны караштыргалап кич җиткерде. Тәрәзә артында караңгылык куера башлагач кына, бүген юньләп тамагына ашамаганы исенә төште. Хатыны Сабрина иртәдән Самарадагы ахирәтенә кунакка барам дип чыгып киткән иде. Берүзе калганына ир шатланып та куйды. Холкы-фигыле буенча ул ялгыз бүре иде. Гомере буе шау-шулы компанияләрне, җыелышып күңел ачуларны, дуслар дигән булып кемнәр беләндер өйлегешеп йөрүләрне яратмады. Тын бүлмәдә, йомшак диванда ялгызы булуны ул бар дөнья шатлыкларыннан артыграк күрә иде. Шуңа да бүгенге көн аның өчен үзенә күрә бер бәйрәм булды. Иртәнге якта урам аша урнашкан паркта озаклап киләп сарып йөрде, менә әле китаплары арасында онытылды. Артыгы кирәкми иде аңа. Күңел хушлану бер нәрсә, әмма организм үзенекен таләп итә, бүреләр улый башлаган иде эчтә. Аш бүлмәсенә чыгып, тартмаларны шап-шоп ачкалап япкалады ул, суыткычта чокчынды. Кыштыр капчыкка тутырылган пилмәннәрдән яхшырагын тапмады. Бу нигъмәтне әзерләүнең артык катлаулылыгы юк. Быкырдап кайнап утырган суга килога якын пилмән тондырасың да, биш минуттан патшалар ризыгы өстәлдә була. Шартына китереп, бер шешә сыра ачты, тәрилкәдә өелеп торган пилмәннәрне каймакка манып ялт иттереп куйды. Артыннан сыра белән юдыргач, изгәләнеп беткән диванына чыгып сузылды. Кулы, гадәт буенча, телевизор пультына үрелде. Әмма кабызмады шул сихер тартмасын Кәбир, ут алмый гына ята бирде өйрәнгән урынында. Тамагы тук, ләкин күңеле урынында түгел иде. Үткән атнада башланды бу йөрәк җилкенүләре. Сәбәбе дә юк кына нәрсә төсле иде. Таныш рәссамнары белән ул яшьләрнең күргәзмәсен ачуда катнашты. Мондый тантаналар, гадәттә, бер-берсенә игезәкләр сыман охшаш була. Мәдәният министрлыгы вәкиле баш сүз сөйли, олпат мэтрлар җилкенчәкләрнең иҗатына кагылышлы берничә җылы сүз әйтә. Аерым күзгә бәрелгән картиналар каршында тукталып фикер алышулар була. Иң соңыннан барысы җыелышып күршедә урнашкан кафеда бераз тамак чылаталар, үткәннәрне искә алалар, яшьләргә акыллы киңәшләр бирәләр. Шуның белән йомгаклана күргәзмәне ачу тантанасы. Рәссамнарның кайсылары соңгы өлешендә катышмый да. Кемнедер чирләре хәмер кабудан катгый тыя, кемнәрдер

Кәрим КАРА (1956) – *прозаик; «Без әнкәйнең йөрәгеннән чыктык» исемле китап авторы. Тәтештә яши.*

әхлаклы йөзләренә кафе Ише нәрсәләрдә чиле-пешле котлет ашап, арзанлы аракы чөмереп тап кундырасылары килми, беришеләр, чынлап та, бик югары баскычта тора. Аларга инде кара халык арасында вакланып йөрү килешеп бетми. Шәхсән барды, кушсалар – басып сөйләде, салсалар – каплап куйды. Ә нигә үзеңне коллективка каршы куярга? Арада сөйләнгәннәрнең күбесе белән Кәбирнең бервакытта да күпчелектән аерылганы булмады, чакырсалар – ул риза булмый иде. Әмма һәрчак елмая төшеп, ипле генә баш кагып, уңай фикердә булганлыгын белдерә, җөпләп бер-ике сүз өсти. Эчеңдәгесен кем белсен, ә менә каршы төшә башласаң, дошманнарың артуын көт тә тор. Кирәкме андый тормыш Кәбиргә? Үткән атнада булган күргәзмә дә башкалардан аерылып тормый иде. Барысы да күнегелгән тәртиптә барды. Төркемгә ияреп йөргән Кәбир, эче пошып, һәр минутны этеп-төртеп үткәрде. Шулай да чыгып китүне яхшысынмады. Бар иде арада очлы күзләр, кырыкка төрләндерерләр иде гамәлен. Безне хөрмәт итми, үзен әллә кемгә куя, артык җире юк, сәнәктән көрәк булган, диярләр иде. Әле анда гына калсалар. Алдагы көннәрдә үч саклап, кара янып йөрмәсәләр. Иптәшләре елмайганда – елмайган булды, нидер сөйләсәләр, уйчан чырай чыгарып, игътибарлап тыңлагандай кыланды. Шулай тыныч кына үтеп китәр төсле иде барысы да. Әмма зал буйлап тагылышып йөри торгач, зур булмаган картина янында тукталдылар. Кәбир дә, кызыксынып, кемнеңдер иңбашы аша үрелеп, әлеге рәсемгә бакты. Картинаның композициясе гади генә иде: ашыйсын ашаган, яшисен яшәгән, күзләренең төсе уңып, йөзен сырлар баскан авыл карты бирчәйгән кулларын малай йоратының иңбашларына салган да зәңгәр офыкка текәлгән. Кыйгач канатлары белән бәрелә язып, кара карлыгач оча яннарында. Арткы фонда чак бөреләнгән каен җилдә тибрәлә. Карауга, яз сулышы кагылып калгандай булды Кәбиргә. Бабай да якын кешесе төсле таныш тоелды, бу сипкелле малайны да кайдадыр очратканы булды шикелле аның. Икенче мизгелдә, гадәт буенча, җитешсезлекләр эзләп күз йөгертте ул, күңелендә ниндидер каршылыклы тойгылар уянды. Тапкан язар нәрсә, нәрсәгә киндер, буяу әрәм иткән диген. Мондый бабакайлар чат саен, бер-берсеннән аермалары шулкадәр генә. Гомер буе изелеп-сытылып нужа йөге тарткандыр да хәзер түшәмгә төкереп пенсия акчасын ашап ята торгандыр карчыгы белән. Белгәне камыт, дирбия, тәртә дә арбадыр. Ат йөген, бәлки, килештереп төйидер анысы, балта эшенә маһирдыр, йә, шуннан? Казанны бер-ике тапкыр килеп күргәндер, район хастаханәсендә бүсерен кискәннәрдер. Менә аның тормыш юлындагы истәлекле вакыйгалар. Кат-кат район гәзитен укый торгандыр, хөкүмәт башлыкларын сүгеп кинәнәдер. Ике җөмләсенең берсе: «Менә без яшь чакларда…» – дип башланадыр. Үсеп таралышкан балаларының тормышлары белән мактанып ирәядер. Тегеләре йә тимер калдыклары җыеп, йә мунча миче эшләп акча суга торганнардыр. Елтыр күзле малай оныгыдыр, тәгаен. Гел берәр чатаклык чыгарып кына торадыр әле юеш танау. Әллә сугыш чукмарыдыр, йә барып чыккан әләкче. Укуга хирыслыгы шикле. Яхшы укыса, компьютерыннан аерыла алмыйдыр, уен уйнап үтәдер көннәре.

Ниндидер ярсу тойгысы үскәннән-үсә барды Кәбирнең күңелендә бу иҗат җимешенә карата. Тирә-яктагылар да беравык карап тордылар да дәррәү рәсемнең кимчелекләрен санарга тотындылар. Имеш тә, кулланылган төсләр артык кычкырып тора, колорит сакланмаган, динамика-статика бәйләнеше юк, перспектива законнары бозылган һәм башкалар, һәм башкалар. Соңыннан бердәм нәтиҗә ясадылар: бу рәсем китч мисалы, автор, популярлыкка омтылып, сәнгатьнең бар кануннарын аяк астына салып таптаган. Шуңа да бу рәсемне

күргәзмәдән бөтенләй алып куйганда яхшырак буласы икән. Коллегаларының фикерләрен тыңлап торганда, ике төрле караш җанын җәфалады Кәбирнең. Бер яктан, рәсемне хурлап әйтелгән сүзләр аның күңеленә сары май булып ятты. Шул кирәк борын асты кипмәгән яшьләргә, дип, һәр әйткәнгә имза салып торды ул. Әле сәнгать белеменең әлифбасын да эстәмәгән, теоретик яктан аксаган, башларында җил уйнаган малай-шалай, бугаз ертып, мин-минлекләрен исбатларга алына. Ни тормыш тәҗрибәсе юк үзләренең, ни шәхес буларак җитлекмәгәннәр. Эт чаба дип бет чаба, кем әйтмешли... Икенче яктан, нигә үз-үзеңне алдарга, авторның таланты һәр штрихта, һәр чагу төстә ярылып ята иде. Кайдан килгәндер ул җитлекмәгән нәрсәгә шундый осталык, пумаласы кагылган урыннарга җан өргән диярсең... Яшь рәссамның картинасын хурладылар, ни гаҗәп, кафега кереп, субординацияне саклап (азау тешләре чыккан мастодонтлар, җитәкче урыннар биләгән иҗат әһелләре, дәүләт премияләренә лаек танылган рәссамнар, башкаларны терсәкләре белән төрткәләп кояш астына үрмәләгәннәр, төрле постау куштаннар, күренеклеләрнең туганнары, дус-ишләре түрне биләделәр), өстәл артына урнашканнан соң да сөйләшүләр әлеге картина хакында барды. Әлбәттә, бирелгән бәя уңай якка үзгәрмәде. Бер-ике чәркәдән кызып алган иҗатчылар, отыры кабынып, сүзләрне сайлап тормыйча, төкерекләрен чәчтеләр. Бәхетсезлегенә күрә, яшь автор үзе дә ишек төбендәге урындыкка артын төртергә батырчылык иткән, имеш. Полотнолары күрше өлкә музейларында эленеп торган Куптарайский никтер авторның кемлеге белән кызыксынасы итте. Арада булган яшьләр, бер-берсен уздырып, әлеге мескен егеткә төртеп күрсәттеләр. Куптарайский, арыслан ялы төсле чәчләрен артка ташлап, урыныннан күтәрелде, тишеп чыгарырдай булып, юка гына гәүдәле егеткә карап катты. Авыр карашны күтәрә алмый, теге дә торып басты, бите кара янып чыкты.

– Син кем? – дип залны яңгыратты Куптарайский, баскан урынында чыдап тора алмыйча. Бу тавыштан барысы дерт итеп төште. Егетнең тубык башлары дер-дер калтырыйдыр дип уйлап куйды кулындагы чәнечкесен авызына җиткерә алмый туктап калган Кәбир.

– Мин... Мәҗитов, – диде өзә-ерта егет. Тавышы шактый сыек яңгырады аның.

– Ма-җи-тофф, ха... – дип, артистларча кулын алга ташлады Куптарайский, – син кем булдың сәнгать даирәсенә шул шапшаклыкларыңны йөкләп керергә? Со свиным рылом в калашний ряд… Әзрәк өйрәтмәделәрмени соң сине остазларың хәреф танырга? Полутоннарның нәрсә икәнен беләсеңме син, киндер пычратучы? Кызыл төскә шәмәхәне ялгый бу малай, чем-кара белән сурикны аталандыра.

– Мин... мин... – дип акланырга теләде егет кисәге, әмма Куптарайский аңа нәрсәдер әйтергә ирек бирмәде.

– Вон! – дип бармак төртте ул ишек ягына. – Вон! Утырма һава бозып чын сәнгать әһелләре арасында...

Теге егеткә чыгып китүдән башка чара калмады. Бу ямьсез күренештән соң өстәл артында киеренке тынлык урнашты. Кемдер ашау белән мәшгуль булып кыланды, кемдер күршесенең колагына нидер шыбырдады, кайсысы кесәсенә шап-шоп суккалап, нидер эзләп маташты. Куптарайский үзе, ах-ух килеп, урындыгында кыбырсынды. Гадәттә, һәр оешкан төркемдә бер телгә беткән адәм табыла. Бу юлы туган киеренкелекне Машков таратып җибәрде.

– Иптәшләр, дуслар, коллегалар! – дип сикереп торды төче телле Анатолий.

– Сәнгать – үлемсез! Ләкин аны якларлык тарафдарлары булган чакта гына. Яшьләрне туры юлга салу – безнең бурыч. Шуңа күрә алар ачы дөреслекне кабул итә белсеннәр. Коллегабыз чын йөрәктән әйтә аларга хаклыкны, чөнки ул бөек сәнгать өчен гомерен сарыф итәргә әзер. Без барыбыз гүзәллекнең тугры коллары, әйдәгез әле, шуның өчен чәркәләрне тотыйк. Бөек Достоевский әйткәнчә: «Красота спасёт мир!»

Бу тостка барысы да ризалашып чәркәләргә үрелделәр. Әкренләп сөйләшүләр икенче агымга кереп китте. Кәбир нотык хуҗасын күзәтте. Теге, үз-үзеннән канәгать булып, алдындагы салатны киң авызына калаклап йөгертә иде. Машков чукындырылган татарлардан иде. Кайдадыр өлкәдә, мәдәният институтын тәмамлаганнан соң, Казанга килеп урнашкан. Чыдамлы эш атына тиң иде ул. Гел кайдадыр ашыга, кемнәр беләндер элемтәгә керә, җыелышлардан калмый, югары даирә затлары арасында бутала, калым артыннан калым табып кына тора. Әле ул авылдагы урыс чиркәвен изгеләр сурәте белән бизи, йә берәр түрәнең автобиографик әсәрен рәсемнәр белән тулыландыра, милләттәшләребезнең халык костюмнарын яңартуда катнаша. Һич тик торганы юк. Шуңа да материаль авырлыклар кичерми, җитеш яши. Менә сәнгатькярләр арасында абруе түбән булганына эче поша, тиресеннән чыгардай булып, үзенең даһилыгын исбатларга тырыша. Берәр төрле конкурс игълан ителсә, катнашмый калмый. Нигә яшерергә, гадәттә, андый конкурсларда беренче урыннар билгеләү талант югарылыгына карап түгел, ә бөтенләй башка үлчәмнәрне исәпкә алып эшләнә. Монысының яше алтмышка җиткән, үз гомеренә бер тапкыр булса да бүләк алып карасын, күпме буяу исраф итте, диләр. Тегесенең баҗасы Министрлар Советында урынбасар, берәр файдасы чыгар дип фикер йөртәләр. Өченчесенең хатыны усал, көн дә идарәгә килеп, иренә дәрәҗә юллый, кемне очрата – шуның тетмәсен тетә, тыгылсын тамагы, дип кул селтиләр. Күптөрле сәбәпләр тәэсир итә урыннарны билгеләгәндә. Саный башласаң, кулдагы бармаклар җитмәс. Менә Машков та төрле юлларны табып (жюри әгъзаларын лыкынганчы сыйлау йә кыйммәтле бүләк төртү бик отышлы юл!), дипломга, премиягә ия булырга ашкына. Еш очрый андый дан өчен мөкиббән киткән адәмнәр. Түрәләрнең әйткән бер мактау сүзе аларга җегәр бирә, мадәт өсти. Алар өчен язган картиналары нинди югарылыкта булуы артык мөһим түгел, исемнәре яңгыравы кадерлерәк. Шулай инде, гади халык каян аешына төшенсен синең сурәтләреңнең, ул күбрәк матбугат битләрендә, радио-телевидениедә исемеңнең ни дәрәҗәдә яңгыраганына карап бәяли.

Табынның калган өлеше билгеле тәртиптә дәвам итте, гадәти тәмамланды да. Яшерәсе түгел, үзләрен югары көчләр тарафыннан сайланып алынган затларга санаган иҗат кешеләре иҗат итү өчен хәмерне иң кирәкле шәй дип исәпли. Тора-бара ныклап дуслаша шешә белән. Минем нечкә күңелемә тынычлык табар өчен йоткаларга туры килә, дип аклана. Өстәл артыннан кузгалганда, арада берничә йөгәнсез бәндә тәмам кондициягә килгән иде инде. Аларны яшьләр култыклап алып чыктылар, хөрмәт йөзеннән өйләренә кадәр илтеп куярга теләк белдерделәр. Кәбир Сәлимов артыгын эчмәде. Гомумән, эчсә – күрсәтми, тартса – ешламый иде ул, күбрәк кеше сөйләгәнне тыңларга гадәтләнгән иде, артыгын әйтеп ташлаудан үзенә күрә саклану чарасы бит ул. Күргәзмә ачу тантанасы үтеп китте, әмма Кәбирнең күңелендә төер калдырды. Әлеге дә баягы картина күңеленә тынгы бирми иде аның.

Бер-ике көн икеләнеп йөрде дә (берәрсе белеп калса!), вакыт табып, тагын барып керде ул телгә алынган күргәзмәгә. Әллә Куптарайскийның тәнкыйтен

исәпкә алмаганнар, әллә куллары җитмәгән, теге рәсем һаман урынында эленеп тора иде әле. Бу юлы инде Кәбир озаклап тукталды картина каршында. Кереп-чыгып йөрүчеләр юк чамасы иде. Бүгенге авыр заманда рәсем карап йөрү кайгысымыни кешеләрдә? Дөресен әйткәндә, иң җитеш чакларда да халык тыгылышып йөрми күргәзмәләргә. Нәрсә аңа рамның читенә чыгарып ясалган аршин зурлык балык яисә яшелле-зәңгәрле тәрәзәле күпкатлы йорт рәсеме? Линейка белән үлчәп, туры сызып та эшләнмәгәннәр, аварга торган кыек-мыек тораклар. Хәзер һәр кешедә машина хакы торган фотоаппаратлар, күңеленә ошаган теләсә нинди күренешне төшереп ала да зурайтып стенасына элеп куя. Хаклары да нинди бит әле, шул киндер кисәкләренә оялмыйча илле мең дә алтмыш мең дип язып элгәннәр. Шулайрак фикер йөртәләр халык вәкилләре. Музей хезмәткәре дә, алтмышны узган карчык, ишек төбендәге урынында кымшанмый утыра бирде, үзенең күзаллауларын аңлатып башны миңгерәтмәде. Тәрәзәдән сузылган көзге кояшның сүрән нурлары рәсемне үзгәртеп җибәргән иде. Ниндидер шатлык тойгылары уятты бу төсләр, барысын кырка өзеп, әнә шул карт белән малай кырына барып басасы килде Кәбирнең. Зәңгәр офыкка карап тын каласы иде, бит алмаларына иркәләп кагылган язгы исерткеч җилне тоясы иде. Дөнья бит ул син уйлаганча түгел, ул бөтенләй икенче, ач күзеңне, уян, дип чаң суга иде сыман бу картина. «Мин анысын үзем дә беләм», – дип, ишетелер-ишетелмәс әйтеп куйды Кәбир. Үз сүзләреннән үзе куркып калып, тиз-тиз тирә-ягына каранып алды. Ярый ла, ялгызы басып тора икән. Бар залны тагын бер кат күз алдыннан үткәреп, сәгатьтән артык йөрде әле ул. Күргәзмәдән Кәбир бөтенләй икенче кеше булып чыкты.

* * *

Әнә шул көннән башлап Кәбир Сәлимовта депрессия башланды. Бу тойгы бер иҗат кешесен дә урап үтми торгандыр. Язасың, язасың да табак-табак битләр тутырып, төшенкелеккә бирелеп туктап каласың. Нәрсә турында язам соң әле мин, кемгә кирәк минем язганнарым, ни мәгънә йөрәктән чыккан бу сүзләрдә? Берәрсе кызыксынып укырмы, фәһем алырмы, үзгәреп китәрме, шакшылыкны киметерме әсәрем, дип үз-үзеңне газапларга саласың. Моңа кадәр гениаль әсәрләр тудырган бөекләр кат-кат язганнар бит инде бу турыда, синең – бөҗәккә тиң затның, энә очы кадәрле булса да яңалыгың булырмы, хисләр тирәнлеге, уйлар балкышы күренерме, дип хәсрәткә каласың. Иҗат – мәкерле остаз. Ул синең күңелеңне яулый, йөрәгеңне буйсындыра, гомереңне сарыф итә, сәламәтлегеңне какшата, җелегеңне суыра. Бар булмышың белән буйсынганда гына нидер тудырырга мөмкинсең. Буш вакытларыңны, тормыш шатлыкларын, нәфесеңне, ихтыярыңны корбан итүеңне таләп итә. Һәм, беркөн килеп, син барысының да юкка гына булганын аңлыйсың, уйлаган уйларың сафсата гына, язган юлларың чүпкә тиң. Бу – авыр халәт. Яшә-яшә дә, эшлә-эшлә дә мәгънәсезлек өеме янында ялгызың басып кал. Әнә шундыйрак уйлар башын тинтерәтте Кәбир Сәлимовның да. Тыштан караганда, барысы да элеккечә иде. Бер журналда рәссам вазифасын башкаруны дәвам итте. Вакытында эшкә килде, вакытында өенә кайтты, иптәшләре белән аралашты, кибетләргә йөрде, срогы чыккан паспортын алыштырырга документлар җыештырды, оныгының ярышта катнашканын карарга барды. Эш урынында алда туган сорауларны редактор белән хәл итте. Барысына таныш булган, шул ук Сәлимов йөри иде кешеләр арасында, әмма автопилотта йөргән төсле хис итте ул үзен. Шулай да бер ял көнне күрше урамдагы подвалда урнашкан остаханәсенә барырга көч тапты. Табигый

яктылык нуры үтеп кермәгән бу почмакны болганышлар чорында мең бәлаләр белән кулга төшергән иде Кәбир. Төрле фасон яктырткычлар җайлаштыргач, мастерскойга охшап китте тагын. Иң мөһиме – бүлмә җылытыла иде. Елның теләсә кайсы фасылында килеп, кулга пумала алырга мөмкинлек бар иде. Соңгы араларда онытылып китеп эшләгәне булмады аның. Йә күңелне кузгатырлык, төн йокыларын югалтырлык идея табылмады, тормыш мәшәкатьләре басты, ялкаулык форсат бирмәде. Керүгә, ишек катында тукталып калды ул. Пәрдәләр капланган, тузан сырган киндерләргә, моңаеп агач аякларында басып торган, үзе белән бергә картайган мольбертына күз йөгертте. Буяу исләре, тынчу һава борынына килеп бәрелде. Бүлмә уртасындагы урындыкка килеп утырып, тәмәкесен кабызды, шарт-шорт бармакларын шартлатты. Ниндидер фикер туып, ашкынып эшләргә килмәгән иде ул. Бары үз тормышының максатына әверелгән һөнәрне барлыйсы, ясаган картиналарын, сызгалаган эскизларын кабат күз алдыннан үткәрәсе килде. Без барыбыз да балачакта онытылып рәсем ясарга яратабыз. Кемнеңдер ипле генә килеп чыга төсле, кемдер ике сызыкны тоташтыра алмый. Әмма һәркемгә ләззәт бирә бу шөгыль, шатлык өләшә. Тора-бара бу һөнәрне үзләштерүчеләр сирәгәя, алар арасыннан иләктән иләнгәннәре генә рәссамлыкны гомерлек юлдашы итеп сайлый. Кәбир үз-үзен белештерә башлаганнан бирле рәсем ясап матавыкланды. Кулына нәрсә эләксә, шуның белән, кайда туры килсә, шунда рәсем төшерде, кулы кычытып кына торды. Мәктәптән чәлдергән акбур кисәге белән койма такталарына иптәшләрен кәкре борынлы, кап корсаклы итеп ясап көлдерә иде. Акшарланган мичкә күмер белән сызгалаганы өчен чыбык эләкте үзенә. Рәсем дәресләрен көтеп ала торган иде. Укытучысы да аны башкалардан аерып мактап бушый алмый иде. Стена гәзитләрен ул бизәде, иптәшләренә рәсемне ул ясап бирде, бәйрәмнәргә багышланган конкурсларда ул беренчелекне алды.

Үз һөнәрен яраткан укытучы, малайның осталыгын хәленнән килгән кадәр үстерергә тырышты, вакыт табып, өстәмә шөгыльләнде. Рәссамнар турында укырга китаплар бирде. Йотлыгып укыды андый китапларны Кәбир, могҗизага тиң язмышларын уйлап әсәрләнде. Шулай да буламы икәнни, дип шаклар катты авыл баласы. Мәсәлән, теге ике грек рәссамының үзара ярышы турында гыйбарә ташка басылгандай хәтеренә бикләнеп калды. Билгеле көнгә үз рәсемнәрен кешеләр хөкеменә китергән ул бөек затларны өнендә күргәндәй булды. Исемнәре хәтерендә калмады. Әмма беренче афиналы үз рәсемен күргәзмәгә куйгач, очар кошлар тукталып, киндердәге җимешләргә ябырылган. Хәтта кошларны саташтырган чын иҗат. Икенчесе үз рәсемен китергәч, иптәше, түземсезләнеп, аннан рәсемне каплап торган пәрдәне ачуын үтенгән. Баксаң, шул пәрдә буяулардан ясалган булган, имеш. Бу юлы инде рәссам тикле рәссам чынбарлыкны ясалмалык белән бутаган. Менә нинди рәссамнар булган дөньяда! Кәбирнең дә тизрәк үсеп җитеп, аларга тиң булмаса да, шулар төсле маһир буласы килә иде. Укыды ул, яхшы укыды, комсызланып үз һөнәренең серләрен үзләштерде. Әйтергә кирәк, урта куллылардан күпкә өстенрәк рәссам булып җитеште. Аерылып торган үз стиле, үз техникасы бар иде аның. Әмма, әмма...

Кәбир, авыр кузгалып, рәсемнәрен барлап китте. Еллар буе кузгатылмаган киндерләрнең тузанын җиңе белән сөрткәләп, озын бер тормыш юлын хәтерендә яңартты. Менә бу почмакта әле аның студент елларында көн белән төнне ялгап ясаган рәсемнәре. Яшь чакта без барыбыз да максималист булабыз шул. Йә күккә ашарга кирәк безгә, йә барысын кире кагып, иблиснең үзен

илаһилаштырырга. Йа Ходa, нинди чирләр белән генә чирләп бетмәде ул чакларда булачак рәссам? Берара төрле ...измнар саташтырды аны. Фовизм, кубизм, футуризм, экспрессионизм, абстракционизм юнәлешләрендә эшлим дип җенләнде. Малевич, Кандинский, Шагал, Дали исемнәрен теленнән төшермәде. Хәтта сирәкләр ишеткән реди-мейд, энвайромент, кинетизм, хеппенинг агымнарын да үз итте. Тормыш чагылышы төсләрдә, тапларда, сызыкларда, чынбарлыкны деформацияләүдә булырга тиеш, дип, очраган берсенә исбатларга тырышты. Менә бу киндерләрдәге өчпочмаклар, бишпочмаклар, хисапсыз түгәрәкләр, аркылы-торкылы сызыклар, гарип-горабага тартым адәм сыннары, зәңгәр куллы, яшел гәүдәле, йорт куяныныкы төсле кызыл күзле адәмнәр – шул чорның шаһитлары. Бераздан капма-каршы фикерләр өстенлек алды рәсемнәрендә. Анысы гиперреализм дип атала, имеш. Фотолардагы төгәллек белән портретларында тәфсилләп һәр чәч бөртеген, йөзендәге нечкә капиллярларны, күз алмасындагы сизелер-сизелмәс кан тамырларын ясау чын сәнгать була дип кабул итте. Романтизм, рококо, барокко, модерн, готика, наив сәнгать – барысы да күңелен кузгаттылар аның, үз артларыннан әйдәделәр. Вакытлар үтү белән, санап чыкканнарның барысыннан да ваз кичте Кәбир. Әмма бу хыялланулар зур мәктәп булды, күп нәрсәләргә өйрәттеләр аны. Кайчандыр ашкынып язган рәсемнәренә игътибар белән карап торды ул. Моннан күп еллар элек үз-үзен аямый тырышкан шул егеткә карата хөрмәт хисе иде күңелендә. Әйдә, эшләгән эшләре җитлекмәгән дә булсын, хаталары күзгә ташланып торсыннар, ләкин самими беркатлылык, язганына ышану, дәрт бөркелә иде рәсемнәрдән. Алгарак китеп, Ленин портреты янында тукталып калды. Әйе, әйе, кайчандыр үтә кызыл рәсемнәрне дә шактый ясады бит ул. Теге чакларда, илне пыран-заран китереп таркатканда, бар вөҗүде белән кабул итмәгән иде ул үзгәртеп коруларны. Кемнәрдер Горбачёвның һәр әйткән сүзен дога урынына кабатлап йөргәндә, яңа, бәхетле тормышка тиенәбез, дип сикереп төшеп шатланганда, бу эйфория аңа кагылмады, ул теше-тырнагы белән каршы торды. Яшьлеге белән, уендагы булганын ачыктан- ачык әйтеп бирә иде Кәбир. Тирә-яктагылар аны адым саен тотып сүктеләр, тиранлыкны яклыйсың, дип гаеп тактылар, юка баш, аңламыйсың яңа карашларны, дип көлделәр. Әмма кибет киштәләре бушап калгач, еллар буе кешеләргә эш хакы түләми башлагач, карточкалар көненә калгач, тындылар тагын. Үзгәрешләрнең материаль җирлеге (ә башкалар нәкъ шул ягын күзалладылар. Капиталистлар булып яши башлыйбыз, дип рәхәт кичерделәр. Чын-чынлап вөҗдан иреге һәм башкалар турында уйлаганнар бармак белән санарлык кына булгандыр), артык кузгатмады күңелен Кәбирнең. «Илдә чыпчык үлми, ничек тә җан асрарга булыр»ына иманы камил иде аның. Аннан соң, теләсә нинди гөнаһларны җилкәсенә йөкләргә әзер, тик байлыкка табыну ул чакларда юк иде аның хасиятендә. Ә менә кыска гына вакыт эчендә гасырлар буе бөртекләп җыелган, саклаган рухи кыйммәтләрне яңа реформаторларның аяк астына салып таптаулары җен ачуларын чыгарды. Шуңа да ул чакларда социалистик дәүләтнең чын-чынлап кыйммәтләре чагылыш тапты рәсемнәрендә. Ул, әлбәттә, совет чорының рәссамнарына ияреп иҗат итмәде, тапталган юл сайламады, үз сукмагын ярды. Палех юнәлешендә ясалган, совет тормышын данлаган рәсемнәре тиз арада тарала башлады. Кызык эзләп, тырым-тыракай килгән Рәсәйне иңләгән чит ил туристларының күңеленә бу картиналар хуш килде. Бай коллекционерлар, исәпләшеп тормый, күпләп алдылар серле, ят җәмгыятьне, кыргый милләтләрне чагылдырган ул рәсемнәрне. Модага кергән

иде Рәсәй экзотикасы. Матрёшкалар, будённовкалар, пионер галстуклары, орден-медальләр йөкләп озатылды көнбатышка, океан артына. Ярый әле акчага кызыгып китеп, конвейер оештырудан вакытында тукталып кала алды Кәбир, читкә тайпылганын төшенде. Ил дефолт кичереп, кризиска чумса, яшь рәссам рухи төшенкелек чоңгылына тарыды. Ярты еллап ул кулына пумала ала алмады, күзенә ниндидер рәсем чалынып калса, күңеле болгана торган булды. Иҗат... иҗат, дип сөйләнгәннәрне ишетсә, тән температурасы күтәрелде, чирлегә әйләнде. Бушлык иде аның башында, котып салкынлыгы биләде күңелен, башка бервакытта да кулына каләм, сангина, пумала, күмер, стек алмас төсле иде. Кемнәр иҗатка якын – бу халәт аларга яхшы таныштыр. Гадәттә, бу тойгы яңа әсәреңне тәмамлаганнан соң туа. Башта әле тәмамлаганыңа сөенеп болытларда йөрисең, кемнәрдер белән шатлыгыңны уртаклашасың, аеруча уңышлы булган урыннарына кат-кат кайтасың, ниләрнедер төзәтәсең, өстисең, үзгәртәсең, сабый бала урынына күреп, кулыңнан төшермисең. Менә синең хезмәт җимешең башкалар кулына күчә, хушлашу мизгелләре уза. Син тагын ак кәгазь бите каршында ялгыз каласың. Атна үтә, ай тәмамлана, утырып язар фикереӊ юк, сюжет башыңа килми, сүзләр табылмый. Бераздан курку керә күңелгә, әллә янып көл булдымы хисләр, корыдымы илһам чишмәсе? «Язасыңмы әле? Нәрсә турыда язасың?» – дип кызыксына очраган берсе. Син көр тавыш белән: «Гөрләп бара эшләр», – дип җаваплыйсың, бар тешләреңне күрсәтеп елмаясың. Еллар үтү белән, әлбәттә, ул тешләрнең саны сирәгәя, күпләре тимер тешләргә алышына. Ни хәл итмәк кирәк, булганы белән бәйрәм, ә сер бирергә ярамый. Шуннан инде холыксызлык башлана, якыннарыңның теңкәсенә тияргә тотынасың. Йә ашка тозны әз (күп!) салганнар, йә кызың артык кыска итәк кигән, йә улың аркылыны буйга алып салмый икән. Беткәнмени сәбәп бәйләнәсе килгән кешегә. Төн йокылары кача, әллә нинди сәер уйлар килә башлый, кинәт булмаган чирләр баш калкыта. Югары көчләргә илһам сорап ялварасың, кырык төрле фикерләр арасында адашып, баш тубал була. Һәм менә бөтенләй уйламаган вакытта, йә мунчада аркаңны мунчала белән ышкыганда, йә булмаса түземсезләнеп кибеттә чиратта торганда, тайгак юлда таеп егылганда, ниндидер сүзләр тезмәсе ишетелеп калгандай була. Әлегә ул зәгыйфь, син әле бу сүзләр тезмәсенең мәгънәсен дә төшенеп бетермисең, башымы, азагымы икәне дә сер булып кала бирә. Күренер-күренмәс җепләр тоташа шулай башка үлчәмнәр белән. Бөтенләй ят күренешләр төсмерләнә, яныңдагы кешеләрне аптыратып, кем беләндер сөйләшә башлыйсың, акыл ягы чамалырак адәм сыман ихахайлап көлеп җибәрәсең. Кыскасы, дөньяга ямь керә, яшиселәр килә башлый.

Кәбир дә әкренләп язылып китте вакытлы чирләреннән, икенче омтылышлар туды, көненә кырык фигыльгә кереп үзгәргән тормыш үз эченә бөтерде аны. Хисапсыз картиналар арасында йөри бирде Кәбир. Соңрак язылганнары күпкә аерылып торалар иде яшьлек эшләреннән. Әлбәттә, осталыгы арткан, техникага сүз тидерерлек түгел, әмма бертөрле җансызлык, конъюнктурага ярарга тырышу, агым уңаена йөзү чагыла иде аларыннан. Ксилографияләрендә «лубок»ка иярү, шәрекъ алымнары, полихром рельеф өлешләре еш кулланылган. Күпчелеккә буйсынып, обоймада сакланып калыр өчен язылган картиналар иде болары. Берсүзсез буйсынганга, әйдәп баручы художниклар белән бер сүздә булганга, аның иҗатын кабул иттеләр, хәтта югары бәяләделәр дә. Берничә эшен музейлар сатып алды. Яхшы кәгазьдә саллы альбомы басылып чыкты, күргәзмәләрдә эшләре түрдә булды, заказлар табылып торды. Аны үз кеше

итеп кабул иттеләр. Мондый карашны тыныч кичерде Кәбир. Күңеле белән эшләгән эшләреннән разый булмаса да, тыныч кына яшәргә, низаглардан читтә торырга, матди яктан авырлыклар кичермәскә мөмкинлек бирә иде бу халәт. Рәсемнәр арасында күңелен биреп, яратып язганнары да бар иде. Зур булмаган фанера кисәгенә майлы буяулар белән ясалган сукыр малайның портреты аңа якын иде. Җәмил исемле малайны яхшы танып белә иде ул. Ятим калган бала эт типкесендә, чыбык очы туганнарында көн күрде. Усаллыклары хәттин ашкан ир белән хатын бу ятимне бушка ашатып ятабыз дип, гомер һәр капкан кабымын санап тордылар. Авыл җире өчен шактый пенсия алалар иде үзләре сукыр гарипкә. Ләкин шул баланың бәбәкләрен түшәмгә терәп, көннәр буе өйдә утырганына шартлар чиккә җиттеләр ирле-хатынлы. Ниһаять, аждаһага тиң хуҗабикә шөгыль уйлап тапты мескен балага. Тау башында иде аларның өйләре. Сукыр малай тау астындагы чишмәдән су ташырга тиеш булды. Сыңар бидрә тотып, кулындагы таягы белән басар урынын кармалап, абына-сөртенә көннәр буе су ташый иде ул. Әллә кирәк булган ул су хуҗаларга, әллә юри мәҗбүр иткәннәр, ни булса да – коеп яңгыр яуса да, көрткә күмеп буран уласа да Җәмил һич туктамый тау төшеп, тау менә иде. Авыл халкы сабыйны жәлләп, хуҗаларны ипкә салырга тырышып карадылар. Аларның үз сүзләре сүз иде, төкереп тә бирмәделәр кемнеңдер үгетләренә. Кәбир шул тирәдәрәк туып-үскәнгә, авылга кайткан саен, су ташыган Җәмилгә юлыга иде. Кайткан саен малайга берәр күчтәнәч кыстырып кайтырга өйрәнде ул. Бидрәсен юлга куйдырып, күчтәнәчен тегенең кулына тоттыра, хәлләрен сораша иде. Ни гаҗәп, малай үзенең авыр хезмәтен гадәти бер хәл итеп тоя иде.

– Менә бүген тугызынчы чиләк менгезәм, – дигәндә, горурлык чаткылары чагылып кала иде сүзләрендә. – Ә өченче көн кирегә төшәргә туры килде. Яңгырдан соң иде бит, чатанлап китеп, тайдым да егылдым, ха-ха-ха... – дип көлә иде, мәрәкәгә алып. Малай атлаган адымнарын гел санап йөри иде. Якты дөньяда ни барын күрмәгәч, әллә бар кешеләр дә иртәдән кичкә кадәр су ташыйлар, яшәү шул була дип уйлагандыр, кем белә? Кәбир төрле сыйфатларда очраткалады аны һәм беркөнне никтер исенә төшереп, картинаны илһамланып өч сәгать эчендә язды. Чын-чынлап көчле картина иде ул. Йөрәкләрне тетрәтерлек, күңелләрдә мәрхәмәт, игелек, изге хисләр уятырлык. Язды даерактарак почмакка алып та куйды. Кемгә кирәк синең гарипне чагылдырган картинаң? Сатып алучы табылмаячак. Берәр кеше үзенең кыйммәтле җиһазлар белән шыплап тутырылган затлы фатирының стенасына күзләренең агы синең тарафка төбәлгән малайның рәсемен элеп куярга теләрме? Җәмгыятебез дә элек-электән зәгыйфьләрне юкка санады, аларны исәптән төшереп куйды. Без үзебез дә аларны ким затлар итеп күрәбез, йөз-фигыльләреннән чирканабыз, каршы очрый калсалар, читкә тайпылабыз. Ядкарь итеп алып карарга гына. Ул малай үткән елны әлеге чишмәгә төшеп, тончыгып үлгән, дип сөйләделәр Кәбиргә.

Шул ук почмактан бер кочак картиналарны алгарак тартып чыгарды да рәссам, үзе дә сизмәстән ыңгырашып куйды. Бу рәсемнәрдә «ню» стилендә язылган шәрә хатын-кыз сыннары иде.

* * *

Кәбир гомере буе «подкаблучник» булды. Өйләнүен соң гына өйләнде, әмма берәгәйле булды өйләнүе. Буйдак чакларында артык гүзәл затлар белән чабаланмады, дияргә була аның турыда. Үзе тудырган хыялый тормышта

яшәде ул. Беркатлылыгы белән бар кешеләргә яхшы, әйләнә-тирәдәгеләр аны яраталар, хөрмәт итәләр, ярдәмгә әзер торалар дип уйлый иде. Кызлар турында әйтәсе дә түгел, очраган берсе Кәбир белән тормыш юлын бергә үтәргә әзер кебек тоелды. Ул чакларын искә алса, хәзер дә исе китә аның. Яши-яши генә төшенә башлады: башкалар өчен ул шулкадәр дә көлкеле булып күренгәндер. Читләр тарафыннан сиңа карата иң яхшы бәя – битарафлык, бармы-юкмы син алар өчен. Моңа шатланырга кирәк. Әгәр күзләренә чалына калсаң, игътибар итсәләр, шунда ук сине иң соңгылар рәтенә кертәләр, адым саен кимчелегеңне эзлиләр, авыз күтәреп көләргә әзер торалар, ялгыш адым ясый калсаң, рәхәтлек кичерәләр. Сине түбәнсетеп, үзләренең яхшырак, акыллырак, остарак икәнлекләрен исбатларга бар көчләрен салалар. Тыштан караганда җан дус булып, очраганда елмаеп күрешеп, тел яздырып, хәлеңә кергәндәй күренеп, син артыңа борылуга, данынңны чәчәргә тотыналар, пычракка аунаталар, гайбәтеңне саталар. Бу аерым кешеләрнең яхшылыгыннан яисә начарлыгыннан тормый, бу – объектив күренеш, адәм заты шундый булып яралган. Моңа каршы көрәшәсе дә, үзгәртергә тырышасы да түгел. Әлмисактан бирле дәвам итә адәм балаларының бер-берсен дошман күрүе, ахырзаманга кадәр барачак та. Бары тик үз кабиләңнең кануннарын дөрес аңлап, яраклашырга өйрәнергә кирәк. Кайчандыр теленә ни килә, шуны сөйләп, очраган берсенә күңелен ачып, кайгысын да, шатлыгын да яшерми, һәрберсен туганы урынына күреп йөргән теге егет күпләрнең кәефен күтәргәндер ачыгавызлыгы белән, бихисап тел чарлауларга сәбәп булгандыр, тәгаен. Кызлар белән дә аралашулары кешечә булмады Кәбирнең. Аның җилбашлыгын, йомшаклыгын белеп алган хәйләкәр чибәркәйләр орчык урынына бөтерәләр иде Кәбирне үз йомышларын йомышлатып. Елмайган-көлгән булып, «Кәбирчик» тә «Кәбирчик», дип юмалап, билгеле артистларның концертларына билет эзләттеләр, сөйгәннәре белән аралары бозылып китсә, егет дипломат ролен үтәде, бәйрәмнәрдә ул җыен җыйды, әле тиң таба алмаган кызларга вакытлыча кавалер миссиясен үтәде. Юка башлы Кәбир кызларның кыланышларын кайнар хисләр чагылышы төсле кабул итте, башлары әйләнде үз шәхесенә шулкадәр игътибардан, кайсысына тукталырга белми газап чикте. Әмма бер-икесен озата барып, йомшак кына кире кагуларга очрады. Мондый чишелеш аны гаҗәпләндерде, әлбәттә. Аның өчен җанын бирергә әзер сыман, очраша калсаң, шатлыгы ташып бара, сөйләшеп сүзләр бетми, ал да гөл барысы. Ә нигәдер Кәбир туры килми икән аңа. Йә күптән ошатып йөргән егете бар, йә аның көткәне чак кына башкарак булырга тиеш, йә холыклары төрле, имеш, аларның.

– Дус кына булып калыйк, яме, Кәбирчик, ачуланма, – дип, ташны эретерлек тавышлары белән егетне юхаладылар. Дус булып калырга Кәбир риза иде, әмма кайчандыр ул да үз гаиләсен корырга тиештер бит, кызларның кайнар кочагы нindирәк икәнен белергә. Һәркемнең күрәчәге алдан язылып куела, диләр. Кәбиргә язган гүзәл зат янында гына йөргән икән лә.

Егерме алтысын тутырган ел иде. Сәнгать институтының кафедра җитәкчесе белән уртак эшкә алындылар алар. Эш гаять кызыклы иде, әмма күп вакыт сарыф итәргә туры килде. Ике айдан артык чиләнделәр. Иңгә иң терәп эшләгәч, әлбәттә, якынаеп киттеләр, аралашулары ешайды. Эштән соң кайчак юл буендагы кафега кереп утыргаладылар, төрле темаларга сөйләштеләр. Беркөнне кандидат аны үз өенә чакырды. Аны-моны уйламады Кәбир, чакырылган җиргә барырга гадәтләнгән иде ул. Бәлки, яңа танышы сый да чыгарыр дип өметләнеп, остазы артыннан иярде. Ямашев урамындагы күпкатлы өйләрнең берсе янында

төшеп калдылар алар, җиденче катка күтәрелделәр. Ишекне күз явын алырлык матур күлмәк киеп куйган, төзәнгән-бизәнгән яшьрәк бер хатын-кыз ачты. Эш киеменнән булган Кәбир каршында өлтерәп торды бу гүзәлкәй.

– Рәхим итегез... менә тапочки элегез аягыгызга... түрдән узыгыз... әнә йомшак кәнәфигә урнашыгыз, – дип сандугач булып сайрады. Мондый каршылауны көтмәгән Кәбиргә уңайсыз булып китте. Кигән киеме дә түрләрдә, йомшак кәнәфиләрдә утырырлык түгел иде. Ул бит аш бүлмәсе өстәле артында берәр нәрсә капкалап, бер-ике чәркә тотып хушлашырга ният итеп килгән иде. Шулай да күрсәтелгән урынга артын төртте. Бүлмәләргә тәмле тәгам исе таралган иде. Кандидат күрше бүлмәдә гаип булды. Шым калып, Кәбир, килеп эләккән өйне күз алдыннан кичерде: тезелеп торган җиһазларның зәвыклыгы, идән тутырып җәелгән палас, чисталык-пөхтәлек исен китәрде гомум ятакның тимер караватында аунаган егетнең. Зур өстәлгә крахмалга катырылган, күз чагылдырырлык япма ябылды. Теге хатын-кыз, оча-куна, бәллүр чәркәләр, көмеш чәнечке-калаклар, авыз суларын китерерлек сый-нигъмәтләр ташыды. Менә өстен-башын яхшыга алыштырган кандидат чыгып, Кәбирне өстәл артына чакырды. Гәүдәгә таза гына хатын моңа кадәр кухняда мәш килгән икән. Дүртәүләшеп табын артына утырдылар. Кандидат үзенең гаилә әгъзалары белән таныштыруны кирәк тапты.

– Минем хәләл җефетем Зөләйхә, ә монысы – кызыбыз Сабрина. Ә бу егет, кызлар, Кәбир исемле. Бик өметле художник, ерак китәр, абынып егылмаса, – дип шаяртып куйды. Өстәл артында ниләр сөйләшкәннәре бик исендә калмады Кәбирнең. Бу купшы хатыннар арасында бик киеренке тотты ул үзен: берара башын күтәреп карарга да уңайсызланып утырды; тамакка-фәлән валчык капланып, төчкереп җибәрмәсәм иде, дип коты очты; нечкә генә аяклы исәпсез савытларның берәрсен аударып җибәрүдән курыкты. Авызын үлчәп кенә ачып, вак-вак кабып, нәрсәләрдер чәйнәгән булды, тәмен дә, ямен дә сизмәде. Кафеда чакларда чәркәләрне ярыйсы гына йөгерткән кандидат өендә йотымлап кына утырган булды, хатын-кызлар ирен генә тидереп алдылар савытларына. Эчемлек кандала тәме килеп торган коньяк иде. Аны гомер хөрмәт итмәде Кәбир, эчәкләрне яндырып төшеп китә торган аракыга ни җитә. Булганын бер күтәреп каплаганда, азрак җан кертер иде дә, әмма башкалардан уздырырга яхшысынмады егет. Өстәл артыннан кузгалганда да, бердәнбер шешә яртылаш та кимемәгән иде. Озак утыргандай тоелды Кәбиргә, кысылып утырып, гәүдәсе оеп бетте. Ә өй хуҗалары үзләрен иркен тоттылар. Кәбиргә кибеттәге әйбергә караган төсле, текәлеп-текәлеп карадылар, һәр борылышын күзәттеләр. Күбрәк хуҗабикә сөйләде. Һәр әйткән сүзенә: «Шулай бит?» – дип, йә иреннән, йә кызыннан раслатып утырды. Тәфсилләп Кәбирдән сорау алдылар: кайда яши, ниләр эшли, кемнәре бар, акча яклары ничегрәк? Ниһаять, газапка тиң табын артыннан кузгалгач, егет иркен сулап куйды. Тагын бер сюрприз көткән икән алда. Ишек катында саубуллашкан чакта Сабрина:

– Үлеп китәм опера тыңларга. Ленинградныкылар килгән шәһәребезгә. «Нибелунги»ны куялар. Сезнең, Кәбир, күрәсегез килмиме бар дөньяга билгеле опера җырчыларын? Миндә артык билет бар иде, – диде, серле елмаеп.

Кызның әти-әнисе дә күтәреп алдылар. Кәбиргә ризалашудан башка чара калмады. Икенче көнне бердәнбер костюмын ипкә-сапка китереп, билгеләнгән вакытка ул опера һәм балет театры каршына барып басты. Өч сәгатьтән артыкка сузылган, немец телендә яңгыраган арияларны тыңлый-тыңлый гаҗиз булды ул. Моның урынына лом алып таш каерса, күпкә җиңелрәк булыр иде, валлаһи.

Берара янында хушбуй исләрен аңкытып утырган Сабрина да бик ихласлап тыңламаган төсле тоелып калды. Әмма шунда ук бу көфер уеннан кире кайтты. Ничек инде, шулай тыңларга ашкынып килгән кыз битараф булсын ди яраткан җырчыларына? Вакытлар үтү белән генә, Сабрина өчен опера сәнгате ике тиен бер акча икәненә төшенде Кәбир. Хатын-кыз хәйләкәрлегенең чираттагы чагылышы гына иде дөньякүләм танылган опера. Менә без дә төшеп калганнардан түгел, югары сәнгать белән кызыксынабыз, дигән ишарә иде.

Егет белән яшь хатын күпчелек араны җәяү атладылар. Сабрина башка таныш кызларга охшамаган төсле тоелды Кәбиргә. Егетнең һәр әйткән сүзе кызыксындырды аны, күзләрен аерып ала алмады Кәбирдән. Кат-кат аның уй-фикерләре белән кызыксынды. Аның акылына, холкына, үткерлегенә, тәвәккәллегенә шаклар катты, сүз саен соклануын белдерде. Кыскача үзе турында да сөйләп алды. Ниндидер адәм актыгына ышанып кияүгә барган да, анысы подлец булып чыккан. Аерылырга мәҗбүр булган. Ул ирдән өч яшьлек кызы бар икән, теге көнне балалар бакчасында булып калган кызыкай.

– Ял көнне таныштырырмын әле үзе белән, – дип вәгъдә итте Кәбиргә. Бәндәне коллыкка төшерү өчен арканнар белән бәйләп кую кирәкми, тасма тел белән дә бер адым читкә атламастай итеп әүрәтергә була икән аны. Әнә шулай Кәбир үзе теләп зур тәҗрибәсе булган Сабринаның тоткынына әйләнде. Көн саен очрашуларга сәбәпләр табылып кына торды. Кино-концертларны калдырмадылар, паркларда йөрделәр, кафеларда утырдылар. Сабрина егетнең һәр теләген үтәргә әзер иде, өстәл артларында:

– Менә бу винoны тәмләп кара, текила эчкәнең бар идеме? Бренди, виски, саке, ром – ир-ат эчемлекләре, – дип көчләп-көчләп сыйлады. Гадәттә, хатын-кызлар эчкән ир-атны якын китерми, ә Сабрина Кәбирне үзе эчерде. Түшәккә дә кыз сөйрәп дигәндәй яткырды тәҗрибәсез егетне. Ул яктан комплекслары юк иде аның. Көн аша кандидатның өендә кунак булдылар. Тагылышып йөри торгач, бердәнбер көнне Сабринага өйләнгәнен сизми дә калды Кәбир. Бабай тиешле кеше, Алмаз Шәфиевич, ресторан тулы кунаклар каршында яшьләргә алар ягыннан туй бүләге – ике бүлмәле фатир икәнен игълан итте. Кемгә эләккән ди әле бер көндә үзең өчен җанын бирергә әзер булган кәләшкә, ике бүлмәле фатирга тиенү? Дөрес, шуңа өстәп, кәләшнең өч яшьлек кызы да бар иде, әмма бала – тормышның чәчкәсе, алар шатлык өстенә шатлык кына өсти.

Алга китеп шуны әйтергә кирәк: Кәбирнең үз баласы булмады, кеше баласын үстереп аякка бастырырга язган икән аңа. Ширбәт ае шатлык эчендә үтте дияргә була. Өчәүләп диңгез буенда ял итеп кайттылар, яңа фатирны үзләренчә бизәп, вакыт үткәне сизелмәде. Тора-бара Кәбир сөекле хатынының, ясалма битлеген салып, бөтенләй башка фигыльгә керә барганын тойды. Беренче низаглар кемнең кем икәнен ачыклаудан башланды. Имеш тә, Кәбир гаилә тормышын бер кат күлмәк-ыштаннан башлаган, юньлегә кияр киеме дә булмаган, кесәсендә җилләр уйнаган, ыштыр хәерче була... Кыскасы, ярый ла изге күңелле Сабрина очраган икән юлына, адәм төсенә керткән аны, өстен бөтәйткән, фатирлы иткән, зыялы кешеләр арасына алып кергән. Шуңа да ирешкәннәре белән кемгә бурычлы икәнен яшь кияү бик яхшы белеп торырга тиеш икән. Хатынының табанын үбеп кенә торса да көн саен, таман гына буласы. Теге кьянти, ркацетели төслерәк шәраблар онытылды, табында булып, чәркәне бетереп капласа да, Сабрина талаш-ызгыш куптарды. Кәбир барып чыккан алкаш, имеш, дәваларга кирәк аны ябык хастаханәләргә салып. Бер тамагына хуҗа була алмаса, сары йортка озатырга вәгъдә итте сөекле кәләше.

Шуннан инде Кәбирнең һәр адымы ныклы контроль астына алынды. Нигә эштән ун минут соңлап кайткан, нинди җыелыш ул төнгә кадәр, ял көнендә өен ташлап кайда барырга җыена, бу эш өчен күпме түләделәр, яшереп калдырмаганмы? Өйдә чакта да тынгылык бирмәде Сабрина. Йә зур кабып ашавын килештермәде, йә кычкырып сөйләшүен ошатмады, анда утырма, монда утыр, кил, кит, дипләр зитына тиде. Өйдә булышмыйсың, дип, тавыш куптарды. Аның чәрелдек тавышын беразга ишетмәс өчен, савыт-саба да юды Кәбир, тузан да суыртты, бүлмәләрне дә сөрткәләде. Бабай тиешле кешенең дә карашы төптән үзгәрде кияүгә карата. Килеп-китеп йөргәндә, йөзеннән төче елмаю китмәгән булса, хәзер инде өстән карап, тавышын кайдандыр бөердән чыгарып сөйләшә торган булды. Һәрвакыт акыл сатты, кияүнең язган эшләрен тәнкыйтьләп бушамады.

– Дөнья базарында сорау белән кулланган, сатылырлык әйберләр җитештер. Аларга югары таләпләр юк. Беренче урынга гаиләне куй. Син акча табучы, – дип төрткәләп кенә торды. Ачылып китеп икәүдән-икәү генә сөйләшүләр онытылды. Хәзер инде Кәбир, бабай күзлегеннән, аның кызын, оныгын матди яктан тәэмин итүче иде. Җигелгән йөген тигез тартуына ирешү зарур. Һаман да көзге яныннан китә алмаган әбисе кияү белән бөтенләй сөйләшмәс булды. Берәр нәрсә әйтә калса да, теш арасыннан кысып кына чыгарды. Аның каршында Кәбир тупас деревенщина иде. Ни сөйләшә белми, ни кулыннан эш килми, ни төсе-башы юк, кайсы яктан карасаң да – бер имгәк. Бу гаиләдә исемнәрне куша беләләр иде. Үз кызларын «Сабрина», дисәләр, оныкларын, чамадан чыгып, «Клеопатра», дип атаганнар. Иркә, холыксыз кызыкай тач патшабикә иде барысы өчен. Картатасын, картыйсын, әнисен утлы табаларда биетеп төшерә иде җен кызы. Әлбәттә, Кәбиргә дә шул тәмуг ялкыныннан яралган бала каршында табынырга куштылар. Баштарак Кәбир каршы торырга булашып карады. Яхшылап, барысын уртага салып аңлашырга адым ясады, чыдар хәл калмаганда, тавышын күтәрде, атна буе авызына су алгандай, сөйләшми-эндәшми йөреп карады. Берсенең дә файдасы тимәде.

Соңыннан Кәбир яраклашырга өйрәнде. Теләмәсә дә – көлде, хаклы булса да – мин ялгышканмын, диде, Сабринасының бар әйткәннәрен җөпләп, теләкләрен үтәп кенә торды. Алай да яшәргә була икән, бераз җиңеләйгән төсле булды әле тормышы. Әмма күңелендә хатынына карата күралмау хисе артканнан-арта гына барды. Ни гаҗәп, иренең ефәк төсле була баруына чын-чынлап ышанды Сабрина, чираттагы җиңүе итеп кабул кылды. Тирә-яктагылар, таныш-белешләр, дус-ишләр, бабай белән әби дә хәтта аларны үрнәк гаиләгә санадылар. Нинди җан газаплары кичергәнен ир кеше үзе генә белә иде. Бер юрган астына яткач, яратмаган яртысын яраткан булып кыланулары җелеген суыра иде Кәбирнең.

Иркә кыз да буй җиткергәнче шактый канын эчте үги этисенең. Ярый әле кияүгә иртә чыкты, ире белән Петербургка барып төпләнделәр. Нәрсә бәйләп тота мине? Әллә барысын кырт өзеп, ташлап кына чыгып китимме бу ясалуы килмәгән нәрсәне? – дип укталганы булды. Әллә батырлыгы җитмәде, әллә артык өйрәнгән иде җитеш тормышка, әллә гадәтләрне үзгәртәсе килмәде, яңа тормыш башларга курыкты – тыелып калды. Яши бирде үз эченә бикләнеп. Еллар үткән саен, аралары суына барды. Тели белеп теләсәң, теләкләр тормышка аша, диләр. Еллар үтү белән, әкренләп Кәбир дә үз территориясен яулый барды. Акча эшләү сәбәбе белән, озаклап мастерскоенда бикләнеп ятты. Ялгызы булганда, күңеле урынына утыра иде ичмасам. Соңыннан, чиргә сылтап, аерым йокларга ирек

алды. Анысы да зур уңыш иде. Ниндидер бәйрәм алдыннан зур гауга кубып, ташка басылган гадәт буенча, бабайларга атна саен барулардан котылды. Бу вакытларда аның хатыны үз тормышы белән яши иде инде. Аңа ахирәтләре белән аралашу, уртак танышларның тормышы белән кызыксыну, кемнәрнеңдер сәгатьләр буе гайбәтен сату, кибетләрдә чокчыну, тәмле ашау, югары даирә ханымнары белән аралашу, телевизорга капланып утыру җитә иде. Әйтергә кирәк, соңгы араларда икесенең аралары тигезләнә төшкән кебек тә булды әле. Кайчандыр ут чәчеп торган Сабрина басыла төште, ир кисәгенә битараф була башлады. Әмма озакка сузылган «бәхетле» гаилә тормышы тәмам чирле ясады Кәбирне. Беренче чиратта, физик яктан сизелде бу киеренкелек, үз-үзен мәҗбүр итеп, мәхәббәт уеннары уйнарга тырышулары бушка үтмәде. Мимылдап торган хатын-кызлар да шәһвәтен уятмый башладылар, төз аякларга, калку күкрәкләргә кызыгып караулар бетте. Шул ук вакытта Кәбирнең күңелендә бар гүзәл затларга карата фәлсәфи нәфрәт туды. Күз алдында чыбаланган һәр итәк аңа тәмуг кисәве булып күренде. «Шерше ля фам – ищите женщину!» тәгъбирен үзенчә аңлый башлады. Бозыклыкның башында һәрвакыт хатын-кыз тора! Алар – гөнаһ җыелмасы! Үтерешүләр-суешулар – шулар аркасында, алдашу, икейөзлелек, хаинлык, тәкәбберлек, кимсетү, үз тиңеңне хурлау, зәһәрлек – шуларда! Тыштан караганда, күктән төшкән фәрештәдәй кыланып, көн эчендә кырык шайтан фигыленә керәләр, дөнья болгаталар, фетнә тудыралар. Мескен ирләрне бәйдәге эт урынына җитәкләп йөртәләр. Ярый да бер гаиләдә шашынган хатын-кыз булып, калганнары изгедән-изге булса. Юк бит, барысы бер калыптан сугылган, берсен хурлап, берсен зурларлык түгел. Җир шары сыкрый алар кылган гөнаһлар авырлыгыннан. Беркатлы ир халкы шуларга ярарга тырышып алдашуга, урлашуга, илләр масштабында сугышуга бара. Тик аларның күңеле булсын, энҗегә тиң күз яшьләре таммасын. Хатын-кызның күңелен күрү өчен, хисапсыз завод-фабрикалар эшләмәйлар, хушбуйлар, әллә нинди нәрсәләрдән (бала ятагындагы матдәләрдән, ир-ат җисеменнән, кит-акулаларның, тагын йөзләрчә төр хайваннарның тән өлешеннән) ясаган кремнар тегеләрнең нәфис тәннәренә сыларга исраф ителә. Шулар өчен хатынша ирләр мода артыннан мода тудыралар, ә күпме материал, тукыма, төрле ясалма тауарлар сарыф ителә киендерергә, шартын китереп чишендерергә – санап кына очына чыгарлык түгел. Бүген теләсә кайсы дәүләт икътисадының уннан тугыз өлеше нәзберек хатын-кызны канәгатьләндерергә сарыф ителә.

Бер уйлады шундыйрак юнәлештә Кәбир, ике уйлады, күңеленең кайсыдыр өлеше белән хаксызлыгын чамалый иде үзе. Әмма кеше акылы гаҗәеп корылган, ешрак кабатлана башласа, ак та кара булып күренә. Баш түбәсе астында яшеренгән нейроннарда ниндидер үзгәрешләр булды ахрысы, кып итеп торган ир-ат һәр очраган хатын-кызны җен урынына күрә башлады. Әмма үз тойгыларын йөгәнли дә, үзгәртә дә алмады. Менә әле дә төрле кыяфәттә булган хатын-кыз рәсемнәре ачуын кабартты аның. Бу рәсемнәрне ясаганда, натураларга очлы күзләре белән ничек ымсынып караганын, кичергән хисләреннән тәннәре кызышып чыкканын тойды ул. Ә бит кайчандыр үзе торган мольберт артында. Булды микәнни аның да кайнар чаклары?..

* * *

Кәбир йокларга әзерләнеп йөргәндә, телефон шалтырады. Газиз яртысы шалтырата, имеш, Самарадан. Тавышына күңелендә кузгалган хисләрне чыгармаска тырышып, ипле генә сөйләште ир, хәл-әхвәл сорашкан булды.

Сабринаның шалтыратуына сәбәп бар икән. Температурасы күтәрелеп, урын өстенә яткан.

– Бронхларга салкын тигән ахрысы. Өч-дүрт көнсез кайта алмам, – диде хатыны, хәлсез генә тавыш белән.

– Давай, яхшылап дәвалан. Монда барысы да тәртиптә, – диде көр тавыш белән Кәбир.

Вакыйгаларның бу борылышына шатланды гына ул. Озаграк кайтмый торса да риза иде. Ялгызына тынычрак булса да, барыбер кош баласы төсле бәргәләнә иде йөрәге күкрәк читлегендә. Юк иде тынгылык күңелендә, кайчан да булса уңай якка үзгәрер кичерешләр дип ышанмый башлаган иде инде. Карап торуга үз җаена тәгәри иде тормыш арбасы. Чыгырдан чыгарырлык кайгы-хәсрәт күзалланмады, чәчләрне йолыккаларлык авыр югалтуларга тарымады, булганыннан колак кагып, хәерче көненә калып, тормыш төбенә төшмәде яисә кичермәс гөнаһлар кылмады, дүрт саны төгәл, сау-сәламәт. Ниемә газаплый үз җанын, нәрсә тели, кая ашкына? Булганына шөкер итеп, киләчәккә өмет итеп, тыныч кына яшәп ятасы иде дә бит... Мендәргә башын салгач та, йоклап китә алмый, әнә шулай уңга-сулга бәргәләнде ул. Озак кына күзләрен шар ачып яткач, тәки торып йокы даруы эчте. Таңга таба төшләнеп уянып китте. Манма су булган иде өстенә кигән майкасы. Төше төш кебек идемени әле аның? Имеш тә, хатыны белән Кызылъяр болынына кымызлык җыярга килгәннәр алар. Икесе дә яшь, берсеннән-берсе чибәрләр. Сабринасы ниндидер өрфия ак күлмәк киеп куйган. Көннең матурлыгы шаккатырлык. Зәп-зәңгәр күктә болыт әсәре юк, һава чип-чиста, күрше авылның урамында йөргән кешеләрне төсмерләргә була хәтта. Сабрина, шәһәр баласы, җыярга да, ашарга да белми табигать нигъмәтен. Ә Кәбир аны нечкә биленнән алып җиргә ия, куе үләннәр арасыннан кымызлыклар күрсәтә. Тегесе шаркылдап көлеп, кечкенә куллары белән үләнгә үрелә, Кәбирнең колак яфрагын иреннәре белән кытыклап:

– Мин синеке – син минеке, җаным, – дип пышылдый. Шулчак кайдандыр усал этләр өере чабып килеп чыга, һау-һаулап өреп, боларга таба чабарга тотыналар. Котлары очкан яшьләр, җитәкләшеп, очы-кырые булмаган болын буйлап йөгерәләр. Берара хәле беткән Сабрина, кулын ычкындырып, үләннәр арасына ава.

– Калдырма мине, Кәби-ир. Якла, арала, зинһар, – дип кычкыра ул Кәбир артыннан. Каты чабып барган җиреннән Кәбир туктап кала. Кире борыласымы, әллә үз җанын саклап калсынмы?.. Шул төштә уянып китте ул.

Лычма су булган майкасын салып атып, тагын юрган астына чумды. Иртә иде әле, тәрәзә артында караңгылык та таралып өлгермәгән. Төшләрдә шулай инде ул, чынбарлыкта булмастай нәрсәләр күзаллана. Сабринасын кара син аның, өндә җәфалаганы җитмәгән, төшләренә кереп тинтерәтә. Гомер иренә фамилиясе белән, «Сәлимов» дип кенә эндәшкән хатыны авызыннан һичкайчан иркә сүзләр ишеткәне булмады бит. «Җаным», имеш, бәлки, башкаларга әйткәндер ул сүзне. Юк, ул яктан да шиге юк Кәбирнең, артык горур хатыны берәр ир-атка ошарга тырышып, якынаюга бармагандыр, болай да суык ул ир-ат нәселенә. Төштә Кәбир үзе дә Сабринасына сыланып кына торды лабаса. Тормышта булдымы икән андый минутлар? Бәлки, яшьрәк чакта, төрлечә булгандыр хатыны да, гел убырлы карчык кыяфәтендә сынланмагандыр ич. Әнә шулай инде ул, озак еллар бер кыек астында яшисең-яшисең дә, төшләрдә дә аерыла алмыйсың икән бер-береңнән. Кызык

мизгелдә өзелеп калды бит әле тарих, кире борылдымы ул хатынын аралап, әллә кул селтәп, юлын дәвам иттеме? Тормышта кабатлана калса бу вакыйга, нәрсә эшләр иде?.. Тәгаен, килер иде ярдәмгә, гомер иткән хатынына гына түгел, җиде ят өчен дә гомерен куркыныч астына куяр иде. Холкы-фигыле буенча ул бит яхшылыкка тартылган адәм заты. Үз уйларыннан үзе елмаеп, Кәбир, урыныннан торды: бүген эш көне. Юынып-киенеп, бер чынаяк чәй эчеп алды да ишек катына җиткәч туктап калды. Машина кабызасымы, әллә автобус тукталышына чыгып басаргамы? Шәһәр буйлап үз машинаңда йөрү – үзе бер мәшәкать. Иртәләрен пробкаларда нервыларың таушала, куяр урын эзләп вакытың үтә. Икенче яктан, шыплап тутырылган автобус салонында кысылып барулары да күңелле түгел. Иң соңгы минутта ишек төбендә торган тумбочка өстендәге машина ачкычларын эләктерде. Тышта җил чыккан икән, пыскаклап вак яңгыр яварга тотынган. Кара көздә шул инде: җил дә яңгыр, яңгыр да кар. Бу эшенә урнашканына ел да тулмаган иде әле Кәбирнең. Дөресен генә әйткәндә, артык өнәми дә иде яңа урынын. Зур бүлмәдә өстәл артында чыр-чу килгән редакция хезмәткәрләре, кереп-чыгып йөргән кешеләр, барысының мәңге кайдадыр, нидер эшләргә каударлану, ашыгулары, туктаусыз шалтыраган телефон аппаратлары, һәр адымының күзәтү астында булуы – чыгырыннан чыгара иде Кәбирне. Тынычлыкка өйрәнгән рәссам бар сәләтен салып эшли алмый иде мондый шартларда. Әмма эшләгән кадәресеннән җитәкчеләр канәгать булгач, артык хафаланмады. Тора-бара бер җае чыгар әле, дип йөри бирде. Бергә эшләгән коллегалары белән артык якынаеп китә алмады ул. Әллә табигый йомыклыгы комачаулады, әллә хезмәткәрләр үз итмәде, аралар җылынмады. Хәер, Кәбир үзе дә якынаерга атлыгып тормады, бу кабиләдә аның күңеле тартылырлык зат юк иде. Кемнең кем икәнлеген коллектив белән Яңа ел каршылаганда бераз чамалаган иде ул. Әле ул чакта яңа килгән кешегә караш икенчерәк иде, кызыксыну бар иде. Бәйрәм хөрмәтенә шактый кызып алгач, кемнәрнеңдер сөйләшәсе килеп китте Кәбир белән. Телләр ачыла бит ул хәрәм ризык авызга керсә. Сатып алынган кафеның гирляндалар белән бизәлгән ишегалдында тәмәке төтене суырганда, бер хезмәткәр килеп җилкәсеннән какты.

– Бергә-бергә эшләргә язсын, кулың оста синең, – дип сүз башлады. – Бәйрәмдә икеләтә шатлык минем өчен. Тәки басыла ел башында яңа романым. Төгәл ике ел чиләндем шуның белән. Күпме күз нурларымны түктем, вакытымны салдым, тазалыгымны бетердем. Җәй көне больницага эләктем, «прединфарктное состояние» диделәр. Чак аякка бастым. Сезгә – художникларга рәхәтрәк, өч-дүрт сәгать пумала селтисез дә – картинагыз әзер. Хаклары да күңел шатландырырлык. Ә монда хәреф чүпләп чекерәеп утырасың, кәгазь бәясен капларлык кына гонорары. Әле шуны да бастырмас өчен аяк терәп карыштылар. Фәлән-төгән, имеш, суы артык, геройлар җитәрлек дәрәҗәдә эшләнмәгән, теле аксый. Үзем дә беләм мин аларын. Ифрат авыр эш бит ул. Язасың, язасың дәфтәрләр тутырып, әллә һәр язган сүзең мәрҗәннән коела, бар битләре талантлы була дип уйлыйсыңмы? Теләсә кайсы язу-сызу белән булашкан кешедән сора, очрый барысының уңышсыз урыннары, күңеле кабул итмәгән бүлекләре. Язган кадәресен юкка чыгарып, чүплеккә атып булмый бит кульъязманы. Тешеңне кысып дәвам итәсең, бер көн килеп соңгы җөмләгә нокта куярга талпынасың. Язылып беткәч, әлбәттә, шомартырга көч саласың кытыршы урыннарын, тик барысы да син дигәнчә булмый. Бассыннар, күпләргә таныш исемем бар минем, билгеле урыным бар әдәбиятта. Ичмасам,

уч тутырып акча бирсәләр икән. Хәерче акчалары өчен шедевр таләп итәләр. Алай булмый ул, иптәш...

Кайсысыдыр җырчылар янына чыгып, үз шигырьләрен дә укып булашты әле. Бик үк мәгънәсен аңлап җитә алмады Кәбир, гел мәхәббәт хакында иде ахрысы тормыш көзенә кергән ханымның гөлләмәләре. Ир уртасы берәү, ялланган тамаданы уздырып, мәзәкләр сөйләде, коллективның күңелен күтәрергә тиресеннән чыгардай булып тырмашты. Кайбер тарихлар көлкеле генә яңгырады кебек. Шул журналда эшләгәч, Кәбир һәр санын караштырып бара иде журналның. Әлеге көлке капчыгының язмаларына да юлыкканы булды. Шома гына тел белән язылган кызыклы вакыйгалар бәян ителә иде язмаларда. Әмма бу анекдотлар һәм әдәбият арасында нинди уртаклык барын һич төшенә алмады яңа хезмәткәр. Эш эш белән, ләкин һәр яңа көн яңалыклар бүлешүдән башлана иде коллективта. Алларындагы материалларны эшкәрткәндә, бер-берсе белән гәп куертырга да форсат табалар иде барысы. Бу сөйләшүләрнең ирексез шаһиты булган Кәбир колак салырга мәҗбүр иде сөйләшүләргә. Хатын-кызлар, гадәттә, дөнья мәшәкатьләренә күбрәк игътибар бүлә: кемгә кем килгән, баласы мәктәптән нинди билгеләр төяп кайткан, тәртип бозганмы, мактанырлык гамәл кылганмы, нәрсә пешергәннәр, онын-тозын күпме салганнар – энәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыгалар. Гадәт буенча, ирләрен телгә алалар, анысы ни майтарган, ничек караган, иркә сүзләр әйткәнме, тавыш башлаганмы... Кием мәсьәләсенә юлыксалар, анысы инде сәгатьләргә сузыла. Телевизордагы бар сериалларны чутлыйлар, геройларның биографияләрен яттан беләләр, алда булачагын фаразлап бәхәскә керәләр.

Бүген исә ир-атлар тавышы өстенлек итте. Дөньядагы яңалыкларны уртаклашып, сәясәтчеләрнең тетмәсен теттеләр, сугыш хәрәкәтләренә үз карашларын белдерделәр. Бер төркем, кызып-кызып, Украина милләтчеләрен черетеп түкте. Һәркемнең үз карашы, адәм баласы җәмгыятьтә барган үзгәрешләрдән читтә кала алмый. Болар – һәр шәхеснең бер өлеше. Әмма Кәбир өчен бу бәхәсләр күтәрә алмаслык сынау булды. Түзеп-түзеп утыра алмагач, ул редактор урынбасарына барып, китәргә рөхсәт сорады. Теге сәбәпләрен дә сорашып тормады, рәхмәт төшкере, рөхсәт бирде. Саф һавага чыккач кына, күз аллары ячтырып киткәндәй булды Кәбирнең.

Яңгыр туктаган иде, шулай да кара болытлар куера иде әле баш өстендә. Ашыгып-ашыгып, машинасына таба атлады ул, юлда кискен мизгелләр тудырып, бетереп газ педаленә басты. Өе янына килеп туктагач кына уянып киткәндәй булды. Кая чаба болай – күзенә ак-кара күренми? Кем көтеп тора аны, кая ашкына? Буш фатирга кереп, почмактан почмакка бәргәләнсенме яисә телевизор экранына кадалсынмы? Авызларын әчеттереп, сигарет артыннан сигарет кабызды, берәр төпле карарга килә алмый интекте. Өйдә табак-савыт шалтыратканчы, берәр урынга барып тамак туйдырырга булды. Өйлә җитмәгәнгәдер, кафеның залы ярым буш иде. Тәрәзә кырындагы читлекләрдә төрле-төрле кошлар чыркылдый, аквариумнарда симез балыклар зур күзләре белән сине күзәтә. Тәкъдим иткән ризыклары да ярыйсы иде. Бераз язылып чыкты бу ноктадан Кәбир. Бер максатсыз тротуар буйлап атлады ул, очраган кешеләргә караш салды, тирә-яктагы корылмаларга күз йөгертте. Бу халәттә эзәрлекләгән уйлары басыла төшкәндәй булды, йөрәк тибеше тигезләнде. Бераз кәефен күтәрергә теләп, «Чәчәкләр» дип язылган киоскка сугыласы итте. Урта яшьләрдәге ике хатын-кыз, чәчәкләр арасына

күмелеп, букетлар тезә иде. Кәбир кергәнне күргәч, берсе прилавка артына чыгып басты. Безнең сатучылар аерым балчыктан ясалганнар ахрысы. Сиңа алар сөмсерләрен коеп, үзләренең дошманына караган төсле карыйлар. Бу сатучы да авыз ачып сүз әйтми, Кәбирнең беренче сүз башлаганын көтеп тора иде.

– Сездә роза чәчкәләре бармы? – дип сорады Кәбир, мөмкин кадәр мөлаемрәк күренергә тырышып.

– Бар. Бер данәсе алтмыш сум, – диде сатучы, кымшанмый да. «Менә, рәхим итегез, ошаганын сайлагыз, сезнең өчен генә берсен алтмыш сумга төшерергә ризабыз», – дисә, эреп китәр идең дә соң...

– Ә сезгә нинди төс ошый төшә? – дип ныкышты Кәбир.

– Анысы нәрсәгә тагы? Сез алырга уйлыйсызмы? – дип, тавышын күтәрә төште сатучы. Чәчәкләр арасында утырганы, көлеп:

– Серо-буро-малиновый, – дип җаваплады.

– Ярый, ике ак төстәге роза бирегез миңа.

Чәчәкләрне алып, акча түләгәч, Кәбир хатыннарга берәр чәчәк сузды.

– Бүген минем шатлыклы көнем. Шатлыгымны сезнең белән дә уртаклашып, сезгә чәчәкләр бүләк итәсем килә.

Аптырап калган хатыннарның йөзе әллә нинди кыяфәтләргә кереп бетте. Елмаеп урам буйлап атлаганда, аларны кабат-кабат күзаллап, рәхәт кичерде Кәбир. Әлбәттә, хатыннар ул чәчәкләрне аның артыннан кергән клиентка сатып җибәрәчәкләр, акча – беренче урында. Ләкин чәчәк алганда кичергән тойгылары да баштан ашкан, әллә моңа кадәр чәчәк бүләк иткәннәр аларга, әллә юк. Тагын яңгыр сибәли башлагач, экспресс-барга кереп яшеренде. Стойка артындагы, урысчалап әйткәндә, вышколенный егет сүзсез генә аның алдына чәркә белән эчемлек, лимон кисәге куйды. Магнитофон тасмасыннан Эдита Пиафның сагышлы тавышы яңгырый иде. «Әллә исергәнче эчәргәме?» дигән уй килде башына Кәбирнең. Аракыны ничек кенә хурламасыннар, аның бер уңай ягы бар – бәндәгә онытылырга ярдәм итә ул. Тынычлап йоклар идем саташулы төшләр күрми, баш күзәнәкләре хәл алыр иде кыска вакытка булса да, дип, һаман үгетләргә тырышты нәфесен. Шунда таныш шагыйренең юллары исенә төште.

> Эч, диделәр, көчләп-көчләп эчерделәр...
> Дөнья яктырып киткәндәй булды.
> Икенче көн булган хәсрәтләрем
> Икеләтә артып тынны буды.

Озакка бармый шул шаукымы хәмернең, бераз җилкетеп ала да эреп югала. Йөри-йөри тәмам аяклары талгач, күптән булмаган музей ишеген ачып керде. Тантаналы тынлык хөкем иткән залларда ул, шым гына басып, экспонатлар сакланган киштәләр буйлап китте. Менә йөзләрчә мең еллар элек җирне таптаган нindидер динозавр, ихтиозаврларның кочак җитмәс сөякләре. Бер кеше генә күтәрә алмас моны, шулай дәү, коточкыч. Чынлап та булдылар микәнни алар җирдә, акыл җитмәс вакыт үлчәме аерганмы аларны? Безгә, адәм баласына, андый төшенчәләр ят. Без үз казаныбызда гына кайныйбыз. Күзаллаган чорыбыз да – туу белән үлем арасы. Уйлап китсәң, бар бит ниндидер бәйлелек менә монда танау тартып басып торган Кәбир белән җир тетрәтеп йөргән таудай җанварлар арасында. Ниләр булып, ниләр юкка чыкмаган бу

чал тарихта?! Таш диварларга арка терәп, кяферләргә каршы торган татарлар арасында берәрсе кайчандыр дөньяга аваз салачак Кәбирнең дә хромосомасын үзендә йөрткәндер. Дошман угыннан йә булмаса ерткыч җанварлар һөҗүменнән һәлак булган ерак бабасы чамалаганмы икән киләчәкне? Менә шул тереклекнең бүгенге көнгә кадәр саклануы юкка гына түгелдер бит. Йөзәр еллар элек яшәгән кешеләр җан сакларга тырышканнар, яратышканнар, җан кыйганнар, шулай да безнең көнгә кадәр эзләре сакланып калган. Нинди осталык белән ясалган менә бу көбә күлмәк. Кемдер акылын җиккән, күңелен салган моны эшләр өчен. Оста үзе күптән балчыкка әйләнгәндер, ә менә аның кул җылысы күчкән комарткы гасырлар аша узып килеп җиткән. Кеше үз эзен калдырырга тиеш фани дөньяда. Нәсел дәвамын, сәнгать әсәрләрен. Сокландырырлык биналар, таң калдырырлык картиналар. Мәсәлән, Кол Гали чорында яшәгәннәр арасында байлыкларына мактанган каруннар, тиран хөкемдарлар, ярты Җир шарын буйсындырган җиһангирлар яшәгәндер, тәгаен. Алар хакында кем хәтерли? Тарихны җентекләп өйрәнгән галим-голамәләр белсә беләдер. Ә менә шагыйрьнең җан тетрәтерлек әсәре бүген дә халык телендә. Украина, дибез бүген, Америка, Польша, дип искә алабыз. Бәлки, ике-өч гасырдан соң җуелыр халык хәтереннән бу атамалар. Бүгенге көннең уй-кайгылары сакланып калмаячак, монысы – факт. Вак-төяккә чәчелеп, тамак кайгыртып, нәфес колы булып яшәү, чын мәгънәсендә, яшәү түгел. Чал тарих синнән тамагың тукмы, өстең бөтенме, күңелең тынычмы, дип сорамый. Бөек Рембрандтның «Төнге каравыл» картинасыннан соң кичергән газаплары сирәкләргә мәгълүм. Леонардо да Винчиның да шәхси тормышы кызыксындырмый, ә «Мона Лиза»сы күз яшьләрен китерә, таң калдыра. Әлбәттә, адәм балалары бу хакта уйлап та карамыйлар, аларга бүгенге көн кыйммәт. Ничек кенә боргаласаң да, җәмгыять күндәм сарык көтүенә тиң. Әйтсәләр – ышана, кусалар – китә, чакырсалар – бара, куркытсалар – тынын да исәпләп ала. Көчле шәхес көтүгә кушылган сарык булырга тиеш түгел. Аның үз юлы, үз инанулары, үз фәлсәфәсе. Күпчелек һәрвакыт битараф, уртак фон ролен генә уйный. Сирәкләр, төркем өстеннән күтәрелеп, үз сукмакларын яра. Әнә шул сайлап алынганнар әйләндерәләр Җир шарының күчәрен. «Мин дә монда булдым», – дип култамганы гына калдырып китәргә килгән булсаң, әйдә, аларның кануннарын кабул ит, алар кубызына бие, алар җырлаган җырларны җырла. Теге һәвәскәр шагыйрьнең мондый юллары да бар иде:

Әлегә мин сезнең арагызда,
Җигелгәнмен сезнең арбагызга...
Ләкин
Сез йөрегән юллар миңа тар.
Мин бит әкияттән,
Мин – тулпар!..

Шагыйрь кеше ни әкият иленә тартылгандыр инде. Әмма тарих җирдә языла, аның битләрен көчле шәхесләр яза...

– Сезгә начар булып киттеме әллә? – дигән тавышка дерт итте Кәбир. Очып китәрдәй, юка гына карчык, иңендәге шәлен тота төшеп, аңа таба иелгән иде. Кәбир, аяклары талгач, бер сырлы урындык янында хәл алырга тукталган иде. Йөгерек уйларына чумып, онытылып киткән икән. Үзен гаепле сизеп, сикереп торды ул, күзлекле карчыктан кат-кат гафу үтенде. Экспонатларга кул белән дә кагылырга ярамый, ә ул җәелгән йомшак кәнәфигә. Әллә монда кайчандыр Һади Атласи яисә Гафур Колахмәтов утырган булгандыр?

– Зарар юк, – диде теге карчык, – барыбер күргән кеше юк, утырыгыз иркенләп. Мин хәлегез начарланып киткәнме әллә дип торам? Күптәннән бирле кымшанмыйсыз да.

Йөреп-йөреп арган-талган иде Кәбир. Тукталышка чыгып, үз маршрутына утырды. Син үзгәртә торган дөньямы? Кайчандыр Тютчев бик тә акыллы киңәш әйткән:

Не рассуждай, не хлопочи!
Безумство ищет, глупость судит;
Дневные раны сном лечи,
А завтра быть чему, то будет.

Акыллы шагыйрьнең киңәшен тотып, Кәбир көпә-көндез саташулы йокыда онытылды.

* * *

Кесә телефоны шалтыравы уятты аны. Йокы аралаш янындагы аппаратны кармалап, күзләрен ачмый гына колагына терәде.

– Әйе, – диде карлыкканрак тавыш белән. Линиянең икенче очында дусты Фатихның тавышы ишетелде.

– Кәбир дускай, син тиз генә минем янга килеп җитә алмассыңмы икән? – дип кычкырды иптәше трубкага. Тавышы танымаслык булып үзгәргән иде аның, нидәндер бик каты курыккан иде булса кирәк. Кырык төрле уй үтте Кәбирнең башыннан, йокысы сыпырып алгандай юкка чыкты.

– Нәрсә, юл бастылармы әллә? – дип сорады, кулын күлмәгенең җиңенә туры китерә алмый азапланып.

– Алай гына булса... Кеше таптаттым мин, Кәбир.

Бу сүзләрне ишеткәч, киенүеннән туктап калды, трубканы чытырдатып кысып, сорашырга тотынды.

– Тереме, үлгәнме? Кайда булды? Төгәл адресыңны әйт, хәзер килеп җитәм. Калганын урында хәл итәрбез...

Ярый әле Фатих дусты әйткән урам якында гына иде. Кәбир барып җиткәндә, мәхшәр иде ул урында. Кешеләр төркеме җыелган, Фатихны полиция машинасы эченә кертеп утырткаННар, колакларын плеер наушниклары белән томалаган яшүсмернең гәүдәсе тротуарга күчерелгән иде. Хокук сакчыларының берсе төркем арасындагы шаһитларның җавапларын блокнотына терки иде.

– Үзе барып керде машина астына, – дип, барысын уздырып сөйләп китте Чапай мыеклы бер ир. – Хәзерге яшьләр уңга-сулга карап тормый алар. Барган җиреннән кырт юлга борылды, аша чыгарга уйлагандыр. Мин какраз артыннан килә идем. Чукынып, күрәчәген эзли, дип уйлап кына өлгердем. И шулай булып чыкты да. Бу иптәш машинасын туктатып өлгерә алмады. И очып кына китте теге шалапай, бамперга бәрелгәч. Һавада әйләнеп чыкты, валлаһи. Асфальтка каты төшкәндер инде. Хәзерге яшьләр алар...

– Шофёрлар да күз тондырып чабалар, – дип каршы төште анысына таякка таянган карт. – Светофор яшелне янганда да, өстеңә менеп баралар. Өлгерсәң өлгереп кал, өлгермәсәң тәпәләп узарга да күп сорап тормыйлар. Эчкән булгандыр әле, көпә-көндез кеше кадәр кешене күрмәскә. Җәяү йөрергә хут калмады бөтенләй, дөньяны машина басты. Маңка малае да машинада җилдерә, ә дукаменты сатып алынган. Байлыкларына чыдаша алмыйлар. Бер-бер чара күрергә кирәк үзләренә. Менә бу хакта мин хөкүмәткә язарга уйлыйм: бер

көндә соңгы саны так булганнар йөрсеннәр, икенче көнне җөп санлыларына рөхсәт бирергә. Бераз һава чистарыр иде.

– Тәк, иптәшләр, әйдәгез, бу авариягә кагылышлы детальләрне генә күрсәтик. Вакыт чикләнгән, – дип тәртип урнаштырырга тырышты хокук сакчысы. Кәбир полиция машинасы кырына килеп тәрәзәдән күз салды. Анда бер лейтенант ашыгып бланклар тутыра иде. Киндердәй агарып калган Фатих дустына карап баш селекте, сүрән генә елмайгандай итте. Күзләренең нуры качкан иде үзенең.

Теге лейтенант, Кәбирне шәйләп алып, тәрәзә пыяласын төшергәндәй итте дә:

– Гражданин, не мешайте работать! – дип кисәтү ясады. Ачы кычкыртып, «Ашыгыч ярдәм» машинасы килеп туктады. Таза-таза санитар егетләр чыгып, мәетне носилкага салдылар. Яшүсмернең кем икәнлеге ачыкланмаган иде әле. Халык төркеме дә тарала төште. Хокук сакчылары юлны ябып, рулеткалар белән ниләрдер үлчәргә, схемалар сызгаларга тотындылар. Фатих та машинадан чыгып басты. Кәбир, кара янып чыккан дусты янына килеп, фаҗиганең ничек булганын сорашты.

– Сизми дә калдым, – дип акланды Фатих, – әкрен генә бара идем. Бу вакытта артык хәрәкәт булмый ич. Көтмәгәндә юлга килеп чыкты малай. Монда переход-фәлән дә юк, ни уйлап борылгандыр. Мин аны күрүгә, әлбәттә, бетергәнче тормозга бастым. Әмма... Ну сиңа гына әйткәндә, мизгел арасы югалып калдым анысы. Көтмәгәндә бит... Исән-сау котылсам, сатам машинаны. Автобуска утырып йөрүгә ни җитә. Карыйсы-җайлыйсы түгел, керәсең дә утырасың. Кирәкле урында төшеп, ике кулыңны селтәп китәсең дә барасың. Төнлә ишегеен ачмыйлармы, аккумуляторын салдырмыйлармы дип кайгырасы түгел. Әле кредиты да түләнеп бетмәгән дә соң. Нигә кирәк иде миңа ул машина?.. – дип, башына тотынды дусты. – Тыныч тормышым челпәрәмә килде шуны алу белән. Утыртып куярлармы икән инде? – дип, Кәбиргә карады ул.

– Әгәр гаепле тапмасалар, акча түләп кенә котылырсың. Сиңа бик яхшы адвокат ялларга кирәк, акчасыннан торма. Ата-анасы кемдер әле, анысы да мөһим.

– Вәт бәхетсез баш, кайдан килеп тарыдым бу бәлагә? Нигә кирәк иде миңа машина? Хатын сүзен тыңлап кем уңган? Белми дә әле үзе бу турыда, – дип такмаклады Фатих. Шактый озак юанганнан соң, хокук сакчылары гаепләнүчене полиция бүлегенә алып киттеләр. Кәбир дә алар артыннан калмады, дустын ташлап китә алмый иде ул. Мигалкалар яндырып чапкан машинадан калмаска тырышып, эченнән генә аты-юлы белән дустын сүкте. Яше кырыктан узгач, руль артына утырган кеше барыбер шома йөртергә өйрәнә алмый, күңелендә курку хисе сакланып кала. Фатих та рәтләп өйрәнеп китә алмады. Туктаса, урнаштыра алмый азапланды машинасын, кузгалса, калтырап кына йөрде. Күрер күз белән чамалаганда да, таба кебек ялтырап яткан юлда үсмерне алдан шәйләп, тукталып кала алыр иде оста шофёр. Бу өйрәнчек куркып калып, соңрак баскан инде тормозга. Ярый да аның файдасына булса хөкем карары. Ә бит кеше гомере өзелгән бер юктан... Полиция бүлегендә кичкә кадәр исәңгерәттеләр әле Фатихны. Коридор буйлап йөри-йөри, тәмам кешелектән чыкты Кәбир дә. Авыз ачып сүз әйтерлек хәле калмаган, ярты картайган дустын, үз машинасына утыртып, фатирына илтеп куйды. Фатихның елый-елый шешенеп беткән хатыны, ишек ачылуга очып чыгып, йодрыклары белән иренең күкрәген төяргә тотынды.

– Нәрсә эшләдең син, җирбит? Кеше башына җиттеңме инде, адәм актыгы? Азынуның чигенә чыктыңмы? – дип шар елап сөйләнде үзе. Ишек янгагында коты очкан бөдрә чәчле кызыкайның башы күренде. Артыгын күтәрә алмады Кәбир, тизрәк китү ягын карады. Үз өе янына килеп туктагач, икеләнеп тормады, күршедәге гастрономга юнәлде. Хәзер алып кереп бирәр стакан каплый да бу каһәрле тормыштан беразга булса да югалып тора. Әмма ялгызың чәркә күтәрү күңелле шөгыль түгел. Сәгатеңә карап, кайчан дәвасы урынына барып җитә дип өметләнү – күңел кайтаргыч күренеш. Борылып чыгып, тирә-якка музыкасы яңгырап торган кафега юл тотты. Кафе яшьләр белән шыгрым тулы иде. Стена буендагы ике-өч өстәлдә буш урын күренмәде. Ярым ялангач кызлар, карачкыдай киенгән егетләр, төрле кыяфәтләргә кереп, шашынып бииләр иде. Кәбир, стойка артына тукталып, эчемлеккә заказ бирде. Адрес буенча кермәгән икән, монда сүз кушарлык кеше тапмассың. Үҗәтләнеп, чәркә артыннан чәркә бушатты ул. Бармен егет тә моны сизде.

– Проблемагыз бармы? – диде ул, чираттагы савытны Кәбиргә шудырып.

– Авария... – диде Кәбир, бер сүз белән генә.

– Аңлыйм хәлегезне, үземнең баштан үткән, – дип кушылып китте теге. – Өр-яңа «Логан» коймак булды. Аны ремонтлыйм дип күпме акча чыгардым, чутлап беткесез.

Кәбир бу очракта сүз машина хакында түгел икәнен ачыклап тормады. Ачыклаган хәлдә дә бу ишеләргә машина кеше гомереннән кыйммәтрәк икәне көн кебек ачык иде. Янындагы тумбага килеп утырган егет игътибарын җәлеп итте аның. Киеп куйган футболкасы аша да тимер мускуллары ташып чыгып килә иде егетнең, муен-фәләне бөтенләй юк төсле.

– Әйдә берәрне минем исәптән, – диде аңа Кәбир, аралашасы килеп.

– Юк, – дип, утыз ике тешен күрсәтеп елмайды алып, – мин сөт эчәм. Йә менә апельсин согы. Эчмим, тартмыйм, кызлар белән дә онытканда бер аралашам.

– Кайдан шулкадәр мускуллар синдә? – диде Кәбир, соклануын яшерә алмыйча. Егет, ирәеп китеп, беләкләрен уйнатып куйды, канәгать елмайды.

– Качок мин, көннәр буе тимер күтәрәм, ничә тонналар җыела. Анаболикларны да куллангалыйм. Мускуллар массасын белеп үстерергә кирәк.

– Ә нигә? – диде гаҗиз калган Кәбир.

– Ә бу минем тормышымның фишкасы. Кемдер аракы чөмерә, кемдер кызлар артыннан чаба. Мин мускуллар үстерәм. Менә сез дә бер күрүгә игътибар иттегез. Башкалар да соклана, хатын-кызлар күзләрен ала алмый. Үз тиңнәремнән аерылып тору миңа наркотик төсле тәэсир итә. Шәп нәрсә ул һәр баскан адымыңны санасалар, мөкиббән китсәләр. Миңа, мәсәлән, ошый.

– Ә болай нәрсә белән шөгыльләнәсең? Кәсебең бармы, эшлисеңме? – дип төпченде Кәбир, төбенә тоз коярга теләп.

– Фитнес клубта культуролог исәпләнәм. Алда күз күрер, тагын торсларны арттыру өстендә эшлисе бар әле...

Алып батырга тиң егет залга кереп китте, Кәбир хәйран калып чәркәсенә үрелде. Болай тору эчен пошырды аның, ни эчкән аракысы башына бәрмәде. Исәп-хисап үткәреп, төнге караңгылыкка атлады.

Яктылыктан ике-өч адым читкә атлап өлгермәде, куаклар янында торган берсе:

– Абзый, тартырга булмасмы? – дип туктатты. Бәйләнүләр, гадәттә, шул

сүздән башлана. Башта тартырга сораган булалар, аннан ипи шүрлегеңә менеп төшәләр, кесәләреңне бушаталар. Бу карачкы да шулар исәбеннәнме икән дип уйлап куйды Кәбир, әмма кесәсеннән пачка чыгарып тегеңә сузды.

– Рәхмәт инде, абый, ярты көн тарткан юк иде. Өйрәнелгән шул нәрсәгә, – дип тәмәке кабызды теге. Шырпы яктысында аның култык таякларына таянып торган яшь кенә ир икәне төсмерләнде. Кәбир дә иптәшкә авызына тәмәке капты.

– Нәрсә, тәмәкелек тә акча калмадымыни? – дип, юри төртмә эндәште ул. Тагын күңеле кайный башлаган иде аның бүген күргәннәрдән. Теге егет ачуланырга уйламады да, киресенчә, ризалашып кат-кат башын какты.

– Тартырга гына түгел, ашарга валчык та калмады өйдә.

Менә, тормышка аяк басып өлгермәгән, алкашлар исемлегенә язылган. Аягы берәү генә булганга, тигезлек саклап кала алмагандыр. Берәр хәрби бәрелештә югалткандыр инде йә минага шартлагандыр. Миналарны шулай җитештерәләр, диләр, гомерне кыймасын, гарип ясасын. Әйдә, хөкүмәт расходлар чыгарып туйдырсын аны үлгәнче. Кайсы акыллысының башына килгән икән мондый мәкерле уй? Еш күрергә була хәзер урамда аяксыз-кулсыз яшьләрне. Хәер, бәрелешләре дә чутсыз булып тора бит.

– Эчәсеңдер? – диде турыдан Кәбир.

– Бар андый гөнаһ, – диде егет, төтен пошкытып. – Ничек эчмисең? Хатын малайны алып ташлап чыгып китте. Ятам ялгыз күке булып бүлмәмдә...

– Чечняда булдыңмы? – дип сорады Кәбир, төпчеген куаклыкларга чиерттереп.

– Юк, мин Плесецкида хезмәт иттем. Ә аякны юләрлек белән заводта югалттым. Авылдан килдек без. Эш юк авылда, өйләнештек тә шәһәргә юлландык хатын белән. Мине заводка алдылар. Хатын яслегә тәрбияче булып урнашты. Ул педучилище бетергән. Бар ягы яхшы шәһәрнең, торыр урын табулары үлем. Бер фатир табып, яши башладык. Беребезнең зарплатасы шул эт оясы кебек нәрсәгә түләргә китеп тора. Аякны өздергәч, завод шунда ук фатир бирде. Әнә теге ятакханәдә малосемейка.

Егет, култык таягы аша кулын сузып, тезелеп киткән күпкатлы йортларга таба ымлады. Үз сиксәне сиксән булса да, Кәбир авызына бер кабым ризык кермәгән мескенне ташлап китә алмады. Кулына акча тоттырсаң, хәзер эчемлеккә әйләндерә инде бу. Иртәгә тагын чыгып баса юл чатына.

– Әйдә әле, әнә теге кибеткә кереп чыгыйк, – дип, егетне үз артыннан ияртте. – Исемең кем синең?

– Габдулла. Урыслар Гаврош дип йөртәләр, ачулары чыкса, Гадик дип тә җиффәрәләр шунда. Ну мин күнеккән...

Кибеттән ике пакет шыплап тутырып, ашамлыклар җыйды Кәбир: ярмалар, токмачлар, көнбагыш мае, консервалар, икмәк...

– Менә, атнага җитәрлек ризык булды сиңа монда. Пенсияңә кадәр суза алырсың.

– Ну рәхмәт, абый. Үз татарың хәлгә керә барыбер. Ә күпләр авыз күтәреп көләргә генә торалар. Бүген үк консервадан аш пешереп ашыйм әле мин. Тирләгәнче шулпа чөмерәм. Ятыр корсак ятыр, ярты икмәкне тартыр, диләр бит...

Кассага акча түләгәч, тагын икеләнеп калды Кәбир. Бу кадәр әйберләрне гарип бәндә ничек йөкләп кайтыр?

– Берәр ничек җайлашам мин, абый. Куллар көчле минем, гел гәүдәне

күтәреп йөреп. Болай да ярдәмегез чутсыз булды, – дип, егет озатуга карышып булашты. Аның сүзләренә карамый, Кәбир алдан төште. Тротуар асфальтына тык-тык таякларын бәреп, егет арттан титаклады.

– Ә хатының нигә ташлап китте? Эчкәнгәдер инде, – дип, өзелгән сүзне ялгады Кәбир, тегенең адымнарына яраклашырга тырышып.

– Шту син, ул чакларда әле мин бәйрәмнән бәйрәмгә генә йоткалый идем. Ну бит айдан ашу больницада ятып чыктым. Иртән өйдә, кич өйдә, гел бәреләсең хатын күзенә. Эш эзләп, тегендә-монда сугылып карадым, кемгә кирәк ярымаксак адәм? Түләгән пенсияләре исемлек кенә. Шуннан башланды инде гаугалар. Урамнан гарип ир янәшәсеннән атларга гарьләнә, берәр ахирәте күренә калса, минем өчен оялып, комачтай кызара. Сикергәләп йөргәнгә җене кузгала. Үзенә якын китерми башлады. Соңыннан малайны күтәреп чыгып китте ахирәтенә. Әле шунда яшиләр ди. Аңлыйм да мин аны, биеп кенә торган хатынның гарип ир белән яшисе килмидер. Бик чибәр дә ул төскә-биткә.

Ятакханә каршындагы кечкенә мәйдан шау-гөр килә иде. Магнитофон кабызып куйганнар, берничә пар вальс әйләнә, шунда ук бала-чага чабып уйный. Яшь балаларын күтәргән әниләр чыгып баскан, кызарып-бүртеп алган ирләр тәмәке пыскыта, нәрсә турындадыр кызып-кызып бәхәсләшәләр. Рәт табылса, арадан берәрсе, җитез генә беренче катта урнашкан кибеткә кереп, сыра күтәреп чыга. Анысы түгәрәк буйлап китә. Монда яшәгәннәр өчен тәгаен мәдәният чыганагы, аралашыр урын булып торадыр ахрысы ишегалды. Ирләргә бераз кәеф күтәрергә мөмкинлек туган. Каядыр барып, шактый акча чыгарып йөрисе түгел, дуслар һәрчак синең белән. Хатыннар да канәгать. Өйдән чыгалмый яңа туган бала бакканнары ичмасам бераз саф һава сулый, кешеләр белән аралаша. Ире дә күз алдында, арт борганын да күреп торасың. Гомерләре күпчелекнең өйдән эшкә, эштән өйгә йөреп үтә. Иртәнге биштә-алтыда күз тырнап торалар да тукталышка ашыгалар. Берәр сәгатьне юлга салып куеп, көне буе болт боралар, тегү тегәләр, бетон изәләр. Соң гына өйгә кайтып, ашарга хәстәрләп, тамакны туйдырганчы, төн җитә. Әле аның арасында йомры башлы малайның дәресен әзерләшәсе бар, садикка алып барырга кызчыкның киемнәрен юып-үтүклисе, ваннадагы тамып торган кранны рәтлисе. Табылып тора мәшәкатьләр. Бераз кул бушагач, телевизор каршына килеп утырасың да, күзләр йомыла башлаганчы, шуңа текәлеп утырасың. Эчпошыргыч бертөрлелек җанны җәфалый, җелекне суыра. Кеше арасына чыгып, бераз язылып керү – бердәнбер шатлык. Подъезд ишегенә үткәндә, кемнәрдер Габдулланың җилкәсеннән какты. Кул биреп күрештеләр, хәл-әхвәл сорашып озаттылар. Мондагы халыкның бер-берсен белеп-танып, аралашып яшәгәне күренеп тора иде. Габдулланың фатиры беренче катта икән. Гарипләргә шулай каралган. Пакетларны кухня өстәленә урнаштыргач, Кәбир алгы якка күз салды. Обойлары ертылып беткән, ишек яңакларында, идәнендә буяулары купшаклаган, чүп баскан бүлмә күңел кайтаргыч иде.

– Монда әзрәк тәртип урнаштырып булмый микән? Чучка абзары да чистарак яхшы хуҗаның, – диде Кәбир, әрнеп. – Шул тиклем үзеңне хөрмәт итмәскә ярыймы соң...

– Кирәкми, – дип, битараф кул селтәде Габдулла, – бүген җыештырсаң, иртәгә тагын шул хәлгә килә ул. Минем фатир бит постоялый двор. Кемдер, хатыныннан яшереп кенә, берәр шешә сындырырга уйласа, кая бара? Туры монда керә. Кунаклар өзелми миннән. Җыйнаулашып китәбез, утырыр урын табып булмый. Хатыны белән тиргәшсә, ишекне кага, йоклап чыгарга сорый. Берәр кыз эләктерсә, миндә төн үткәрә. Эчкән хатыннар еш кунак була.

Андыйлар да җитәрлек бездә. Гупчым, галәмәт инде. Мин каршы түгел, буш кул белән кермиләр бит алар. Күңелне күтәрәләр, тамакны туйдыралар, әйдә, ятып йокласыннар, җәлмени. Минем үземнең пенсиям, күп дигәндә, өч көнгә бара. Шуннан авызны чөйгә эләм. Ярый подъезддагылар ярдәм иткәләп тора. Пример, хатын-кыз, чиста зат, алып куйган дөгесендә бөҗәккә охшаган берәр нәрсә шәйләп ала. Йөгертеп миңа төшереп бирә. Суга салып кайнатсаң, фил кадәр фил пешеп чыгар иде, ә монда энә очы зурлык бөҗәк. Ашны гына тәмләтеп җибәрә ул. Чүпкә ташламыйлар, каткан-коткан икмәкләрен, искергән ризыкларын минем ишек төбендә калдыралар. Таман гына була миңа. Тамак – бер нәрсә, эшсезлек җанны талый. Барысы да таралып беткәч, чыгып сөяләм шулай подъезд алдына, уңга карыйм, сулга карыйм. Барыр җир юк, гариплек ирек бирми, эт тә чабып үтми ичмасам. Кереп яткандай итәм дә тагын чыгып басам. Урамга чыгып хәер эстәргә хәлемнән килми, нәрсәдер җибәрми әчтә.

– Шулай күпме дәвам итәр? – дип кызыксынды Кәбир.

– Озак калмады инде, – диде Габдулла, туктап калып. Бу адәм бер-бер карарга килгәнме, үзенә кул салырга уйлыймы, дигән уй килеп калды Кәбирнең башына. Бата-калка рәхимсез язмыш дулкыннарында тирбәлгән бу егет җәл иде аңа.

– Фатирны хатынга калдырам да авылга кайтып китәм, – диде Габдулла. – Малай адәм рәтле урында үссен, мәктәпкә йөрергә кирәк әле аңа, бәлки, берәр түгәрәккә урнаштырыр әнисе. Монда якында гына спорт сарае бар. Кеше тупсасында үсмәсен. Түлке ныгытып куям, улыбыз тормыш аешына төшенә башлаганчы, әнисе кияүгә чыкмый торсын. Үги әтисе рәнҗеткәндә, мин ничек түзәргә тиеш? Үзем дә ятимлекне беләм мин.

– Ә нигә сузасың? – диде Кәбир.

– Сәбәбе бар аның, – диде дә Габдулла, тын калды. Тырышып-тырмашып балык консервасының калаен ачарга тотынды. Шулай да түзмәде, өстәп куйды: – Минем әти гомер буе умарта тотты. Мин бәләкәйдән үк бар нечкәлекләрен беләм ул эшнең. Кайтам да бал кортлары карый башлыйм. Ул эшне бер аяк белән дә эшләп була. Күз алдыңа китер, агачлар арасында, яшел үләнгә басып йөрисең, тирә-якта кошлар сайрый. Түтәлләрдән йә суганын, йә кыярын алып кабасың. Безнең умарталар бакчада утыра, җәннәт инде, җәннәт. Акчалы да ул шөгыль. Гарип икәнлегем дә онытылыр, кайтсам. Әмма бүгеннән кузгалып кайтып китеп булмый.

Габдулла, әйтергәме, әйтмәскәме икән дигәндәй, икеләнеп калды, аннан соң шыбырдап кына:

– Мин әти үлгәнне көтәм, – диде.

– Аңламыйм, – диде Кәбир, баш чайкап.

– Аңласы-нитәсе түгел, әти үлгәч кенә кайта алам мин төп йортка. Безнең әни иртә үлде. Әти бер аждаһа алып кайтты хатынлыкка. Мине күрә алмый, кайтып керсәң, күзләре акая шул тәмуг кисәвенең. Ялгыз калгач та, әтидән кайтырга рөхсәт сораган идем, сафура бураннары купты өйдә. Әти аның сүзеннән чыкмый. Тизрәк китү ягын карадым. Ну әти үлә калса, кайтып куып чыгарам мин аны өйдән. Үзем хуҗа булып яши башлыйм. Быел кышны үткәрсәм, кайтырмын дип уйлыйм. Бәлки, иртәрәк тә булыр әле.

– Әтиеңнең сәламәтлеге начармыни? – дип кызыксынды Кәбир.

– Имән кебек таза карт. Ну әкренләп какшый. Соңгы шалтыратканда тавышы карлыкканрак төсле тоелды, – диде Габдулла.

– Юкка өметләнәсеңдер, авыл картлары озын гомерле була, – дип, кирегә саплады Кәбир.

– Юк, кыштан да калмас. Мин серен беләм аның, – диде Габдулла, мәгънәле

карап. – Миңа бер апа өйрәтте. Кибеттән өр-яңа пычак сатып аласың һәм дә шул пычакны көн дә үткерләргә кирәк. Каршыңа ниятләгән кешеңнең фоторәсемен куясың, шул рәсемгә карап игисең дә игисең корычны. Эчтән генә: «Менә шул тимер ашалгандай тазалыгың кимесен», – дип юрыйсың. Күптәннән булашам инде мин бу эш белән, пычак җитәрлек кенә ашалды. Вакыт күп, миңа нәрсә, утырам да үткерлим. Күрсәтер идем, кешегә күрсәтергә ярамый. Әйтәм бит, кышны чыга алмас. Ну аннан соң ничек яшәргә белермен дә.

Кинәт кенә икенчегә борды сүзне Габдулла:

– Ә менә скумбрия нәрсә дигәнне аңлата икән?

– Шундый балык исеме, – диде Кәбир, китәргә җыенып.

– Балык икәнен беләм мин. Башка мәгънәсе дә бардыр бит. Татарча өй, дисәң, өелгән, значит, бүлмә бүленгән дигәннән килеп чыккандыр, утын – ут сүзенә бәйледер. «Скумбрия» сүзенә дә берәр мәгънә салынгандыр, тәгаен. Мин шулай еш уйлыйм, үземчә фаразлыйм сүзләрне.

– Анысын мин белмим, энекәш. Соң инде, мин китим, – дип, урыныннан кузгалды Кәбир, Габдулланың тел төбен белергә теләми иде ул.

– Чәй эчеп китәр идегез, хәзер ашны өлгертәм, – дип өтәләнде Габдулла.

Кәбир сыйдан баш тартты. Болай да баштан ашкан иде бүгенге ишеткәннәре-күргәннәре. Аруы җиткән булган, күрәсең, кайтып, мендәренә башын төртүгә, ул йоклап та китте.

* * *

Иртән уянганда, җеп өзәрлек тә хәле юк иде Кәбирнең. Авыз эче кибеп, теле аңкавына ябышкан, күз алларында яшелле-кызыллы божралар бөтереләә, һәр сөяге кузгалырга да ирек бирми сызлый иде. Ничек итсә итеп, башын күтәрә төшеп, сәгатькә күз салды. Эшкә соңга калган болай булгач, хәер, мондый хәлдә эшкә бару турында уйлыйсы да юк. Юрап китердеме чирне, әллә яңгыр астында юешләнеп йөрүләреннән салкын суккандыр, эчкән хәмеренең шаукымы йокларга ятканчы ук чыгып беткән иде бит инде. Авыртулардан битәр, чамадан тыш хәлсезлек аптыратты, әз генә борылса, сул як арка өлеше, сул беләге чәнчергә тотынды, сулуы капты. Мондый хәл булганы юк иде әле аның белән. Бераз исәнгерәп яткач, сакланып кына торырга булашты. Күкрәк турысына меңнәрчә энә кадалгандай булды, сыны катты. Тешен кысып булса да аякланды, тотынгалап, аш бүлмәсенә табаннарын шудырды. Кухнядагы өске шкафта саклана иде бар дарулар, берәрсе файда бирмәсме дип уйлады. Каты чәй дә кан тамырларын киңәйтеп җибәрә, кипкән тамагын җебетергә иде исәбе. Калтыранган куллары белән чәй куеп, дару сәдәфләре эзләп әллә күпме булашты. Даруларны да кайсысын кабарга белми сайланды, танымый да иде ул аларны. Шулай да валидол алып тел астына салды. Куе итеп ясалган чәй дә көтелгән нәтиҗәне бирмәде. Хәле мөшкелләнгән төсле генә тоелды. Ялгыз башың шытып калырсың монда, дип куркуга төште ул. Табигый уңайсызлануын җиңеп, телефоннан «Скорый» чакыртты. Ни гаҗәп, якын-тирәдә булгандырмы машина, ишектә кыңгырау шалтырады. Сакаллы-мыеклы берәү аны диванга сузып салып, кан басымын үлчәде, күз кабакларын кайтарып карады, ихласлап йөрәк тирәсен тыңлады.

– Без сине үзебез белән алып китәбез, батенька. Давлениегез сикергән, йөрәк тибеше дә тигез түгел, приступ булу куркынычы бар кебек, – дип, мобильнигына тотынды. Бу хәбәрдән Кәбир югалып калды. Ничек инде, фатирны бикләп куеп, больницага кереп ятсынмы? Хатыны да өйдә юк, эш

урынында югалтырлар. Гомумән, җене сөйми аның хлор иснәп, палатада зарыгып ятуны. Аягын каймыктырып бер эләккән иде, исенә төшкән саен сырт йоннары кабара.

– Юк, юк, бу мөмкин түгел, мин каршы, – дип карышты ул. – Сез, доктор, хәлегездән килгән кадәресе ярдәм күрсәтегез дә, тернәкләнеп китәрмен әле. Зинһар, шулай килешик.

– Һем, һем, ут белән уйныйсыз, иптәш. Йөрәк белән шаярмыйлар. Болай килешик без: чак кына начаррак сизсәгез үзегезне, туры безгә шалтыратыгыз. Ә хәзергә мин сезгә йөрәккә көч бирә торган бер-ике укол кадармын, таблеткалар калдырырмын. Әлбәттә, ятып кына торырга, начар уйларны читкә куаларга. Беренче урында – тынычлык. Йоклый алсагыз, тагы да яхшырак булыр. Ялгызыгыз гынамы өйдә? Шулай да мин рецепт язып калдырам, берәр танышыгыз аша алдырыгыз даруларны.

Врач үз эшләрен эшләде дә саубуллашып чыгып китте. Уколлардан соң бераз җиңеллек тойган Кәбир тагын йокы бүлмәсенә кереп ятты. Уйларын читкә юнәлтер өчен, китап ачып карады. Әмма хәрефләр күз алдында биеште, муены талгандай тоелды. Китабын да белми сайлаган икән. Фейхтвангермы инде күңел тынычландыра торган китап?! Кулларын баш астына кыстырып, акшарланган түшәмгә төбәлде. Менә шундый ул тормыш. Кичә генә урам буйлап чабып йөри иде Кәбир, бүген аягына басарга хәле юк. Чир дә якында гына йөри, әҗәле дә ерак түгелдер. Галәм масштабындагы уйлар белән күңелен җилкендергән була. Нәрсәдән башланды соң әле барысы? Ә-ә, әлеге юеш танауның картинасына юлыкканнан соң. Дөресен әйтергә кирәк, талантлы егет, илһамын түкми-чәчми сакласа, игътибарга лаек картиналар иҗат итәр, әйтер әле сүзен. Үзеннән соң калыр ташка баскан исеме. Кулын йөрәгенә куеп әйтә ала Кәбир, бар иде кайчандыр анда да илһам очкыны, бар иде. Тырышлыгы да, үз карашы да, яңа идеяләре дә бар иде. Кайда алар? «Умный в гору не пойдёт, умный гору обойдёт», – дип, акыллы кыланып, әйләнә-тирә мохиткә яраклашып, юкка чыкты алсу хыяллары, кыю уй-фикерләре. Дөнья артыннан куды, мактаулы исемнәр аласы килде, югары даирәдәге мастодонтлар белән аралашырга теләде, хатынына ярап, акча сукты. Бер алтын тәңкәне йөз бакыр тиенгә алыштырды. Уйлап карасаң, шул тиеннәрдән сум җыелган төсле, ә юк – бакыр бакыр инде ул, йөз булса да, мең булса да, алтын тәңкәгә тиңләшә алмый. Әнә шулай вакланды Кәбир дә. Әле соң да түгел кебек, ялган кыйммәтләр белән араны шарт өзеп, яңадан тотынса, телгә алырлык иҗат җимеше тудыра алган булыр төсле ул. Тик чишмәсе саеккан, буяулары корыган, – ник бер юньле фикер килсен башына. Бүгенге гарасатта киндергә төшерерлек хәлвакыйгалар табарсыңмы? Нигә алынсаң – барысы кыска гомерле, бер көнлек тема, ширпотреб. Чын картинада рәссамның осталыгы тирән фикерне чагылдырган булырга тиеш бит. Фотоаппарат әнә күпкә төгәлрәк рәсемнәрен бирә кешеләрнең дә, табигатьнең дә. Рәссам җанының бер өлеше картинага күчкән булса гына, ул – сәнгать. Мәсәлән, бер рәссам тарафыннан ясалган ипи кыйпылчыгы, озак яткач, күгәрек белән каплана башлаган. Чынбарлыкта шулай бит, икмәк кисәге дымлырак урында күгәрә башлый. Ә монда – киндердә кырып алырдай күгәрек. Чистарталар, бераздан тагын шул ук хәл кабатлана. Мистикамы? Юк, бу – сәнгать әсәре. Ул синең реаль тормышыңа, физика, химия законнарына буйсынмый. Перов үзенең «Тройка» картинасын язганда, уртага җигелгән малай образын Вася исемле крестьян улына карап яза. Картина күргәзмәгә эленә, Васяның әнисе, елап, художникның аягына килеп егыла. Зинһар өчен, миңа да улымның портретын ясa, көтмәгәндә үлде Вася, ди. Очраклы хәлме? Һич түгел! Сәнгать

сихерләрен белгән рәссам малайның җанын үз картинасына күчерә. Башка сәнгать төрләрендә дә моңа мисаллар җитәрлек. Әйтик, һәркемгә дә билгеле Эдгар По, ачылмаган җинаять хакында үз фаразлары теркәлгән хикәясен яза. Берничә елдан соң, җинаятьчене кулга алгач, язучының фаразлары бермә-бер тәңгәл килгәнлеге ачыклана. «Титаник» лайнерын алыйк. Кораб төзелә башламас борын, аның айсбергка бәрелеп су төбенә китәчәге хакында китап басылып чыга. Сәләт кешегә югары көчләр тарафыннан бирелә торгандыр. Шуның кадерен белми, тәгаенләнгән тәкъдирне кире кагып, үзең өчен генә яшәсәң, замиры була аның. Тагын бер ягы бар иҗат итүнең. Рәссамның үз карашы булырга тиеш дөньяга. Ә Кәбир – инкубатор баласы. Үзләрен зыялылар исемлегенә кертеп йөргән меңнәрчә замандашларыннан бер ягы белән дә аерылып тормый. Балалар бакчасы, урта мәктәп, институт һәм ул – сәнгать әһеле! Нәрсә күргән дә ни белгән ул, нинди тормыш вакыйгаларында кайнаган? Тормыш тәҗрибәсе юк дәрәҗәсендә, тетрәндерерлек хисләр кичергәне булмады, яшәү белән үлем арасында калып, рухи яктан чиркану алмады. Ә күкрәк киерә, рәсүлгә тиңли үзен, кемнәргәдер туры юл күрсәтеп булаша. Аңа бит күпләрдән артыграк бирелгән мөмкинлекләр. Кичә очраткан яңа танышы Габдулла хәлендә калмаган, иртәгә нәрсә ашармын дигән уйлар кыйнамый җанын. Белеме дә, акыл кимәле дә, таланты да өстен. Яисә бахыр Фатихны искә алсак. Бәлки, гадәти тормышыннан аерылып, иртәгә төрмә ишекләрен ачып керер дусты. Анда инде кирәкми синең фәлсәфәләрең, югары материялар хакында фикерләрең, күккә ашкан хыялларың. Параша яныннан нарга күчәр өчен, тешең-тырнагың белән тырышачаксың. Тулуз – Лотрек, Шагал, Пикассолар башыңа да кереп чыкмаячак. Ярый, анысын калдырыйк, ни дисәң дә, аннан да кешелеген югалтмый чыккан адәмнәр очрый. Юл буенда аунаган яшүсмер мәете – кисәтү түгелме? Яшисе дә яшисе генә иде бит аңа. Үлем беркемне дә аямый, синең яшеңне сорап тормый. Якаңнан бөтереп ала да, килеп җиттең – синең тукталыш, дип, фанилыктан исемеңне сыза, җаныңны билгесезлеккә озата. Анда ни барын кем белгән? Яшәргә ашыгырга кирәк. Иртәгә ни көткәнен беребез дә белми. Үҗәтләнеп, күңел салып тотынырга чын иҗатка...

Шулчак коридорда ниндидер тавышлар ишетелеп калгандай булды. Ишекне бикләргә онытканмынмы икәнни, кайсысы йөри тагын, дип, Кәбир урыныннан калкынгандай итте. Чүәген аягына элеп өлгермәде, бүлмә ишегендә хатыны Сабрина күренде.

– Син нишләп эштә түгел? – дип, гаҗәпкә калды хатыны. – Сәгать унбер тулган, ә бу иркә һаман урын өстендә ауный...

– Менә чир басты мине дә, – дип, гаепле елмайды Кәбир, ничек итсә итеп, караватына торып утырды.

– Әйтәм аны, бар өйгә дару исе таралган, – дип борынын җыерды Сабрина. Өстәл янына килеп, таблеткаларга игътибар итте. – Ә болары нинди дару? Каян алдың? Рецепт язганнар. Эринит, метронидазол, анаприлин… Йөрәк дарулары ла болар. Нәрсә, врач чакырттыңмыни? Моңа кадәр зарланганың юк иде лә йөрәгеңә? Ят, ят, постельный режим, диелгән бит. Һич үзеңне генә калдырып китеп булмый. Берәр мөгез чыгарырга гына торасың. Мин чиргә тарыгач, калышмаска, сиңа да урын өстенә ятарга кирәк инде...

Сабринаның үзенең дә чирләгәне йөзенә чыккан иде, күз кабаклары асылынып төшкән, йөзе акшарлаган төсле. Шулай да кәефе күтәренке күренде.

– Кеше почмагында «ках-ках» йөткереп, борын сеңгереп ятканчы, кайтыйм дип уйладым. Үз өеңнең һавасы да икенчерәк. Бераз ютәл дә басыла төште. Ясап куйган үлән төнәтмәләрем бар иде, шуларны эчәрмен. Кая, чәй куйыйм әле.

Аш бүлмәсендә кечкенә радиоалгыч эленгән иде Кәбирләрнең, Сабрина кабызып куйды ахрысы, татар моңы яңгырады. Ялгызлык чама белән генә әйбәт. Әле менә кырында тере җан булуы күңелен урынына утыртып җибәрде Кәбирнең. Акмы, карамы, үз яртың, шуның белән чирек гасыр яшәлгән. Ят ятып карар, үзеңнеке торып карар, дигәннәр борынгылар. Тамагың кипкәндә су алып эчерсә дә, күңелең була. Хатыны юрагannan да арттырды, лимонлап чәй китереп куйды алдына, кучтәнәчләрен тезде. Локма ризык кабарга теләми иде Кәбир, ә кайнар чәйне йотлыгып чөмерде.

– Хәзер аш куям да аптекага барып килермен. Үземә дә дарулар алырга кирәк, – дип тә сөендерде Сабринасы. Адәм баласы бит ул, бар вөҗүде белән врач язган даруларга ышана, шул төймәләр аның гомерен саклап калыр төсле тоя. Тәкъдиргә язылганына артык ышанып бармый.

Каз итеннән майлы шулпа эчеп куйгач, аштан соң шифалы дару төймәләрен дә йоткач, ару гына шәпләнеп китте Кәбир. Әмма хәлсезлек баскан иде бар халәтен. Хатыны үз эшләре белән зур якта мәш килде, Кәбир сиртмәле караватын саклады. Өн белән төш арасында күпме шулай яткандыр, кесә телефонының чәрелдәвенә сискәнеп китте. Рәссамнар берләшмәсеннән шалтыраталар икән.

– Сәлимов, без сезне Кырымга барачак төркем исемлегенә керттек, – дип гөрелдәде рәис урынбасары. – Тыгыз элемтәдә бит без хәзер милләттәшләр белән. Билгеле вакыйгалардан соң, хәлдән килгән кадәр ярдәм итәргә тырышабыз. Тарихи комарткыларга реставрация башлап җибәргәннәр икән. Сез, танылган рәссам буларак, үз киңәшләрегезне бирерсез, өйрәтерсез, гомумән, җитәкчелек итәрсез. Союз әгъзалары сезгә ышана.

– Мин чирләп киттем бит әле. Урыннан тора алмыйм, дарулар йотып кына җан асрыйм, – дип карышырга булашты Кәбир. Көтелмәгән тәкъдим уйларын чыбалтып җибәрде аның.

– Зарар юк, чирләми тормый адәм баласы. Тәмам терелгәч, соңлабрак барырсыз. Файдага гына булыр, так сказать, реабилитация. Анда бит җәй, кипарислар, диңгез һавасы, җиләк-җимеш, чибәр кызлар, ха-ха-ха, – дип рәхәт кичерде урынбасар. – Командировканы шартына китереп төзербез, эш урынында хезмәт хакың сакланыр, берләшмәдән дә әзме-күпме материаль ярдәм булыр, Кырымдагы иптәшләр дә буш итмәсләр. Давай, алын, синнән башка яраклы кандидат юк. Соңыннан рәхмәтләр укырсың...

Иртәгә төпле җавап бирү шарты белән, хушлаштылар. Кырым әйбәт анысы. Атна-ун көн үтәр, монда кар бөртекләре күренә башлар, ялыктыргыч кышны әз генә булса да кыскарту мөмкинлеге чыгып тора. Озакка сузылырмы икән ул командировка? Матди яктан шактый отышлы эш булырга охшаган. Кәбир күптәннән машинасын алыштырырга уйлап йөри. Шәһәр читендә җир бирергә вәгъдә иткәннәр иде. Кешеләр төсле дачалы буласы килә аның да. Картайган көнендә җирдә казыныр, бакча үстерер. Табигать кочагында яшәүгә ни җитә! Сәламәтлегенә файда булыр, бушлай курортка җибәрәләр ич. Соңгы араларда мактанырлык түгел сәламәтлеге, нервылары какшады. Кырык төрле уй килеп тинтерәтә, кысыр хыяллар җанны җәфалый. Гадирәк яшәргә кирәк, булганына шөкер итеп. Үзе дә инде, башына берәр уй килә калса, күтәрелеп бәрелә, барысын кара төсләрдә күрә башлый. Ни әйтсәң дә, адәм баласына яшәр өчен иң мөһиме – җан тынычлыгы һәм дә күңел күтәренкелеге кирәк!..



Халисә
Мөдәррисова

# ГАЛӘМНӘРГӘ ЧАКЛЫ АГЫЛА

## Көз керә...

Усакларның мәрмәр муеннан
Яңгырмы ул, яшьме йөгерә?
Чаукалыктан умырзая исен,
Яшәү исен алып яз керә.

Мәңгегәме килә дәртле җәйләр,
Дөнья, синнән яшәү өркелә!
Ә мин куам сине, йә син мине,
Биреләбез сөю иркенә.

Болын түрләрендә соңгы нурлар
Курпы өсләренә җан өрә,
Җил качышлы уйный яфрак белән,
Бер кычкырып елый, бер көлә.

Гомер басуымның уңышлары
Амбарларда инде, кибәндә,
Камылларым өстә, ә асылы –
Тамырларда, аста – тирәндә!..

Син – хәйләкәр! Син– алдаткыч, дөнья!
Җәй булып – җәй, ул да искерә!..
Буыннарда соңгы җылы тибә,
Күзләремдә менә – дым да кибә,
Туфрак исе булып көз керә…

---

Халисә МӨДӘРРИСОВА – *шагыйрә, прозаик; татар, башкорт телләрендә чыккан «Көмеш дага», «Шәмәхә төн», «Балан» һ.б. китаплар авторы. Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Башкортстанда яши.*

## Кем булсаң да

Яхшыртасы килеп дөньяны
Тир түккән ир – чират артында
Тешен кыса, төйни йодрык,
Түрә «эш күрсәтә», ә чынында –
Этеш-төртеш кояш астында.

Яктыртасы килеп өзлеккән
Ризык җыя урам чатында.
Шәп машина тәрәзәсеннән
Хәрәм җыйган тиен ыргыта,
Этеш-төртеш кояш астында.

Мәңгелеккә килгән шикелле
Соса чорсыз кеше хакына.
Намуслыга монда урын юк,
Тагаракка якын килгәнне
Этеш-төртеш кояш астында.

Баш сөяге тора ыржаеп,
Төпсез караш буш күз астында…
Этеш-төртеш – ярык тагарак!
Һәркем тузан вакыт каршында –
Кем булсаң да кояш астында.

## Икәү генә

Ниһаять, без икәү, икәү генә...
Зарыктырган, көткән тартылу,
Җаным тулы серем, әйтер сүзем,
Эчләремне өткән талпыну.

Мең мәшәкать, мең ваклыкка ярап,
Гафу итче, тагын соңладым.
И сөеклем, уңдыңмы син миннән,
Уңдыңмы син, әллә уңмадың?

Минем куллар синең йөзне назлый,
Кайнар дулкын күчә каныма,
Ә булмышым йолдыз күче булып
Галәмнәргә чаклы агыла.

Таңга чаклы бүген сөйләшербез,
Тансык миңа синең якынлык,
Ни әйтсәм дә, беләм, син түзәрсең,
Алдашырга шуңа хакым юк.

Әйтер сүзем синең аша насыйп,
Ә гарешләр белән юк бәхәс.
Ниһаять, без икәү, икәү генә,
И, сердәшем, тугры Ак кәгазь!

## Каләм

Сулу, суыну сулышы,
Кышларга гомер әрәм.
Күкләрдән көмеш җырларны
Җыярга тора каләм.

Кырлар бушанган, пошынган,
Болын түрендә кибән.
Соңарган сөюгә һәйкәл
Коярга тора каләм.

Коелган коен шавында
Үткән язлардан сәлам,
Дөньяны алтын төсләргә
Буярга тора каләм.

Яшәү-яшьнәү ахыры бу,
Хыялга урын тәмам,
Тик үлмәс өмет көчедәй
Кәгазь өстендә каләм.

***

Көтмәгәндә, арттан пычак кебек,
Ак җәймәгә гүя кара корт...
Дус, дип йөрдем, дус, дип уйлый идем,
Ышанасы килми: «Син дә, Брут?!.»

Дошман – явыз, аның күңел кара,
Кулы керле, җаны – үчендә!
Дошман ачык, аннан качып була,
Яки көтеп була –
Әзерләнеп була һөҗүмгә,
Йә булмаса солых төзеп була,
Һәр якка да кирәк өченгә.

Горурланып, кадереңне белеп,
«Дус», дип йөрдем, – галәм танысын!
Берни әйтми, бер кылыгың белән
Урынына куйдың барысын.

Өлешеңә кермәдем дә кебек,
Булдым һәрчак якты теләктә.
Дус куллары хәнҗәр батырдылар
Ак перчатка киеп йөрәккә.

Күпме күңел кайту. Бинахакка
Азмы яңаклады бу язмыш...
Бөтен нәрсә үтә, бу да үтәр,
Тантанада бары – яңарыш,
Дуслык кайтмас, шунысы аяныч!

## Ал бака

*Бәкер шифаханәсендә ял итүчеләр арасында*
*Озын күл ләмендә ал бака күрсәң,*
*бар сырхауларыңнан да арынырсың,*
*дигән ышаныч йөри.*

Камышлыктан яр башына
Ал бака чыгып яткан.
(Кайсы әкият батыры,
Ук атып, күлмәк яккан?)

Кемнәр килә, кемнәр китә,
Үрелеп карап тора –
Аллеяда төгәл сәгать
Вакытны санап тора.

Назлы Аккош, бүз Тургае
Һәм җитез Карлыгачы,
Иртән-иртүк куаклыкта
Өздерә Сандугачы.

Монда әкият дөньясы –
Һәркем яңа тугандай,
Мәгъруր чыршы шөлеменә
Килеп куна тулган ай.

Кыр үрдәкләре сазлыкта
Һәр язда оя кора,
Каенсарда пар аккошлар
Томшыгын учка куя,
Монда аяк асларына
Алмагач алма коя.

Бәкер картның ат өере
Шикелле ак томаннар,
Таңнан торып, Озын күлгә
Төшеп су коеналар.

Елак талның толымына
Өмет килеп сарыла,
Томшыгына бишек элеп,
Ләк-ләк канат кагына.

Бу якларның күңеле киң –
Һәркемгә җитеп тора,
Сырхауларга сихәт теләп,
Ал бака көтеп тора.

## Кышкы иртә

Керфекләрен ачты бәсле иртә,
Агач ботаклары –
Әйтерсең лә
Йонтач койрык, йомшак бәбкәләр –
Әйлән-бәйлән уйнап таң нурында,
Җиргә коя көмеш тәңкәләр.

Матур да ул һәм хәтәр дә салкын,
Чыңлый тынлык, ак кар шыгырдый.
Уян инде, дөнья, уян тизрәк,
Ныклыгыңны сынап кыш йөри.

Якты иртә җиргә бер Илаһтан
Иминлек һәм муллык үтенә.
Лач-лоч итеп сарай почмагында
Яңа туган бозау сөт имә.

## Укытучы

*Ришат Салих улы Исмәгыйлевкә*

Маңгайларда еллар сыры –
Мәңге тынмас көрәш кыры.
Ә иңнәрдә зур хәзинә –
Җырларга тиң гомер юлы.

Әйләнеп бер баксаң артка –
Утта янган Брест ята,
Сыңар аяк, тәндә ярчык,
Үч итеп бар киртәләргә,
Яшәүгә чәм, ярсу арта.

Зая түгел бу гомерләр,
Булмады бу яшәү хата.

Орлык төште яшь җаннарга:
Әхлак, хаклык, милләт йөзе,
Бәһасез бер олы байлык –
Ана теле – намус сүзе.

Кыйтгаларның һәрберсендә
Шәкертләр бар – сезнең җимеш.
Мәйдан тота, тарих яза,
Тантанада – сезнең өлеш!

Сезнең шәхес – үзе дәрес,
Рух һәм илһам уятучы.
Гомерегез кош юлыдай,
Сез – мәңгелек Укытучы!

**Редакциядән:**
*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Дилбәр Булатова

# СОҢ ТҮГЕЛ!

ПОВЕСТЬ

**Әдип**

Әдип таң белән гаражга керде дә, ач кеше табынга йотылып карагандай, ашыгып-ашыгып, машинасын урап чыкты. Исән, төп-төзек. Шулай булырын белсә дә, күңел бит әллә кайларга йөгерә: гаражга төшмәгәннәрме, үчләшеп тәгәрмәчен тишмәгәннәрме... Яңа да үзе, бик кыйммәтле дә булгач, аерата кадерле шул. Гараждагы сыңар лампочканың сүрән яктысы да яшерә алмый: тәрәзәләре, номерлары көзге кебек ялтырап тора. Аларны йомшак чүпрәк белән сөртеп, чистарткандай итте. Башын кырын салып, берникадәр вакыт машинасына сокланып карап торды. Елкылдап торган кап-кара, өр-яңа «Форд» яхшы нәсел айгырымыни! Яратып, аның ишеген сыпырды. Ир канаты – ат, дигән борынгылар, ә бүген безнең канат – машина, дип уйлап куйды.

Ул кечкенә чакта әтисенең аты бар иде. Үзенеке түгел инде – колхозныкы. Тик әтисе бригадир булгач, ул ат ел әйләнәсендә аларның абзарында асрала иде. Исеме – «Кашка». Әдип Кашканы карап, тугарып, атланып йөреп үсте. Исендә, алтынчыда укыганда, колхоз Сабан туенда ул шул Кашка белән иң алдан килгән иде!

Инде авылда сыңар ат та калмады, ат абзарын сүтеп аттылар, малкайларның кайсын кая озаттылар. Атлар гына түгел, авылның җир җимертеп эшли торган уңган ир-атлары да 90нчы елларда чебен урынына кырылды. Кайсы авырып, эштән чыгып егылды, кайсының башына ялган аракы җитте. Алар белән авылның яме бетте, чалгы чыңнары тынды, көтүләр чыкмый башлады, фермаларны сүтеп, кирпечләрен, плитәләрен районның көчлерәк колхозларына ташыдылар. Аның әтисе Гаяз да шул шаукымлы елларда язгы чәчү вакытында кинәт вафат булды. Әлеге дә баягы, колхоз эше дип янып, чабып йөргән җиреннән. Бер яшь механизатор, ялгышыпмы, эчкән баштанмы, бодай басуы уртасына килеп, әллә ничә буй көнбагыш чәчкән. Шуңа йөрәге кубып кайтып керде, сорап алып, бер чүмеч салкын кое суы эчте һәм күкрәген тотып аяктан егылды.

---

Дилбәр БУЛАТОВА (СӨЛӘЙМАНОВА) – *язучы, «Туй», «Көлдән яралган гөл» китаплары авторы; Башкортстан Язучылар берлеге әгъзасы, филология фәннәре кандидаты. Уфада яши.*

Әдип янә машинасын әйләнеп чыкты. Тәгәрмәчләргә күз салды. Өр-яңа тәгәрмәчләр, юлга чыгарга ашкынып, ажгырып торалар сыман. Их, матуркай, елгыркай! Дөрес, кредитка алырга туры килде үзен. Биш ел буе түлисе булачак, процентлары белән арттырып. Аның каравы, бүген үк утыр да йөр.

Кар ява, җил чыкмакчы, себертергә җыена. Гөлчәчәк кыстый торгач, быел, үз турларына киоск куеп, кибет ачканнар иде алар. Авыл зур, тауар үтә, олы юл буе булгач, үткән-сүткән юлаучылар да туктамый китми. Атнага ике-өч тапкыр Уфага тауарга бара Әдип. Иртән үк барып тормасаң, теләгән тауарың бетеп, сайландыгы гына калырга мөмкин. Тырышмый булмый. Сәүдә эшен яратмыйм, дип иркәләнеп тора алмыйсың. Аягың тәпелдәмәсә, авызың чәпелдәми, диләрме әле? Шыңгырдап торган нарат бүрәнәләрдән салып чыккан әкият йортыдай матур биек йорт та күзгә күренми, үзе балта остасы булып тапкан акча да чыгып кына оча, хатыны тырышып үстергән казларның ите, йоны, акчага әйләнеп, судай ага – барыбер җитми. Җан тиреңне түгеп, күпме генә тырышма, хәләл көч белән бик әллә кая китеп булмый икән шул. Ә кибеттән акмаса да тама.

Элек болай ук тынгысыз түгел иде алар. Ә хәзер, дөнья көтәбез, җитмәгәнне җиткерәбез, дипме, ашыгудан бушамыйлар. Туганнар, күршеләр белән табыннарга җыелышулар да бетте. Алар белән тормышның да яме китте сыман. Тормыш яме кешегә түгел, әйберләргә күчте, дип уйлый Әдип. Берәр яңа әйбер алсаң, рәхәт булып китә. Тик бу бәхет, бу рәхәтлек озакка бармый, тагын башка әйберләр кирәк була башлый... Әнә, залдагы диван искергән, яңасын аласы бар, машина кредитын тизрәк түләп бетерергә иде, кибетне зурайтканда шәп булачак, балаларны алда БДИ көтә – район үзәгенә репетиторга йөртә башларга кирәк...

Кая анда туган-тумача, кая инде күрше-күлән! Алар түгел, бер-берсенә күтәрелеп карарга вакытлары юк. Җитмәсә, соңгы арада татулыклары югалып тора. Ир дигәнеңә ризыкны да үзенә җылытып ашарга калды. Ә хатын дигән кешегә сүз дә дәшеп булмый – дөрт итеп кабынып китәргә, еларга, тиргәшергә генә тора.

Кайчан башланды соң бу җайсызлыклар? Бик матур гына, авылда бер итеп туй ясап өйләнешкәннәр иде, югыйсә. Тәүдә Әдипләрдә, төп йортта яшәделәр. Ул елларны Гөлчәчәк телсез-тешсез, уңган килен иде. Үзе чибәр. Озынча да, түгәрәк тә түгел, килешле йөз-бит, борын очларында сөйкемле булып – сипкелләр, яшькелт-соры күзләрендә шаян очкыннар биешә. Бал кортыныкыдай неп-нечкә бил. Купшы киенә. Гәүдәгә никадәр кечкенә булса, шулкадәр тынгысыз: бер минут та эшсез утыра белми. Атлап түгел, йөгереп, юк, очып дигәндәй йөри. Әнә шул ашыгуы сәбәп булдымы, көтелмәгән бәлагә тарыды ул.

Өч ел элек, көзге якта, әбиләр чуагында булды бу аяныч хәл. Хатын ул көнне түбән очка, әниләренә хәл белергә киткән иде. Балаларны ияртмәде, алар өйдә калды. Әдип ул көнне, кышка кергәнче дип, капка баганаларын төзәтеп булашты. Бер тимер багана кыйшайганрак кебек иде. Аны суырып алып, чокырын тирәнәйтеп, яңадан цементлап измәгә утыртмакчы булды. Кичкә эшен тәмамларга җыенса да, көзге көн алдата, караңгы тиз төште – багананы утырту иртәгегә калды.

Урам баганаларында ут үткән кыштан ук сүнек – айсыз-йолдызсыз, дөм-караңгы көзге төн. Әниләреннән кайтып килгән Гөлчәчәк шул чокырга егылып төшкән. Чокыр өстенә капланган такталар, калайлар нишләптер ике якка каерылган булган. Хатынының күгәргән-бәрелгән урыннары тиз төзәлде, тик бу хәлне ул бик авыр кичерде, йөрәге кубып, коты алынып калды. Холкы да шуннан соң үзгәрде бугай. «Минем әниләргә китүне өнәмичә, мин кайтуга

махсус казып куйгансыңдыр», дип, тузга язмаган шикләр уйлап чыгарды. Үпкәчел, гарьчелгә әверелде. Чокыр сәбәп кенә булгандыр, дип уйлый Әдип. Арадагы татулык айлар-еллар буена сиздерми генә кителә, ишелә барган инде ул...

***

Хатынының әти-әнисе белән дә аралар бозылды соңгы арада. Бигрәк тә бабасы белән ике арадан кара мәче узды.

Бабаларында бәрәңге утырткан көн иде. Анда эш булса, электән үк шулай куелган: Әдип, Гөлчәчәк, балалар – берсе дә калмый, үзләренә эшләгәндәй эшләшәләр, ярдәмләшәләр. Бу ихатада һәр кадак, һәр бүрәнә таныш аңа. Егерме ел эчендә һәркайсына кияүнең кулы тими калмагандыр. Әби белән бабасын да үз итеп, якын итеп сөйләшә. Тик аның бер гадәте бар: якын кешесенә уйлаганын әйтми кала алмый. Эшләгән кешенең тире чыга, тире белән ачы теле чыга, дигәндәй, теле ачы. Чит кешегә әйтергә кыймый. Ә үзенекеләренә аның төртмә сүзләре эләгеп кенә тора.

Менә ул көнне дә бабасы үзенең гаражыннан иске, тутыгып беткән «Муравей» мотоциклын алып чыгып кабызырга тотынды. Ул арада Шамил белән Диләрә, шаярышып, «Муравей» арбасына утырдылар да, бер менеп, бер төшеп, сикерешеп уйный башладылар. Диләрәсе ярый инде, олы котый Шамилгә ни калган?!

– Төшегез, шилмалар! – дип, аларга җикерде бабасы. – Арбаны ватасыз! – Ачуланып, кулындагы соляркалы иске чүпрәк белән кизәнде.

Әллә аның балаларга җикергәненә җаны көеп китте, әллә телен тыя алмады, кияү кеше шулчак:

– Әллә кабынмый? И бабай, бабай, картайган көнеңдә шул иске «Муравей»га карап калдыңмы инде! – диде.

Алар икәүләп теге атнада гына Әдип кулдан алган искерәк «МАЗ» машинасын «юганнар» иде. Шунда бабасы кияүдән көлеп рәхәтләнде. Янәсе, авылны чыгып җитә алса, ярый, бу калтырча беренче түмгәктә үк шалтырап таралачак! Бабай кеше көлә-көлә өстәгән иде: «МАЗ»лы булдың, кияү, тик «КА»сын каян табарсың икән инде?» – дигән иде. «КамАЗ» алам диеп йөреп, «МАЗ» алганга төрттерүе иде инде.

Шул шаяртуларны дәвам итүе иде Әдипнең. Тик сүзне мәзәккә борыр дип көткән бабайның йөзен гүя кара болыт басты – бите кап-кара булды, кашлары җимерелде. Бер сүз дә әйтмәде, мотоциклдан төште дә җәһәт кенә, эре-эре атлап, өйгә кереп китте.

Карлыган куаклары читендәге йомшак түтәлне тырматып, чәчәкләр утыртып булашкан Гөлчәчәк:

– Әдип, син нәрсә? Гафу үтен әтидән! Әйдә! Өйгә керик, хәзер үк гафу үтен! – дип, килеп, иренең җиңеннән тартып, өйгә әйдәде. Тик Әдипнең тискәресе килгән идеме – баскан урынында һәйкәл сыман үрә катып калды. Нәрсә әйтте ул чаклы гафу үтенерлек! Шаяртты гына бит! Үз итеп кенә!

Хатыны, яшькә төелеп, өйгә таба йөгерде. Балалар гына, берни дә булмагандай, өлкәннәргә игътибар бирми, иске кызыл «Муравей» тирәсендә мәш килде.

***

Машина җылына торган арада Әдип өй ишеген бикләп килде, өйдәгеләр әле барысы да йокыда. Әйдә, йокласыннар, алар уяна башлауга, ул урап та кайтыр – Уфага утыз гына чакрым бит аларның авылыннан.

Урамнан барганда, гадәтенчә, ике якка да күз салып үтте. Уң якта, якты тәрәзәләрен балкытып, әнисенең йорты калды – әнисе иртә торырга гадәтләнгән, мал карарга чыккандыр. Авыл очында, сул яктагы кечерәк йортта бабасы белән әбисе яши, утлары янмый иде әле, алар, соңрак торып, төн уртасында гына ятарга гадәтләнгәннәр.

Авылны үтеп, яланга чыккангамы, җил көчәйгәндәй булды. Прицеплы «КамАЗ» артына басты да шуның артыннан менә ун-унбиш минутлап килә әкрен генә. Узып китүдән файда юк, буранлап торгач, алтмыш белән генә барырга туры килә. Юл да үргә күтәрелә. Бардачоктагы фотога күз ташлап алды. Моннан ун ел элек, әле фотоаппаратлар сирәк вакытта, Гөлчәчәк бала табу йортыннан чыккан көнне төшерелгән фото иде ул. Әдип белән Шамил бер кочак чәчәк, табибларга, шәфкать туташларына күчтәнәчләр алып барганнар иде. Шунда иске «Зенит»ына кемнәндер төшерттергән иде. Ул фотосурәтне Шамил хезмәт дәресендә сырлап-бизәкләп ясаган матур агач рамга утыртты. Фотога күз салу белән, күңел канатланып киткәндәй, гаугасыз, бәхетле, тату көннәрнең шаһиты ул бу фото.

«Шәрык» радиосын кабызып җибәрде, «Форд»ның стереосистемасы яхшы, сыйфатлы – өр-яңа җырларны, балдай ягымлы тавышлы алып баручыларны тыңлап рәхәтлән генә.

Шулай бер җай гына китеп барганда, кинәт алдында зур көрән тап пәйда булды. Якты дөньяны каплап алган бу зур тап көрән «Киа» машинасы иде. Әдип үзеннән-үзе тормозга басты. Теге машина дөп итеп сул як канатка килеп бәрелде. Чыңгырдап тимер изелде, челтерәп тәрәзәләр коелды, «Форд», кырт борылып, барган җиреннән туктап калды. Әдип алгы панельгә башы белән бәрелде, уң аягын әрнүле авырту сыздырып үтте.

Ни булды бу? Әкрен генә, тыныч кына «КамАЗ» артыннан бара иде бит! Сул ишек яньчелеп, изелеп кергән – ачылмады. Үрелеп, уң як ишекне ачып, чыкмакчы булды. Тик уң кулы күтәрелми. Аның авыртуы да сизелми. Сулы белән уң кулны күтәрмәкче булган иде, җилкәдән аска таба, электр тогы суккандай, авырту телеп үтте. Авырту басыла төшкәч, Әдип янәшәдәге утыргычта яткан телефонын алды, контактларны ача алмады, бармаклары калтырый, яшел төймәгә басты. Кичтән иң соңгы сөйләшкән кеше Әминә апасы булган икән, аның «Алло» дигәнен ишетү белән:

– Апа, машина җимерек! Авария! Мин «КамАЗ» артыннан гына бардым бит! – дия алды, авыртудан ыңгырашып.

Күз алдындагы көрән тап зурайганнан-зурайды, һәм аны гүя нииндидер тирән кара упкын буар елан сыман үз кочагына суырып алды.

## Апа

– Апа, машина җимерек! Авария! Мин «КамАЗ» артыннан гына бардым бит!

Иртән торып, чәй эчәргә җыенып йөргән Әминә, энесенең телефоннан әйткән бу сүзләрен ишетеп, эсселе-суыклы булып китте. Йөрәгенә чыра кадалдымыни!

Кат-кат шалтыратты, телефон белән бергә өзелеп-өзелеп чакырды, ялынды, ялварды, тик энесе телефонны алмады. Авария урынына барырга кирәк бит! Тик кая? Кемгә шалтыратырга?

Киленнәренең, Гөлчәчәкнең номерын җыйды. Анысы соңгы арада үпкәләбрәк тора иде, алырмы? Алды. Йокылы тавышы канәгатьсез иде:

– Таң тишегеннән ни булды?

– Гөлчәчәк, Әдип шалтыратты. Ул авариягә эләккән!

– Булдырган икән!

– Кая киткән иде соң ул? Тауаргамыни?

– Әйттем мин аңа, көндез чыгарсың, минем дә барасы бар, дидем...

– Әдип кая китте дип сорыйм, Гөлчәчәк! Авария урынына хәзер үк барырга кирәк. Бәлки, аңа ярдәм кирәктер!

– Тукта, ә ник ул сиңа шалтырата, ә ник миңа түгел?

– Гөлчәчәк, тауарга киткән идеме ул?

– Ну, әйе, шунда барырга тиеш иде... Ул бит миннән сорап тормый. Үзе белә дә үзе эшли.

Әминә киленен башкача тыңлап тормады. Ирен уятып, күңелсез хәбәрне җиткерде дә, юлга ашыктылар. Кызлары алар белән барырга теләгән иде дә, аны ияртмәделәр, ул институтына лекциягә китте.

Аралашырга, сөйләшергә яратучы Әминә үзе көйгәләгрәк булса да, ире Газиз – аның капма-каршысы. Бер сүз әйткәнче, җиде кат уйлый торган заттан. Юл буе диярлек хатын аһ-ваһ килеп сөйләнеп барды. Озын калын гәүдәле, күзлекле ире исә ара-тирә генә сүз кыстырырга өлгерә иде.

– Инде исән була гына күрсен! Инде, Аллам, башкае исән-сау котылсын бу бәлаләрдән! Барып күрмичә, энигә шалтыратмый торам инде, телефоннан әйтсәм, йөрәге ярылыр! Без – без инде, ә энем – аның төпчеге, иң яраткан баласы бит. Бу Әдипне дә әйтәм, таң караңгысы белән чыгып китмәсә инде. Әткәйгә охшап, бигрәк каудар! Ул бит әле, машина җимерелде, ди, үзен сөйләми! Ичмасам, көне буранлы, өшеп, сызланып, юл буенда ята микән, машинасыннан чыга алмый кысылып калды микән?

– Олы юл бит, әнисе, – диде ире. – Полиция, «Ашыгыч ярдәм» килгәндер.

– Тизрәк барып җитәргә кирәк! Бәлки, өлгерербез, берәр ничек ярдәм итә алырбыз!

– Син минем ярты ел элек кенә машина белән әйләнеп, юл читенә очканны оныттыңмы? – диде Газиз, кашын җыерып. – Андый чакта беркем дә ярдәм итә алмый ул. Бернәрсәне дә үзгәртә алмыйсың. Буласы була да куя. Ходай ярдәменнән ташламасын, диген!

– Әйе шул! – дип, авызы белән учын каплады Әминә. – Ул чакта сине, үзең әйтмешли, фәрештәләрең саклагандыр инде, маңгаең гына күгәргән иде бит! Бу ни хәл бу! Соңгы арада гел кирегә дә кирегә! Бер проблемадан котылмыйсың, яңасы калкып чыга.

– Тик кенә өйдә ятсаң, бер проблема да булмас иде, – диде ире. – Без үзебез бит, койрык астына нашатырь кыстыргандай, чабабыз да чабабыз.

– Анысы шулай инде, – дип ризалашты хәләл җефете. – Егерме ел эчендә күченүләр генә дә дүрт тапкыр булды, ике йорт салдык, ничә эш урыны алыштырдык! Энем дә – безнең сыңар. Алар безгә караганда да тынгысызрак яши. Авылда тормыш көтүе авыррак шул, мәшәкатьлерәк!

– Шәһәрдә дә җиңел димәс идем, – дип куйды ире, уйчан гына.

***

Әминә тынып калды. Әле Газиз белмәгән нәрсәләр дә күп. Ире белән никадәр яхшы яшәмәсеннәр, аңа сөйләргә ярамаган серләр дә бар. Газиз «авыр» дип зарлана, ә аның урынында булып караса, ул моннан биш ел элек кичергәннәрне кичерсә, ни дияр иде икән?

Хатын, сулга борылыбрак, иренә күз ташлады. Җанга якын йөз, газиз чалымнар, газиз сын... Исеме дә җисеменә туры килеп тора. Студент елларыннан ук гаилә кордылар. Шул еллардан башлап мәхәббәт йолдызлары елдан-ел яктырак яна кебек.

Иреннән дә ныграк аңа үзенең әнисе, туганнары гына кадерлерәктер, мөгаен! Арадан Әдип бигрәк якын. Аның кебек кеше дөньяда юк. Аларның гаиләсендә бу – кечкенәдән билгеле аксиома. Энесе кебек сөйкемле, аның кебек игелекле, җор сүзле, туган җанлы башка берәү дә юк!

Әйе, биш ел үтте. Тик иренә һаман бернәрсә дә сөйләмәде. Кан басымым югары, дип зарланды. Вакыт-вакыт дәваханәгә кереп ятуларын «профилактика өчен» дип аңлатты. Никадәр көчле авырганын сөйләмәс тә инде, мөгаен. Үзе белән алып китәр бу серне.

Белсә, Газизне югалтырмын дип курыкты хатын. Авыру хатын кемгә кирәк? Сәламәт, чәчәк кебек хатыннарны да ташлап китәләр! Көтеп кунагың килмәсә, авырып хатының үлмәсә, яман, дигән мәкаль дә чыгарган бит әнә безнең халык...

Бик каты авырып киткән иде шул ул чакта. Хәле кыл өстендә калган иде. Чирнең тамыр җәйгәнен сизми калган. Көннәрдән бер көнне дәрес уртасында өянәге тотты. Унберенчеләрдә БДИ биремнәрен тикшерәләр иде. Кискен, көчле авыртудан аңын җуеп, такта янында дивар буйлап, кискән агачтай, ишелгән дә төшкән. Бу хәлнең юньлегә түгел икәнлеген белә иде, педагогия институтына кергәнче, бер ел медучилищеда укыган иде ул. Ә шулай да... өмет бит. Яшь табибәнең, яман шеш булмавына сөенегез, дигәнен гүя томан аша гына ишетте. Җитди операция ясатырга кирәк иде. Авыруының җитди икәнен эшендә дә белдермәде. Чыш-пыш китүеннән, җәлләүләреннән курыкты. Гел көлеп, шаярып йөрүче, бөтен эшне бик җитез, бик җиңел генә башкара торган тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы Әминә Гаязовна булып каласы килде.

Чираттагы больничныйны алып, республиканың үзәк дәваханәсенә китте. Аңа тиешле операцияне иң алдынгы ысул белән Мәскәүдә генә ясый алалар икән. Уфада ясаткан очракта, пычак астына өч тапкыр ятарга кирәк булачак. Мәскәүгә юлламаны бер кеше генә бирә ала икән. Бу кеше кабинетына бер сәгатькә соңга калып килде. Ишек төбендә ике хатын, бер ир көтteләр. Өчесенең дә гаиләләре, балалары бар. Өчесенең дә яшисе, бик яшисе килә. Табиб, практикант кызлар белән шаярыша-шаярыша, бүлмәсенә керде.

Әминәне кабул иткәндә, игътибарсыз гына, исем өчен генә аның авыру тарихын актаргалаган булды.

Һәм юллама бирүдән баш тартты.

– Аңлагыз, минем савыгасым, савыгып чыккач, әле озак еллар эшлисем килә! – дип ялварды Әминә, салкын күзләргә карап.

Салкын күзле табиб исә:

– Безнең коллегалар да мәскәүлеләрдән ким түгел! – диде һәм, сүз бетте дигәндәй, халатын сала башлады.

Хатын, арып-талып, фатирына кайтып керде. Ире эштә, кызы әле укудан кайтмаган. Хәле юк, башы әйләнә. Кан басымы күтәрелдеме – җилкәдән, күзләрдән авырттырып, укшыта. Сумкасыннан дару алып эчте дә душка керде. Бүгенге бөтен газаплы кичерешләрне, өметләнү, өмет өзелүләрне юып төшерергә теләгәндәй, бик озак җылы агым астында басып торды. Аннан юрган астына чумды. Бәләкәй чагындагы шикелле, башыннан ук капланып ятты да тынып калды.

Тыелгысыз үкси башлады. Күзеннән яшь чыкмады, алар елый-елый кипкән иде инде, ахры. «И Аллам, ник болар барысы да төш түгел?! – дип, әрнеп сыкранды. – Нишлим соң, нишлим? Ни хәл итим? Ни өчен нәкъ миңа шундый газаплар? Берәрсен рәнҗеттемме, кемгәдер зыян эшләдемме әллә?

Хатын үткән айларны-елларны, балачагын, студент чакларын күз алдыннан үткәрде. Аннан эш... Мәктәп, балалар, имтиханнар, төннәр буе дәрескә әзерләнүләр... Юк, бер баланы да, коллегаларын да рәнҗетергә, аяк чалырга тырышмады кебек. Дөрес, кешедән ким булмаска омтылды. Үзенә, бары тик үзенең акылына, эчке тоемлавына таянды. Намус белән эшләде. Шәһәр мәктәбендә дә менә дигән укытты, соңгы ике елда мәгариф бүлегендә эшләде, яхшы эшләгәнен күреп, тарих фәненнән методист итеп чакырдылар. Аннан районга күченергә туры килде – янә мәктәпкә эшкә керде. Дөрес, бер коллективта да ул үз кеше булып китә алмады. Аңа һәрвакыт сагаеп карадылар. Түрәләр үз кәнәфие өчен курыкты, ялкаулар исә беркайчан да уңганрак коллегаларын өнәп бетерми. Ә аның табигате шулай – берәр эшкә тотынса, аны идеаль итеп үк булмаса да, идеалга якын итеп эшләргә тырыша. Көчме? Көч-энергия әллә каян килә иде. Күктәнме, Ходайданмы. Ире дә аптырап бетә иде – үзең гәүдәгә орчык чаклы гына, үзең шундый бөтерчек кебек, ди.

Тик менә хәзер, киресенчә, көч дигәнең, бармаклар арасыннан аккан ком сыман, бертуктаусыз агыла да агыла, тотып тыям, туктатам, димә...

Әминә, юрганын ачып ыргытып, сикереп торды да көзге янына килде. Көзгедән аңа ябык, саргая төшкән, бите җилсенгән, маңгаен, ирен читләрен җептәй нәзек усал сырлар ермачлый башлаган ханым карап тора иде. Шундый арыган, алҗыган ул! Сабырлыгы сынган... Тик күзләре генә бирешмәгән, алар утлы күмер кебек янып ялтырый!

Тәрәзә төбендәге гөлләргә күзе төште. Үзендә алар кайгысы юк, бүтәннәрнең кулы җитмәгән. Иң нәзберәге – озын, киң яфраклы, суны күп «эчә» торган кытай розасы бөтенләй сулып, шиңеп төшкән.

Мин дә шулай шиңәрменме? Өч тапкыр пычак астына ятып, исән котыла алырмынмы? Корыган гөлне савыты-ние белән чыгарып түккән кебек, аны да өеннән алып чыгып китеп, кабергә күмәрләрме? Әллә дәваханәдә өзелерме гомере? Бу уйлардан күңеле йомшарып, ике бөртек күз яше тәгәрәде. Кибеп бетмәгәннәр икән әле...

Ул, идәнгә чүгеп, келәмгә тезләнде. Куллары, аяклары, үзләреннән-үзләре әтисенең әнисе Хәмдия карчык намаз укыгандагыдай рәвеш алдылар. Әбисе бик укымышлы карчык иде, гозерең булса, Аллаһы Тәгаләгә сәҗдә кылып сора, адәм баласының Аллаһка иң якын вакыты шул, дия иде.

Гел өстә, югарыда йөрергә күнеккән баш түбән иелде, гел елмаерга гадәтләнгән иреннәр ялварып дерелдәде, көләч күзләр йомылып, догага оеды...

– Аллаһым, Раббым, – диде пышылдап Әминә. – Котылу юлын күрсәтче миңа! Минем үләсем килми! Минем кызымны кем карар, кем туй ясар? Мин үлсәм, бу чәчәк кебек дөньям кемгә калыр? Мин бит күпме көч түктем бу дөньяда. Минем белемем, минем белгәннәрем шулай тиз юкка чыгармыни? Мин бит әле күпме балаларны укыта алам! – Күзеннән, ни гаҗәп, чишмә кебек яшьләр саркыла башлады. Яшь агу белән күңеленә дә җиңеллек өркелгән сыман тоелды. – Чирне дә, шифаны да Син бирәсең, шифа бирсәңче минем тәнемә! Савыгасым килә, Син кушкан юллардан гына йөрер идем, тыйганнарыңнан тыелыр идем...

Шулчак ишектә кыңгырау шалтырады. Ире кайткандыр, вакыт соң. Әминә

яшьләрен тиз-тиз халат итәге белән корытты, барып ишекне ачты һәм, берни булмагандай: «Кадерлем, кайттыңмы?» – дип, үрелеп, ирнең яңагыннан үбеп алды.

Иртәгәсенә ул томография кабинетының шәфкать туташына шалтыратырга уйлады. Батып барган кеше саламга да ябыша бит. Беркөн, кабинетка килеп кергәндә, чечен кызы Зараның телефоннан кем беләндер Мәскәүдәге клиника турында сөйләшүен ишетеп калган иде. Шалтыратты, хәлен аңлатты. Буш итмәм, җаныкаем, дип ялынды. Әйе, кара көнгә дип җыйган маясы бар, терелтсеннәр генә, берни дә жәл түгел. Кешелекле кеше булып чыкты Зара, аның үтенечен кире какмады, шундук кирәкле телефон номерын да табып бирде. Кияүгә чыгып, Уфага күчкәнче, Зара ике ел шунда эшләп алган булган икән. Әминә ул номерга курка-курка гына шалтыратты. Куркуы юкка булган: алдагы атнага ук аны клиникага чакырдылар.

Үтте кара көннәр. Операция ясатты, тиешле дәвалау курсларын алды. Шөкер, эшләп йөри. Каралып, тикшерелеп тора, хәле зарланырлык түгел.

Инде менә энесе аңа чарасыз калып шалтырата! Әминә, керфекләре чыланганын иренә сиздермәскә тырышып, башын түбән иде. Их, дөнья, беркемнең дә гамь казаны буш түгел!..

## Гөлчәчәк

Җаны әрнеп, иркен өй эчендә әрле-бирле йөренде дә йөренде Гөлчәчәк. Харап иткәндер инде ире өр-яңа «Форд»ны! Аңа шалтыратмыйча, апасына шалтыратуы да шуннандыр! Ишетер иде, юкса, ишетмәгәнен!

Йокыдан уянып кына килгән Диләрәгә дә өлеш эләкте. Кичтән рәсем төшереп булашкан иде кызы, пумала-буяу, альбом битләре белән зал тулган. Буяу алып җиткермәле түгел!

Берничә тапкыр Әдипкә шалтыратып карады. Тик ире телефонын алмады. Ярый, апасы барып җитсә, Гөлчәчәккә анда урын булмаячак, эш калмаячак. Әйдә, көйләсен Әминә сөекле энесен!

Дөньяны күпме бөтәйтергә тырышма, бөтәйми икән ул... Инде теләгәнемә ирештем, дип уйлыйсың, ә ул тез астыңа шундый итеп китереп суга! Теләгәнең генә түгел, булганыңнан да колак кагасың! Гөлчәчәк инде ничә ел шундый нәүмиз халәттә яши. Күңеленә урын тапмый. Читтән караганда, барысы да яхшы кебек. Ә ул аңлаешсыз шом эчендә. Матур киенергә ярата иде, анысының да кызыгы калмады. Теге чакта ире казыган чокырга егылгач, аның битендә җөй калды. Ничек кенә матур киенмә, иң тәүдә шул эз күзгә ташлана... Нечкә генә, кыска гына, тик барыбер җанны үрти. Балалары үсеп килә, яхшы укыйлар – анысы да сөенеч бирми.

Аптырап, җанын әрнеткән сорауларга җавап эзләп, күрәзәче карчыкларга барды. Сәбәбен беләсе килде. Кемдер – күз тигән, кемдер бозым, диде. Кемдер, ireңнең ка́рмасы пычранган, дип күрәзәлек кылды.

Соңгы версиягә хатын чат ябышты. Ничек үзенең дә башына килмәгән! Әлбәттә, ка́рма! Әдипкә кияүгә чыкмаса, ул шул каһәрле чокырны казып куймаса, бу хәл булмый иде. Нәсел ка́рмасы! Кырык елдан соң да кырын эшнең киялеге чыга, кыены төшә ул! Гөлчәчәкнең имгәнүе дә шуннандыр әле! Әдипнең картәтисе гомере буе участковый булып эшләгән бит. Утыз ел эчендә кемнәрнең генә башына җитмәгәндер дә кемнәрне генә төрмәдә черетмәгәндер ул! Ә этисе бригадир булган. Бригадир Гаяз Ленин ордены

алсын өчен, бөтен авыл бил бөктеме – бөкте! Бик усал абзый иде, Гөлчәчәкләр чөгендер утаганда, карап, чүбе калса, берәмтекләп өздереп йөри иде. Әдип исә – этисенә аркаланып, иркә генә үскән төпчек малай.

Эшләре алга бармауның, акчаның теләгәнчә мул кермәвенең сәбәбен дә иреннән күрә башлады хатын. Кеше ирләре, әнә, Себергә барып, көрәп акча алып кайта. Ә бу, кусаң да китми, өем бар, булганы җитә, ди. Яздан көзгә кадәр осталыкта йөри йөрүен, кышкылыкта андый эшләр азая бит. Ә Гөлчәчәк алай итә алмый. Әдип юкта абзардагы мал-туар да аның өстендә, балалар да, киоск та. Сәламәтлегем юк, дип тормый, тиен урынына бөтерелә. Иренә нәрсә, ул сәламәт, ул һәрвакыт шәп, көләч, шаян! Һәммәсе белән шаяртып сөйләшергә сүз таба, ә хатыны өчен бер җылы сүзе, якты йөзе жәл.

Уйлый-уйлый, аның ни сәбәпле Себергә китәргә теләмәвен дә аңлады ул. Китәсе килми, димәк, монда сөяркәсе бар аның! Бу уй шулкадәр дөрес булып тоелды ки, Гөлчәчәк хәтта елмаеп куйды! Барысы да аңлашыла иде хәзер: капка төбенә казылган чокыр да, иренең аның ямьсезләнүенә игътибар бирмәве дә! Чокырга төшеп, муенын сындырыр дип уйлаган ул! Битендәге яра эзенә исе китмәве дә аңлашыла: димәк, аңа бар ни дә, юк ни Гөлчәчәк! Аны күрми дә ул, чөнки уенда башка берәү! Хатыны монда абына-сөртенә, җан тиргә батып, Әдипнең дөньясын көтә, ә ул гулять сыптыра, кәеф-сафа кора! Дөньялары алга бармауның да сәбәбе шушы – бар тапканын сөяркәсенә ташый, димәк!

Үз фаразларына исбатлау эзләп, ире күрмәгәндә генә аның телефонын карый, кесәләрен актара торган булып китте. Тырыша торгач, тапты да. Менә, Тәнзилә дигән хатынга биш тапкыр шалтыраткан, Нәсимә дигәненең исемен, телефонын кәгазьгә язып, түш кесәсенә тыгып куйган. Тик бу фактларны бер талашканда зур тантана хисе белән иренә җиткергәч, тегесенең бер дә исе китмәде. Кычкырып, авызындагы утыз ике теше күренерлек итеп көлде дә: «Оптовикларның телефоннары бит ул!» диде.

Димәк, бүтән хатын, дигән нәтиҗә ясады Гөлчәчәк һәм эзләнүләрен дәвам итте. Иренең «Одноклассники» сайтындагы битендә бер сабакташының фотоларына гел «класс» куеп баруын ачыклады. Ә ул хатын күрше авылда яши. Димәк, Әдип, тауарга йөрим дип, шуның янына чаба!

Түзмәде, бөтен шикләрен бер барганда эти-әнисе белән бүлеште. Әнисенең соңгы бер-ике елда кодагые белән аралары суынган иде, кияү белән бабай арасыннан да кара мәче үткән – алар тулысынча кызларын яклады.

– Җитәр, кызым, күп хезмәт иттең аларга! – диде әнисе. – Күпме бергә тордыгыз, чәчең белән җир генә себермәдең. Барыбер ярый алмадың. Диләрәнең бәби туен да үткәрмәде кодагый, ә йортын Әминәгә яздырды, – дип, әллә кайчангы һәм өр-яңа үпкә-ачуларына ирек бирде. – Син генә түгел, безне дә хезмәт иттерделәр. Йорт, аннан мунча салганда, әткәң куна-төнә эшләшеп ятты, безнең хакыбыз бик күп анда.

– Бик шәп булып кылана ул Әдибең... – дип, учакка куз өстәде әткәсе дә. – Авылда беренче булмакчы. Тик шуны уйламый: синсез, безсез әллә кая китә алмас иде!

– Шуларга ярыйм дип, ашкынып эшләп йөреп, сәламәтлегеңне бетердең! Аларның клуб хәтле өйләрен җыештырып, басу хәтле бакчаларын утап! – диде әнкәсе, кызының иң нечкә җиренә кагылып. – Алай өстеңнән дә йөргәч...

Тора-бара Гөлчәчәкнең күңелендә Әдипкә карата бер җылы да калмады сыман. Аралар суынганнан-суынды. Әйдә, миннән башка тырышып карасын

әле, дип, ачуланып уйлады ул. Киемеңне үзең юып, ашарга үзең пешереп, савыт-сабаңны үзең җыештыра башласаң, бик шәпләнеп, чәчкә атып йөри алмассың – кикригең тиз шиңәр!

Моңарчы дөнья арбасына парлап җигелеп тигез тартсалар, хәзер хатын үзенең ягына каера башлады. Әнисе әйтмешли, җитәр. Юкса, бар көченә, өзеп-йолкып, ир дөньясын көтә! Әдип – шәп, Әдип – яхшы! Ә ул күләгәдә! Кеше хатыннары ирләрен Себергә озата да, яхшы шәраб эчеп, бер-берсенә кунакка йөрешеп туймый. Мал да асрамыйлар, бакча дип тә өзгәләнмиләр – Себер акчасы артыгы белән каплый.

Иренә каршы әйтүдән, аның бер сүзен дә тыңламаудан тәм таба башлады. Дөрес, кайчак: «Болай барса, этле-мәчеле яшәсәк, аерылышып туктыйбыз бит!» – дип уйлап куя. Аннан: «Ярар, аерылышса соң, бер без генәмени, ун парның җидесе аерылыша хәзер, – дип үзен юата. – Авылда өй рәтеннән китсәң, кем аерылган, кем буйдак, авыл тулы ялгыз әби-сәби. Телевизорны ачсаң, әнә, артистлар: әбиләре – малайга, кызлары бабайга бара, баланы пробиркадан табалар, балаларның атасын тест ясатып кына беләләр».

Ничек кенә булмасын, ул элеккечә баш иеп яшәмәячәк! Ире йә баш бирә, бирмәсә, үзенә үпкәләсен! Ник гел Гөлчәчәк, баш иеп, аны тыңларга тиеш? Ул да тыңласын аны! Барсын әнә Себергә! Уч тутырып акча алып кайтсын! Шунда сөйләшергә була! Ә аның әле – утыз, әле биш мең алып кайтканына авыз җәеп торып булмас.

Төннәр буе йокламыйча хыялланып ята торгач, тагын шундый уйга килде: иренә генә карап утырмаска, акча эшләргә! Әдипкә әйтмичә, аңа белдермичә генә! Менә шул чакта ул бөтенләй үзаллы булачак. Шул чакта ул Әдипнең авызына түгел, Әдип аның авызына карап торыр!

Шундый уйлар белән юанды Гөлчәчәк. Кайчандыр балкыган мәхәббәт балкышыннан берни дә калмады, ул аллы-гөлле сихри салават күпере иренә каршы төбәлгән, агулы ук төзәгән зәһәр җәягә әверелде. Өй эче сугыш яланына әверелде. Хатынның иренә каршы игълан ителмәгән сугышы иде ул. Дөрес, тыштан барысы да элеккечә кебек. Бомбалар ярылмый, сызгырып пулялар очмый, елга булып каннар акмый. Тик бу тыштан гына шулай. Чынында исә бомбалар – усал сүзләр, пулялар – усал карашлар, ә кан урынына кимсетелүле, үпкәле хисләр ага. Ир-ат бит катырак була, Гөлчәчәкнең үзенә дә эләгә: ул түккән яшьләр диңгез үк булмаса да, инде күл булгандыр. Ире белән бергә аның туганнарына, бианасына да нәфрәттән өлеш мул чыкты. Елына берике аш-фәләндә күрешүне санамаганда, элеккечә туган көннәргә чакырышу, котлашулар, сәгатьләр буе телефоннан сөйләшүләр бетте.

Улы Шамил кайчак әйтеп куя:

– Югары оч картинәйләргә ник бармыйбыз ул, әни? – ди.

– Аның эше күп, безнең кайгы юк! – дип кырт кисә Гөлчәчәк.

– Мин аны беркөн кибеттә очраттым. Ул, мине оныттыңмыни, Шамил, ник кунакка килмисез, – ди.

– Юк-бар белән башымны катырма әле! – ди әнисе, ачуланып. – Бар, укуыңны укы! Бик шәп булгач, нәнәң хет берәр шоколад алып бирдеме соң үзеңә?

– Юк!

– Менә, күрдеңме! Алырсың алардан берәр нәрсә! Ярар, ничава, күрәселәре алда әле! Селкетербез әле без аларны, капчыкларын әйләндереп селкербез!

Үсмер егет, беркатлыланып, төпченеп маташты:

– Нинди капчыкларын, әни?

– Хәзер мин синең үзеңне тотып селкәм! Бар, шилма малай, укуыңны укы дидем бит!

***

Сыерны савып, Шамил белән бергәләп малларны карап керүгә, Диләрә торып җиткән. Чәй эчеп булашканчы, сәгать 11ләр булды.

Шулчак әнисе шалтыратты:

– Кызы-ым, тиз генә шәһәр каналын ач! Әдибең кеше таптаткан анда!

Хатын, абына-сөртенә дигәндәй барып, телевизорның пультын алды. Кирәкле каналны тапканчы, хәбәрнең азагына гына өлгерде: «Автомобильләрнең бәрелешүенә «Форд» автомашинасының каршы полосага чыгуы сәбәпче булган!»

Ул да түгел, әнисе яңадан шалтыратты:

– Ишеттеңме, ике кеше үлгән! Водитель белән хатыны. Юк, өч кеше – ул хатын авырлы булган!

Гөлчәчәк, аһылдап, башына ябышты.

– Апасы шалтыратканые шул иртән! – дия алды.

– Кая киткәние соң кияү? – дип сорашты әнисе.

– Тауарга инде, кая булсын!

– Кичтән сыра-фәлән тотмаганыемы?

– Эчми бит ул, беләсең ич!

– Барыбер котылалмый, утырталар инде аны!

– Нишләп алай дисең, әни?

– Бәй, ишетмәдеңмени? Каршы полосага чыккан бит! «Форд»ның карарлыгы да калмаган, тимер өеменә әйләнгән!

– Биш ел кредит! – Хатын тәмам буынсыз калды. – Әле йөк машинасыныкыннан көчкә котылганыек!

– Страховкасы барыемы? – диде әнисе.

– Булу беләнмени! Үзе гаепле булгач!

– И балам, бер бәхеткәйләрең булмады, бу хәсрәт капчыгына чыгып! – Әни кеше мышкылдап елап җибәрде. – Торуыгыз да этле-песиле. Муеннан бурыч! Инде менә тагын бәла!

– Әни! – дип бүлдерде аны шулчак Гөлчәчәк, шомланган тавыш белән. – Әни, беләсеңме, бер экстрасенс былтыр миңа нәрсә диде?

– Нәрсә тагын? Бетмәде инде шул корткаларың!

– Ирең машинасыннан колак кагачак, диде. Алай гына да түгел әле...

– Үзеңне нәрсә диде – шунысын сөйлә син!

– Сине зур үзгәрешләр көтә, диде...

– Амин, амин, яхшы якка үзгәрешләр булсын, балам! – диде ана кеше, аның бу сүзләрен хуплап.

– Әни, Әдипне күрсәттеләрме телевизордан? – диде Гөлчәчәк акрын гына.

– Дәваханәгә озатканнар. Янына барып килербез инде, кешедән яхшы түгел. Күрше-тирә болай да тырнак астыннан кер эзләргә генә тора. Күрше Гайшә әйтә беркөн: «Нишләп кияү балакаең күренми соңгы вакытта? Элек бөтен эшегезне эшләшә иде», – дигән була. Мин әйтәм: «Үзеңнең киленең кая югалды? Элек җәйләр буе балалары белән кайтып ята иде, бер-бер хәл булдымы әллә?» дим. Шундук авызы ябылды.

– Бүген барабызмы? Апасыннан белешимме?

– Ярар, – диде әнисе. – Курыкма, бернәрсә дә булмагандыр ул кадәр. Син

үзеңне сакла. Тынычландыра торган даруларыңны эч! Нервыларың болай да беткән!

Гөлчәчәк телефонны өстәлгә куйды да, тәрәзәдән урамга карап, тын калды. Тышта күбәләк-күбәләк кар ява. Шундый матур! Агачлар ап-ак бәстә! Аларның никахы да шундый матур кыш көнендә булган иде бит!

Их, ул көннәр! Түрле чанага атлар җигеп үткәрде алар туйны. Әдип теләгәнчә. Шулкадәр ат ярата иде бит ул. Ә кәләш өчен әзерләнгән купшы чанага өч ат җигелгән иде. Мондый хәлне күрмәгән яше-карты капка төбенә чыкты, таң калып, рәсемдә йә телевизорда гына күргән тройканы күзәттеләр, баш чайкап, тел шартлаттылар. Нинди бәхетле иде алар. Ничек ярата иде ул Әдипне! Аңардан башка күзенә беркем чалынмады, беркемне башына да кертмәде. Икесе шулкадәр пар килгәннәр, шулкадәр бәхетле булырлар иде кебек. Һинд артистларына охшап торучы, җор телле, шаян, көләч Әдип өчен авылның бөтен кызлары булмаса да, яртысы җан ата иде. Ә ул, аларны көнләштереп, Гөлчәчәкне сайлады. Гөлчәчәк аны армиядән көтеп алды, бар булмышы белән тугрылык саклады. Аңа кыз белән малай табып бирде, аларны «өф» итеп кенә үстерде.

Тик соңгы арада барысы да кирегә китте. Ярый әле әнисе белән әтисе ярдәм итеп, киңәшләрен биреп торалар. Әле дә алар бар. Юкса, нишләр иде! Кемгә эч серләрен сөйләр иде дә кем белән кайгы-хәсрәтләрен бүлешер иде... Өстенә бер-бер артлы өелгән тау сыман авырлыкларны ничек күтәрер иде...

Җанын җылытучы тагын бер нәрсә бар: өч атна элек егерме мең сум акчасына «Лимитед-Интернейшенл» дигән бер чит ил компаниясенең кыйммәтле кәгазьләрен алды. Шулардан, компания вәгъдә иткәнчә, бонуслар килә дә башлады! Болай булса, җитәр бер көн: үзеннән өстәрәк баскычта торучы хезмәткәрләр кебек, күбрәк сумма кертә һәм тагын да күбрәк бонуслар ала башлар! Уфада үткәрелгән җыелышларына да барып кайтты. Андагы хатыннарны, яшь кенә кызларны күреп шаккатты. Барысы да матур итеп киенгән, үзләре дә матур, сөйләгән сүзләре дә матур, телләре телгә йокмый. Һәркайсы үзенең бүген «Лимитед-Интернейшенл» ярдәмендә нинди уңышларга ирешүе белән уртаклашты. Кемдер машинасын яңарткан, кемдер чит илгә барып кайткан. Ә иң күп взнос керткән кешеләрне самолёт белән диңгез өстеннән йөртәчәкләр икән. Аның да алар кебек үк буласы килә! Аның да кешеләр кебек Төркиягә, Мисырга барасы килә! Үзенең кимсенүләрен, бәхетсезлекләрен, барча проблемаларын оныткандай булды, алдында матур кешеләр, сөйкемле сүзләр белән тулы аллы-гөлле дөнья ачылды. Син – аларга, алар сиңа кирәк. Хәлеңне сорашалар, эшләреңнең ничек баруы белән кызыксыналар. Йомшак кына, елмаеп кына аны да үзләре белән бергә якты, уңышлы, акчалы тормышка әйдиләр!

## Әни

Авария урыны әллә каян күренеп тора иде: көрән «Киа» белән энесенең «Форд»ы, сөзешергә җыенган ике тәкәдәй, капма-каршы килеп, юл уртасында хәрәкәткә аркылы туктап калганнар. Һәркайсы үз полосасында. Ике яктан килгән автомобильләр, акрынаеп, юл читенә чыгып, урап үтәләр.

– Туганкаем! – дип, кычкырып елап җибәрде Әминә. – Күрәчәкләрең шушында булды микәнни?

Акрын гына кар ява иде. Акрын яуса да, бозлы асфальт өстенә бер-ике бармак калынлыгында кар катламы ятып өлгергән – погонлы кешеләр юлдагы карны себерә.

– Туганым кая? – дип үрсәләнде хатын, машинадан төшеп, як-якка каранып.

– «Ашыгыч ярдәм» алып киткәндер, – диде аның янына килеп баскан ире.

Ул теге кешеләрнең берсе янына йөгереп барды.

– «Форд»ның водителе мондамы?

– Алып киттеләр инде аларны...

– Кая алып киттеләр?! Хәле ничек?! Туганым исәнме?

– Сез кем буласыз?

– Апасы! Йә, әйтегез инде, зинһар! – Хатын ЮХИДИ хезмәткәренең җиңенә ябышты.

– Исән. Тик хәле авыр.

– Районгамы?

– Әйе.

– Тагын кемнәр?

– «Киа»ның водителе, аның хатыны – үлгәннәр.

Әминә, һушы алынып, ире янына йөгерде.

– Газиз, эшләр харап, киттек дәваханәгә!

– Ашыкма, – диде ире. – Авария урынын карарга кирәк. Каенишне реанимациягә салганнардыр, янына барыбер кертмәячәкләр.

– Газиз, анда ике кеше үлгән!!!

– Да-а... Болай ук булгач, ашыкмыйк әле без. Авария урынын әйбәтләп күздән кичерик.

Хәләле һәрвакыттагыча дөрес сөйли иде. Ләкин, аңы белән моны аңласа да, Әминә энесе белән әнисен уйлап бәргәләнде. Әнисенә бу хәлләр турында ничек хәбәр итәр? Ничекләр итеп аның күзенә карар?

Икәүләп шул якка киттеләр. Хатын әле генә яхшылап карый алды, баягы кешеләр ЮХИДИ хезмәткәрләре икән. Алар үзләре себергән асфальттан нидер эзли.

Кырылган-фәлән урын юкмы икән дип эзләнәләрдер, дигән нәтиҗә ясады Газиз.

Әминә, якынрак килеп, һәм «Форд» астында караеп яткан эзләрне шәйләп алды. Эзләр полосага аркылы рәвештә иде.

– Ник алай? – диде аптырап.

Гомере буе физика укыткан ире, бераз уйланып торгач:

– Арткы тәгәрмәч эзләре. Нәкъ шулай булырга тиеш! – диде.

Хатын бу хакта уйлый алмады, җаны көйде. Һушсыз яткан энесен күз алдына китерде, әнисен уйлап җаны көйде. Иренә:

– Мин башкача монда кала алмыйм, әни янына кайтырга кирәк, – диде дә машиналарына таба атлады.

– Алайса, мин булса да калыйм, – диде ире. – Мондый чакта һәлакәт урыныннан китәргә ярамый. Ә син бар, әби янына кайт! Тик кайтырлык хәлдәсеңме соң?

– Мондый чакта үзеңне уйлап буламыни! – диде хатын, әрнеп. – Мин бер-ике сәгатьтән урап килергә тырышырмын. Термос белән чәй алырмын. Тик син өши күрмә, берәрсенең машинасына кереп җылынырга тырыш.

Машинасын куалап, сыкранулы уйларга уралып, туган авылына ашыкты Әминә.

***

Тәрәзә төбендәге гөлләргә су сибеп йөри иде Заһидә апа. Көннәр язга таба тартканны сизеп, чәчәккә бөреләнгәннәр. Мондый чакта аларны, көн дә булмаса да, ике-өч көнгә бер судан өзмәскә кирәк.

Үзе акрын гына, ишетелер-ишетелмәс кенә җырлый:

Исле гөлем исле була,
Чәчәкләр аткан чакта ла.
Шул чәчәкләргә карыйм мин,
Сезне сагынган чакта...

Менә бу купшы, сортлы, җете кызыл чәчәк атучы яранны кызы Әминә Уфадан кайтарып биргән иде. Ул бу яранны кызының үзенә охшата: Әминә дә бит, кызурак холыклы, гөлт итеп кабынып китүчән, үзен-үзе җәлләми, балкып, бар дөньяга чәчелергә әзер.

Уртада тыйнак кына елмайган ап-ак чәчәклесе – уртанчысы, Әлифәсе. Ул электән үк тыйнак, акыллы булды, әрли башласаң да елмаеп кына, башын кырын салып кына торыр иде. Күрше авыл егетенә кияүгә чыкты да төшкән җиренә таш булып батты. Ире белән дә шул тыныч холкы аркасында тавыш-тынсыз яши инде.

Ә бу алсу яран – төпчеге, Әдибе. Тирә-якка тармакланып үскән, биш-алты чәчәге бар, тагын өч-дүрткә бөреләнгән. Суны да күп сибәргә кирәк. Улы да шулай тынгысыз, ул да шулай гел игътибар сорый бит...

Гөлләрем кебек иркәләп кенә үстердем бит сезне, дип, уенда балалары белән сөйләште әни кеше. Гөлләремә карап кына торган кебек, сезне көн-төн уйлап яшәдем. Сезнең өчен көеп, сезнең өчен янып үтте гомерем.

Моннан ун ел элек ире үлеп киткәч, канаты каерылган кош сыман моңаеп калды ул. Тик бирешмәде. Дөньяга үзе төптән җигелде, балалары ярдәм итте. Берләшеп, бер йодрык булып, җил-бураннарга бергәләп каршы тордылар. Ананың, балалар дип, таңы атты, балалар дип, кояшы баеды.

Менә бүген дә иртән улы таң сарысыннан юлга кузгалды. Заһидә аның яңа машинасының тавышын, шунда ук хәтерендә калдырып, җыр откандай отып алган иде. Тәрәзәдән үрелеп карап, юл догаларын укып калды. Калкулыкка менеп югалган Уфа юлы өйнең түр як тәрәзәсеннән бик әйбәт күренә. Исән йөрсен, балакай, фәрештәләр сакласын үзен!

Аннан бәлеш салырга уйлады. Әдип җомга көн Уфага барса, әнисе яраткан кара икмәкне алып, кайтышлый аңа керми узмый торган иде. Суыткычтан ит алып, микродулкынлы мичкә эретергә куйды. Харап уңайлы ул мич. Әминәсе алып кайтып биргәч, башта өйрәнә алмый интеккән иде, хәзер ит эретергә булса да шуны кабыза, аш-боткасын да шуңарда гына җылытып ала. Суганын, бәрәңгесен әрчеде. Хатын-кыз үпкәләсә, ашау ягын кыса торган, килен әллә пешерә, әллә юк – кая әле, сыйласын улын тәмле бәлеш белән. Әдип ул ач йөрмәс, тик шулай да өй ашына җитми бит!

Өй эченә ит бәлешенең авыз суларын китерерлек тәмле исе тарала башлаганда, урамда таныш машина күренде. Бәрәч, кызы, Әминәсе кайткан түгелме соң? Көн буе диярлек ике күзе урам як тәрәзәдә булган Заһидә аптырауга төште: шалтыратмаган иде бит, ник болай иртә кайтырга булган икән?

Каршы алырга чыгарга киенеп бетүгә, бәгырь кисәге йөгереп кереп тә җиткән.

– Әни, ни хәлдә? Исән-сау тордыңмы? – дип кочаклап алды.

Ананың йөрәге жу итеп китте. Нәрсәдер булган! Кызының, елмаерга тырышса да, калтыранган иреннәрен күрү, калтыранып чыккан кыюсыз тавышын ишетү белән үк, ниндидер бәхетсезлек булганын бар җаны-тәне белән тоеп алды.

Менә нәрсәгә булган икән! Бүген төнлә күргән төшен хәтерләде. Әдибе, бер ат чанасы бүрәнә төяп, авыл очына таба китте. Бүрәнә күрдеңме, яхшыга түгел инде ул!

Әнисенең йөзе үзгәреп китүен күрү белән үк, Әминә башка түзеп тора алмасын аңлады.

– Әни, Әдип исән! – диде тизрәк. – Тик ул авариягә эләккән!

– Балакаем! – дип, сыкранулы аһылдап, ана диванга утырды. – Аяк-куллары исәнме? Күз-башы?

– Исән, әни, исән. Ул бит үзе шалтыратты миңа!

– Ник үзе кайтмады соң, балам?

– Аны дәваханәгә алып киткәннәр, әни.

– Бәй, нишләп торабыз, әйдә, Әдип янына барыйк! – дип, Заһидә, духовка миченнән бәлешне ала башлады. – Менә аңа дип бәлеш салган идем, әле генә пешеп чыкты!..

– Анда безне кертмәсләр әле, әни. Мин шалтыратып белештем, әлегә бернәрсә дә кирәкми, иртәгә генә килерсез, диделәр.

– Бәрелгән машинадагы кеше исәнме? – дип, сагаеп сорады ана.

Әминә тынып калды. Тик җавап көтеп аңа төбәлгән әнисенә нидер ялганлаудан файда юк иде – ул болай да барысын да белә иде кебек!

– Рульдәге ир белән аның хатыны үлгәннәр, әни! – диде, башын түбән иеп.

Заһидә, һушы алынып, чигенә төшеп, диванга барып утырды. Йөзе ап-ак булды. Иреннәре, ияге дерелди башлады, куллары калтыранып, тезендәге күлмәк итәген бертуктаусыз сыпырдылар.

– Йа Рабби! – дип, тынып калды. – Күрәчәкләребез бар икән! Кемнәрнең газиз балалары икән?! Йа Раббым, минем улымны, гаебе булса, кичер! Аңа исәнлек бир, сабырлык бир!

Әминә үз күзләренә үзе ышанмады – бер мизгел эчендә әнисенең ак яулык читеннән күренеп торган чигә чәчләре ап-ак булдылар!

– Әни! – дип, өзгәләнеп, аны барып кочаклады Әминә. – Әни, синең чәчләрең... агара...

Ә ул бу сүзләрне гүя ишетми дә иде. Кашлары җыерылган, маңгаендагы җыерчыклары тирәнәйгән. Көтмәгәндә ишелеп төшкән тау кебек хәсрәттән тагын да кечерәеп, бөрешеп калган иде. Менә калтыранган куллар югары күтәрелде. Кипшенгән, дерелдәгән иреннәр дога сүзләре пышылдады:

– И Раббым, аларны Җәннәт ияләре ит, ата-аналарына, туганнарына, якыннарына сабырлык бир...

Хатын, тунын салып, тиз генә чәй куеп җибәрде. Дарулар тартмасын алып, ампула-шприцлар, кан басымын үлчи торган аппаратны алды. Әнисенә дә, үзенә дә укол кадарга кирәк булыр.

Ул да түгел, ишегалдында аяк тавышы ишетелде. Күрше апа икән. Аның коты очкан йөзен күрү белән, Әминә хәбәрнең кешеләргә таралуын аңлап алды. Һәм бүген беренче тапкыр аз гына булса да күңелен юатырдай уй сызылып үтте: ярый әле кайтып өлгерде, ярый әле әнисенә әкренләп кенә үзе җиткерә алды

кайгылы хәбәрне... Аннан күрше авылда яшәгән Әлифә сеңлесенә шалтыратты. Мондый кайгылы вакытта әниләрен берүзен генә калдыру ярамас. Ишекне кайгы каккан чакларда баланның, туганыңның, якын кешеңнең янында гына булуы да зур терәк ул!

## Тикшерүче

Авария урынына якынлашуга һәм бер-берсенә чәкәләшеп туктаган ике машинаны, бераз алдарак туктап калган йөк машинасын күрүгә үк, Булатка барысы да ап-ачык иде. Классик очрак. Калкулыкка таба менгән «Форд», «КамАЗ»ны узам дип, каршы полосадан килгән «Киа»га бәрелгән. Чикләүче билгеләр юк, әмма бу ситуациядә узгынга чыкмаска кирәклеге азмы-күпме тәҗрибәсе булган теләсә нинди водительгә билгеле! Мондый типтагы аварияләр елына йөз булмаса да, дистәләрчә була. Шунысы гына аңлашылып бетми: нишләп «Киа» юл читенә чыгып йә кюветка ук очып төшмәгән? Мөгаен, һәр закончалыктан искәрмәләр була торгандыр... Әйе, барысы да ап-ачык: «Форд»ның водителе, туып өлгермәгән нарасыйны да исәпләсәң, өч кешенең гомерен өзгән. Ул, мөгаен, исерек тә булгандыр. Алай да булса, бетте инде аңа якты көн. Исән калганына үкенәчәк.

Ул шулчак як-ягына күз салды да, җаны өшеп китте: ике якта да офыкка тоташкан, кар күмгән киң яланнар. Никадәр иркенлек! Юл да ачык, бер машина да, кеше әсәре дә юк. Кирәк бит, үтерүче белән корбан пространствоның һәм вакытның бер киселешендә – бер ноктасында бер-берсен килеп тапканнар! Дөрес, юл тар. Уфага якын гына булса да, заманча юллар төзелеп бетмәгән, ике юнәлеш махсус барьер белән аерымланмаган. Кызганыч, юллар – илнең башын авырттырган бәла, ләкин бу авария ясарга хокук бирә дигән сүз түгел!

Аларга статистиканы җиткереп торалар: илдә аварияләр күп. Эчеп рульгә утыручыларга каты штрафлар, заманча юллар төзү, видеорегистраторлар үз эшен эшләми түгел: алар кими бара. Тик барыбер дә артык күп алар, артык күп! Аларда бик күп кешенең гомере өзелә. Бер елда – ун еллык Әфган сугышында һәлак булган солдатлардан да күбрәк. Димәк, күзгә күренмәгән сугыш уты ялмый Рәсәйнең иксез-чиксез киңлекләрен... Кем белән кем сугыша соң? Водительләр бер-берсе белән җитезлектә ярышамы, вакытны куып тотмакчылармы? Әллә инде барыбер дә койрыгын тоттырмас дөнья артыннан күз алартып куалармы? Абынып-сөртенеп, бәрелеп-сугылып... Үлеп-бетеп! Бу сорауларга җавап юк. Һәр авариягә бетмәс-төкәнмәс сәбәп-нәтиҗә чылбыры килеп тоташа. Булат шомланып, калтыранып куйды – гүя теге дөньяның салкын сулышы килеп кагылгандай, тәненнән салкын дулкын үтеп китте. Юк, болай булмый, эмоциягә бирелергә ярамый. Тойгы-хисләрне авызлыкларга, акылга таянырга кирәк, дип, үз-үзен ныгытты ул.

Ничек кенә булмасын, Булатның вазифасы һәм кешелек бурычы шуны таләп итә: гаеплене ачыкларга һәм аны суд алдына илтеп бастырырга! Гаепле кеше кәеф-сафа корып йөрергә тиеш түгел: ул тиешле җәзасын алырга тиеш. Руль артына утырганчы, югары тизлеккә салганчы йөз кат уйларга тиеш!

Тикшерүче сержантлар белән кул биреп исәнләште дә машиналарны әйләнеп карап чыкты. Ай-һай, дип башын чайкады. Каты бәрелгәннәр! Көне-төне гадәттән тыш хәлләрнең шаһиты булып, каешланып беткәнмендер дип уйласаң да, кайгыга күнегеп, йөрәккә боерып булмый, мондый хәлләр авыр тәэсир итә. Кичен хатынының энесе туган көнгә чакырган иде. Нинди туган

көн, нинди кәеф инде моннан соң? Берьюлы өч мәет! Аның районында мондый ЧПның күптән булганы юк иде.

Полиция машинасында тагын бер ир кеше бар иде. Булатның ул якка текәлеп каравын күреп, сержантларның берсе:

– «Форд» водителенең җизнәсе, – диде.

Ул арада теге ир дә, килеп, тикшерүче белән исәнләште.

– Тикшерүче Булат Гайсин.

– Мин – Әдип Карамовның җизнәсе Газиз.

– Авариянең шаһитымы?

– Юк, без соңыннан килдек.

– Аңлашыла, – диде тикшерүче.

Аңлашылганы шул иде: җизни кеше шактый үткергә, белемле кешегә охшаган. Ас кебек, авыздан чыккан һәр сүзне аулап бара. Ә менә вафат булган гаиләнең якыннарына хәбәр ителде микән?

Сержантлардан бу хакта белеште. Водительнең һәм хатынының телефоннарын, тикшерү максатында дип, алганнар, ләкин шалтыратырга өлгермәгәннәр.

– Хәбәр итәргә кирәк! – диде Булат.

Үзе машиналар янына килде. Их, ничек харап иткәннәр! «Форд»ы бөтенләй өр-яңа инде әллә? Кирәк бит, ә! Машинаның шәплегенә ышанган инде Карамов иптәш! Тә-әк, эксперт чакыртырга кирәк. Фотоаппаратын онытмасын. Протоколга теркәр өчен, бәрелешнең схемасын төзергә кирәк булачак.

Карамовның гаебе көн кебек ачык булса да, кызганыч, шаһитлар юк. «КамАЗ» шофёры берни күрмәгән, чөнки тәгәрмәчләрдән тузгып күтәрелгән кар һәм солярка төтене барысын да каплаган. Тагын шунысы: бәрелешү урынын кардан чистарттылар, тик асфальтта көпчәк эзе күренмәде!

Тиешле урыннарга шалтыраткалаганчы, Газиз янына яшькелт «Ниссан» килеп туктады. Аннан яхшы киенгән ханым төште. Карамовның апасы, мөгаен. Булатның күзе үткен, нәкъ шулай булып чыкты. Туганнары кадерле, дип уйлап алды Гайсин, теге ханымның, утка баскан мәчедәй, үзенә таба ашыгып атлавын күреп. Ярый, боларның энеләре исән. Ә вафат булган Рөстәмовлар моргта!

– Иптәш следователь! – Сулуы капкан ханым килеп тә җитте, тезеп, сөйләп алып та китте: – Мин Әдип Карамовның бертуган апасы булам. Авария хакында туганым миңа үзе хәбәр итте. Ә бу – минем ирем.

– Ничәдә? – дип, аны бүлдерде Булат.

– Иртәнге сигезләр булгандыр. Юк, мин сезгә телефонымнан карап әйтәм. Менә, карагыз, сәгать сигез туларга егерме минут кала шалтыраткан. Шалтыратты да: «Апа, машина җимерек! Авария! Мин «КамАЗ» артыннан гына бардым бит!», диде. – Ханым елап җибәрде. – Иптәш следователь, әйтегезче, безгә нишләргә хәзер?!

– Тынычланырга! Тикшерүгә комачауламаска! – диде Булат. Үзе уйлап алды: бик үҗәткә охшаган бу ханым!

Ханым белән аның ире ерак китмәделәр. Ханым, кесә телефонын алып, машиналарны фотога төшерергә кереште.

Булатның йөзе чытылды, ләкин эндәшмәде. Әйе, ялгышмаган, үҗәт ханым бу! Үзе дә, телефонын алып, берничә фото ясады.

Менә район үзәгеннән эксперт-криминалист килеп җитте. Җитди, күп сөйләшми торган егет. Үз эшен тиз генә башкарды да китәргә рөхсәт сорады.

Ул ясаган схемада бәрелешү урыны күрсәтелмәгән иде. «Да-а, – дип сузды

Булат үзалдына. – Болай гына булмый, авария җитди! Өстән ярдәм сорарга кирәк! Карамовның туганнары да карчыгадай бөтерелә. Күпме сынаганы бар: бик җиңел генә чишелердәй тоелган эшләр, гадәттә, нәкъ киресе була – очыкырыена чыгып булмый!

Янә бер сәгатьтән Уфадан яшь кенә егет килеп җитте. Бу – яңа гына институт тәмамлаган булса да, җитди вазифалы, катлаулы аварияләр буенча махсуслашкан эксперт иде. Ул, тәүге эш итеп, каршы полосаны җентекләп карый башлады. Чынлап та, тырышып эзли торгач, асфальтта яңа гына тырналган эз табылды. Димәк, бу эз – яньчелгән «Форд»ныкы! Үз полосасына чыгып утырганчы ул шушында әлеге «тамга»ны калдырган.

Ниһаять, дип җиңел сулады Булат, эзләгән – таба, ниһаять, офыкта яктылык күренде. Юкса, чынлап та аптырарлык иде: мондый хәтәр бәрелешүдән эз калмавы башка сыярлык түгел.

Эксперт егет, автокран чакыртып, авария моментын күзалларга кирәк, дигән тәкъдим дә әйтте. Булат бу тәкъдимне күтәреп алды. Әлбәттә, дөрес идея! Тимерне кызуында сугарга кирәк!

Сәгать икеләр җиткәнче булашсалар булаштылар, ләкин байтак эш эшләнде. Иң мөһиме, өч кешенең башына җиткән водительнең гаебе ачыклансын һәм исбат ителсен!

Эш урынына кайтып барганда да, шактый туңуга, ачыгуга карамастан, уйлары авария тирәсендә әйләнде Булатның. Тикшерүче буларак, объективлык кирәклеген бик яхшы белә ул. Ләкин күңел дигәнең дә бар бит әле. Ә аның күңеле – вафат булган гаилә ягында. Аларны яклашучы кеше юк, туганнары да күренми. Күз алдына туып та өлгермәгән нарасый килде! Менә ул сабыйны кем яклар! Туып та өлгермәгән сабыйны!

Булат эшкә якты уйлар белән урнашкан иде. Кимсетелгән, казага тарыган кешеләрне яклау – шундый иде нияте. Дөрес, эшли-эшли, яши-яши, акның – ак кына, ә караның кара гына була алмавына инанды. Кешеләрнең ялгышларын, йомшак якларын аңларга тырышып карый башлады. Шул кичерешләр белән бергә һөнәреннәнме, әллә кешеләрдәнме, күңел кайту кебегрәк хис тә яралды инде әллә. Күпчелектә бит эгоизм көчле. Күпчелек үзен, гаиләсен, күп дигәндә, туганнарын кайгырта. Хәер, хәзер туган дип тә бик өзгәләнмиләр әле. Күпме кеше ата-анасының искереп беткән йорты өчен туганнары белән өзешеп, эткә дә әйтмәслек сүзләр әйтешеп бетә. Үз рәхәте, үз бәхете өчен генә тырышалар. Шул тырышкан мәлләрендә башкаларның юлларына аркылы төшәләр, башкалар теләгәнне алданрак эләктереп өлгерәләр. Бу Карамов та шулай ашыгып китеп барган инде. Үз кибете бар, ди, бит. Тагын да ныграк баюда булган инде аның уе...

Булатта еш кына шундый хис туа: әйтерсең, алдындагы юл кинәт юкка чыга. Кая барырга да белмисең. Алай гына түгел, уңны-сулны да аермый башлыйсың, тәмам югалып каласың. Ул эгоист һәм үз мәнфәгатьләрен генә кайгырткан кешеләрнең кайсын якларга? Ничек дөресрәк була? Кемне кемнән якларга? Көчлерәгенме? Әллә көчсез кеше ягына басаргамы? Күңеле белән гомер бакый көчсезрәкләр, рәнҗетелгәннәр ягында булды ул. Тик күңел кушканча гына яшәү мөмкин түгел, ул законга таянырга тиеш. Закон нәрсә куша, нәрсә таләп итә – шуны эшләргә дә һәм... тизрәк пенсия яшенә җитеп, тыныч тормышка күчәргә! Алмагач үстерергә, токымлы этләр асрарга, чебиләр үрчетергә! Әйе, әйе, чебиләр үрчетергә. Аңлый, соңгы теләге – аталык инстинкты. Ничә ел яшәп, күпме дәваханә юлы таптап та үзләренең сабыйлары юк аларның.

Балалар йортыннан игезәк кыз белән малай алып үстерделәр. Шуңадырмы, балаларга карата кылынган җинаятьләргә беркайчан да тыныч күңел белән карый алмый. Кем-кем, ә ак-пакь, бер гөнаһсыз сабыйларга кул күтәрергә, аларның гомеренә кизәнергә беркемнең дә хакы юк! Күтәрә икән, ул кеше үзенә үпкәләсен! Дөньядагы иң кансыз, хаясыз адәм актыгы шул, димәк. Аңа бернинди кызгану да, яклау да булырга тиеш түгел! Монысы инде закон сүзе генә түгел, Булатның йөрәк сүзе!

## Гаеп

Өч атнадан Әдипне дәваханәдән чыгардылар. Аягындагы гипс алынмаган иде әле. Сөяк картрак булган саен, гипсны да шулкадәр озаграк тоталар бит. Сынган урын сулкылдап-әрнеп сызлый, тик моңа игътибар итәргә вакыты юк, башын авырдан-авыр уйлар баскан. Реанимациядә аңына килү белән сораган тәүге соравы каршыга чыккан машина пассажирлары хакында булды. Аларның үлүен, хатын кешенең авырлы булуын белгәч, кояшлы көннәр айсыз, очсыз-кырыйсыз төнгә әверелде. Дәваханәдән чыгу белән, әти-әниләре, туганнары янына барырга ниятләде.

Кайткан көнне үк ике як күршесе хәл белергә керделәр. Аларның күзләрендә сүзсез сорау иде. Таныш сорау иде ул. Хастахәнәгә хәл белешергә килүчеләрнең күзеннән дә сикереп төшәрдәй булып тора иде ул өнсез сорау. «Әдип, син кеше таптаттыңмыни? – ди иде бу күзләр. – Нишләп? Ник? Синме бу? Тумаган баланың гомерен өздеңме? Нишләдең син?»

Бу сораулар кычкырып әйтелмәде, тик алар һавада очты, алар аны изде, кул-аякларын богаулады. Һәм ул үзенең вафат булган кешеләрнең якыннары янына бара алмасын аңлады. Алар бу сорауны йөзенә бәреп сораячак. Әдип үзе дә белмәгән җавапны таләп итәчәкләр... Ташбака йә әкәм-төкәм үзенең кабырчыгына яшеренгән кебек, ул өенә, ихатасына качты, посты. Әйе, бу куркаклык иде, тик берни дә эшләп булмый, ул башкача булдыра алмый иде.

Ул урамга да аяк басмый башлады. Култык таягына таянып, аксаклап, көненә өч тапкыр абзарга мал карашырга гына чыга. Улы Шамил бәләкәйрәк, буыны ныгып җитмәгән, аңа авырлык килмәсен дип тырышуы. Таягы бозда таеп китеп, егылып, аягын янә авырттырды. Ярый, сынмады, тик температурасы күтәрелеп китте.

Тәне кызышып, тәненнән дә бигрәк җаны көеп яткан көннәрнең берсендә, авариягә бер ай дигәндә, тикшерүчедән повестка килеп төште. Почтальон сузган кәгазьгә кул куеп алып калды, тик барырга көче дә, хәле дә юк иде, бара алмады. Ә өч көннән аларның турына ят машина килеп туктады. Богаулавын-богауламадылар, ләкин тикшерүчегә утыртып алып барып, сорау алып, протоколга кул куйдырып, яшәгән урыныннан беркая да чыкмау турындагы распискага кул куйдырып кайтардылар. Булат Гайсин кузгаткан җинаять эшендә Әдип Карамов гаепләнүче сыйфатында иде.

Ул тикшерүченең сорауларын тәүдә юньләп аңлап та бетермәде. Тәне ут булып яна, башы чатнап авырта, үзе гүя томан эчендә.

– Барысы да ап-ачык бит: үз гаебегезне таныгыз да протоколга кул куегыз...

– Юк, мин гаепле түгел.

– «КамАЗ»ны узарга теләп, каршы полосага чыккансыз. Юл үргә таба һәм буранлап тору сәбәпле, каршыга килгән «Киа»ны күрми калгансыз!

– Юк, мин аермачык хәтерлим: «КамАЗ» артыннан гына бардым. Үргә таба

иде бит. Обгонга чыгарга уйламадым да. Күрән «Киа» үзе минем каршыга килеп керде!

– Карамов, уйлап карагыз әле: «Киа» ни өчен сезнең полосага чыгарга тиеш?

– Мин анысын белмим. Тик ул көтмәгәндә кинәт кенә алга килеп керде. «КамАЗ» тәгәрмәчләре кар тузгыта иде бит, бәлки, күрмәгәндер?

– Ник? Аның алдында бит юл ап-ачык! Ә сезнең алда – «КамАЗ»!

– Мин «КамАЗ» артыннан гына бардым! – дип, янә кабатлады Әдип.

– Ә сез гел алга гына карап бардыгызмы?

– Әйе.

– Бары тик алга гынамы?

Әдип ык-мык килде.

– Көзге аша артка да күз салдым.

– Арттан нинди дә булса автомобиль килә идеме?

– Юк.

– Сез артка караган арада, рульне йомшартып, каршы полосага чыгуыгыз мөмкин идеме?

– Белмим...

– Во, шул-шул! Ә шулкадәр ышаныч белән сөйлисез! Бәлки, сез идарәне югалткансыздыр?

Ул тынып кала... Инде ул үзен әллә ялгышаммы дип икеләнә башлады. Менә бит тикшерүче дә аны гаепли, күршеләр, кешеләр, хәтта Гөлчәчәк тә аны гаепле дип уйлый. Әллә наркозлардан хәтеренә зыян килдеме? Инде йөзенчеме, меңенчеме тапкыр, хәтерен камчылап, ул көнне күз алдыннан үткәрә. Ләкин ул бит аермачык белә: алдындагы «КамАЗ»ны узу уенда да юк иде! Аның бит беркайчан да рульдә алай хәвефле йөргәне булмады. Җитмәсә, өр-яңа машина белән!

Болар хакында тикшерүчегә сөйли, әмма Булат Гайсин кымшанмас кыя сыман.

– Нәкъ менә машина яңа булганга, үз-үзегезгә ышанып, обгонга чыккансыз да инде, Карамов! Йә, гаебегезне таныгыз да кул куегыз! Тикшерү ягына бассагыз, моны онытмагыз, судта искә алыначак, срок кимételәчәк!

– Срок?!

– Әйе, срок! Бала-чага булып кыланмагыз. Үзегез дә моны бик яхшы беләсез.

– Юк, мин белмәдем... – дип, авыз эчендә ботка пешерде Әдип. Тик күрә: Булат Гайсин аның сыңар сүзенә дә ышанмый. Һәм ул сорарга ашыга:

– Миңа ничә ел бирергә мөмкиннәр, гражданин тикшерүче?

– Сигез! Гаебегезне танысагыз, ышандыра алам, бу срок күпкә кимételәчәк!

Әдип башын иде. Берни дә дәшмәде.

– Онытмагыз, авария нәтиҗәсендә өч кешенең гомере өзелгән!

Ул янә бер сүз дә әйтә алмады.

– Йә, Карамов, таныйсызмы гаебегезне?

Әдип башын күтәрде. Булат Гайсинның күзенә туп-туры итеп карады һәм керфек тә какмый:

– Юк! Минем гаебем юк! – диде.

Тикшерүченең, сиздермәскә тырышса да, ачуы кайный. Түзә алмый, торып, әрле-бирле йөренә башлый. Аннан янә урынына килеп утыра. Һәм боздай караш, боздай тавыш белән:

– Мин сезнең файдага тырышып карадым, гражданин Карамов! – ди. –

Ләкин сез мин сузган ярдәм кулын кире кактыгыз. Бу – сезнең хокукыгыз... Сез бүгеннән башлап авылыгыздан беркая да чыгып китмәскә, телефоныгызны сүндермәскә тиеш буласыз. Теләсә нинди вакытта сорау алырга чакыртырга мөмкинбез.

***

Гөлчәчәк аны дүрт күз белән көтеп торган иде. Телевизор карап утырган җиреннән сикереп торып, ишек төбенә ашыкты.

– Нәрсә диделәр? – диде ул, өметләнү катыш кызыксынулы тавыш белән. Әдип култык таяклары белән бусагадан көч-хәл атлап керүгә, тиз генә табурет китереп куйды.

– Эшләр начар! – Ире, табуреткага утырып, сыңар пимасын салды. – Эшләр начар, әнисе! Мине гаепле итмәкчеләр.

Хатынының йөзе үзгәреп китте.

– Ә кредит?! Машинасыз да калдык, болай булгач, страховка да булмаячакмы?

– Кредит кредит әле, әнисе, баш исән булса, кайгырма, мал табылыр ул. Мине утыртып куярга мөмкиннәр!

– Күпмегә!

– Сигез елга!

Гөлчәчәк, учлары белән битен каплады. Аннан тиз-тиз, пулемёттан аткан сыман, ачуын тыя алмыйча, сөйли башлады:

– Үләм! Тереләй суйдың мине болай булгач! Әйттем, көт мине, төш җиткәч барырбыз, дидем! Ашыккан ашка пешкән, ди. Ни пычагыма таң тишегеннән чыгып чаптың?! Үзең пешергән ботканы үзең аша менә хәзер! Мин синең кредитларыңны түләргә җыенмыйм! Их, үтте бит гомеркәем кем белән! Әрәм генә булды бит җиләк кебек чакларым! Ул ике баланы мин ничек үстерим?!

– Әнисе, тукта әле, кызма! Син мине бүгеннән үк утыртып куярга җыендыңмыни? Тикшерү бетмәгән, Гайсинның сүзе суд карары түгел бит әле.

– Карга күзен карга чукымый. Алар бер сүзне сөйли инде ул, шуны белмисеңмени кырык яшькә җитеп!

– Мин адвокат яллыйм!

– Ха-ха-ха! – Хатыны кычкырып көлә башлады. – Ха-ха-ха, берне түгел, йөзне ялла, кем ышансын ди сиңа? Бөтен авыл сөйли бит, урамнан үтәр хәл юк, ирең өч кешенең башына җиткән, диләр. – Көлү елауга күчте: – Балаларның мәктәпкә барып күренерлеге юк, әтиегез кеше үтергәнмени, дип сорыйлар, ди.

– Гөлчәчәк, мин бит гаепле түгел!

– Син моны абзардагы тавыкларга чыгып сөйлә инде, яме, ышанса, алар ышанырлар!

– Тукта, син дә миңа ышанмыйсыңмыни?

– «Ышанмыйсыңмыни!» Конечно, ышанмыйм!

– Их, син, син дә мине аңламагач...

– Ә син мине аңладыңмы? Миңа кыен чакта минем хәлемә кердеңме? Кая хәлгә керү, башымнан көлдең!

– Нәрсә сөйлисең син, Гөлчәчәк! Нинди көлү ул? Кайчан?

– Миңа чокыр казып куюың? Сөяркәләрең?

Әдип йөзен чытты. Әллә саташа инде бичәсе?

– Әйттем бит инде: беркемем дә юк синнән башка, дип! Каян керде ул уй сиңа, аптырыйм!

– Ә чокыр?

– Кем уйлаган сине анда төшәр дип?

– Вот-вот, уйламыйсың шул. Уйларга кирәк шул! Ярар, вакытың күп булыр хәзер уйланырга!

– Гөлчәчәк! Син чынлап сөйлисеңме бу сүзләрне?

Ир, тәү күргәндәй, хатынына текәлде. Алыштырып куйганнармыни аны!

– Юк, уйныйм. Син әйтмешли, шаяртам гына! Менә миңа шаярта торган көннәр килде! Үзең казыган чокырга үзең төштең, җаныем!

Ул киенде дә ишекне шапылдатып ябып чыгып китте.

Әниләренә киткәндер. Соңгы елларда, көн аралаш булмаса да, атнасына берничә көне анда үтә бит аның, дип уйлады Әдип. Ишек төбеннән торып, чишенми-нитми караватына барып ауды. Шунда гына тәненең януын, авыз эченең кибүен тойды. Гөлчәчәкнең усал сүзләре турында уйланырлык та хәле калмаган иде аның. Торып, дару эчәргә кирәк, дип уйлады, тик тора алмады, яткан урынында тирән йокыга талды.

## «Соң булуы бар...»

Туган йортының капкасын ачып керде дә биек капканың эчке ягына сөялде хатын. Аһ, ничек арыды ул! Тәмам чиләнде! Бетмәс-төкәнмәс проблемалардан, эш-мәшәкатьләрдән. Бурыч-кредитлардан. Мәңге бетмәс киеренкелектән! Еллар буена үз-үзен тыеп, богаулап яшәүдән!

Күзе бакчага корылган тимер сеткага төште. Имән баганага көздән йолкынмаган үрмә гөлләр эләгеп калган. Үзен ул шул корыган, кышкы җилләр өзгәләп-талкып бетергән гөлләргә охшатты. Ул да бит иреннән таяныч тапмакчы булды. Әдип шундый ышанычлы, шат күңелле, бернәрсә алдында аптырап калмастай ир-егет булып тоела иде. Ә ул, әнә, төбе череп кыйшая башлаган багана кебек булып чыкты. Аңа таянып та булмый, ышанып та. Ул үзе, күзен мөлдерәтеп, бәләкәй генә, ябык кына хатыныннан ярдәм көтә...

Юк, Гөлчәчәктә андый көч юк. Көч аның үзенә дә бик кирәк. Әнисе дөрес әйтә, аның үзенең нервылары беткән. Ә бөтен авырулар нервыдан. Авырсаң, беркемгә дә кирәкмисең. Монысын инде ул бик яхшы белә. Теге вакыт чиргә тарыгач, аның хәленә керүче булмады да түгелме? Башын чиргә сала дип уйладылар, көлделәр.

Кияүгә чыкканнан бирле аның көне якты түгел, төне караңгы түгел. Иләс-миләс, эңгер-меңгер аның көннәре дә, төннәре дә. Яхшы хатын булырга тырышып та арыды. Яхшы килен булырга тырышып та ялыкты. Хәзер тырышмый да инде.

Туган йортында гына ул ирекле. Монда гына ул – чын Гөлчәчәк. Биредә генә аңлаучы, яклаучы кешеләр бар!

Әнисе газ плитәсе янында чажлатып тәбикмәк пешерә иде, этисе, диванга чалкан ятып, телевизордан Бразилия сериалы карый. Нинди идиллия, нинди рәхәтлек! Җылы, тәмле исләр, матур гөлләр, ачык күңелле әнисе, юк-барга көяләнеп бармаучы этисе. Булса, оҗмах йорты нәкъ шундый буладыр! Ник соң үзләрендә шулай түгел? Шулай булыр иде, ире гел эштә: йә кешеләргә печән чабыша, йә тракторы белән җир сөрә, йә осталыкка чыгып киткән. Беркемгә дә «юк» дия белми, беркемнең дә үтенечен екмый. Яшәп буламыни шулай! Кая анда утырып сөйләшү, рәхәтләнеп телевизор карау! Эш, эш, эш! Бетмәс-төкәнмәс һәм очы-кырые күренмәс эш!

– Әни! – дип, әнисен кочаклап алды ул. – Әни, безнең тагын проблема!

– Тагын ни булды? – дип сорады әнисе, табада соңгы тәбикмәген оста гына әйләндереп. – Әйдә, чәй әзерлик, табын янында сөйләшербез.

– Телефоннан әйткән идем бит, Әдипне тикшерүче чакыртты дип. – Гөлчәчәк бәләкәй чәйнеккә хуш исле һинд чәе, җиләк, бөтнек яфраклары салды. Өйгә җәй исе таралды.

– Онытып та торам, әйе, шуннан?

– Шуннан – шул, аны сигез елга утыртып куярга мөмкиннәр!

Әнисенең кулындагы тәлинкә чүмәләдәй өелгән майлы тәбикмәкләре белән бергә шуып төшеп китә язды.

– Бәй, син нишләрсең аннан?!

Бу сөйләшүне ишетеп, әтисе дә табын янына килде.

– Кит аннан, чынлап сөйлисеңме? – диде, кызына текәлеп карап. Йөзендә бер мускул селкенмәсә дә, чалара башлаган куе мыек очлары кыймылдап куйды, яшькелт күзләре зураеп китте.

– Соң, сезне алдап утыраммыни инде! – диде Гөлчәчәк, турсаеп. – Елардай булып кайтып керде.

– Шуннан, шуннан? – Әтисе, аның һәр сүзен келәшчә белән тартып алырга теләгәндәй, киеренкелек белән тыңлый иде.

– Тикшерүче шулай дигән. Аңа авылдан чыгып йөрмәскә кушканнар.

– Алай икән, алай икә-ән, – дип сузды әтисе. – Нишләргә безгә, хәлләр болайга киткәч?

Менә шуның өчен ярата әтисен Гөлчәчәк. Ул беркайчан да проблеманы хатын-кызга аударып калдырмый. Үзе уйлый, үзе эшли, үзе үк теләсә нинди проблеманың чишелешен таба. Армиядә алган һөнәрен бик ярата иде әтисе, гомере буе элемтәче булып эшләде. Телефон чыбыгы кайда өзелсә дә, сәбәбен юллап табарга кирәк бит, аптырап утырудан файда юк.

Әдип түгел инде: орчык буе хатыныннан ярдәм көтеп утырмый, йөкне җигелеп тартышыр, дип, әллә ниләр өмет итми! Ир булса, салып очырсын да тартып торгызсын! Ә Әдипнең үзен төртеп ексаң да елмаеп кына куяр. Талаша да белми бит ул, ичмасам! Бар белгәне – эш! Ничә ел бергә гомер итеп, һаман шуны аңлый алмый: әллә артык яхшы кеше, әллә артык юаш...

– Тә-әк, аны утыртырлар, сигез елдан әйләнеп тә кайтыр ул, чурт та булмас! Әниең дөрес әйтә, ә менә син нишләрсең?!

– Булмады бит бәхеткәе бердәнбер баламның! – дип елап җибәрде әнисе. – Кем уйлаган болай булып бетәр дип! Гаяз малаена бирер идемме болай булырын белсәм!

– Карчык, тукта әле, шыңшыма, – дип, аны шып туктатты йорт хуҗасы. – Монда елап кына файда юк, акыл белән уйларга кирәк.

– Аның кредитлары күпме бит әле!

– Вәт, менә сүзне шуңа бормакчы идем мин дә. Кредиттан бигрәк, ике катлы йорт, гараж, мунча, трактор, «МАЗ», кибет... Сез, тавык башлар, шуларны уйлыйсызмы?

– Уйлап нәрсә? – диде, иренең аны наданга санап сөйләшүенә эче пошып, хуҗабикә. – Аларны төрмәгә күтәреп алып китмәс инде!

– Ул китмәс-китүен. Ә үлгән семьяның туганнары акча таптыра башласа? Моральный вред, дип. Татарча әхлакый зыян була. «Кызыл таң» гәзитен укыганыгыз юкмыни, анда шулай язалар бит! Ишеткәнегез бармы шундый сүзне?

Аналы-кызлы, эчкән чәйләрен куеп, тынып калдылар. Бу уй аларның башына кереп тә чыкмаган иде. Чынлап та, шундый хәл килеп чыкса? Ул кредитлардан ничек котылырга, ике баланы ничек үстерергә?

– Суд приставларына барыбер, – диде ата кеше. – Минем үземнең ишеткәнем булды. Район үзәгендәге бер ирнең, өч балага алимент түләми качып йөргәне өчен, машинасын тартып алганнар, фатирына арест салганнар. Кияү төрмәгә керер дә утырыр ул. Җылы анда, ашаталар, эчерәләр. Сигез елдан бакыр биш тиен кебек ялтырап кайтып төшәр, ни хәлдәсез, мин кайттым, дип. Тик ул кайтуга өең дә булмас, мунчаң да, кияргә тишек ыштаның да, кызым-кымызым! Ә балалар? Аларны ничек үстерерсең, ничек укытырсың?

Гөлчәчәкнең йөзе тәмам караңгыланды. Нәрсә-нәрсә, мондый ук борылышка әзер түгел иде ул. Аның ничә ел берне биш итеп тырышканнары, интегеп, берәмтекләп җыйган дөньялары шулай бик тиз генә юкка чыгармы? Әлеге дә баягы шул хәчтерүш ире аркасында!

Ул, аптырап, әтисенә карады. Ә аның тирән күлдәй каракучкыл яшел күзләрендә өмет уты яна иде. Әһә, димәк, ул нишләргә кирәген беләӏ! Их, әти, әти, әле дә син бар, дип уйлап алды ул. Син исән булганда, мине беркем дә кыерсыта алмаячак! Аталы бала – аркалы, дип, юкка әйтмиләр.

– Мондый чакта бер генә юл кала, кызым!

– Нинди юл, әти?

– Аерылышырга!

Хатын тынып калды. Әтисенең дөрес җавап табарын белә иде инде ул. Тик, нигәдер, ул җавап башкачарак булыр кебек иде. Монысы башка сыймый торганрак хәл иде.

– Әйе, әйе, – дип, кызып-кызып, ата кеше сүзен дәвам итте: – Курыкма, кызым! Закон буенча, мал-мөлкәтнең яртысы синеке! Судка кадәр аерылып өлгерсәң, синең өлешкә беркем тия алмаячак. Әле балаларның өлеше дә бар! Үзеңнең дә, аларның да язмышын уйларга кирәк! Ашатырга, киендерергә! БДИ бирергә, укырга кертергә! Шулай түгелме?

– Әти, аерылышуны фиктив итеп тә була бит?!

Гөлчәчәк шулай дип ычкындырды да үз сүзләренә үзе үкенеп тә куйды. Әтисенең киявен өнәмәвен белә иде бит инде.

Ни сәбәпледер, әтисе кызып китмәде.

– Ничек булса да булсын, тик аерылышырга кирәк, әлеге моментта башка юл юк! – диде, ныклы ышаныч белән.

Бу сүзләр Гөлчәчәкнең күңелен кузгатып җибәрде. Аерылышу хакында үзенең дә уйлаганы булды бит. Тик... чын итеп түгел. Әдипкә ачу итеп кенә. Ә әтисе ул уйларны чынга ашырырга куша. Дөрес, тирәннән уйлаганда, аның сүзләрендә, чынлап та, хаклык бар. Бар гына түгел, ул дөрес әйтә, әлеге ситуациядә бу – бердәнбер дөрес юл. Дөрес, учак өемендә калган соңгы күмер кисәгедәй, сүрән генә тагын бер хис пыскый. Бу – жәлләү хисе. Ничек кенә булмасын, Әдип жәл. Ул гына түгел, бергә яшәлгән еллары, бергә үтелгән юллары жәл. Ничек итеп аларны бер тында чабып өзәсең! Алар бит бәгырьгә сеңгән, йөрәк түренә үрләгән! Әле этле-мәчеле яшәсәләр дә, гел алай түгел иде бит!

Бар иде Әдипнең мәхәббәттән исереп, аңа чәчәк гөлләмәләре ташыган чаклары! Беркем авылда йөргән кызына чәчәк ташымый, ә ул ташый иде. Бер гөлләмәсе шиңәргә өлгерми, ул икенчесен күтәреп килә иде. Гөлчәчәкнең, пәрдә артына яшеренеп, төнге урамны күзләгән, егетнең мотоциклы кайчан

тавыш-тынсыз гына килеп туктар инде, дип, сагалаган төннәре – алар да бар иде бит! Тавыш-тынсыз, чөнки аларның турына җитәргә дүрт-биш йорт кала двигателен сүндерә. Ә күрешү турында кичә кичтән сүз куешканнар – хәзерге кебек телефоннар юк!

Аның хисләнеп китүен әнисе сизмәде дә. Ире яккан учакка утын өстәде:

– Әйе, кызым, әтиең дөрес әйтә. Әле дә ул бар, нишләр идек!

– Белмим, – ди Гөлчәчәк. – Мин... мин куркам.

– Ач-ялангач калудан куркырга кирәк! – диде әтисе. – Авыз ачып торыр чак түгел. Чакыр бүген үк Әдипне. Курыксаң, үзем сөйләшәм.

– Юк, әти, тукта, ашыкма. Тагын бер кат ныклап уйлыйк әле!

– Иртәгә соң булуы бар! – диде әтисе. – Мин бит син дип тырышам, кызым, оныкларым өчен. Аңла, бу эшне тиз тотарга кирәк!

– Хет бер атна! – диде Гөлчәчәк. Аннан, әтисенең тагын нидер әйтүеннән курыккандай, тиз-тиз киенә башлады. – Мин кайтыйм әле. Сыер савылмаган.

– Уйла, кызый, – дип калды әтисе. Ачуы кабара башласа, ул шулай «кызый» дип эндәшә. – Соң булмагае!

– Кызым, тукта, мә, балаларга күчтәнәч! – дип, әнисе аңа җылы тәбикмәкләр төреп бирде, капкадан озатып калды.

Гөлчәчәк, әни җылысы, тәмле ис аңкыган төенчекне күкрәгенә кысып, үзләренә ашыкты.

## Янгын

– Пожа-ар! Пожа-ар! Әдипләр яна-а!

Йөрәге алынган Зәһидә ап-ак оекбаштан апрель урамына йөгереп чыкты. Шулай, өстенә дә, аягына да кимәгән килеш, түбән очка – улларының йортына таба йөгерде.

Ике-өч урам үтүгә, сулышы бетеп, бөгелеп төште. Янгын чыкканын ишетеп йөгерешә башлаган кешеләр аны күреп алды. Кемдер үзенең шәлен, фуфайкасын салып бирде. Ул, сулышы бераз тигезләнүгә, шул фуфайканы кияр-кимәс, шәлне ябар-япмас килеш куе кара төтен ургылган якка омтылды.

Аһылдап килеп җиткәндә, байтак халык җыелган иде инде. Кемдер тырма, сәнәк тотып килгән, кемдер чиләк тоткан. Ләкин ут чорнаган мансардалы биек йортка берничә чиләк су нәрсә инде! Батыррак егетләр, башларына өс киемнәрен чорнап, ут эченә йөгереп кереп китәләр дә берәр кием-фәләнме, урындык-фәләнме күтәреп чыгалар.

Ана, кулларын канат сыман җәеп, шул якка атылды.

– Җибәрмим! Кая керәсең ут эченә! Янасың бит! – дип, ачыргаланып, берсенең юлына каршы төште, икенчесенең кулынаябышты.

Аны тыңладылар. Аны читкә этәрергә кыймадылар.

– Күршеләрнең өенә су сибегез! Җил алар ягына исә!

Чыннан да, көньяктан искән язгы җил төтен болытын күршеләр ягына куалый, ул, куркыныч бер аждаһа сыман, янәшәдәге йортка да үрелергә маташа иде.

– Әдипне күрмәдегезме?! – дип сорады Зәһидә баягы егетләрдән.

– Малларны чыгарырга китте! – диделәр алар.

Зәһидә инде абзарга таба йөгерде. Улы, куалап, күзе-башы акайган сыерны абзардан чыгарып маташа иде. Зәһидә сыерны муенчагыннан тотып тарткач, малкай тыңлады, зур күзләрен акайтып, үрле-кырлы сикереп, ихатадан чабып чыгып ук китте.

– Килен кайда? Балалар? – дип куркынып сорады Заһидә.

– Гөлчәчәкләргә төшеп киттеләр.

– Әлхәмдүлилләһи шөкер! – дип, өстеннән тау төшкәндәй, җиңел сулады ана. – Аллаһыга шөкер, исән-сау икән барысы да! Тик син, улым, егетләрне искә ал, ут эченә кермәсеннәр!

– Документларны эләктереп чыга алдым! – диде Әдип, әнисенең күңелен тагын да күтәрергә теләгәндәй.

– Пожарныйларга шалтыраттыгызмы?

– Әйе. Алар килми бернәрсә дә эшләп булмый инде монда. Ишек ягыннан чыккан бит!

– Нәрсә булды соң? – диде ул, улының күзләренә карап.

– Мин өстә телевизор карап ята идем. Карале, мин әйтәм, күршеләр мунча яккан, төтене керә, димен. Нишләп атна уртасында якканнар икән, дип тә уйладым әле.

– Газың кабынып калган идеме әллә?

– Юк инде, әнкәй, син бөтенләй.

– Бәй, каян чыкты икән ул ут? – диде аларны тыңлап торган бер хатын, үтә дә кызыксынып.

– Йөрәгеннән! – диде дә Заһидә, тиз-тиз атлап, урам якка чыкты.

Анда янгын сүндерү машинасының килеп туктаганы күренде. Шөкер, күрше-күләнгә, абзар-курага, урамдагы киоскка үрли алмады ялкын, тиз сүндерделәр. Өй урынында бүрәнә өеме генә пыскып-төтәп калды...

***

Алар йортларын сатып алынган ихатага салганнар иде. Әлеге милектә бер иске генә, бәләкәй генә өй бар. Аны җәй көне файдаланалар, эссе чиллә көннәрендә Гөлчәчәк, яңа өйгә пар чыкмасын өчен, шулпа-фәлән, кызыл эремчекне шунда кайната иде. Яшәр өчен бөтен кирәк-ярагы эчендә. Әдип бер-ике көн әнисендә кунды да мичен ягып, шул өйдә яши башлады. Балалар янгын чыккан көнне әниләре белән картәтиләренә куна киткән килеш шунда торып калдылар.

Әллә нишләп, өйләре янганга артык кайгырмады кебек ул. Шулай тиеш булгандыр, дип, үзен-үзе юатты. Бу бәла беренчесен – аварияне аз булса да оныттырып торырлык сәбәп булды бугай.

Гөлчәчәк кенә янгыннан соң дәваханәгә кереп ятты. Куллары калтырап, йөрәге дерелдәп тора башлаган хатынны берсүзсез алып калдылар. Әдип ике мәртәбә хәл белергә барды. Теге барганда да, монысында да Гөлчәчәк елады да елады, палатада кеше дә булгач, юньләп сөйләшә дә алмадылар. Ярый, кайткач, утырып бер аңлашырлар әле.

Авыл башында автобустан төшеп калган ир апрель аеның җепшек юлыннан үзләренә таба атлады. Әниләренә кереп тормады инде, күз салып кына үтте. Юлда очраганнар белән исәнләште, хәл-әхвәл сорашты. Кемнең кемлеге авыр чакта беленә, ди. Шунысы аптыратты: бу юлы авылдашлары аңа кырын карамый кебек тоелды. Кем белән генә сөйләшеп тормасын, барысы да диярлек, «Кайгырма, баш исән булса, дөнья малы табылыр», дигән мәгънәдәрәк сүзләр сөйләп, аңа килгән бәла ачысын аз булса да җиңеләйтергә тырыштылар. Кулыннан эш килердәйләре, өй күтәрсәң, өмә ит, килербез, ярдәмләшербез, диделәр. Өмәләр элегрәк була торган иде, онытылып та бара инде алар. Менә бит, кирәк чакта анысы да искә төшә.

Кичкелеккә аш куеп җибәрде, сыерны сауды. Шамил аның янына куна килгән иде, маладис, малларны караган, тавыкларга җим салган.

Өйдә җылы, тәмле исләр аңкытып, симез каз шулпасы кайный. Тик хатын-кыз булмагач, өйгә ямь кунмый. Их, тизрәк савыксын иде Гөлчәчәк!

Төнлә как сәкедә әйләнә-тулгана озак кына уйланып ятты Әдип. Алга таба кайда яшисен уйлады. Төрлечә план корып карады. Бәлки, хатыны төп нигезгә күчәргә риза булыр. Элек шулай бергә-бергә яшиләр иде бит әле. Әтисе дә исән, сыялар, бер тавыш-тын чыкмый иде. Аңынчы «МАЗ»ын сатып җибәрер. Яшәп торырга, балаларга кием-салым алырга акча кирәк бит. Апасы, адвокат яллыйбыз, диде, аңа да чыгымнар кирәк булачак.

Өе янган кешеләргә район хакимияте агачка рөхсәт бирә, ди. Ул агачны кисеп, каезлап сатарга, акчасына, страховка акчасын да кушып, әзер коры бура алып була бит. Бер җәйдә үзе дә эшләп чыга аны, иптәшкә берәр оста булса. Шамил дә кул астына керер, өйрәнчеккә яхшы булыр.

Әнә шулай үзенчә зур-зур хыяллар корып куйды ир. Аларны хатыны белән дә бүлешәсе иде. Ул нәрсә дияр? Әллә аның кирпечтән саласы килерме? Кирпечкә дә риза Әдип. Бер елны җәй буе район үзәгендә бер түрәгә йорт салдылар. Кирпеч-бетон эшен шунда өйрәнде. Аңа эшне өйрәтәсе юк, кемнеңдер эшләгәнен бер карап торса – җитә, тагын да остарак итеп эшләп куя ала, нинди эшкә дә кулы ята.

***

Гөлчәчәкне дәваханәдән алырга күршесенең машинасы белән бардылар. Элегрәк аңа акча биреп торгалаганы булды, башка үтенечләрен дә кире какмый иде, шуңадырмы, берсүзсез тыңлады. Бензин хакын да алмады хәтта.

Хатыны гына, иске «Лада»га утырырга кыенсындымы, тегесе ишетмәгәндә Әдипкә:

– Тагын да искерәген таба алмадыңмы? – дип пышылдады.

Ир бу төртмәле сүзләрне колагына да алмады, Гөлчәчәкнең савыгып чыгуы аның өчен зур шатлык иде. Төрттерә башлаган, димәк, чынлап та терелгән! Аның хәтта шул төртмә телен дә сагынды бит ул.

Унбиш-егерме минутта алар авылга кайтып та җитте. Күршесе аларның ихатасы турына килеп туктады. Әдип багажниктан тиз-тиз хатынының әйберләрен ташый башлады. Рәхмәт әйтеп, яңадан ихатага керсә, хатыны өй нигезенә карап катып калган. Ул үзе, әллә инде көненә әллә ничә үтеп-сүтеп йөргәнгәме, йорты януга күнгән иде. Хыял илендә өметләр белән яшәде бит бу көннәрдә. Ә Гөлчәчәк дәваханәдә онытылыбрак торган кайгыны менә тагын өр-яңадан кичерде. Ыржаеп, тешсез авыз сыман ачылган баз, язгы пычрак белән буталып беткән күмер-корымлы такта-бүрәнә кисәкләре... Бер читтә өелгән чүпрәк-чапрак, кап-кара тәлинкә-чынаяк, мис-табалар...

Өстәвенә, «Лимитед-Интернейшенл»... Күпме өмет баглаган компания җитәкчеләре көннәрнең берсендә суга төшкәндәй юк булдылар да куйдылар. Телефонны алмыйлар, Интернеттагы битләре ябылды! Дәваханәдән бер көнне сорап чыгып, офисларына барып килгән иде. Шундый авыр чакта счётына бонус-фәлән килеп төшмәсме дигән өмете бар иде. Тик ябык офис ишеге төбендә үзе кебек өч авыл хатыныннан башка кеше юк. Алар ул көнне дүртәүләп нәрсәдер көтеп утырды-утырды да таралыштылар. Икенче көнне барса, ул офис бүлмәсен бөтенләй башка оешма арендага алып эшли башлаган. Ә бит Гөлчәчәк бу «Лимитед-Интернейшенл»га, кредитка алып булса да, тагын йөз мең сум акча илтеп бирде! Исәпләве буенча, бурычы да, бурычы

буенча процентлар да атна саен тамып торачак бонуслар хисабына бик тиз капланырга тиеш иде бит!

Ул тирә-ягына күз салды. Йа, Хода! Ни өчен?! Ни өчен ул шундый бәхетсез?! Ничә ел корган дөньяң күккә очсын әле! Менә бу чынаяк сервизын аларның туена Гөлчәчәкнең икетуган апасы бүләк иткән иде. Кунак килгәндә генә тота иде, матурлык өчен шкафка тезеп куйган иде. Әнә коймага аның яратып кигән кышкы пальтосы эленгән. Кыйммәтле якасы өтелгән, буй-буй сары эзләр калган. Ул аны, Уфага барып, көн буе эзләп сатып алды. Әдип җилләтергә дип элгәндер дә онытгандыр инде – язгы яңгырда шәбәреп беткән... Ә болар – балаларның уенчыклары. Аю малаеның ярты ягы корымнан кап-кара булган, уенчык кавырсын машина, эреп, йомгакка әверелгән.

Әрәм булган дөньясын жәлләпме, үзен кызгануданмы, күзеннән берәм-берәм яшь тамчылары тәгәрәргә тотынды. Шулчак Ире аның аркасына орынды. Кочып юатмакчы булды. Хатын тупас-кискен итеп аның кулын этеп җибәрде. Менә ул гаепле! Ул! Артына ут капканны да сизмичә өске катта яткан! Ә Гөлчәчәк авыру килеш тә, хатын-кыз башы белән дә акча эшләргә тырышып йөргән булган иде. Шулай дип кредитка батты!

Эчендә пыскыган ачу күмерләренә җил өрдемени – бу уйлардан нәфрәт хисе тагын да яңарак көч белән яна башлады. Һәм ул соңгы берничә ел йөрткән икеләнүләренә, ниһаять, чишелеш тапты. Бер сүз дә әйтми борылды да капкага таба китте. Ире аның артыннан иярде. Ахмак кеше сыман елмаеп, кочагын җәеп сөйләнүен белде:

– Гөлчәчәк, әйдә, җәйге өй менә дигән яшәрлек.

Хатын дәшмәде. Ирнең кулыннан үзенең бәләкәй сумкасын йолкып дигәндәй тартып алды да, капканы ачып, урамга чыкты һәм, артына борылып та карамыйча, әниләренә юнәлде.

Әдипнең аның артыннан йөгерәсе, кайт, җаным, дип ялынасы килде. Тик баскан урыныннан кымшана да алмады.

## Тикшерүчедә

Матур җәйләр коточкыч тизлектә азагына якынлаша. Ә Әдипнең эше һаман бер урында. Ул үзе күптән кул селтәде. «Апа, туйдым, минем алга таба йөрергә көчем дә, теләгем дә юк, ни булса, шул булыр», ди. Үзен ни көткәнен дә уйламый, башы-аягы белән эшкә чумды. Тракторы белән кешеләргә бакча сөрә, машина кредитын түли.

«Форд»ны төзәтерлек түгел иде инде, аны сүтеп, детальләрен Интернет аша сатты. Тик шунысы: гаилә белән төшкән теге фотоны күпме эзләмәсен, тапмады. Суга төшкәндәй юк булды ул. Гаражда берәр кая куйдым микән, дип, актарып чыкты – юк, табылмады. Әйтерсең, шул югалган фотосурәт белән бергә Әдипнең бәхетле көннәре дә югалды, тормышында бәхетнең үзе түгел, исе дә калмады...

Тикшерүче белән Әминә берүзе тарткалаша. Нотариустан ышаныч кәгазе имзалатып, энесе өчен үзе йөри, аның исеменнән ходатайстволар, жалобалар, гаризалар яза, экспертизаларга чаба. Әйе, чак кына әзерлегең булмаса, мондый юлларны таптый алмыйсың. Ул үзе, мәктәптә җәмгыять белеме фәнен укыткач, законнар белән яхшы таныш. Җинаять кодексын, кызыл ручка тотып, кирәкле урыннарның астына сыза-сыза, яңадан җентекләп укып чыкты.

Әти исән булса, ул да шулай итәр иде, дигән уй ныклык бирә аңа. Әтисе Әдип

өчен җан ата иде бит. Ул – ике кыз арасында бердәнбер малай. Җитмәсә, төпчек! Энесен яклашу Әминәнең тормыш рәвешенә әйләнде дисәң дә була. Карчыга сыман бөтен игътибарын туплады, ана арыслан кебек, бөтен батырлыгын җыйды. Былтыр бөтен вакыты дәваханә юлын таптап үтсә, быел үзе турында уйлаганы да юк, быел тикшерү комитеты, прокуратура юлын таптый ул.

Аны инде хәзер прокуратурада таный ук башладылар. Районныкында гына түгел, Уфаныкында да. «Гаепләнүченең үз-үзен шулай яклавын тәү күрәбез», диделәр бер кабинетта. Андый ачыктан-ачык сөйләшүчеләр сирәк. Хокук сакчыларының күбесе – аз сүзле, һәр сүзне үлчәп, уйлап сөйли торган кешеләр. Хис-тойгыларын да белермен димә. Алар гүя кулга-кул тотынышып, боҗрага баскан. «Ал кирәк, гөл кирәк» уенындагы кебек. Син атылып йөгереп киләсең дә кысып җитәкләшкән кулларны өзмәкче буласың. Уен уйнаганда кулларны өзү берни дә түгел. Ә монда ул куллар корыч кебек! Боҗра-муенсаны өзәрлек түгел.

Менә бүген дә Булат Гайсин белән очрашу тәгаенләнгән. Әминә төгәл унда ишек шакыды:

– Мөмкинме?

– Мөмкин, – диде Гайсин, салкын гына.

Тавышыннан ук сизелә: кәефе юк. Яшь кенә булса да, артык җитди, артык җаваплы кеше бу Гайсин.

– Булат Кинҗәгулович, беләсездер, мин экспертиза нәтиҗәләре белән танышырга килдем.

Булат, шкафына борылып, кара тышлы калын папкадан өч битлек документны алды һәм сүзсез генә өстәлгә салды.

Әминә, ашыгып, кәгазьгә үрелде һәм башын укып та тормый, азаккы битен карады. Йөрәге «жу» итеп китте. Аңлавынча, нәтиҗә энесе файдасына түгел. Хәзер инде кәгазьне башыннан җентекләбрәк укырга тотынды.

Моны күреп, Булат, нервланыбрак:

– Кул куегыз да үз копиягез белән өйдә иркенләп танышырсыз, – диде.

Ханым:

– Гафу итегез, мин тиз... – дип, ашыгып-ашыгып, экспертның нәрсә язганын белергә тырышты.

Тикшерүче, канәгатьсезлек күрсәтеп, өстәл өстендәге папкаларны ачып-япкалады.

– Без тагын экспертиза үткәрүне таләп итәбез, – диде Әминә, ашык-пошык кына документны укып чыгып. – Монда да «Форд» астындагы эзләр исәпкә алынмаган! Ә алар бит фотоларда бар, ярылып яталар! Ни өчен эксперт аларны күрми?!

Булат кашларын җыерды:

– Апа, былтыргы кар быел юк бит инде ул!!!

– Фотоларда бар! – Әминәнең битләре кызарып чыкты. – Шуны аңлагыз: мин энемнең гаепсез икәнен исбатламыйча торып, туктамаячакмын!

– Бу – сезнең хокукыгыз!

– Әйе! – диде ханым да, нык итеп. – Без ахыргача көрәшәчәкбез!

– Ә мин шуны аңламыйм: ни өчен тикшерү юлында сез йөрисез? Ә энегез?

– Ул авылда. Малы бар, өе янды.

– Сез бит – акыллы ханым! Ә сез шуны уйламыйсызмы, – Булат, урыныннан торып, тәрәзә янына барып басты, – бу ситуация энегезгә юкка гына бирелмәгән. Урыслар әйтер иде: «Это – его крест», дип. Без әйтәбез, язмыш, дип. Сез,

аның язмышына тыкшынып, аңа тәгаенләнгән йөкне аңардан күтәрттермәскә тырышасыз. Бәлки, сез бу рәвешле энегезгә зыян гына эшлисездер?

– Мине экспертиза нәтиҗәләре борчый! – дип, сүзне үз ягына бормакчы булды Әминә.

Әмма тикшерүче, карашы салкынаеп, тавышында корыч чыңнары чыңлатып, үз сүзен сөйләде:

– Бәлки, сез энегездән бигрәк, үзегез өчен тырышасыздыр, Әминә ханым? Сезнең иптәшегез, белүемчә, мәктәп директоры булырга омтыла икән. Ә монда, аның кадерле тормыш иптәшенең сөекле энесе өстеннән суд булырга тора! Әлбәттә инде, эшне ничек тә судка алып барып җиткермәскә кирәк! Үлгән кеше үлгән, яклашып, таләп итеп йөрергә көчле туганнары юк, әти-әниләре хәлсезләр, картлар! Шулаймы?

Әминә тынып калды. Тикшерүченең сүзләрендә хаклык юк түгел иде. Тик ул хаклык Әминәнең үзенә башкачарак булып күренә.

– Әйе! – диде ул, әңгәмәдәшенең күзләренә туп-туры карап. – Мин эшнең судка барып җитүен теләмим. Әйе, минем ирем өчен карьера шактый мөһим. Тик сез шунысын исәпкә алмыйсыз: минем энемнең гаебе юк! Ни өчен ул булмаган гаепне үз өстенә алырга тиеш? Әйе, авариядә, кызганычка каршы, кешеләр һәлак булган! Бу – бик зур бәхетсезлек! Без өлешчә үзебезнең гаепне таныйбыз: әгәр ул көнне энем юлга чыкмаса, бәлки, бу хәл булмый калган булыр иде! Ләкин иртә белән җыенып юлга чыгып китү җинаятьме?

– Сез барып мәрхүмнәрнең әти-әниләреннән гафу үтендегезме хет?

– Мин бардым! – диде ханым. – Ул ир икенчегә өйләнгән булган. Беренче хатынын эзләп таптым. Мәрхүм водитель моңа кадәр ике авария ясаган, ГАИдагы танышы ярдәме белән генә правасын саклап калган икән. Юлның әле бер, әле икенче ягына чыгып очныбрак йөри торган гадәте булган. Боларны миңа шул беренче хатыны сөйләде. Һәлак булган яшь хатынның әти-әнисе янына да бардым. Алар мине өйләренә дә кертмәделәр. Алар Әдипне гаепле дип саный. Тик мин әйтеп киттем, «минем энем гаепле түгел», дидем! Алар бит аны бернинди исбатлауларсыз гаепли. Ләкин энемнең гаебе юк. Әйе, кызганыч, кешеләр һәлак булган. Әнием мәрхүмнәр рухына дип, көн-төн дога укый, Коръән чыга.

– Ә энегез?

– Аңа болай да авыр...

– Күрәсезме! – диде Булат Гайсин, имән бармагын өскә чөеп. – Һәм янә өстәл янына килеп утырды. – Монда сез йөрисез, тегендә әниегез хафалана! Ә энегез үзе нишли соң? Хатыны итәге астына качтымы?

– Ул... Ул хатыны белән аерылышып йөри, – диде Әминә, башын иеп.

– Дөрес эшли аның хатыны! – диде тикшерүче, үртәлеп. – Аңлыйсызмы, эмоцияләрне тыеп, читтән караганда, сезнең энегез – шулкадәр ихтыярсыз, куркак кеше! Эгоист! Ә сез, үзегез дә сизмичә, аның кубызына биисез! Бәлки, ул, хатыны белән фиктив рәвештә аерылышадыр? Мал-мөлкәтен конфискацияләүдән куркып? Ягез, култамгагызны куегыз!

Әминә, аптырап, күзләрен түгәрәкләндереп, тикшерүчегә карап торды. Яшь кенә килеш ничек мондый усал уйлар уйлый ала бу Гайсин? Һөнәре шуңа этәрәме? Һәр эштә явыз ният, һәркемдә җинаятьче күрә.

Култамгасын куеп, ручканы өстәлгә салып, урыныннан торды.

– Хушыгыз, Булат Кинҗәгулович. Ләкин минем сезгә тиздән тагын юлым төшәр дип уйлыйм! – диде.

– Бу – сезнең законлы хокукыгыз! – диде тикшерүче, башын күтәрми генә.

...Хатын авыр уйлар белән машинасына таба атлады. Район үзәгеннән авыл ягына илтүче юлга төшкәч, борылып, каен посадкасына кереп туктады. Бу хәлендә авылга әнисе, энесе янына кайтып керерлек түгел иде. Машинасын сүндереп, тышка чыкты. Быелгы җәй үтеп бара, аны күрмисизми дә калды кебек. Көтелмәгән вакыйгалар өсте-өстенә өелә генә торды, як-ягына карарга түгел, тын алырга да вакыты булмады кебек! Кайчан гына агачларның ботакларын яшел яфракчыклар сырып алган иде! Хәзер инде алар тупасланганнар, өсләренә тузан кунган, кайберләре саргаеп, җиргә үк төшеп яткан! Без дә шулай... – дип уйланды хатын, – без дә шулай картаябыз... Күңел ката, тупаслана, аңа яшәлгән еллардан, йөрелгән юллардан купкан тузаннар, пычраклар куна... Бәхетсезлекләр аны тырный, яралый. Яралар төзәлгәндәй булса да, аларның җөе кала. Кемнеңдер ул эзләргә саксыз йә махсус кагылуы була – алар янә кансырап сулкылдый башлый... Әнә, сөрелә башлаган камыллы басудагы сабан эзләре кебек... Җәй коры килгәч, кап-кара туфрак кантарлары актарылып-актарылып чыккан. Басуга уҗым чәчәрләр, язын биредә ямь-яшел хәтфә арыш күтәрелер. Ә аның яралы йөрәгендәге юл-юл эзләр башка. Алар гомер буена сызлар. Бәлки, вакыт дәвалар аларны. Бар да үтә, диләр бит... Их, быелгы барча бу хәлләр кайчан да бер онытылсын иде дә, элеккечә, гамьсез генә яшисе иде! Нинди күлмәк алыйм икән, ялга кая барыйм икән, дип баш ватып, оныклар чыр-чуына күмелеп, аларның мәшәкате белән мәш килеп...

Хыяллар матур булса да, чынбарлыкны алдау, аңардан качу мөмкин түгел иде. Кайтып керүенә әнисе белән энесе, өметләнеп, аңа төбәләчәкләр. Нәрсә дияргә? Дөресен әйтергәме? Әллә әйтми торып, яңадан экспертиза таләп итеп, гариза язаргамы?

Ул, төпченә торгач, тикшерүченең ник каты торганына төшенә башлады кебек инде. Тамчылап-тамчылап булса да, мәгълүмат килеп ирешә: авария булган көнне Уфадан чакыртылган эксперт гади генә егет түгел икән, әнисе бик югары урында эшли, ди. Егет схеманы үзенчә төзегән, анда энесенең автомобиле астындагы эзләр исәпкә алынмаган. Ул эзләр бары тик бердәнбер фотода гына күренә. Һәм Әминә белән Газиз аларны үз күзләре белән күрделәр. Схеманы ялгыш дип тану Уфадан чакыртылган экспертның хатасын тану булыр иде. Ә ул – яшь, зур перспективалы кадр. Аңа үсәргә, күтәрелергә кирәк. Аңа хата ясарга ярамый! Ясаганда да, хатасын танырга ярамый!

Ә Әдип – кечкенә кеше. Әдип тә, Әминә, Газиз, әнисе Заһидә дә – кечкенә кешеләр. Аларның язмышлары чишелмәс йомгак булып төйнәлгән, йомгакның чишелмәве тикшерү ягы өчен файдалы. Булат Гайсин да – кечкенә кеше. Аңа да үз урыны кадерле. Гаиләсе, балалары бардыр, аның да карьера эшлисе киләдер. Карга күзен чәүкә чокый алмый...

Тик Әминәгә чигенергә ярамый! Үлчәүгә энесенең, әнисенең, үзенең намусы, исеме куелган! Артка юл юк! Мөмкин булганның һәм булмаганның барысын да эшләргә кирәк! Бәлки, гәзиткә язып карарга кирәктер? Депутатларга мөрәҗәгать итәргә! Президент халык белән сөйләшкәндә, аңа сорау юлларга! Мөгаен, боларның барысын да эшләргәдер? Ә иртәгә тагын Гайсинга килеп, өстәмә экспертизага гариза язарга!

Телефоннан шалтыратып, бу уй-ниятләрен иренә сөйләп бирде. Ә Газиз, гариза язу уе белән килешсә дә, калганына әлегә сабыр итәргә

киңәш итте, ашыкма, әнисе, әлегә гариза язып кайт, аннан ныклабрак уйлашырбыз, диде.

Бераз ял итеп алган, уйларын тәртипкә салган ханым, янә машинасына кереп утырып, юлга коелган берәм-сәрәм сары яфракларны туздырып, авыл ягына юнәлде.

## Август

Август – муллык ае. Аягында нык басып торган ир уртасы кебек, юмарт һәм киң күңелле. Әдип теплицадан табак белән кыяр, кызарган помидорлар җыеп чыкты да аларны кечерәк капчыкларга тутырды. Иң тәмле алмалы алмагачның ботакларын селкетеп, бер чиләк алма җыйды. Балалары алма ярата бит, Диләрәсе бигрәк тә. Сыйланыр туйганчы. Койма буйлап тезелгән карлыганнарга карап, ачынып уйлап куйды: җыючы юк, сыгылып утыралар, кибеп бетәрләр инде. Төрле сорттан чүп үләннәре гаскәре баш калкыткан, тигәнәкләр котырып утыра, әремнәр чал башын чайкый, чәчәкнең заты да юк – хатын-кыз кулы тимәгәнлеге әллә каян күренеп тора. Әнисенең боларга вакыты җитми. Тутырган капчыкларны төрле яклап велосипедка асты. Җәяү барганчы барыбер дә җиңелрәк булыр. Өйгә кереп, алдан әзерләп куйган бүләген алып чыгып, аны түш кесәсенә салды. Әйтерсең лә яшь чагы: дулкынлана, каушый. Гөлчәчәк белән әйбәтләп сөйләшеп карарга иде аның исәбе. Әнисе шуны куәтли: «Ни дисәң дә, үз хатының, балаларыңның әнисе. Ир кеше бичәсен көйләргә тиеш инде ул. Хатын-кызның хәтере кыска, онытыр, йомшарып китәр», – ди. Аларның аерылышуларын әнисе Әдипкә караганда да авыррак кабул итте. Бик биреште, кан басымы уйнап, көн-төн даруга торып калды. Менә әле дә, үзе чебешләрен ашата, үзе улын күзәтә. Аны дәшми генә карашы белән озатып, эченнән догаларын укып озатып калды.

...Гөлчәчәк тә бакчада йөри иде. Чүп-мазар күренмәсә дә, җимеш-җиләкләре артык күп түгел.

– Гөлчәчәк! – дип дәште Әдип хатынына койма аша. Аны монда очратканына шатланып куйды. Өйгә кереп, әби-бабасының агу капкандай ачулы йөзләрен күрәсе килеп тормый.

Хатын, берәм-сәрәм алма өзгән җиреннән аны күреп, дертләп китте. Кулындагы сары кавырсын савыт төшеп китә язды. Үзенең каушавына үзенең ачуы килеп:

– Нәрсә? – диде тупас кына.

– Сөйләшәсе бар иде! – диде Әдип, аның кояшта янган йөзенә, матур беләкләренә яратып карап. Шундый сагындырган! Бернигә карамый, койма аша сикереп керәсе дә кочып аласы килә үзен!

Гөлчәчәк, башын иеп, бераз дәшми торды да, ачулырак кыяфәттә:

– Сөйләшәсен сөйләштек бит инде! – диде.

Әдип бик яхшы белә, бу – аның «әйдә, сайрап кара», дигән сүзе.

Бәләкәй капканы ачып, ихатага үтте дә, велосипедын эчтәге зәңгәр коймага сөяп, бакчага керде. Хатыны, алмагач ботакларын аралап, һаман алма җыюында булды.

– Гөлчәчәк! – дип, аңа якынайды Әдип. – Мин сиңа кечкенә генә бүләк алып кигән идем... – Түш кесәсеннән алтын алкалар салынган бәрхет тышлы кечкенә кызыл савытны алды. – Менә, тагып кара әле, килешерме икән? – диде, кыюсыз гына.

Гөлчәчәкнең күзләрендә кызыксыну кабынды, кулындагы савытны куеп, бәрхет тартмачыкны алып, ачып карады. Йөзенә, яңгырдан соң чыккан кояш кебек, елмаю нуры йөгерде.

– Рәхмәт! – диде. – Тик әле такмыйм, куллар юмаган.

– Гөлчәчәк! Әйдә, үзебезгә кайтыйк! – Әдип йомшак кына итеп ялынды. Үзе дә сизми, хатынының кызларныкыдай нечкә биленә үрелде.

Моңарчы ниндидер хисси дулкында йөзгән Гөлчәчәк, йокыдан уянгандай, сискәнеп китте. Карашы салкынайды.

– Кая? Җәйге өйгәмени? – диде.

– Син кайтсаң, мин барысын да яңадан корам. Күреп тордың бит, нигез инде әзер. Суд юлында йөрмәсәм, инде бура да утырткан булыр идем!

«Суд» сүзен ишетү белән, хатын тәмам чынбарлыкка кайтты. Әйе, ник җебеп төште әле ул? Алар бит инде законлы нигездә аерылыштылар. Суд шундый карар чыгарды: ихатадагы бөтен каралты-кура, җәйге өй, мунча, урамдагы киоск, сыерны Гөлчәчәк белән балаларга бирергә. Әдип өлешенә «МАЗ» белән трактор калды. Иргә ишекләре тутыгып, тәрәзәләре чатнап беткән «МАЗ»ын, тракторын әнисе ихатасына күчереп, үзе дә әнисе йортына кайтудан башка чара калмаган иде.

– Кирәкми! – диде хатын, карашында утлар уйнатып. – Интегеп торма. Минем анда аяк басачагым юк. Ул ихатаны сатарга куйдым мин!

– Их, алай итмәскә иде! – дип тешен кысты Әдип. – Ә киоскны нишләтәсең?

– Аны да сатам. Барыбер кеше йөрми. Авылда җыен кортка-сартка гына калып бара. Аларны ипи ташып ашатасы хәлем юк.

– Күпме көч салып ачкан идек!

Аның бу сүзләрен дә ошатмады хатыны.

– Салынган шул! – диде ачуланып. Кулында тотып торган бәрхет савытны күлмәк кесәсенә тыгып куйды. – Ә монысы элек түккән көчләр өчен булыр!

– Гөлчәчәк, кара әле, тагын ачуланышмыйк! Барысын да онытыйк та яңадан башлыйк! Кайтыгыз балалар белән, ә?!

Хатын эндәшмәде. Аннан, хәтеренә нәрсәдер төшеп, җанланып китте:

– Ә син әтидән сора! – диде. – Теге вакытта гафу үтенмәдең бит, менә хәзер үтен! Алай гына да түгел, син аңа оялмыйча кул күтәрдең! Ни хакың бар? Ялвар, кирәк булса, алдына тезлән! Әти сине гафу итсә, мин дә, бәлки, уйлап карармын!

Ирнең йөзе караңгыланып китте. Нәрсә, хатыны аңардан мунчала ясап, бау ишәргә җыенамы?

– Юк, – диде өзеп. – Минем аның алдында гафу үтенерлек гаебем юк!

– Во-во, – диде Гөлчәчәк, күзләрен кысып, усаллашып. – Синең беркем алдында да «гаебең юк»! Теге ир белән хатын да үзләрен үзләре таптатканнар! Мин дә чокырны үзем казып, үзем барып төшкәнмен! Ә син актан ак, пакьтән пакь! Каян килгән әүлия! Бар, кайт әнкәңә! Яшәгез икәү ике әүлия! Менә, өйрәтсен хәзер үзенең иркә малаен, күңеле булганчы! Туйганчы укынсын, ырымласын!

– Нәрсә сөйләгәнеңне колагың ишетәме? – диде Әдип тә, кыза башлап. Кемгә-кемгә, әнисенә сүз тидерәсе килмәде.

– Мин бик әйбәт ишетәм, тик менә син сакбайлангансың, – диде хатыны, бирешергә җыенмыйча. – Бар, бар, сыпырт моннан!

Әдип, ярсып, кураларны, карлыган ботакларын изә-сындыра, чыгар якка атлады. Велосипедына бәйләнгән күчтәнәч капчыкларын өзә-йолка дигәндәй

чишеп ташлады да урам як капкага юнәлде. Кызарып пешкән алмалар, тәгәрәшеп, бәбкә үләненә чәчелеп калдылар.

...Улының йөзе качканын күрү белән, Заһидә коелып төште. Ул капка төбендә почта тартмасыннан гәзитләр алып булаша иде. Кулындагы кечкенә юка кәгазьне яшермәкче булды. Тик өлгерә алмады, велосипеды белән килеп туктаган улы җәһәт кенә кәгазьгә кулын сузды. Соңгы арада андый кәгазьләр аларга еш килә һәм, кагыйдә буларак, берсе дә яхшылык вәгъдә итми иде. Монысын суд приставы җибәргән. Әдип аны укыды да, йөзен җыерып, велосипедын этеп, капкага юнәлде.

– Нинди кәгазь? – дип, әнисе, ашыгып, аның артыннан иярде.

– Суд приставыннан. Алимент түләмәгәнгә штраф язганнар.

– Бәй, син бит эшләмисең, нинди алимент, нинди штраф инде ул? – дип аптырады Заһидә.

– Эшләмәгән өчен шулай язганнар да инде, – диде Әдип. – Әминә апа әйткән гел дөрескә чыга. Шулай булыр, дигән иде инде...

– И Аллаһым! – дип, ике кулы белән башына ябышты әни кеше. – Ничекләр итеп түләрбез!

– «МАЗ»ны сатмый булмый. Сатарга да искерәк булса да җиңел машина алырга кирәк. КФХ ачабыз.

– Анысы нәрсә була?

– Крестьянско-фермерское хозяйство була ул, әнкәй. Мин Интернеттан карадым, югары оч Фәнүрдән дә сораштым инде. Ул әйтә, әйдә Чатра басуына икәү чәчәбез, үзем өлгермим, ди.

– Нәрсә чәчәсең инде? Аңа бит ашлыгы, ашламасы, соляркасы кирәк!

– Шуңа күрә «МАЗ»ны сатам, димен бит инде.

– Әй, улым, улым, бик җаваплы бит, тагын үз өстеңә йөк аласың. Шунда Уфадамы, Себердәме кереп кенә эшли торган эш юкмы соң? Хөкүмәт эшенә барыр да кайтыр идең, башың тыныч булыр иде. Үз эшең булгач, аны бит көн дә, төн дә уйларга кирәк, тынгылык күрмисең!

Улы:

– Син дә мине Себергә куасыңмы инде, әнкәй! – дип, үпкәләбрәк әйтеп куйгач, Заһидә башкача дәшмәде.

– Мин шәһәр кешесе түгел, әнкәй, беләсең бит инде, – дип, Әдип, өйгә кереп китте.

Карчык, аптырап, бәрәңге бакчасына юнәлде. Иелеп, колорадо коңгызларын караган булды, күзенә, кулына эләккән билчәннәрне, эт эчәгеләрен йолкыштырды. Үзе, йөрәге янып, улын уйлады. И бала, бала! Гөлчәчәге белән эшләре пешмәгәндер инде, сорыйсы да юк, дип әрнүле хисләргә батты. Инде нишләр? Хатын-кыз ялгызы даирешми ул. Елап эчен бушата, балаларына тотынып яши. Ташта – елан эзе, хатында ир эзе калмас, ди. Ә ир-атның, күктә очкан кош сыман, таянычы юк. Төшеп кунар оясы булмаса, бәрелеп-сугылып, каңгырып-адашып йөри дә кешелектән чыга... Аның улын да шундый аянычлы язмыш көтәме? Инде ары-бире начар уйлар кермәсен күңеленә!

Кем уйлаган, шундый хәлләр килеп чыгар дип. Әллә күз тидерделәр – улының гөрләп торган дөньясы, бер ел үттеме-юкмы, пыран-заран килде! Гаяз исән булса да, болай ук булмас иде. Ничек тә җаен табар, ирләрчә бер акыллы сүз әйтер иде. Ул вафат булгач, бөтенесе дә бозылды, түгәрәк дөнья кителде бит. Улы белән килен, бөтен булган маяга ике катлы йорт салып, башка чыгып киттеләр. Әнә шул башка чыкканнан соң, үзара килешә алмый башладылар!

Гаяз булганда, Әдип тә этисенең авызына гына карап тора иде, Гөлчәчәкнең дә артык сүзе ычкынмый иде.

Ичмасам, тикшерү эше һаман сузыла! Тәмам арыды Заһидә. Ул инде, дөресен генә әйткәндә, нәрсәгә дә әзер кебек. Сукмак читендә әрем күреп, шуның яфрагын өзеп капты. Әмма йөрәктәге янгынны әрем генә баса алмады, җаны сулкылдап әрни, бу әрнү басылырлык та, качып котылырлык та түгел иде.

– И Аллаһым! Син рәхимле-шәфкатьле! Баламның гөнаһлары булса кичер, аңа бу бәлаләрдән котылу юлы күрсәт! – дип, дога-теләкләрен пышылдый-пышылдый, өйгә керде.

Ул кергәндә, улы, ноутбугын кабызып, экранга текәлгән иде. Хәзер яшьләр көне-төне шунда карап утыралар. Әнә каршыдагы яшь гаилә дә сыер тотмый, тавык-чебеш асрамый, хәтта бакчаларына бәрәңге дә утыртмыйлар. Ул йортны ана капиталына сатып алып, былтыр күрше авылдан килеп урнашты алар. Беркөнне аларга кәҗә сөте бирим дип керсә, Заһидә аптырап китте: ир дигән кеше өстәлдәге телевизор кебек зур компьютерга текәлгән, кәрт уены уйный. Хатыны, корсагына ноутбук куеп, бот күтәреп диванда ята. Зур улларының кулында телефон, төймәләренә еш-еш баскалый. Бишектә яткан бәби малай гына, түшәмгә карап, үзалдына нидер гыгылдап яткан була. Аның белән сөйләшүче дә, аңа игътибар итүче дә юк. Әстәгъфирулла, дип уйлады Заһидә. Ничек яшәмәк кирәк болай? Ир Себердә эшләсә ни, ул хатын мал асраса, бакча караса, иш өстенә куш булмас иде микәнни? Бала үстергәндә, ай, күп кирәк бит: ризыгы да, кием-салымы да... Аның картәнисе сөйли торган иде, ахырзаман җитсә, кешеләр кузгалмый-селкенми бер почмакка карап утырырлар, дип. Почмактагы ул әйберне башта телевизор, дип уйлаганнар иде. Анысы бер бәла булган икән әле. Ә бу компьютер дигәннәре тагын да харабрак... Йота бит бәндәләрне үз эченә...

Әдипнең ашыгып ноутбукка тотынуының сәбәбе бар иде шул. Үткән атнада «Сабакташлар» челтәренә ул үзенең яңа фотоларын куйды. Печән чапканда телефонга гына төшелгән фоторәсемнәрне, нишләптер, интернет-дуслары бик яратты. Атна эчендә йөздән артык «класс» җыелды. Әллә монда күптән кергәне булмаганга, үзен сагынып өлгергәннәр, белмәссең.

Ул да түгел, күрше районнан бер матур яшь ханым комментарий язган: «Беләсе иде, бу матур егетнең уенда ни икән?» – дигән, дуслашырга тәкъдим юллаган. Гөлчәчәк белән бүгенге сөйләшүдән соң бөтен өметләр киселде. Бүгенгә кадәр, бәлки, аралар җылыныр әле, дип өмет баглый иде. Тик хатыны берничек тә җайга килерлек түгел. Бер кискән икмәк ябышмый, диюләре шушыдыр инде. Әдиптә дә бар бит горурлык!

Кайтканда, аның хәтеренә нәкъ шушы комментарий килеп төште. Теге ханымга җавап язачак ул. Исеме дә матур – Гөлшат!

«Сабакташлар»да Гөлшатның битен эзләп табып, аның белән «дуслашты» һәм, аның: «Беләсе иде, бу матур егетнең уенда ни икән?» – дигәненә каршы болай дип хәбәр язды:

– Сәлам, Гөлшат! Инде егет чаклар үтсә дә, егетләрчә уй йөртәбез!

Гөлшат онлайнда иде, аның хатын көтеп кенә торгандай, җавап килеп төште:

– Минем сезнең хакта күбрәк беләсем килә, Әдип! Вакытыгыз булса, үзегез хакында язсагыз иде!

Әдип уйга калды. Нәрсә дип язарга? Төймә басып түгел, балта-көрәк тотып күнеккән калын бармаклары, клавишаларны көчкә эзләп таба-таба, әкрен генә сүзләр тезде:

– Башта минем үземнең сезнең хакта беләсем килә!

– Авылда фельдшер булып эшлим. Менә әле дә пунктта утырам. Бүген, Аллага шөкер, авырулар бөтенләй юк. Әби-сәбиләр өйләрендә генә ята бугай. Алар көзен-кышын күбәя башлый. Кызыма унбиш яшь. Ирем, аңа биш яшь тулгач, авариягә очрап вафат булды.

– Мин – балта остасы, – дип язды Әдип. – Хәзер агроном һөнәрен өйрәнергә йөргән көн. Хатын белән аерылыштык. Ике балам бар.

– Без икебез дә – сыңар канат икән... – дигән җавап килде Гөлшаттан.

Ирнең күңеле йомшап китте. Ничектер, үз хәле турында читтән бәһа ишетү авыррак... Әйе, сыңар канат шул...

– Сезнең пункт ничәгә кадәр эшли? – дигән сорауны җыйды ул ноутбук төймәләрендә.

– Бишкә кадәр... Ә нигә?

– Болай гына.

– Әллә авырып торасызмы?

– Әйе шул.

– Кай төшегез авырта?

– Бөтен җирем дә. Йөрәк сызлый, теш сыкрый, баш чатный, буыннар каткан, бил кәкрәйгән!

– Ай-һай, симптомнар хәтәр икән! Диагноз куеп бетерерлек түгел!

– Менә шуңа сезгә барып чыгам әле! – дип язды Әдип, кызып-кызып. – Көтегез!

– Бүген үкмени?! – Гөлшаттан аптыраулы «смайлик»лар яуды.

– Хәзер үк! – диде Әдип, һәм, сайттан чыгып, ноутбукны сүндерде. Йөгереп чыгып, «МАЗ»ын кабызды да Гөлшатларның авылына китеп тә барды.

Сайттагы фотосына караганда да чибәррәк иде Гөлшат. Матурлыгыннан бигрәк Әдипне аның йомшак холкы әсир итте. Сөйләшкәндә гел елмаеп кына тора, күзеннән, йөзеннән нур чәчелә кебек. Ә тавышы сандугач сайравына тиң. Бу тавышны көннәр, төннәр буена тыңласаң да ялкытмас кебек, киресенчә, аны гел ишетәсе генә килеп тора. Хатын да аны тәү күрүдә үк ошатты сыман. Әйтерсең, ун ел буе аның җавап язарын көтеп торган.

Мәктәп укучысыдай, башы-аягы белән гашыйк булганын сизми дә калды ир. Тик, авызы бер пешкәч, мәхәббәт дигән хиснең, хатын-кыз дигән затның ягымлы гына түгел, көйдерүче-яндыручы икәнен дә белә иде ул. Гөлшатлар авылыннан чыгышлый, биш чакрымлы озын урамның очында туктап, эскәмиядә утырган бер әбидән юл сораган булды. Әлбәттә инде, авылның фельдшеры турында белешергә дә онытмады. Әбиләр – авылның «Яндекс»ы белән «Гугл»ы инде ул – карчык минуты-секунды белән бөтен мәгълүматны чыгарды да салды:

– Гөлшатмы? Аның кебек әйбәт хатын районда юк! Кулы шифалы аның. Чиреңне бер карау белән белә. Даруы шунда ук килешә! Инде кияүгә чыгып, китеп бара күрмәсен, дип теләп кенә торабыз!

– Ул кияүдә түгелмени?

– Ире үлгәч, бүтән чыкмады. Кызын үстерде менә дигән итеп. Кызы да үзе кебек медицинскийга җыена, диләр бит. Ә син үзең кем буласың әле? Күрше авыл Радик малае инде әллә? Нишләп йөрисең?

Әбинең сораулары күбәйгәнче, Әдип, саубуллашып, китәргә ашыкты:

– Әйе, шул кеше инде мин! Ярар, апа, рәхмәт, исән бул! – дип, машинасына таба атлады.

## Туй

Заһидә апаның йорты бүген гөр килә. Ачык тәрәзәләрдән Элвин Грей, үзебезчә әйткәндә, Радик Юлъякшин дигән Уфа егетенең «Уфтанма» дигән җыры яңгырый.

Уфтанма, гомерләр яз кебек үтә, дип,
Чал чәчең күрсәң дә, уфтанма.
Яз килә дә китә, гомер шулай үтә,
Уфтанма, уфтанма, уфтанма...

Капка төбендә бәйрәмчә киенгән бала-чага үз уеннарын уйный, телефоннары белән мактаныша. Өлкәннәр өйдә. Мулла бабай никах укып кайтып киткән, инде туй мәҗлесенең, кем әйтмешли, «рәсми булмаган» өлеше башланган. Әдипнең ике апасы, ике җизнәсе, аларның балалары, Заһидә апа, Гаяз абыйның туганнары, кода-кодагыйлар җыелган. Бу туйда Гөлчәчәк белән аның әти-әнисе генә катнашмый. Капка төбендә шатланышып уйнаган балалар арасында – Диләрә, табын янындагы үсмерләр арасында Шамил дә юк. Аларны ияртеп, Гөлчәчәк Уфага, зоопаркка китте.

## Соң түгел!

Әдипнең эшен район үзәгенең шактый искерә төшкән, күптән ремонт күрмәгән хөкем бинасының утырышлар залында карадылар. Бик күп судларның шаһиты булгандыр бу лагы кырылган паркет идәннәр, буявы коела төшкән агач рамнар, урыны-урыны белән куба башлаган саргылт штукатурка... Ә җиһазга акча бүленгәндер, күрәсең: кызыл дерматин урындыклар, заманча өстәлләр өр-яңа.

Утырыш иртәнге унда башланырга тиеш иде, шулай булды да. Тиешле кешеләрнең барысы да тиешле вакытка җыелып беттеләр. Башка бик күп утырышлардагы кебек, судья Хәкимова да, дәүләт гаепләүчесе прокурор Харитонов та җитди һәм эшлекле кыяфәттә иделәр. Алар икесе дә инде урта яшьтән өлкәнрәк, тәҗрибәле. Караласы эш белән яхшылап танышканнар, чөнки Карамов эше, башка шуңа охшаш эшләрдән озакка сузылуы, апасының энесен актив яклашуы белән телгә менгән иде. Әнә бит, документлар, протоколлар тупланган томнар тау сыман өелгән. Ә ул тау эчендә асылташлар түгел, кан-яшь, аһ-зар... Кеше гомерләре, кеше язмышлары... Район, республика гәзитләрендә дә мәкаләләр булды, авария хакындагы сюжет шул көнне үк телеэкранга менде. Бу аңлашыла да, авария җитди: ике кеше, дөньяга туып та өлгермәгән сабый һәлак булган!

Әнә – вафат булган шофёрның сеңлесе. Уртача буйлы, шомырт кара кыска чәчле, кара кысалы тар күзлек кигән бу ханым иртән үзен шактый агрессив тотты. Утырыш башланганчы әле, коридорга килеп керү белән, тирә-якны тынгысыз карашы белән айкады һәм, Әдипне күреп, аның каршына килеп басты, өстенә очып кунардай булып:

– Озак йөрдең иректә! Син бит – кеше үтерүче! Синең урының – рәшәткә артында! – дип кычкырынды һәм, кызарынып-бүртенеп, күзем күрмәсен, дигәндәй, ишек төбенә барып басты.

Әдип, барысына да әзер булырга, каты-нык торырга дип әзерләнеп килгән иде. Шулай да бу сүзләр, өстенә бозлы су сипкәндәй, гәүдәсен куырып алды.

Һәлак булган яшь ханымның әтисен ул тәү тапкыр шушында, суд залында гына күрде. Әнисе, кан басымы күтәрелеп, утырышка килә алмаган. Ябык кына, озынча буйлы әти кеше авыр сабыр холыклылардан иде, ахры. Аның тирән сырлар баскан, авыл кешеләрендә генә була алганча, кояшта янган, җилдә какланган йөзенә карап берни дә белеп булмый. Тик шунысы ачык: ул кызының үлемен бик авыр кичергәндер, иңнәре нәкъ шул авыр кайгыдан басылгандыр, карашы шуңа шулкадәр авырдыр. Судьяның сорауларына ул өзеп-өзеп кенә, берәр-икешәр генә сүз белән җавап бирә барды. Әдипкә борылып та карамады, аларның карашлары бер тапкыр да очрашмады. Бусы тагын да авыррак иде. Бу сүзсезлек, бу авыр сабырлык Әдипнең дә иңен таш булып баса иде кебек.

Шуңа күрә дә ул суд эше башланганда була торган формаль мәшәкатьләрдә үзен бик тынгысыз тотты. Хәтта адресын әйткәндә дә ялгышты, көннәрне бутады. Тирләп-пешеп, бертуктаусыз маңгаен, җилкәсен сөртте. Ярый әле Әминә апасы кичтән кесәсенә кулъяулык салган булган.

Әдипнең адвокаты Уфаныкы иде. Шактый күп эшләрдә үз сүзен үткәрә алган, калын гәүдәле, чал чәчле, күзлекле абзый иде ул. Аның төп сыйфатын саклык дип билгеләү дөрес булыр иде, мөгаен. Ашыкмый, һәр сүзен үлчәп, уйлап сөйли. Кулындагы кәгазьгә күз дә салмый. Башкаларны яхшы итеп тыңлый белә. Аның чыгышы экспертиза нәтиҗәләренең каршылыклы икәнлегенә, тикшерү эшен алып барганда, схемалар, протоколлар төзелгәндә, байтак ялгышлар җибәрелгән булуына нигезләнгән иде. Эшкә теркәлгән, тәгәрмәч эзе төшерелгән бердәнбер фото да, көчле дәлил буларак телгә алынды.

Гаепләүче Харитонов исә – үз-үзенә ышанган, акыллылыгы йөзенә чыккан мөлаем кеше – аварияныӊ типик булуына басым ясады, «Киа»ның каршы якка чыгарга сәбәбе юклыгын, аның алдында юл ачык булып, хәрәкәткә комачау тудырмавын ассызыклады:

– Логика белән уйлап карагыз: «Киа» водителе алдында чиста полоса, юл түбәнгә таба, ә «Форд»ның алдыннан авыр йөк машинасы бара! Кем обгонга чыгарга тиеш? Әлбәттә, «Форд»! Барча фактлар, ике экспертиза нәкъ шуны исбатлый!

Судья Хәкимова, вазифасына килешкәнчә, һәркемне дә игътибар белән тыңлады. Аның үтә сынаулы карашы Әдипне гүя үтәли тишә иде сыман. Әмма ул ашыга һәм нәрсәгәдер борчыла иде сыман. Берничә мәртәбә алдындагы Җинаять кодексын ачып карады. Сорауларын битараф халәттә бирергә тырышса да, ниндидер бер мизгелдә Әдип барысын да аңлап алды. Судья сораулар бирә, ләкин инде бу сораулар сорау түгел, гаепләү булып яңгырыйлар иде. Алардан Әдип үзен көткән киләчәкне тоеп алды! Бу мизгелгә кадәр өмет бар иде әле. Әле нәрсәнедер үзгәртергә соң түгел кебек иде... Инде бетте.

Инде ул утырыш барышын игътибарлап карамый-тыңламый да башлады. Барысы да ачык, хәл ителгән! Ләкин спектакль бара, тамашачылар ишетергә тиешле сораулар, тиешле җаваплар яңгырый. Ә һавада инде хәл ителгән карар «йөзә»... Ул карар судьяның тынгысыз карашына язылган, Харитоновның акыллы йөзендә чагыла, адвокатның тыныч кыяфәтеннән беленә... Карар Әдип файдасына түгел. Иң гаҗәбе – Әдип моңа кайгырмый. Ул аның шулай буласын белә, көтә иде кебек инде. Һәм ул язмышына риза.

Әминә апасы әле моны белми. Ул әнә, гадәтенчә, кабалана-кабалана, тирләп-пешеп, үз исбатлауларын китерергә тырыша. Әйе, ул чыгышын әллә кайчан, айлар буена алдан әзерләгән. Тик юкка... Болар бар да бушка...

Судның булачак карарын мәрхүмнәрнең якыннары әле белми. Шофёрның

сеңлесе, көйдердәй булып, әледән-әле Әдипкә каш астыннан утлы-нәфрәтле караш ташлый. Кызын, туып та өлгермәгән оныгын югалткан абзый, кайгылары, хәсрәтле истәлекләре актарылып, тагын да ныграк бөкрәйгән, башы тагын да ныграк иелгән...

Хәлләрнең шулай тәмамланасын әнисе дә белгәндер. Белгәнгә күрә, моны кабул итәргә теләмәгәнгә күрә, бу дөнья белән алыш-бирешен өзәргә ашыкты ул. Юкса күтәрә алмас иде бу хәбәрне! Йөрәге ярылыр иде...

***

Әдип Гөлшат белән кичәге сөйләшүне хәтерләде. Төн буе керфек тә какмый сөйләшеп чыкты алар. Яшерер нәрсә юк, алар тәҗрибәсез яшь егет белән кыз түгел.

– Көтәрсеңме? – диде ул, караңгы булса да, йөзен Гөлшатның куе, хуш исле чәчләренә яшереп.

– Ничек инде көтмим? – дип, сорауга сорау белән җаваплады хатын.

– Бик озак булса дамы?

– Гомер буена да! – Бераз торгач тагын өстәде. – Мин бит инде болай да шундый озак көттем сине!

– Сиңа безнең йортта торырга кирәк булачак, Гөлшат! Нигезне суытырга ярамый.

– Мин риза...

– Миңа синең шушы сүзең кирәк иде! Рәхмәт, Гөлшат! Тик син курыкмассыңмы?

– Мин бернәрсәдән дә курыкмыйм! – диде хатын. – Мин Аллаһы Тәгаләдән генә куркам. Без монда вакытлыча гына! Ә аннан соң безне мәңгелек көтә! Анда нахак та, газап та юк! Барысы да ап-ачык! Син дә көяләнмә!

– Мондый сүзләрне каян беләсең? – дип, аптырап, сорамыйча булдыра алмады ир.

– Акыл иртә керде бит, – Гөлшатның елмайганы сизелде. – Фельдшер булгач, бала туса да, кеше үлсә дә, миңа йөгереп киләләр. Курыкмаска өйрәндем. Төннәрем дә ялгыз иде – уйланырга вакыт җитәрлек булды.

– Син миңа ышанасыңмы соң? – Әдип бу сорауны бирми булдыра алмады.

Гөлшат эндәшмәде. Йомшак кулы белән аның ябык чигәләрен сыпырды.

– Ышанмасам, мин монда ятмас идем... – диде.

– Гөлшат... – диде ул бераздан. – Басу-кырларыбызны ташламаска иде...

– Бер эшкә дә соң түгел! – дип, аны хуплады хатын. – Шул исәптән, агроном булырга да!.. Соң түгел! Без әле синең белән мәчет салачакбыз. Башта – сезнең авылга, аннан – безнекенә!

***

Судья хөкем карарын укый башлады. Әдип, күтәрелеп, Гөлшатка карады. Күзләр очрашты. Хатынның йөзендә балкыган тынычлык, якты нур, гүя, аның йөрәгенә дә күчте. Аркасы турайды. Җиңел сулап куйды. Һәм, хәтеренә мәңгегә сеңдерергә теләгәндәй, аңа йотылып карады. Тәмам бетеренгән, йөзе качкан апасына да томырылып бер карап алды. «Апам, рәхмәт сиңа!» дип әйтәсе килде...

Менә аңа соңгы сүз бирделәр. Ул күкрәген тутырып сулыш алды да соңгы сүзләрен әйтте:

– Кичерегез мине, тик минем гаебем юк!

## Дилбәр Булатова. «Соң түгел»

«Башкорт ягы»нда яшәүчеләрнең хис-кичереш тирәнлеген, иҗади талантын, осталыгын расларга теләгәндәй, шушы як татар әдәбиятын матур әсәрләр, милли әдәбиятыбызда булмаган күренешләр, яңа исемнәр белән шатландырып тора. Дилбәр Булатова да – шулардан. Соңгы елларда Татарстанда да аның исеме күренә башлады. Инде менә журналда әдибәнең «Соң түгел» повесте тәкъдим ителә. Әсәр күп кенә сыйфатлары белән игътибарны җәлеп итә.

Укыла! «Башкорт ягы»нда иҗат ителгән әсәрләргә хас булганча, теле матур, ачык, бай! Татар әдәбияты традицияләрендә, укучыга әхлакый фикер, мөһим идея җиткерә: тормышны яңадан башларга – соң түгел, гафу үтенергә – соң түгел, башкаларга ярдәм итәргә – соң түгел дип дәшә аның авторы.

Повесть безнең заман турында сөйли. Яратышып өйләнешкән, балалары үсеп килгән Әдип белән Гөлчәчәк тормышында мәхәббәт, үпкәләргә күмелеп, югалса да, гаилә яшәвен дәвам итә. Әмма Әдипнең авариягә очравы, шул авариядә өч кешенең гомере өзелеп, ирнең гаепләнүе хәлне үзгәртә: алар аерылышалар. Әдип үзен аңлардай яр – Гөлшатны таба. Ирнең апасы Әминә энесенең гаепсезлеген исбатлау өчен күп көч куя, ләкин ситуация алар файдасына булып чыкмый. Вакыйгалар суд залында төгәлләнә: язучы әйтмәсә дә, Әдипне акламаулары тоемлана. Аның гафу үтенүе дә – гаебен тану түгел, бәлки гаепсезлеген тагын бер кат ишеттерү булып аңлашыла.

Повестьның отышлы ягы – психологизм алымнарына мөрәҗәгать итүдә. Язучы Әдип, Гөлчәчәк, Әминә һәм тикшерүче Булат исеменнән хикәяли. Гомумән, нәкъ менә психологизм текстны эчтәлек сөйләүгә корылган публицистик әсәр булудан коткара да. Әмма психологизмның өлешчә генә кулланылуы әсәрнең эшләнеп бетмәгән кебек кабул ителүенә китерә.

Әдип белән аерылышуга, язучы Гөлчәчәк исеменнән сөйләүдән туктый: бу сызык өзелеп кала. Әдипнең балалары белән мөнәсәбәтләре шулай ук бернинди дәвамсыз, ирнең кичереш-мөнәсәбәтен күрсәтмичә генә туктый. Гөлшат линиясе, әлеге тормышны яңадан башлау соң түгеллеккә иллюстрация булса да, повесть өчен артык. Гөлшаттан башка да бу эчтәлекне повесть итеп язып бетерергә мөмкин. Матур гына эшләнә башлаган ана образы аның үлеме хакында соңыннан бер җөмлә әйтү белән кырт киселә.

Шуның белән бергә, әсәрдә әйтелеп бетмәгән күп кенә мәсьәләләр кала. Бу урында әдәбият белемендәге классик мисалны – стенага эленгән мылтыкның атылырга тиешлеген искә төшерми булмас. Ни өчен Гөлчәчәкнең әти-әниләре кияүне яратмыйлар? Ни өчен балалар әтиләрен якламый? Гөлчәчәк Әдипкә, чынлап та, яратып кияүгә чыкканмы? Ни өчен «Киа» машинасы каршыга килеп чыккан (язучы аның руле артындагы ирнең гамьсез йөрүен әйтә-әйтүен)? Өйгә кем ут төрткән (Гөлчәчәкнең әтисе дияр идең, алар мал бүлешү белән мәшгуль)? һ.б.

Әсәрдә типиклаштыру юлы табылмау – шулай ук төп кимчелекләрдән. Язучы хатаны тану – гафу үтенү, кешеләрнең ялгыш күзаллаулар белән яшәве (Гөлчәчәкнең баштагы монологы яки Булат фикерләре), башкалар тормышына аңламыйча да кыенлык, хәтта кайгы китерү кебек сызыкларны башлый – әмма аларны тормыш закончалыгы дәрәҗәсенә җиткерми. Әдипнең уйларында язучы заман көнитешенә, кешеләрнең байлык артыннан кууына бәя бирдерә бирдерүен. Әмма бу бәя генә повесть жанры таләп иткән гомумиләштерүгә мөмкинлек бирми.

Образлар белән аларны тудырганда кулланылган детальләрнең тәңгәл килмәвенә дә игътибар итәргә кирәк. «Әдип таң белән гаражга керде дә, ач кеше табынга йотылып карагандай, ашыгып-ашыгып, машинасын урап чыкты». Бердән, ач кеше белән чагыштыру повестьта алга таба тергезеләчәк Әдип образы белән ярашмый. Икенчедән, гомумән, кешенең ач кеше табынга карагандай машинасына каравы сатирик пафослы әсәр өчен генә урынлы. Яки шул ук беренче биттә авыл ир-атларының чебен кебек кырылуы да әсәрнең пафосына туры килми. Фактик төгәлсезлекләр дә бар: Әминә белән Әдипнең әтиләре Гаяз икәнлеге кат-кат әйтелсә дә, бер урында Әминә Халиковна варианты кулланыла.

Төп мәсьәлә – әсәрдә тергезелгән тормышның бербөтен сурәт булып җыелып бетәргә тиешлегендә. Бу талантлы каләмнән шушы якларга игътибар иткән әсәр көтеп калам.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы*



Айдар
Хәлим

# ЧИТТӘ

хикәя

– Авызыңны яп. Карга кереп китмәсен.

Салих, борылып, карашын дустына күчергәнче, болдырдагы кыз инде кереп тә киткән иде.

– Күрәсең дә капланасың. Һәдияңә әйтергә дә күп сорамам...

Шундый ачы телле, үткен тешле инде ул Гайрәт. Тешләгән җиреннән өзәр. Инде тагын:

– Кара аны, малай, муеныңны сындырасың. Тарт, дим бит!..

Гайрәтнең боерыгы кабатлануга, Салих, аңына килгәндәй, бармагының әрнүен тойды. Ул кыз ягына караган арада шырпы кадалган икән. Шырпыны тартып алдым дигәндә, пылт итеп кан сытылып чыкты. Малай аны ялап алганын сизми дә калды. Әлбәттә, кан тозлы иде. Мондый вак мәшәкатьләрне әле генә тупсада басып торган кызкай күрәдер дигәндәй, әрнешен сиздермәскә тырышып, пычкысын тартты. «Дзин». Эскрипкә кылы зеңгелди диярсең. Агачы да еллар буе кибеп-корып, сөяккә калган иске бүрәнә шул. Инде пычкыны каршысында аңа кулдаш булып утын тураклап маташкан Гайрәт үзенә тартты. Күз кырые белән генә кыелып карады – кыз күренми иде шул. Тагын – «дзин»: Салих – үзенә, Гайрәт – үзенә, Салих – үзенә, Гайрәт – үзенә...

– Кереп китте бит инде!.. Пычкы тартуыңны бел!

Тартты Салих. Шулай сәгатьләр буена «дзин-дзин», «дзин-дзин». Туйдыра гынамы? Ашказанында әйләнгән ач тешле тегермән ташларыннан кая ди дөнья матурлыгы, кызлар матурлыгы турында да җырлыйсы килми. Көеп чыккан пычкы онышнан һава кызгандай итә. Гайрәт, гомумән, агач исен һәм тирес исен ярата. Ашау дигән нәрсәгә килгәндә, аны беразга гына булса да әнә шул кыз гына онытгырып куя. Әмма ул да, хәерчегә җил каршы, дигәндәй, күренеп өлгерми, күз ачып йомганчы керә дә китә, шайтан алгыры! Ә менә ашау мәсьәләсенә килгәндә, аларның атлары гел генә җигелгән. Кем әйтмешли, кая кашык, кая катык, кая катламаларың?

Туралган түмәрләрнең оны иренеп кенә кузла астына куелган таска коела. Тасның төбе тишек. Пычкы онын шулай кузла астына куелган таска

---

Айдар ХӘЛИМ (1942) – *шагыйрь, прозаик, публицист; «Өч аяклы ат», «Татар моңы», «Хунвейбин» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Исхакый исемендәге әдәби премия лауреаты. Чаллыда яши.*

җыю галәмәтен беренче тапкыр күргән Салих үзләрен яллаган Сәфәргали абзыйларыннан, аптырап:

– Нигә алай итәсез? – дип сорамый булдыра алмады. – Пычкы чүбен болай итеп бер генә дә җыйганнары юк бит...

– Это – калория, – диде теге, бик белемле кыяфәт белән. – Мин аны ягып, өйне җылытачакмын. Золасыннан щёлочь ясаячакмын. Пычкы золасыннан алынган щёлочь бельёны исключительно яхшы агарта, ди хатын...

Бу сүзләрнең күбесен аңламаган малайлар аның белән килештеләр. Кирәк тек кирәк. Аларга нәрсә? Кушкач – җыярлар. Әнә, күкне дә бит идән юган мунчала кебек лачкылдык авыр кара болытлар биләп алган. Гүя ул бүселеп җыларга гына тора. Бу болытлар менә хәзер, менә хәзер беренче туңнарны көтеп сыкранган җиргә яңгырмы, кар беләнме ишелер. Агачның нәселенә, яшенә карап, таска коелган он төрле төстә: сөт аклыгыннан башлап эче бозылган саен кызара бара. Череп бушакланган саен, оны күп, пычкы өне тыгылып кыза. Тирә-якны агач онынннан аңкыган хуш ис баса. Агач катылана төшсә, онның күләме кими. Ничек кенә булмасын, төрле төстәге пычкы онының таска эләкмәгән өлеше аяк астында ноябрь салкыннарын, беренче кышкы чебеннәрнең чиметүен көтеп кипкән, башын югалтып, коры тамырда гына калган бәбкә үләнен һәм малайларның ботинка башларын үзенчә бизәргә тырыша. Ял көннәрендә авыллары белән ике арада чабатада йөрсәләр дә, алар, чагыштырмача хәлле нәсел балалары буларак, Кыргызда ботинка киеп форсить иткән булалар. Дөрес, авылдашлары Галимулла карт әйткәненчә, «плинни нимесләр» ясаган бу аяк савытларының тулы хокуклы ботинка диярлек җирләре дә юк: өслекләре – картон, аслык-табанлыклары – каты эрзин. Һичкайчан тузарлык түгел, түзәрлек кенә булсын. Җәен тирләтә, кышын өшетә. Аякларыңны бер өшетсәң, җылытам димә. Алар чабаталарын, иң кадерле байлыклары итеп, караулат асларында саклый. Кибеп коргаксып, алар шимбә төштән соң юлга сигнал көтеп ята...

Кәүсә киселеп, пычкы тешләре теге очтан тышка ялтырап тишелеп чыкмады микән дип күзләрең күгәрә башлый. Ә бу кайгы – ашказанындагы тегермән ташы тавышларын да оныттыра торган төп кайгы. Нишләтәсең, кышкылыкка утын кистерүче хуҗалары хәстәрләгән бу агач ифрат дәрәҗәдә нәселсез, дөресрәге, төрле нәселле иске бура булып чыкты. Агачлар арасында очраклы рәвештә елга буеннан кайткан һәм йокылы-уяулы хәлендә җырлап киселгән кызыл зирек, урманнан төшкән йомшак, ак тәнле юкәдән башлап, чынлап та таш-сөяккә әйләнгән һәм пычкы теше кагылу белән зеңгелдәп урамны яңгыраткан имән, усак, каен бүрәнәләргә кадәр бар иде. Соңгылары кайчандыр, барысы бердәм бураны тәшкил итеп, килешеп яшәгәннәр дә, гүя ниргәдән ычкынып, сүтелгәч, «мин дә мин!» дип, нәкъ үз кавемебез кебек, үзара кычкырыша, бәхәсләшә башлаганнар. Кайчакта пычкы теше бүрәнәләргә башын яшереп кереп качкан, дибырсантлар кебек, шунда посып яшәп яткан кадакларга тап килеп, ачы тимер, эскрипкәнең кылы өзелгән тавыш чыгара, бу чакларда кадак ялтырап агара, малайларның йөзләре карая, йөрәк кыллары да аһ итеп өзелгәндәй була. Өзелерсең дә. Пычкыны үткерләү, ягъни тешәү, җиңел эш түгел. Моның өчен мачтыр булырга кирәк. Пычкыны бот араларына кыстырып кына «акылга китереп» булмый. Моның өчен корычны яратырга, аның телен аңларга, зарларын сөйләтергә кирәк. Аннан тыш җылап торган түгел, җырлап торган корыч игәүләр, тешне теши торган струмин[1] – ярыклы кыскыч кирәк. Шатлыкка, Гайрәтнең, ялланып, чит авылларда бура бурап йөргән агасы Зәригать нәкъ менә

[1] «Инструмент»тан алынган.

шундый мачтыр да инде. Аның юл капчыгында барысы да бар. Әмма ул, әгәр син ихластан да ачыгавыз булып, агачтагы кадакка пычкыңны каптыргансың, тешләрен җимерттергәнсең икән, бәлаңне үз өстеңә ал, абзаң көн саен килеп йөри алмый, атнасына бер тапкыр, үтеп китешли, иреннәрен кысып кына, син җимерткән тешләрне теши, сафка бастыра...

Хәер, Салих белән Гайрәт тә читтән килеп ялланган ялчылар инде: чынбарлыкта, алар ялчы түгел, ялчы булып ялланган кичәге кулак балалары. Аларның бабаларын, бу якларда атаклы Рәхимкол нәселенең уналты тармагын, утызынчы елларда башка-баш кисеп, тураклап, кайсын кайда озатып бетергәннәр иде. Әмма алар үзләренең якыннан-якын туган икәнлекләрен белми, бераз гына белсә-сизенсә дә, белмәс дәрәҗәдә хәбәрсез иде, чөнки аларның «сыйнфый дошман» буларак куркытылган аналары бу хакта бөтенләй дә эндәшми-тындашмый иде. Алар кем – моннан егерме чакрымда яткан авыл балалары, кем – быел Кыргыз урта мәктәбенең сигезенче сыйныфында гыйлем эсти башлаган укучылар, кем – дәресләреннән соң шулай Кыргыз «ыслушшилары»на[2] кышкылыкка утын тураклау белән мәшгульләр. Хәер, бу өченче тапкыр ялланулары. Берсендә германнан күзе кызып кайткан әфисәр бу якларда күрелмәгән алма бакчасы өчен чокырлар казытты. Алмаларын ашарга насыйп итәр микән? Сугыш ятимнәре, әниләренә бераз гына булса җиңелгә төшәр, дип, менә шушы бик тә саваплы, ул гынамы, хәтта ки ярыйсы гына акчалы – кубик метрын берәр тәңкәдән! – эш башкарып, үзләрен бик бәхетле зат – эш бетергән кеше итеп тоялар. Алар кубометрны үзләренчә киная белән «күп метр-чүп метр», дип тә йөртәләр. Ә күпмерәк була соң ул «күп метр-чүп метр»? Иңе – бер метр. Буе – бер метр. Биеклеге – бер метр. Менә шушы аралыкка сыя торган утын түмәрләре бер кубик метр дип атала. Кулларына төшкән акчаданмы, әллә аларның башкаларны җылытырга тырышуларыннан киләме ул бәхет – малайлар, дөресрәге, борыннарына ис кергән ундүрт-унбиш яшьлек үсмерләр, бу хакта уйлап та карамый гына түгел, уйлауны күз алдына да китермиләр. Аларга, туган авылларыннан чыгып, «читтә» яшәгән ике дуска, ач тамагым – тыныч колагым, рәхәт, күңелләре көр – шунысы мөһим. Әлеге сәгатьтә Кыргызның чираттагы, инде өченче «ыслушши»ына утын кисеп яталар. Ярмыйлар да, вакламыйлар да. Тураклыйлар гына. Һәм курчак итеп өеп куялар. Шулай кушылган. Тормышны үз адымнары, үз карышлары белән генә үлчәп, үз авылларына, ата-инәләренә хас булган гамәлләрне башкалардан да таләп итеп яшәгән беркатлы авыл балалары, карашларын йорт болдырыннан төшермичә, «менә-менә өйләренә чакырырлар, менә-менә ашатырлар, бәлеш-гөбәдиясе булмаса да, ипи катысы белән булса да чәй эчерерләр», дип күзләрен күгәрткән ялчылар, үз өметләренә ирешә алмагач, «ыслушши»лар кеше түгел икән, дигән карарга килгәннәр иде.

Әмма өметләрен өзмәгән иделәр. Бигрәк тә бу кешегә ялкангач, өметләре аеруча үсә төште. Бигрәк тә Салихның. Аның ничек кенә булса да үзләрен тыштан эчкә чакыртасы, әлеге өйгә керәсе, шуннан файдаланып, бу кызны якыннан күрәсе килә иде. Әмма. Сугыш бетүгә ун ел булуга карамастан, аягыннан салмаган армия итекләрендәге тузанны өреп төшергәннән, бәрхет чүпрәк белән ялтыратканнан, гимнастёркасын иңеннән аркылы төшкән йолдызлы әфисәр каешы белән буып ныгытканнан соң гына болдырына чыгып баса торган Соргылт абзый – сугышта полк хисапчысы булган бухгалтер, майор, имеш. Татар икән. Сәфәргали. Сәфәргали Сондыков (хатыны аңа йә «Серёжа!», йә «Сундуков!» дип кенә эндәшә). Сәфәргали исә моңа авызын кутәреп бер сүз әйтми.

[2] «Служащий»дан бозылып халык теленә кергән сүз. Хезмәткәр.

## ТУКАЙНЫҢ «ТУГАН ТЕЛ»Е

**Гасыр буена дөрләгән**
**Утлардан чыгып тере,**
**Кояштай сарыла җанга**
**Тукайның «Туган тел»е.**

**Булса да ул милли гимн**
**Һәм илче азатлыктан,**
**Үз телен йотканга, илем**
**Гомерлек газап откан.**

**Тел белән илгә берегү**
**Татарга әллә язык?!.**
**Җырлата, елата Тукай,**
**Телләрне безнең язып.**

**Читкә  сибелгән татарны**
**«Туган тел» табыштыра,**
**Караңгы кара төннәрне**
**Таңнарга авыштыра.**

**Рухия АХУНҖАНОВА**

Малайларның тәҗрибәсе шуны раслый: «ыслушши»лар арасында кеше диярлекләре күп булмаса да, татар дигәннәре байтак очрый. Монысы «Сбербанк» нәчәнниге икән. «Сбербанк» сүзен беренче ишеткән малайлар сыйныф җитәкчесе Әкълимә апаларыннан белештеләр. «Сбербанк» – ул акча саклый торган урын, ди. Кыска гына итеп әйткәндә, акча капчыгының сакчысы булып чыга. Моны белеп алгач, җегетләрнең күңел апарасы күперепме-күперде: бүген аларның кушаяклы кузла дырылдатуларының соңгы, бишенче көне, Алла боерса, утыннарын кисеп бетерсәләр, Соргылт абзыйлары кичләтеп кайтып керсә, сөйләшенгән биш кубик метрыннан чыгып исәпләгәндә, бу акча капчыгы булган абзыйга галифе кесәсеннән кыршылып беткән биш тәңкә урынына сайрап торган ун тәңкә чыгарып бирү нәрсә тора инде?! Әгәр кискән утыннары алты, җиде кубометр булып чыкса, менә улаячак аларның бүреләре! Бу хакта хыяллана, түләүне арттырганнан-арттыра төшеп, өметләрен үстерә барып, түләтәсе хаклары илле тәңкәгә кадәр барып төртелгәч, һәм ул утын өеме тәмам акча өеменә әверелгәч, һәм ялчылар хыялый йөк башына менеп утыргач, алар моның мотлак шулай килеп чыгачагына тәмам ышанып беткәннәр иде. Шуның белән бергә кайгылары да бермә-бер артты. Акча кайгысыз йөрми, кайда акча, шунда кайгы икән. Абзалары бу кадәр дә акча бирсә, аны кәгазь акчадамы, әллә тимер акчадамы бирер? Тышка чыгарып бирерме, әллә өйләренә чакырыпмы? Түр башында кунак итепме, әллә салкын суын да эчермәстәнме? Бу кадәр акчаны кайларга гына тыгып бетерерләр? Ипи, ак күмәч, шикәр... Кая ди алар гына! Кәчтүн! Яңа җылы бишмәт! Аякка итек! Киез итек!.. Инәләренә күлмәклек!.. Шулай булачак та!.. Югыйсә, бар тирә-як шушы максатка хезмәт итә иде: Соргылт абзыйның марҗа хатыны да, чәчләрен ике якка үреп, күбәләкләп бәйләгән фәрештә рәвешендәге теге кызлары да. Ул, әлбәттә, аларның кызы булырга тиеш. Исеме дә ачыкланды. Катя, Катюша, Катерина. Екатерина Сәфәргалиевна. Менә кызык! Бер күрүдә үк ошатты аны Салих. Гел генә шуның ягына борыла баш дигәнең. Әмма аны, үзе якында, тупса аша гына булса да, якыннан күрү мөмкинлеге юкка тиң. Шуңа да ул якындагы кызның ерактагы ялкынында яна. Беренчедән, кызкай тышка сирәк чыга. Йөзен-чыраен юньләп күреп булмый. Ул Салих ягына карамый да. Салих үзе карарга теләсә, Гайрәт борылырга ирек бирми. Хет ят та үл. Җитмәсә, авылда калган Һәдиясенә әләкләү белән яный. Фаҗига. Трагедия. Куркыткан гына була инде. Көнләшә, кәнишне. Юк, көнләшми. Болай гына әйтә. Шулай да... «Кызның күңеле кырыкта» дигәндәй, егетләрнеке ничәдә икән? Болдырга арты белән торып утын кискән Салих, Катяны чыкканы саен күрергә теләп, Гайрәткә кулны алыштыру турында тәкъдим ясагач, теге, бик шикле елмаеп, урынын бирмәде. Имеш, кул уңае түгел. Ничек кул уңае булмасын? Сулагай-фәлән дә түгел. Гади итеп кенә әйткәндә, урынын бирми. Этләшә. Болай булганда, Катяны беренче булып ул күреп ала. Үзенең дә күзе төшкәнме? Яшерә генәме?

Хуҗа хатынның марҗа булып чыгуы туган ояларында бернинди әрҗә-марҗа күрмәгән-ишетмәгән малайларның уй-теләкләрен тагын да көчәйтеп-узындырып җибәрде. Шулай булмыйча тагын. Сәфәргали абзыйлары туган якларында күренмәгән табыш итеп каяндыр Житомир тарафларыннан алып кайткач, уңганлыгы ягыннан татар хатыннарына биргесездер инде ул. Әмма!.. Син заманнарның туры килеп кабатлануын кара! Алар күптән түгел Мәҗит Гафуриның «Ярлылар, яки Өйдәш хатын» дигән хикәясен өйрәнгән иделәр. Язучы әйткән шәһәрдәге кебек, аларның Кыргыз дигән зур авылында да, «солы катыш үскән бодай кебек, татар һәм урыслары катыш торалар» икән. Андагы хикәядә базардан утын илтешкән Шәрифкә марҗа хатын акчаның

көткәненнән артыгын бирә. Үзенә бай кыяфәтләре кереп киткән көнлекче ул акчаның «унике тиененә лафкадан ике кадак икмәк белән бер кап шырпы, өч мыскал чәй алып кайта». Гафуриның Шәрифе кичергән уйлар дәрестән соң, йөрәк майларын талатып, көн саен утын туракларга барган малайларны авыз суларын корыткан дәрәҗәдә газаплады. «Бу кяфер кырык тиен бирмәс микән? Бирер, бирер, бу утын сажиннан күп артык бит, юк инде, кырык тиен генә бирсен, шул да җитәр», – дип, Гайрәтнең язучы сүзләрен кабатлап бетүенә, Салих хикәянең дәвамын шул ук язучы сүзләре белән артыннан: «Күптәннән бирле ит ашаган юк иде, берәр егерме тиенлек ит алып кайтсам, егерме тиен кала. Егерме тиеннең биш тиен көмешенә токмачка он алсам, аннан да биш-ун тиен артып кала, унбиш тиенгә биш кадак икмәк алып кайтсам..» – дип ямап куя да, өметсез шайтан кебек шаркылдап көләләр...

Боларның марҗалары беркайда да эшләми бугай. Базарга да йөрми. Аның каравы, караңгыда капшангандай итеп, буаз базар сумкасын күтәргән, телен аркасына әйләндереп салып ахмалларга төшкән Соргылт Абзый үзе кайтып керә. Аның башы да, күзе дә юк кебек. Гүя эшендә торгызып калдырган. Гафуриның марҗасы гасыр башында тышкы салкында сурәтләнгән булса, ул инде хәзер, гасыр уртасында, күптән татарның җылы өенә хуҗабикә булып кергән икән. Аларның иреннәрендәге иннек буяулары куллары тигән җиргә буялып кала икән. Алай гына булса, ни дияр идең. Исем-фамилияләрен, туганнарын тартып алды. Хатын үзе чыгып та азапланмый. Малайлар, дөресрәге, Салих кына, аны ике генә тапкыр күз кырые белән күреп өлгерде. Анысында да ай күрде – кояш алды. Тегеләр җыештырынып маташканда, өйләрен җилләткәнме, кинәт урам ягындагы ачык тәрәзәдән ап-ак пәрдә, үтәли җилдән кабарып, тышка томырылып чыкты һәм ак болыт сымак тулгана башлады. Кешегә ярдәм итү, пәрдәне эләктереп алып, эчкә сузганда, бер уңайдан Катеринасын күрә алу уе белән ялтакайланып йөгереп барган Салихның тәрәзәдән чыгып өзгәләнгән пәрдәне кулына эләктерергә тырышып сузылуы булды, эчтән:

– Не лезь! У тя руки грязные! – дип кычкырдылар, ана каз тавышы белән гаңгылдап.

– Нәрсә диде ул сиңа? – дип сорады Гайрәт, дусты килеп пычкысын тарта башлагач.

– Герәзний, диде! – дип ачынып җавап бирде дустына Салих, аннан өстәп куйды. – Сиңа кысылмаска кушты.

Алар бер-берсе белән шулай егетләрчә кырыс мөнәсәбәттә. Хуҗаларча өндәмә белән эчтән кем кычкырды икән? Катямы, әллә әнисеме? Катя түгелдер. Аның Катясының тавышы андый каты бәгырьле булмас. Шулай да малай эчтән ишетелгән бу гөрбиян боерыкка нык кына рәнҗеде. Туган авылыннан беренче тапкыр читкә чыккан, инде чын-чынында инәләреннән аерылып читтә яшәгән, әле ят җирләрне яд иткәнче, өйрәнеп киткәнче иртәсен дә, кичен дә Кыргыз дигән зур авылның чит агачларын, кешеләрен, мәктәптәге укучы-укытучыларын гына түгел, хәтта ки йортлар, таш урамнар, райкомның беренче тапкыр күргән ике катлы бинасын, төнге уникедән иртәнге алтыга кадәр дөп-дөп килеп электр уты биреп утырган дизель станциясен дә күзләренә кадалган ят шырпы итеп кабул иткән ике яшь колынчакның берсенә җитә калды. Ул, үзенә «герәзний» кушаматы алган малай, елап җибәрердәй булып яшькәзгән карашы белән дустына карады – биредә аның кебек үк чит вә ят булган Гайрәт тә яңа шартларга тизрәк илегәсе килә, әмма илегә генә алмый газаплана, шулай да аның күз чокыры коры, ул еламый иде! Әйе, алар өчен

беренче тапкыр күргән электр яктысы да якты түгел, караңгы иде. Пакустан килгән бу ике үсмер, ике таш мускуллы җырчы, кайчакларында, сагынуларын кая куярга белмичә, кеше ишетмәс җирдә тамырланып, җырлап җибәрергә дә күп сорамый иде:

Чит-чит, дидем, читкә киттем,
Чит иде теләкләрем,
Инде хәзер читтә яшим,
Өзелә үзәкләрем...

Авыр хезмәт, йөрәк маеңны учыңда талкып, пычкы тарту аларга шушындый да ятсыну-юксынуны беразга булса да оныттырып тора иде, Ходаем! Шунысы сәер: алар туган якларындагы кешеләрне түгел, нишләптер аның җир-суын, үзләре аунап үскән елга буйларын, җиләк җыйган урман-аланнарын, ат куналарына йөргән тау кырлачларын – гомумиләштереп әйткәндә, табигатен сагыналар иде...

Тамырлану, дигәннән. Салихны аеруча рәнҗеткәне нәкъ әнә шул тамыр булды да инде. Ул ниндидер алтынчы тойгысы белән үзләренең бу җирдә хуҗа икәнлекләрен тоя, әмма шул хуҗа булу дигәннең тамырларын таба алмыйча йөрәкси. Ул тамырлар кайдадыр киселеп калган икән. Ул үзе биредә чынлап та чит икән. Туган җирендә дә чит. Малай моны авылы капкасын чыгу белән сизенде. Бу сагыш юл буендагы үлән кыякларының йөзләрендә дә чагыла иде. Аныкыннан тирәнрәк тамырларга икенчеләр – менә шушы күбәләк кыз Катя һәм аның тәрәзә пәрдәсен ярсу җилләрдән тотарга маташкан әнисе хуҗа булып алган.

Бер караганда, Салих белән Гайрәт бер нәселнең туганнан туган балалары иде. Аларның фамилияләре дә бер булырга тиеш тә, ләкин кемдер кемнәндер, нәрсәдәндер качып, исән калу өчен яшереп, акча төртеп, башка фамилия әтмәлләгән. Малайлар бу якларда ике бертуганның төрле фамилия йөртү серләрен анык кына белмәсәләр дә, тамырларының чынлыкта бер, уртак һәм тирән икәнен беләләр. Ләкин алар сугышта ирсез калган тол аналарының күңелләрендәге фаҗигане, йөзләрендәге кайгыны, күзләрендәге юксынуны, телләрендәге ачы зәһәрлекне яшереп, татлы телле, шат йөзле, якты күзле булырга тырышулары аркасында язмышларына ниндидер фаҗига катнашканлыгын сизмичә дә үстеләр. Ничек мөмкин бу?! Гүя аларның тамыры, иң астагы җимерелгән тамырларга төшеп тормыйча, өстәге соры катламнар дымы белән генә тукланып яшәгән. Баксаң, аларның шактый хәлле, хәтта бай дип атарлык нәселләре өч катлам – өч өлештән тора икән. Беренчеләрендә – инәләре пышын-пышын гына сөйләнеп, егерменче-утызынчы елларда кулга алынган, атылган, сөргеннәргә сөрелгәннәр, исән чакта таңнарны иңнәренә бөркәнеп, авылдан чыгып качкан коръәнхафиз мулла-мунтагайлар, мәзин-мөтәвәллиләр, абыстайлар... Җәй җитте исә, аларның өзелеп, үткерләнеп исән калган очтыкларының өсләренә үзбәк-таҗикның ерактан кычкырып торган укалы әдрәс күлмәкле, кәләпүшле, ефәк, атлас, бәрхеттән тегелгән кәзәки-камзуллы ташкыны авылны баса иде. Каян гына, нинди генә үзбәк-фарсы кияү-кәләшләр ияртеп кайтмыйлар! Яшәгән-торган төякләренең исемнәре дә ят һәм серле: Ташкин, Кентау, Фиргана, Үргәнеч, Әндижан, Пскент, Сталинабад, Ленинабад, Күкташ... Кайтучыларның исемнәрен инәләре генә белә: «Исән-сау гына йөреп кайттыңмы, Миннәхмәт мәзин?», «Хәл-әхвәлләрегез аманмы, Маһибәдәр абыстай!», «Әссәламегаләйкем, Шардада җиңги!» Шардада дигән

исем дә булыр икән эрвәлүтсион татарда! Авыл, чиратка басып, камыр куя, мунча яга, югын да бар итеп аларны кунак итә. Миһманнар[3], ара-тирә шул ук үзбәк-таҗик сүзләрен кулланып, ата-бабалары хөрмәтенә үзләре дә коръән ашлары үткәрәләр. Ташларны үбеп, чалшайган иске читән-казыкларны кочаклап елыйлар. Алар алып кайткан Ташкин күчтәнәчләре Салихлар кебек «шәлия табыны»[4] өлешенә дә төшкәли, кунаклар белән бергә авыл да өрек рәвешенә кереп алсулана. Малайлар өчен бүген күршедә генә яткан Кыргызлары никадәр чит-ят тоелган кебек, кайтканнар өчен кичәге туган авыллары шулкадәр газиз һәм үз иде. Әгәр кайчандыр авылдан чыгып киткәннәр, хәзер читтән кайтып, үз авылларында үзләрен никадәр үз тойсалар, хәзер үз җирләрендәге ике малай күрше Кыргыз авылында үзләрен шулкадәр ят тоялар иде.

Катламның икенче өлешендә – сугышка китеп кайтмый калган әтәйләре һәм агалары, бабалары...

Өченчеләрендә – алар буыны, үзләре кебек әле менә шулай алга-артка тырышып пычкы тарта-тарта дөньяга чыгып маташучылар.

Иң кызыгы һәм аптыратканы тагын да шул: алар, өченче катламнар, бу кадәр югалтулар кичергән нәселнең ятим балалары, инәләре куенында үзләрен җир йөзенең иң бәхетле кешеләре итеп тоя иде. Үсеп җиткәч, үзләре дә тормыш корып, бала үстерә башлагач, мондый хәлгә аптырап, җавап та таба алмаячаклар.

Ә пычкыны алар бер-берсенә авырга килмәсен дип, көч куеп, бер-берсен сүзсез дә аңлап, кипкән аңкаулары белән инде салкыная барган һаваны сосып, бердәм тарталар һәм бердәм этәләр. Арып, хәлләре мөшкелләнгәч, күз алдында меж-меж килеп кара чебеннәр оча башлагач кына, туктап хәл җыялар. Шул арада пинжәкләре кесәсендәге ипи түтәрәмен чыгарып, башта урталай, аннан тагын урталай бүлеп капкалыйлар да, калса, калганын киләчәктә йөрәк ялгарга дип кире тыгып куялар. Халыкта «Уртак аш белән уртак малны эт җыймас» дигән сүз булса да, боларның алай түгел. Шулай булмый ни! Туганнан туган, алар берсе-берсенә охшаган да, охшамаган да. Гайрәт, төп кебек, кыска буйлы, сары чәчле, яшькелт күзле, кием-салымга бик пөхтә, хәйләкәр, аңарда сәүдәгәрлек чалымы ярылып ята. Аш-суга оста, кирәк икән, токмач басып, аш та пешерер. Салих озынрак буйлы, куе коңгырт чәчле, көйдереп караган зәңгәр күзле, алабарманрак холыклы, гамәлендә тота-кабарак кылана. Әмма алар охшаш: күңел бердәмлеге шулай охшаш итә. Беренчедән сигезенчегә кадәр бергә укып, аларның бер-берсенә кул түгел, тел дә тидергәне юк. Дүртенчедән сигезенчегә кадәр, көн дә ун чакрым юл үтеп, күрше авылда укыдылар. Буранлы кышларда адашкан чаклары булса да, бер-берсеннән адашкан, бер-берсенә алдашкан чаклары булмады. Бер тапкыр бүредән шыр җибәрүләрен хәзер елмаеп кына телгә алалар. Шулай, бер салкын көнне, әйтәсе дә юк, көпә-көндез, күз ачкысыз буран кузгалды. Юлларны күз йомганчы көрт басып китте. «Тырын Түбәсе»нә җиткәндә адаштылар да куйдылар. Юл буена үзең кадаган маякларың түгел, үзеңнеке булган аякларың да күренми. Әйләнәләр дә берүк эскерткә килеп чыгалар, тулганалар да берүк эскерткә килеп чыгалар. Арыган-талчыккан, тирләп-пешкән малайлар бераз хәл җыярга дип эскерткә тукталдылар. Һәркем үзенә оя ясап, өненә кереп чумды. Шулчак үзенең шапшаклыгы, ялкаулыгы белән «социалистик ярыш алдынгысы» кушаматы

[3] Миһман *(фарсыча)* – кунак.
[4] Шәлия табыны *(җирле сөйләш)* – кунак ашы үткәрелгән йортның алгы ягындагы малай-шалай, ыбыр-чыбыр табыны мәгънәсендә.

алган Габдерәүф дигән малай тула оегын чабата киндерәсенә кадәр сыдырып төшерде дә, тәненнән бет артыннан бет чеметеп алып:

– Йөк булып бушка утырып килгәнегез өчен сезне бик каты җәзага тарттырам, – дип, кар өстенә ыргыта башлады.

Салих:

– Әгәр туктамасаң, хәзер үзеңне ач бетең урынына карга ыргытып калдырабыз, – дигәч, һәркайсы шаркылдап көлде.

Буран басылгандай итте. Гайрәт алдан төшеп, таяк белән көрттә капшана-капшана, аларны юлга алып чыкты. Юл үргә таба чамаланды. Алда Тырын Түбәсе булырга тиеш. Кинәт күрәләр: алларында бүре утыра. Курыкканга куш күренә, дигәннәре дөрес икән. Җил арттан этәрә, әмма берсенең дә җил җилкәне астында бүре авызына барып керәсе килми. Берсе икенчесен алга чыгарырга тырыша. Шул ук Габдерәүф, каләм очлый торган пәкесен чыгарып, бүрегә ташлана:

– Алга, пирүт, дошман өстенә! Бүрене закускага!..

– Бүрене чәнче! – диде Салих. – Тиресен – миңа!..

Инде кымшанмаганын абайлап, бүрегә якын ук килеп җитсәләр, тотып та карасалар, ул малайларның күзенә бүре булып күренгән, землемер баганасына җил китереп сылаган чүпрәк аламасы икән...

Төне буе адашып йөреп, иртәнге алтыда гына авыллары каршына килеп чыктылар һәм шатлыкларыннан җылап җибәрделәр...

...Кинәт итек шыгырдады. Юк, Сәфәргали абзый түгел. Майламаган ишекләре генә шыгырдаган икән.

– Тарт, дим!..

Салих уянып киткәндәй итте. Бәй, ул тагын да Катясын күреп катып калган лабаса! Тегесе болдырда халатларын ачып, яланаякларына нәфис чүәк эләктереп алган да, шәрә чәлтерләрен күргәзеп, аларга карап елмая!..

– Йомшак җирләреннән күзеңне алмыйсың, ләгыйнь[5]. Чынлап та, Һәдияңә әләкләми булмас!

– Оятсыз син, Гайрәт!..

Фаразлавынча, мондый кыз кызыл чүәкле, шәрә чәлтерле генә түгел, ачык чырайлы да, батыр да, камил холыклы да булырга тиеш. Һм. Ничәнче сыйныфта укый икән ул? Укыймы? Әллә утырмага гына кайткан кунак кызымы? Укыса, ул аны мәктәпнең урыс сыйныфларында күргәне булыр иде! Һәдиясен күз алдына китереп, аның бит очлары алсуланды. Тик нишләргә, Катяны күргән саен, аңарда көч арта, пычкысын да тырышыбрак тарта. Бу куанычтан ул Гайрәтнең күзенә карарга оялды. Мең газап белән, башын дусты ягына борды.

– Чынлап та, муеныңны сындырасың син...

Ул, Гайрәтнең сүзләренә игътибар итмичә, башын кабат кызкай тарафына каерды. Әле генә елмаеп торган кыздан инде җилләр искән иде.

– Матур бит...

– Алар шул түгәрәк матурлыклары белән безне ямхәлли[6] инде! – диде дустына караганда исәп-хисаплырак булган Гайрәт. Аннан Салихның уйларын сизеп алган кебек өстәде. – Аның ничәнчедә, кайсы сыйныфта укыганын белеп алсаң, подручкым да йөри башларсыз, мөгаен...

– Син тагын бигрәк!

– Юк, чынлап! Катя-Катюшаның ире, Сәйфетдин Сондыковның кияве

[5] Ләгыйнь *(гарәпчә)* – юньсез.
[6] Ямхәлләү *(җирле сөйләш)* – әсир итү, бу очракта – йоту мәгънәсендә.

дә булып алсаң, син безнең эше туң халык кебек туңкаеп, утын тураклап йөрмәссең инде...

Алар шулай берсен-берсе чәнчеп-чеметеп сөйләшә беләләр. Ләкин үпкәләшми-бозылышмыйлар. Киресенчә, якынаялар. Туганнар булгангамы? Юк, биредә туганлыктан да тирәндәрәк нәрсә бар шикелле. Еш кына туганнар да берсе икенчесен ашап бара бит. Ә болар берсе икенчесенә тартылып, елышып бара. Бу шундый тойгы, шундый хис, ул карар күзгә оялтыр дәрәҗәдәге чиста моң булып калка. Кая ди монда ниндидер ят сөяккә өйләнү?! Салих кая барса да, кемне генә күрсә дә, күз алдында әнисе булып ниндидер Ак Әби, ниндидер Ак Бабай бармагын селкеп тора: «Карагыз аны, өебезгә кяфир-кяфирә алып кайтасы булмагыз!»

Үсмерләрнең күз карашлары үтә дә моңлы. Әмма җылак түгел. Ә моң – чама, сабырлык, үзеңә теләгәнне башкага да теләү дигән сүз. Керсезлек, инсафлылык. Мин-мин дип җенләнеп, якыныңа типмәү-тапамау. Нигә авылларының башлангыч мәктәбендә укыганда олылар түгел, балигъ булмаган, нибары өченчегә кергән керсез сабыйларны, гомумиләштереп әйткәндә, бишектән төшеп, кулына китап алып кына өлгергән ылан-тәнәйләрне[7], хәтта бертуганнарны, берсен икенчесенә үчектереп, көнләштереп, әләкче, сугыш чукмары ясап, бары тик «бишле» алыр өчен «сәтсиәлистик ярышка» куып кертеп дошманлаштырмадылармыни? Авыл балалары, алар аркасында ата-инәләре, туган-тумачалары, хәтта мал-туарлары, этләре-песиләре үзара дошманга әверелде. «Бишле», «дүртле» өчен туган белән туган сугышты. «Өчле» алган бала, чакырып чыгаруны көтмичә, сыйныфның «көфер почмагына» чыгып басты. Ата-аналарыннан талчыбык ашады. Бәйрәмнәрдә катнаштырылмады. Әйе, өченчегә алар бераз соңлап төштеләр. Укытучылары булмый торды. Аннан, октябрь башларында булса кирәк, ниһаять, авылларына ирле-хатынлы укытучылар килеп төште. Алар башкорт һәм «бедден Дим буе» башкортлары түгел, ә чын башкортны көндезен шәм кабызып та күрә алмаган татар авылы өчен, ««беззең тип һәйләгән «чи» башкортлар иде. Мәсьәлә һич кенә дә кемнең кайсы кавемнән булуында, ягъни башкорт йә татар булуында түгел, ә, бәлки, шундый көтмәгән «ярыш ялкыны»н кабызып җибәрә белүендә иде. Халык аларны яратып кабул итте, төзек, җылы йорт табып бирде, азык-төлек белән тәэмин итте. Укыт кына, төпле белем генә бир! Причум монда башкорт та, причум монда татар?! Шундый әкәмәт кешеләр булган тек булган! Ә менә яңа укытучылар тирән белемгә һәм тынсыз тәртипкә икенчерәк, мондагы халык күз алдына китерә алмаган ысул – балаларны үзара ярыштыру – үзләре уйлап тапкан «сәтсиәлистик ярыш» юлы белән ирешергә тырышкан. Һәр бала икенче бала белән укуда һәм тәртиптә ярышырга мәҗбүр һәм тиеш. Һәркем эчтән ачылды, тыштан тишелде, кыскасы һәркем серкәсе су күтәрә алмаган «әфәндегә» әверелде. Шатлык шарты шарт-шортлык шартына әйләнде. Үзара ярышкан малайлар, берәрсе «өчле», «дүртле» («икеле»-«берле» турында әйтеп тә торасы юк!) алса, дәрес тәмамлангач, үзе белән ярышып «бишле» алган малайга каршы мич арасындагы пүләннәр белән коралланып һөҗүм итә, кызлар исә тынычрак юл белән белемгә ирешә – берсе икенчесенең чәчен төбе-тамыры белән йолкый. Йә булмаса, арттан килеп, бердәнбер күлмәген аерып төшерә. Мич арасында мичкә ягарлык утын да калмады. Аларны өч ел бер сыйныфта утырган, бүген килеп, теге буранлы эскерттән карга бет ыргыткан коймак иренле Гәбдерәүф берәмләп укытучы апаларына ташып, «сәтсиәлистик ярыш алдынгысы» дигән исемгә ия булган, һәм бу ләкап аңа нәкъ шул чордан

[7] Ылан *(җирле сөйләш)* – угъланнан алынган.

ябешеп калган да иде. Ә менә Салих белән Гайрәтне һәм тагын унлап баланы алар дошманлаштыра, кинә кууга китерә алмадылар. Чөнки ярыштыра алмадылар. Алар табигатьтән камил холыклы, тәрбияле, китаплы, иманлы нәсел балалары иде. Үзара «мыр-мыр»га, «һау-һау»га баткан этне-песине, бар мал-туарны инәләре мал догасын укып тынычландырды. Болай итеп моңсыз ярышудан балаларын да тыйды. «Карагыз, малайлар, – диде, мәсәлән, Гайрәтнең инәсе Рәзифә түти аларга. – Сез аш күрмәгән ата балалары түгел. Сез – бертуган, үз гайрәтегезне үзегез белеп туган. Агачлар аеры үссә дә, тамыры бер. Әгәр бер-берегезне әләкләсәгез, тузышсагыз, өйгә кайтып кермәгез. Телегезне үтмәс пычкы белән тураклыйм».

Уку елы башында бу укытучылар авылга ничек күренмичә килеп кергән булса, уку елы тәмамлангач та, шулай ук яңа төр «сәтсиәлистик ярыш» эзләп, күренмичә күздән югалды да.

...Алар әлеге сәгатьтә дәхи, үтә дә эчкә кереп үтмәсләнә барган пычкыларын тарттылар да тарттылар. Бу барыш белән тагын да өч сәгать чамасы кисәрлек агачлары бар иде әле. Алар бик ашыктырмыйлар да. Бүген барыбер кисеп бетерәчәкләр. Эчләреннән чиксез куаныч кичереп, күз алларында уйнаклаган кара чебеннәрне күрмәскә тырышып, шул мизгелне Сәфәргали абзыйлары кайткан минутларга туры китерергә исәпләп куйганнар иде.

– Әнә, тагын чыкты җанашың, күреп кал!

Борылып карардан алда Салихның йөрәген дәһшәтле уй телеп төште: гүя кемдер аңа: «Син бу кызны соңгы тапкыр күрәсең!» дип пышылдады. Гайрәт дусты да, шуны белеп торгандай: «Күреп кал!» дип кычкыра, ичмасам. Ярар, нәрсә булса да булыр. Ул пычкысын тартудан туктап борылды һәм Катясына таба китте. Бер адым, ике... өч... Кыз аңа укталды, карашыннан очкыннар чәчрәтеп елмайды да вак чәчкәле зәңгәрсу сарафанының итәген парашют итеп фырылдатып кереп тә китте. Салихның күзләренә яшь типте. Ул монда чынлап та чит, чынлап та хуҗа түгел иде шул. Әнә шул читтәлек, әнә шул хуҗа булалмау кайгысы малайларны фатирга да аерым урнаштырды. Дөрес, ике айдан мәктәп интернаты эшли башлагач, алар, сугыш ятимнәре буларак, шунда төпләнәчәкләр. Әмма әлегесе кыйммәт: малайлар шул интернат канаты астына кергәнче, бик тә бер фатирга урнашырга теләгәннәр иде дә, тик кем гади авыл кешесеннән «ыслушши»га әверелгән аксөякле Кыргыз кадәр Кыргызда җимереп ашый, җимереп яши торган ике карасөякле малайны тәрбиягә алсын? Кешенең сөйкемсез сөяген кем, ничек карасын, ашатсын-эчертсен? Йоклатсын, уятсын, керен юсын? Инәләренә «без бер-беребездән аерылмыйбыз», дип инәлепләр ялынсалар да, Гайрәткә вакытлыча – малайларның икесенә дә туганнан туган Зөләйха әбисендә, ә Салихка үткән кышта Габдерәхим агасының туена ат чанасы китергән Сәйфетдин кодасы белән чәчкәле чәйнүк кебек Мәрьямбикә кодагыйларында кунакларга туры килде. Агасы белән матур җиңгәсе инде төп йорттан аерылып, башка чыкканнар, анда теге чакта бала-чага белән чырылдап торган түр як бөтенләй диярлек бушап калган. Кем балалары, кая киткәннәр, анысы хакында малай шым, колакка каты, иң мөһиме – Салихның үзенә хөррият. Кодаларының икенчедә һәм дүртенчедә укыган ике баласыннан Салих бернинди зыян күрми. Алар шундый тынычлар, барлыклары күзгә дә чалынмый. Шулай да, кодалары ничек кенә такта чәйле, якты чырайлы булмасын, малай анда да туган авылын сагынудан саргайды. Аңа биредә барысы чит иде. Тупса чит, абзар, мал бәйли торган баганалары, хәтта инде чыгарыр вакыт җиткән бәрәңге сабаклары да, алар тамыр ярган туфрак та ятның яты, читнең чите иде. Кыргыз дигән явыз «райсинтыр

нәстә» дустыннан аерып, аны да чит ясаган иде. Бу хакта кайгысын кем белән уртаклашырга белмичә, ул үзенең бала чагыннан якын һәм кадерле, алтын күз күнендә бала башыдай эре бүлбеләре белән яктырган бәрәңге ызаннары белән серләшергә теләгәндә дә, тегеләр, гүя аны тыңлаудан баш тартып, артларын күрсәтәләр иде...

Ярый әле, биредә ни-нәрсәсе беләндер авылдашларына охшаган Сәйфетдин кодасы бар. Ул аны «Бәләкәй Кода», дип йөртә. Салих шул эре сөякле, сугышта автомат келәсендә бармакларын өшетеп, келәшчә кебек кәкрәеп беткән зат белән юану таба. Аңардан «Ничек яраландың?» дип сорасаң, ул, елмаеп, «Яраланмадым, калхуз колыннарын санаганда, кулымны каймыктырдым», дип шаярта. Салих кебек, ул да ат ярата. Юкка гына колхозда ат караучы түгел. Кыргыздагы ярым-йорты колхозны ул «чатан калхуз», дип атый. Чөнки райсинтырда кемгә күз атма, корсагын киергән «ыслушши». Менә әле алар утын тураган Сәфәргали абзыйлары кебек.

Киеме ярлы булса да, бай күренә белә Сәйфетдин кодасы. Мал-туарны яраткангамы? Аның иң яратмаган кешесе – ат кыйнаган да, хатын кыйнаган. Шул да булдымы үнәр ир-атка? Әйе, ул «һөнәр», дип азапланмый, «үнәр», ди. Телгә ифрат үткер. Беркөнне төнге уникегә чаклы электр бирергә тиешле дизель электр бирмәде. «Илектерик булмады бу, – диде кодасы, уфырып. – «Дөмектерик!» булды». Атка кул күтәргән егетләрне ул шаңнап очырырга да күп сорамый. Ул мал дигәнне кешегә караганда тирәнрәк аңлый. Аныңча, һәр малның карахтеры, адымы, тын алышы бар. Сыер көтүдән ихатага лаштырдап, сарык малы леркелдәп, кәҗә малы мекердәп кайтып керә. Малда кешедәге кебек хәйлә, хөсетлек һәм ялкаулык, эшләмичә ашау дигән нәрсә юк...

Сугышта, Берлинны алгач, кибеттә каеш җөгәннәр очрата ул. Моңа кадәр юкә, яхшы дигәндә дә, сүс дирбиядән башка нәрсә күрмәгән кодасы, сөйләве буенча, тынсыз кала. Вагуны белән ал! Тыррафи[8] хакына дип талап та алырга мөмкин. Автомат белән янасаң, нимес бушка бирергә дә күп сорамый. Совет солдатын вәхши санамасыннар дип, Сәйфетдин кодасы шундук ун нимес маркасына – бәямени, чүп бит ул – егерме кәмпликет көмеш сәдәпле җөгән алып, Сталин исемендәге туган колхозына посылка салган...

– Бу җөгәннәрнең әҗерен былтыр гына кайтардылар, – диде кодасы, горурланып. – Дүрт синтныр бодай бирделәр. Рәхмәт, калхуз дигәнең, алдакчы булса да, онытмый.

– Колхозыгыз бай икән, Олы Кода! – дип кычкырып җибәргәнен сизми дә калды Салих. Аннан, капкаларыннан кунакка Гайрәт дусты килеп кергәнен күреп, өстәде. – Әнә, бу тырыш иптәшкә дә берәр синтныр бодай арттырмас микән колхозыгыз?!

– Арттырыр, ник арттырмасын ди!.. Дөрес, колхозыбыз бай булса да, бодае сабакта коелса да, акчасы бер дә кесәсеннән коелып йөрми йөрүен, Бәләкәй кода!.. – дип япты кодасының авызын Сәйфетдин шундук. – Исеме генә элеккечә «Ысталин» түгел. Нindидер «культи личныс» дигән нәрсә уйлап табып, юлбашчыбызны юк иттеләр бит тәки. «Культи» дигәненең аяксызларга... култык таягы икәнен беләм белүен, «личныс»ының нәрсә икәнен хет сез аңлатмассызмы, бәләкәй кодалар?

– Белмибез шул, Олы Кода! – дип кычкырып җибәрде Гайрәт. – Әле моны безгә аңлатмадылар! Законы чыкмаган, димәк...

– Анысы шулайдыр, – диде Сәйфетдин. – Менә, ичмасам, безнең, калхузның, әтәч кычкырган саен, законы чыгып кына тора...

[8] «Трофей»дан кергән алынма.

Дәрескә китәр алдыннан, бигрәк тә аннан кайткач очрашкан минутларда, ул биредә үзенең чит икәнлеген дә онытып куйгалый. Ничек кенәләр онытылмассың? Шундый мавыктыргыч итеп сөйли бит ул!

– Үгезне загатскутка иткә тапшырып кайттым әле, Бәләкәй Кода, – дип тезеп китте ул моннан берничә көн элек кенә. – Үзебезгә насыйп итмәгәндер. Чистый привесы өч синтныр тартты. Тагын да мулрак тарткан булыр иде, аңа абзар иясе – ләтчә тынгы бирмәде. Нишләптер яратмады. Кытыклап азаплады. Танау тишекләре киңәеп китәр иде мескенкәйнең. Үзе шыбыр тиргә бата. Аптырагач, иткә итәрдән алдагы төннәрдә тышка чыгарып кундырдым. Абзар иясе, монда да эзләп таба бит, әй! Һаман тирләтә бит малкайны! «Абзарга кермәсәң, мин сине монда кытыклыйм!» – дип, тегенең түшләрен кети-кети китерә, муеннарына асылына, биглый...

Сәйфетдин кодасы – каен себеркесен бәйләү остасы. Аның мунча себеркеләре каймак кебек йомшак, хуш исле була. Аңардан барлык Кыргыз халкы себерке бәйләттерә. Ни өчен шулай шифалы аның миннекләре? Баксаң, аларны кодасы җәй уянган, дөресрәге, яз белән җәй ялганган, җәйнең язны озаткан көнендә – нәкъ 7 июнь көнне сындыра икән. Ул татарның Сабан туе көннәренә туры килә. Шуңа күрә адәмнәр шушы көннәрдә, аеруча сабантуй-бәйгеләрдән кайткан чакларда, бәйли каймак кебек себеркеләрне...

Дәресләрен әзерләү белән, Салих кодасы янәшәсенә ашыга. Ул барыбер ниндидер бер кызыклы нәрсә сөйли дә куя. Чынлап та, үзеңне туган авылыңда тоеп, читтә икәнлегеңне онытасың...

– Берәүнең танасы тилерде, малай, – дип сөйләп торды ул кичә генә. – Аптырагач, хуҗасы, ахмак, аны атып үтерүдән башка чара тапмаган. Эш үткәч, бу, нишләргә дип, мине чакыра. Тананың, мескенкәйнең, күзләрендә, сөрмәле керфекләрендә әлҗе-мөлҗе килеп энҗе яшь бөртекләре асылынып тора. Мин аның корыдан кипкән эче-карынын, җиленнәрен капшап карыйм. Эче салкын, җиленнәре кайнар, малай! Әле суынып та бетмәгән.

– Аттым да куйдым, югыйсә абзарымның аратасын җимереп чыга иде бит, мәлгунь! – ди бу.

– Ахмак син, дим. Ул бит синнән мылтык сорамаган, үгез сораган! Сине теләп, тана кебек койрыгын күтәрсә, хатыныңны да атып үтерә күрмә тагын!..

Алар Мәрьямбикә кодагый белән берсе икенчесенә юл биреп, килешеп яшиләр. Тормышның тәмен беләләр. Сүз юктан сүз булсын, ата казың күкәй саламы, дигәндәй, бушка сүз куертмыйлар. Тавышланмыйлар. Берсен-берсе кичерә беләләр. Кайчакта кичләрен, сирәкләп, кеше-кара яткач, авыр эштән арып-талчыккан Мәрьямбикә кодагый, Сәйфетдин кода, капма-каршы утырып, ачы бал эчкәлиләр. Пышын-пышын сөйләшеп көлешәләр. Мондый чакларында, өйне яктыртып, бит алмалары алсуланып китә. Җырлап та җибәргәлиләр. Аларның бер җыры хәтерендә калган. Үзләре кебек, кара-каршы җырланган җыр булды ул. Салих ишеткән көй түгел иде. Озын, бик тә озын көй иде:

Таудин тауга без җитәбез, атның ла дагалары ла кызганчы.
Ярны да гына сөйсәң, сөй катырак, йөрәкнең майлары ла сызганчы.
Алчы, җегет, бирче лә малыңны,
Мин кызганмыйм газиз лә җанымны...

– дип сузды Мәрьямбикә кодагый.

Аны эчтән генә, ябык тавыш белән сызып, Сәйфетдин кодасы күтәреп алды:

Иртә дә генә торып, тышка чыксам, җил аударган күркәм лә каенны.
Янымда юк юлдаш, җан тынычсыз, кемгә сөйлим авыр ла хәлемне.
Ала калсам, суырып үбәрмен,
Ала алмасам, егылып үләрмен...

Шушындый җырлар арасында яшәп, ул кодагыеның кодасына икенче хатын булып килгәнен дә белде. Бервакыт келәт янында эшләгән берничә сердәше аңа ияреп чәй эчәргә керде.

– Сулагай да булгач, башка ир табылмас, диеп, шушы фрунт гарибе Сәйфетдингә... хатыны үлгәние... дүрт җиткән баласы өстенә чыктым да куйдым инде! – дип сөйләнде кодагые. – Аллага шөкер, бер дә гарип-гораба дип, үги дип тормадык. Үгиләремнең дүртесен дә башлы-күзле иттек. Үзем дә дүрт бала таптым. Берсе тугач та, икенчесе – бишектәгесе үлде...

– Әйе, шөкер ит! – дип күтәреп алдылар Мәрьямбикәне ахирәтләре. – Урыннары оҗмахта булсын бишек фәрештәләренең. Теттереп дөнья көтәсез, куана гына бел, Мәрьям!..

Бәррәч, аның уңганнан-уңган Мәрьямбикә кодагые сулагай микәнни?! Шушы уңганлыктанмы, аш-су биргәндә, сулагайлыгы бер дә күзгә чалынмый бит! Кайвакыт, колхоз дворындагы атларыннан аерылып, кодасы өенә сугылып чыга. Андый чакта ул мич башында гөжелдәп утырган мичкәдән эрзин эчәге белән бер тустаган балны суыртып ала, килә-килешли, почмактагы кисмәктә купыраеп утырган урман агачыдай дәү фикусның чабата кадәр яфрагын чеметеп кенә өзеп ала, урынына утыра, вәкарь белән, ара-тирә кикергәләп, балын чөмереп эчә, агулы гөл дип тормый – фикус яфрагын тәмләп чәйни һәм, як-ягына карап:

– Хар-руш! – ди дә эшенә чыгып китә...

Шулай, кәефе килгәндә, ул һәрвакыт «хар-руш!» дип сөйләшә. Кешеләрнең кәефен дә шулай: «Ну ничек, эш харушмы?» дип сораша.

...Туракларга дигән җирдә өч-дүрт кенә буй агач калганлыгын күреп, малайлар җиңел тын алдылар. Җиңәләр, Алла боерса!.. Көзге көннең сулышы кыска, төштән соң, чабатаңны чишеп, туфрагын каккалап бәйләгәнче, күз дә бәйләнә башлый. Соргылт абзый белән менә шул күз бәйләнгәнче исәп-хисап ясап, тиярен ала алсалар, эшләре дә җайланыр, эчләре дә майланыр иде югыйсә. Малайлар өйгән утыннарын инде кырык тапкыр әйләнеп, әфсен-төфсенләп чыккан иделәр. Алар фикеренчә, киң атлам белән атлап үлчәсәң дә, киерелгән карыш белән карышлап үлчәсәң дә, өемдә артыгы белән биш кубометр утын бар. Бик бәйләнеп, киметү ягына барып, чутлашып-ваклашып маташмаса, юк димә, бәлки, алты-җиде кубометр да булып чыгар. Буе, киерелеп атлаганда, алты адым, ягъни алты метр, иңе, ботларыңны кысып атлаганда, өч адым, ягъни ике метр ярым, биеклеге алар карышы белән ике карыш ярым, ягъни артыгы белән кырык-илле сантиметрдан (малайлар, көчләрен саклап, өемне биектән итмәделәр!) исәпләп тапкырласаң, шартлатып алты кубометр килә дә чыга. Әле тураклап бетерәсе ике агач бар. Өсләренә шул пүләннәрне дә салсаң, кая китә! Аларның, ялга туктаган саен, үзләре өйгән әрдәнәне үзләре үлчи-үлчи, шуннан тәм таба-таба башлары әйләнгән, йотар төкерекләре калмыйча, үңәчләре кипкән иде. Урам ягыннан «шак!» итеп рәшәткә капкасы ябылганы ишетелде. Соңгы агачларына тотынган малайлар ялт итеп шул якка карадылар һәм шыбыр тиргә төштеләр – буаз сумкасын күтәргән хәрби фуражкалы Соргылт абзыйлары болдырга якынлашып килә иде.

– Сәфәргали абзый, без бетереп киләбез! – дип кычкырды җаваплылыкны

үз өстенә алган Салих. Аннан, ишетми калмасын дигәндәй, тагын бер тапкыр сузып кычкырды. – Без бетереп ята-а-а-бы-ы-ыз!..

Абзыйлары эндәшмичә генә ишегенең тишегенә кереп чумды. Катя чыгып басып, аларны бер карашы белән куандыра торган болдырдан малайларга бу юлы котып салкыны бөркелде. Бер кайнардан бер салкынга төшү аларның игътибарын тагын да нечкәртте. Алар уйлары белән, инде төкерекләрен йотып, кулларындагы сайрап торган кәгазь акчаларын учларында учмарлап, Ленин исемендәге урам чатындагы азык кибетеннән күзләре нигә төшә, шуны сыдырып яталар иде...

Салих белән Гайрәт соңгы агачларын тураклап, түмәрләрне, эш азагында хасыйл була торган аерым бер җыйнаклык күрсәтеп, өемнәре өстенә өйделәр, өс-башларын, аяк-кулларын каккалап алдылар да, пычкы-балталарын, чит-ят күзгә артык ялтыратмаслык итеп, капчык чүпрәгенә төреп, утын өстенә куйгач, җәядән ычкынырга торган ук булып, абзыйларын көтә башладылар.

Тирә-юньгә таралган агач хуш исен җиңеп, кинәт һаваны арттан килгән тирес исе аңкытты.

Галифеләрен җилкәндәй җилфердәтеп, хуҗа абзаның килеп җитүе икән. Тирес исе дә аннан килә. Бик хуп. Моңа кадәр башын-күзен күрсәтмәгән булса да, бар нәрсәсе урынында икән югыйсә. Атна буена аңа эшләп, бары тик икенче тапкыр гына якыннан күргән абзалары чынлап та соргылт йөзле – кипкән каен чырасы кебек чырайсыз кеше булып чыкты. Бу кеше гел кәбестә шулпасында яшидер, дип уйлап алды Салих. Шулай булмаса, аның йөзендә тере кан төсе, һич югы авыл балалары ашап үскән балтырган шаукымы булган булыр иде... Шешә корсагыдай бүлтәеп торган галифе кесәсеннән линейкага охшаган ниндидер сәер нәрсә тырпаеп торган Сәфәргали абзыйлары фуражкасын өендә калдырган, яланбаш, иңеннән аркылы төшкән портупея каешлы хәрби гимнастёркадан иде.

– Сез монда күпмерәк була дип уйлыйсыз инде, братва? – диде ул, утын өемен күздән кичергәннән соң. – Исәпләдегезме? И каким образом исәпләдегез?

– Кубометры, сез әйткәнчә, бер сумнан инде, – диде Салих.

– Так-то так. Ә биредә ничә кубометр?

– Алтыдан да ким түгел, абзый, – дип сүзгә кушылды Гайрәт. – Без аны кат-кат... бик нык... күзләребез чәчрәп чыкканчы үлчәдек...

– Чәчрәп. Эт-то хорошо. Мин күпме отстегнуть должен?

– Стегнуть, дип... – дип өстәде үзен батыррак тоткан Салих. – Безгә кешенеке кирәкми. Алты сум булып чыга инде, димәк.

– Һы! – дип көлемсерәде Сәфәргали абзый. – Ә ничек үлчәдегез?

– Ничек, дип. Математика ничек өйрәтте, шулай тоттык та үлчәдек... – Һәм малайлар, икесе ике яктан атламнары белән дә, карышлары белән дә утын өемен уратып, үзләренең исәбен расларга тотындылар.

– Так не бывает, братва. Ул менә так бывает. – Шешә авызыннан суырып алгандай хәрәкәт ясап, галифе кесәсеннән линейкага охшаган ялтыравык нәрсәсен чыгарды. – Бу – логарифма... югары математик вычислитель була. Троффей, ызначит. Германиядән. Сезнең в жизни дә күргәнегез юк...

«Троффей», дигәч, Салихның күз алдына Сәйфетдин кодасының Берлиннан Кыргызга җибәргән трофей җөгәннәре килде.

– Вот без хәзер аны шушы логарифма белән эт сигәнче вычислять итәбез. Карап торыгыз, братва, миңа кешенеке грамм да не нужен... – дип дәвам итте Сәфәргали абзый һәм утын өемен буйлатып һәм иңләтеп, астан һәм өстән үлчи башлады. – Т-тә-ә-әк... Сезнең буйга алты метр дигәнегез, биш целых ноль

сиксән биш, иңгә ике метр ярым дигәнегез... Синус!.. Хәзер беләбез аны... Тә-ә-әк... ике бөтен четыре целых метр, ә биеклеге дигәнегез... Хәзер ачыклыйбыз анысын да... Косинус!.. Тә-ә-әк... кырык сантиметр түгел, ә нибары утыз сигез сантиметр. Акча тәгәллекне ярата. Хәзер исәплибез...

Малайлар, уклау йоткан кебек, үрә катканнар иде.

– Хәзер окончательный расчёт, ызначит... – Сәфәргали абзый логарифманың өстәге аелын шудыртып, гармун басмакларына баскан шикелле итеп баскалады. – Сезнең зряплата... итоһо... уптым илаһым, если наскрести, биш сум 33 тиен килеп чыга. Внушительно!.. Канәгатьсезме? Мин, мәсәлән, канәгать булыр идем. После уроков!.. Физкультура урынына!.. Столько денег!..

– Синус-косинус... Безнең үлчәм белән монда алтыдан да ким түгел, Сәфәргали абзый! – диде ачынып Салих.

– Ну, бу бит, братва, сезнең авыл... деревенский үлчәм! Безнең район җирендә үзебезнең үлчәм, так сказать! – Ул галифесенең уң як кесәсеннән үзе кебек соргылт акча янчыгы, аннан буынтыклы шакмак бармаклары белән кибеп саргайган бишлек китереп чыгарды.

– Кайсыгыз старшой? Синме? – Ул бишлекне Салихка сузды. – Возьми. Бүлешерсез. Утыз өч тиененә вак акчам юк икән, чёрт возьми. Берәр заман, сугылып чыгарсыз...

Көтелмәгән хәлдән тетрәнгән Салих акчаны алырга ашыкмады. Яшел кәгазьнең өстенә, каяндыр адашып килеп, эре тамчы яңгыр тамды. Тамчының көзгедәй түгәрәге, үзендә бар дөньяны чагылдырып, түбәнгә тәгәрәде. Салихны ток суккандай булды. Малай банкир кулыннан ассигнацияне өзеп-умырып диярлек алды. Шулчак уенда-буенда ниндидер ятимлек гаре уянган Салих тәне белән түгел, җаны белән, гәүдәсе белән түгел, йөрәге-кальбе белән утын өеменә сикереп менде, аякларын хуҗаларча аерып басты һәм, кулларын болгый-болгый, абзасына төртеп күрсәтә-күрсәтә сөйли башлады:

– И-и-и, Сәфәргали абзый, сасыма, җаныкаем! Утыз өч тиенең тамагыңа аркылы торсын! Тынычлан! Без аның артыннан кереп йөрмәбез! Син аны учыңа учлап ләхетеңә алып керерсең! Әмма ул да хәлеңнән килмәс!.. У-у-у, адәм тәганәсе, мин сине ничек кенәләр яратмыйм! Ничек кенәләр каһәрлим! Син – утынлыгыңдагы агачта да читкә әйләнгән корт! Син – үз җиреңдә үз җиреңне, үз телеңне корыткан корткыч, абзый!..

Әмма Салих әлегә югарыда, өем башында түгел, өемнең астында, түбәндә иде.

– Рәхмәт, абзый... – диде иреннәре калтыранган сабыйлар. – Рәхмәт сезгә, яме.

Агач исе сеңгән, өс-башлары пычкы оны белән онланган ике малай рәшәткә капкасын шапылдатмыйча гына урамга чыктылар. Кара җир өстен агартып, үзенчә өзлегеп, беренче кар бөртекләре төшә башлады.

Малайлар үкенечле моңсу, әмма үзләренчә шат иде.

Күгәргән кадакта тешсез калган пычкыларын култык астына кыстырган бу ике сабый кешегә түгел, кешеләр аларга бурычлы иде.

– Хуш, Катя! – дип, тәрәзә ягына кулын селкеде Гайрәт. – Пращай, бәгърем!

Салих дустына яшь аша елмайды.

Аларны барыбер чәй эчәргә чакырмадылар. Ул Катясын туйганчы күрә дә алмады, ичмасам.



Рәсимә Гарифуллина

# АЙ НУРЫНДА ЭНҖЕ ЯНА

## Кагылмагыз яраларга!

Аерылулар авыр икән,
Сагынулар дару микән?
Сыңар канат, калды канап...
Кайтмас җиргә китте иркәм.

Кагылмагыз яраларга,
Тырышмагыз дәваларга.
Сөйгәнемнең карашыннан
Башка дәва юк аларга.

Ялгышларны кабатладым,
Киселделәр канатларым.
Кайтмас җиргә китте ярым,
Мин башканы яратмамын.

Кагылмагыз яраларга,
Өмет итеп дәваларга.
Сөйгәнемнең назларыннан
Башка дәва юк аларга.

Белмәгәнгә кадерләрен,
Кисә йөрәк-бәгырьләрен.
Бер киткәннәр кайтмыйлар шул...
Кочып елыйм каберләрен.

Кагылмагыз яраларга,
Бер дәва да юк аларга.
Уртак юллар аерылды...
Үлем керде араларга.

Рәсимә ГАРИФУЛЛИНА – *шагыйрә; «Бүген ярат», «Яшәү мәңгелек», «Зәңгәр дуга» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Балык Бистәсендә яши.*

## Яшьлек белән сөйләшү

Үзгәрдеңме, йөрәк, әйтче миңа,
Нинди хисләр белән яшисең?
Кайтавазы булып гомеремнең,
Сорау бирә шулай яшьлегем.

Зирәкләндең, акыл утырттыңмы,
Нинди уйлар белән яшисең?
Әйтми саклар гамәлләрең бармы,
Шуңамы соң бер дә дәшмисең?

Үзгәрдем дә бераз, юк та сыман,
Йөрәгемдә һаман яшисең.
Бер кайтаваз булып яшьлегемнән,
Китмә, диеп, нигә дәшмисең?

## Бала көтә ана

Бала көтә ана, бала көтә,
Мең борчуы йөрәк түрендә.
Күпме изге теләк теләде ул,
Иртә таңнан торып бүген дә.

Малай булса, батыр булсын, диде,
Кызы туса, булсын ил күрке.
Йөзләрендә нурлар уйнап торсын,
Икесен дә бөтен ил күрсен.

Карынында типкән баласына
Өмет баглап бәхет юрады.
Бер Ходайдан гомер белән бергә
Шәфкать, мәрхәмәтен сорады.

Һай бик кирәк безнең балаларга,
Рәхим-рахман кирәк, игелек.
Ата-ана тигезлеге кирәк,
Сыңар канат итмә, үгилек!

Мең төрле уй ана күңелендә,
Мең өмете йөрәк түрендә.
Ана мәхәббәте ярдәм бирсен
Газизенең туар көнендә.

Балаң булу – иң зур бәхет бит ул,
Әни булу – олы мәртәбә.
Шушы изге хисне биргән өчен,
Мәрхабә, йә Ходам, мәрхабә!

Сабыеңның битләреннән үбү,
Бишек җыры көйләү яратып.
Күкрәк сөтең белән көч бирүең,
Мең борчуларыңны таратып.

Иң зур теләк шушы, иң зур өмет,
Туар балаң өчен сөенү.
Киләчәктә аның рәхмәтенә,
Рәхим-шәфкатенә тиенү.

Әнә шундый якты уйлар белән
Бала көтә ана – мәрхабә!
Җан җылыңны сабыеңа бирер
Ана булу – олы мәртәбә.

## Чулман өстендә рәшә

Дулкын шавы булып гомер дәшә,
Яшел таллар яулык болгыйлар.
Чулман өскәйләре зәңгәр рәшә,
Гашыйк акчарлаклар уйныйлар.

Онытылып бөтен уйларымнан,
Әйләнәсем килә дулкынга.
Кагыласы килә синең ярга,
Атыласы синең упкынга.

Янәшәңдә бер җылыныр идем,
Дулкыннарга килә дәшәсем.
Акчарлаклы яшьлегемә кайтып,
Синең белән килә яшисем.
Акчарлаклы яшьлегемә илтче,
Туган якның зәңгәр рәшәсе!

## Кышкы кичтә

Бөтерелеп-бөтерелеп,
Кичен ап-ак карлар ява.
Сокланырлык бер манзара –
Ай нурында энҗе яна.

Бөтерелеп-бөтерелеп,
Ап-ак карлар уйнап оча.
Йомшак кына иркәләнеп,
Ак мамыктай җирне коча.

Бөтерелеп-бөтерелеп,
Карлар ява, карлар ява.
Кышкы кичтә сине көтеп,
Минем сүнмәс йөрәк яна.

## Кадерен бел!

Берәү дә берәүдән ким түгел,
Гомеркәй синнән дә, миннән дә уза ул.
Тик менә кемнеңдер йөрәге,
Бәгыре моңнардан сыза ул.

Ике кат яшәми бирәү дә,
Гомерем минем дә узгын ла.
Нәкъ синең шикелле янамын
Бер килгән сөюнең кузында.

## Җырым кала

Якты дөнья буйлап барам –
Җир өстендә эзем кала.
Моң уяна йөрәгемдә,
Күңел кылым зеңләп ала.

Якты дөнья буйлап барам,
Җырым белән җирне бизәп.
Үземнән соң җырым кала,
Яшьлек кала, кулын изәп.

Якты дөнья буйлап барам –
Тормыш матур, яшәү рәхәт.
Матурлыкка күзем ачкан
Туган җирем, мең-мең рәхмәт!

## Яшисе иде бергә

Икебезгә ике дөнья –
Син үзең дә, мин үзем.
Сагынабыз, яратабыз,
Кавышып булмый, бир түзем!

Икебезгә ике йөрәк –
Әмма бергә яналар.
Сагынабыз, саргаябыз –
Бик ерак шул аралар.

Икебезгә ике гомер –
Һәркем яши үзенчә.
Сагынсак та, саргайсак та,
Чара юк бит түзмичә.

Икебезнең язмышларны
Кушасы иде бергә.
Сагынмыйча, саргаймыйча,
Сөеп һәм сөелеп кенә
Яшисе иде безгә!

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*

# КИНӘНЕП ОЧАР ӨЧЕН!

Бүгенге көндә Алинә Галиева Казан (Идел буе) федераль университетында татар филологиясе һәм журналистикасы белгечлеге буенча өченче курста укый, шигырь, проза, драма әсәрләре иҗат итә. Ул «Илһамлы каләм», «Илһам», «Иделем акчарлагы» конкурсларында һәрдаим җиңү яулап килә.

«Иделем акчарлагы» дигәннән... Инде менә егерме елга якын берөзлексез дәвам иткән бу мәртәбәле конкурсны башкалабыздагы «Идел» яшьләр үзәге оештыра. Афәрин аларга! Заманында әлеге конкурста Гран-при яулаган «акчарлак»лардан Ленар Шәех, Рөстәм Галиуллин, Рүзәл Мөхәммәтшиннар хәзер инде әдәбиятыбыз күгендәге үз биеклеген таба баралар.

Яңа буын «акчарлагы» Алинә Галиева исә (төсмерләсәгез, Олимпия йолдызыбыз Алинә Заһитова аңа тач охшаган!) өч ел рәттән конкурсның шигырь, драма, проза һәм балалар әдәбияты номинацияләрендә уңышка ирешә. Мәсәлән, сезнең хөкемегезгә тапшырылган менә бу хикәясе узган елгы конкурста беренче урынны алган иде. Афәрин дими, ни дисең?!

Жюриның даими әгъзасы буларак, янә шунысын әйтә алам: яшь әһле каләм иялəре бирегә фәкать бүләк вә урын алыр өчен генә килмиләр. Әлбәттә ки, лауреат, яки Гран-прига лаек та булып куйсаң, бермә-бер куаныч инде анысы. Алар, кинәнеп очар өчен, «Иделем акчарлагы»нда канат ныгыталар һәм аларны әдәбиятыбызның киләчәге-күге түземсезлек белән көтә дә!

**Марат ЗАКИР**



Алинә
Галиева

# КИЛӘЧӘККӘ АТАП

ФАНТАСТИК ХИКӘЯ

– Бүген, ниһаять, хыялларыбыз чынга ашты, – дип, керә-керешкә сүз башлады җитәкче. Аның кәефе шәплеге килеш-килбәтеннән үк күренеп тора: костюм төймәләрен ычкындырган, галстугының төсе үзгәргән. Хәтта йөзендә елмаюга охшаш чалымнарны да күрергә була. Эшчеләр аның мондый вакытын күптән хәтерләми: «төксе чырай» дигән кушамат тагылып, мең кат раслап куелган... Менә бит ничек – дөньядагы иң усал һәм явыз күренгән адәм дә,

үз дигәненә ирешкәч, елмая белә икән! – Ниһаять, машина ясалып бетте, – диде ул. Әлбәттә, сүзнең нәрсә турында барганлыгы бүлмәдә утыручыларга яхшы аңлашыла. Кайчандыр янгын аркасында юкка чыккан канун кәгазен яңадан булдырганнар, димәк. – Без күпме тир түктек, яңадан элеккеге рәхәт вакытларны кайтарырга тырыштык. Ә менә бүген, бүген ... – дип, бармагын өскә күтәреп дәвам итте ул, хисләренә буылып, тын алырга да онытты бугай, бераз дәшми торды. – Әлеге сынауда катнашу өчен, үз эшенә бирелгән, җаваплы һәм ышанычлы батыр кирәк. Йә, кемне җибәрәбез?

Өстәл араларында кечкенә бөҗәкләр шикелле тезелешеп утырган соры костюмнар кымшанмады да хәтта. Җитәкченең күзләре кысылды, озын бармаклары түземсез рәвештә биешә башлады. Ул, тавышын югары күтәреп, түрәләргә хас булган боеру белән тагын бер кат кабатлады.

– Кайсыгыз бара, дим? Сез нәрсә, барыгыз да авызыгызга су капкан кебек утырасыз?! Безнең тарих өчен, юк, бөтен дөнья өчен иң зур эш эшләвегезне күз алдыгызга китерәсезме?! Соң, сезне бит, аннары кулдан кулга гына йөртәчәкләр, бу адәм безнең киләчәгебезне саклап калган, дип риваятьләр чыгарып, оныкларына сөйләячәкләр. Тьфү, куркаклар! Бөтенегезне эштән куам!..

Ул бу сүзләрне котырынган үгез шикелле мышнап, ярсый-ярсый сөйләде. Йөзе бүртеп, яңа пешкән бөрлегәнгә охшап калды.

– Кирамны җибәрергә кирәк! – Бүлмә эченнән яңгыраган тавыш аны бераз тынычланырга мәҗбүр итте.

Бүлмәгә яктылык кереп җитә алмаганлыктан, сорылык бөтен почмакны биләгән – ул юри бу кешеләрнең йөзләрен яшерергә тырыша булса кирәк. Шуңа күрә аннан кемне дә булса аерып алу да авыр. Кыңгыр эш кылып йөрүчеләр дә үз ниятләрен караңгы төшкәч тормышка ашыралар бит. Кеше-кара ялгыш күреп калмасын, танымасын дип. Ә яктыргач бернәрсә дә булмаган төсле елмаеп йөриләр. Караңгыда кешенең чын асылын белергә була. Җитәкче, чыдый алмыйча:

– Бас! – дип кычкырды.

Өстендәге костюмы капчык кебек асылынып торган ябык гәүдәле бер ир-ат әкрен генә урыныннан торды.

– Синме инде ул Кирам? – дип сорады, ә үзе шундук: «Әйләнеп кайта алмаса да кызганыч түгел икән, эшен генә эшләсен», дип уйлап өлгерде.

– Мин булам, – дип җавап кайтарды аягүрә баскан адәм.

– Күпме хезмәт итәсең инде бездә?

– Унынчы ел китте, әфәндем.

– Яхшы, яхшы... – дип, уйлаган кыяфәт чыгарды җитәкче. Үзе янында торган булышчысының колагына нидер әйтеп алды. Тегесе, шул минут эчендә, бу адәм турында язылган мәгълүмат дәфтәрен аның кулына китереп тә тоттырды.

– Хмм, ярар, ярар... – диде ул, язулы битләрне актарган булып. – Әзерлән, бүген кояш көннең уртасына җиткәч тә юлга чыгарсың. Кара аны, синең бары тик бер генә мөмкинлегең бар. Әгәр шуны кулдан ычкындырсаң, башың белән хушлашырга әзер бул, – диде катгый гына. Аннары сынаулы караш белән күзен сикертеп: – Безнең нинди кагыйдәләр бар әле? – дип сорады.

– Беренче кагыйдә: берәү белән дә сөйләшмәскә!

Икенче: беренче кагыйдәне истә тотарга!

Өченчесе: алда әйтелгән ике кагыйдәне онытмаска!

– Ярый... Менә ул – син барачак авыл. Без шәһәр сакчыларында шик уятырга

тиеш түгел. Андагы кешеләр турында мәгълүмат һәм ышанычлык кенәгәсе. Шуның буенча канун саклана торган бүлмәгә керерсең, – дип, Кирамга бер-берсе өстенә өелгән кәгазь битләре тоттырды.

– Барысы да аңлашылды, әфәндем, – диде ул.

– Барыгыз, таралыгыз. Ә син, кара аны, – диде ир-ат, әлеге дә баягы бармагы белән янап. Әйтерсең, ул бармакта дөньяның бөтен куәте җыелган.

Насыйр, башкалар шикелле үк, күтәрелеп карарга базмыйча, бүлмәдән чыгып китте. Аның инде яшьлеге узып, чәчләре агарырга да өлгергән. Һе, унынчы ел китте дигән була бит, ә аннан: «Насыйр абзый, син бездә ничә ел хезмәт куясың инде?» – дип ник берсе сорасын. Ә ул: «Егерменче ел китте инде, акыллым», – дип җавап кайтарыр иде. Шактый гомер, шушы сорылык эчендә, әллә никадәр тау итеп өярлек эш эшләп үтте, тик аларның берсе дә «рәхмәт» дигән сүз белән булса да үлчәнмәде. Кушканны башкарды, каршы дәшмәде, түзде, чыдады, аның саен җилкәдәге авыр йөк артып, бөкресе барлыкка килде. Үткәндәге хата-ялгышлар шулай вакыт-вакыт җанны бимазалап ала да, беркая да юкка чыкмыйча, җилкәгә менеп утыра иделәр. Югыйсә әле алай карт та түгел үзе, 55 яшь бит инде ул – ирләрнең иң җитлеккән, уңыш җыя торган мәле булырга тиеш. Йа Хода, үзең генә беләсең минем хәлләремне, кешегә сөйләсәң, кеше ышанмас, дип уйлады ул.

Кирам белән алар дуслар иде. Ничек дус дип, күрешкәндә бер-ике сүз әйтешәләр иде инде. Шуның белән бетте-китте, вәссәлам. Монда алай аралашу дигән әйбер юк, кирәк түгел, вакытны юкка сарыф итү, янәсе. Тьфү, аның вакытына! Гомер буе кеше кушканны эшләп йөрү – менә монысы инде чынлап та ыштан туздыру. Насыйр картның үз-үзенә ачуы килде, җебек авыз, бер сүз дә каршы әйтә алмый торган бөҗәк,  дип тиргәде ул үзен. Аннары яныннан гына узып баручы Кирамны күреп алды. Аның кәефе киткән: кашларын җыерып, җил-җил каядыр ашыга. Насыйр аның артыннан иярде.

– Синең эшләр хутта, – диде ул.

Кирам күтәрелеп карады да туктамый гына юлын дәвам итте.

– Бик хөрмәтле кеше булачаксың инде болай булгач! Әнә хәзердән үк безнең шикеллеләргә ләм-мим! – дигән сүзләр белән битәрләп ул Кирам артыннан җитешергә тырыша иде.

– Ник минем арттан йөрисең? Әйе, шундый яхшы эш инде. Пычагыма кирәк миңа, үткәнгә кайтып, үз гомерем белән саубуллашу, – диде Кирам, кинәт туктап.

– Ничек инде саубуллашу? Син бит анда барып кына кайтасың, – дип гаҗәпләнде карт.

– Бер тәүлек. Бары тик 24 сәгатькә генә көйләнгән ул, аңлыйсыңмы?! Әгәр җитешмәсәм, әнә, ишетеп тордың, нәрсә әйткәнен, – диде ул. Аның күзләрендә гаҗизлек хөкем сөрә иде. Ул Насыйр шикелле карт түгел, яңа гына өйләнде дә бугай. Тиздән, бәлки, Алла кушса, балаларын да сөяргә насыйп булыр. 24 сәгать – бер көн ди бит. Һи!

– Кара әле, кая җибәрәләр соң сине? Нинди җиргә? – дип кызыксынды карт.

– Менә, монда язылган, диделәр. Хәзер... – Кирам кәгазь актара башлады. – «Мор-та-за» дигән авыл. Күргәнем, ишеткәнем дә юк! – дип, тагын каш җыерды.

Насыйр: «Мортаза, Мортаза», дип кабатлады аның артыннан. Бик якын, таныш исем. Кая ишеткәне бар соң аның бу исемне?! Йа Хода, юк, ул түгелдер! Картның аяк буыннары тотмас булып, ул якындагы эскәмиягә килеп

утырды. «Мортаза бит, Мортаза», диде ул кабат. Бу бит... Аннары, Кирамның сорауларына да карамый, бүлмәсенә ашыкты. Әлеге сүзләрдән соң аның җаны кузгалгандай булды, мүкләнеп беткән йөрәк үзен сиздереп бер кат кагып алды. Ничә еллар үз гәүдәсендә йөртергә тиеш булган соры костюмын салып, урындыкка элеп куйганнан соң, хуҗасына көлеп карап торган тукыманы шелтәлисе, тормышы шундый булганга тиргисе килде, бар гаеп шунда гына, имеш, ул гына аны монда богаулар белән бәйләп тота, янәсе. Аннары стенада эленеп торган кечкенә генә көзгегә күз салды. Насыйр урынына анда бөтенләй башка, җыерчыклы һәм сарырак йөзле, берән-сәрән чәч бөртекләре тырпайган карт карап тора иде. Уфтансаң да, уфтанмасаң да юк. «Юк, юк», дип мыгырданды ул авыз эченнән. Йөзе агарынган, куллары берөзлексез калтырый иде. Ул, аякларын көчкә кузгатып, календарьдагы язуны карады: 2062 елны күрсәтә, нәрсәдер санады, арлы-бирле йөренде дә, мин кайтырга тиеш, дип, кергәннән соң әле ябылып та өлгермәгән ишек аша янәдән чыгып йөгерде. Шыгырдый-шыгырдый чайкалып калган ишек аны озатып калды.

Кирам үз кабинетында нindидер кәгазьләрне карап, сызгалап утыра иде.

– Кирам, – диде Насыйр, шакып та тормастан бүлмәгә бәреп кереп, аннары сулуын басарга бер-ике кат комсызланып һава йотты. – Кирам, син бит анда барасы килми, дигән идең, шулаймы? Әйдә, үзем барам, – дип әйтеп тә салды.

Шундый ук соры костюм урыныннан күтәрелде дә:

– Син? – диде, мыскыллы елмаеп. – Соң син бит анда барып та җитә алмыйсың. Өстәвенә, мине «теге» үтерә аннары. Эштән куылуымны телисеңмени?

– Кирам, соң мин бит сиңа яхшылык кына теләп.

– Үземнең өлешне сиңа бирер хәлем юк!

– Үзең бит яңарак кына зарланып тордың?

– Торса соң, зарланырмын да, синең эшең булмасын анда! – дип, Кирам бөтен ачуын картка җибәрде.

Насыйр бу тормышта бөтен нәрсәне дә күрдем, күпне беләм дип уйлый иде, ялгышкан, күрәсең. Ничек үсенде бит, ә, ничек тоткан була үзен! Яңа гына маңка малай кебек, «эшләп бир», дип арттан ялынып йөрүләрен оныткан ахры. Әмма бирешәсе килми иде. Күпме еллар үз хокукларын куллана алмаган кешегә бу очрак, теге дөньяга киткәнче, Аллаһы Тәгалә тарафыннан җибәрелгән бүләк дип кабул ителергә тиеш иде. Тик йокламаска, үҗәт булырга кирәк.

– Кирам, үтенәм, минем сиңа кылган яхшылыкларым хакына, бер генә үтенечен үтә карт кешенең, – дип ялынды ул үзенә сынаулы караш белән карап торучы ир-атка. Горурлык хисе чеметеп алса да, бер катка гына түзәргә була әле.

– Тәәк... Барам, дисең инде алайса? – дип елмайды ул.

Картның күңеленә җылы кереп киткәндәй булды. Кырт кисмәде, димәк, нindидер өмет бар әле.

– Барам, барам, – дип кабатлады.

– Ярар, бүлмәңә чык, чакырырлар, – диде ул. Насыйр, тиз үзгәргән фикергә ышанырга да ышанмаска да белмичә, торган урынында катып калды, сөенечтән йөзләре яктырып китте.

– Рәхмәт, рәхмәт... Тазалык белән гомер итәргә язсын сиңа! – дип, Кирамның кулларын үбәргә тотынды.

– Ярый, бар, кит инде моннан. Бөтен эшләремнән бүлдең.

Насыйр тизрәк кирәк-яракны җыярга, әзерләнә торырга кирәк, дип бүлмәсенә ашыкты.

Коридор борылышында очраган ике кеше аңа комачаулык итте, әздән генә маңгайга-маңгай бәрелешми калдылар.

– Алдыңа карап йөре, күзең чыккан мәллә! – дип кычкырды берсе.

– Гафу итегез, күрмәдем, – дип мыгырданды Насыйр. Аның эшчеләр күтәреп килә торган зур гына биштәргә күзе төште. Гади генә сумка түгеллеге аермачык күренеп тора.

Ул алар артыннан тагын Кирам бүлмәсенә таба атлады.

Ишекләре ябылып бетмәгән, сүзләр бик яхшы ишетелә. Әнә Кирам, телефоныннан кем беләндер сөйләшә-сөйләшә, портфеленә тыгызлап кәгазь тутыра. Тукта, яңа гына Насыйрга вәгъдә биреп, сәяхәткә үзе җыенып ята түгелме соң? Карт, мондый астыртынлыкка чыдый алмыйча, бүлмәгә атылып кереп тә китте, тик ялгыш адым ясавын аңлаганда соң иде инде. Кирам аны күргәч тә, бернинди шик уятмастан, үзен тыныч тотарга тырышып:

– Насыйр карт, син һаман китмәдеңмени әле? – диде.

– Ю-юк, – дип сузды карт. Үзе, нәрсәдер эшләргә кирәклекне белеп, башыннан мең төрле ысулны әйләндерде. – Сине-е анда чакыралар, теге, – дип өстәде.

Әлбәттә, ялганлады, ләкин нәтиҗәсе булды бит: Кирам чыгып китте. Бу гадәтне еш кына «яман», дип атыйлар, балаларны да «алдарга ярамый» дип үстергән булалар. Ялганчылар! Дөньясы үзе шуңа корылган икән, синең белән минем генә яхшылыкка карап торамы соң? Алдарга кирәк, алайса бөтенләй сытып китәчәкләр.

Ничек тә сумканы кулга төшерергә кирәк. Каһәр суккан, бу икесе кулларыннан да җибәрми басып торалар. Әһә, әнә шкафта һәрнәрсәне чишә ала торган тылсымлы сыеклык тора. Насыйр, елмайган булып, пыяла савыттагы эчемлекне өстәлгә китереп утыртты, аннары, күз кысып, кечкенә генә шундый ук пыяла савытларга агыза да башлады. Тегеләр, башта ул якка карамаска тырышсалар да, ахыр чиктә биштәрле сумканы урындыкка куеп, өстәл янына килеп утырдылар. Насыйрга шул гына кирәк тә иде инде. Болар чираттагыга үрелгәндә, шыпырт кына яннарыннан тайды да сумканы аркасына асты. Ниндидер төймәләр белән урап алынган бу җайланманың ул, ихтимал, берниен дә аңламый иде, «Аллага тапшырдык», дип, башкаларыннан зуррак булып аерылып торган кызыл төймәгә басты. Аннары, янындагы портфельне эләктереп, чытырдатып күзләрен йомды.

– Кая карыйсыз! Тотыгыз каракны, бетерә башны! – дип кычкырып калган Кирам сүзләре дә һавада эреп юк булды. Мондагы тормыш куркыныч бер төш шикелле артта калды.

*24 сәгать*

...2042 ел. Насыйр карт күпме еллардан соң кабаттан авылына әйләнеп кайтты. Шул гомер билгесезлек, дөресрәге, юклык билгесе булып хезмәт иткән бу җир почмагы яшел хәтфә үләннәре, сокландыргыч табигате, чишмәсе белән һаман да үз көенә яшәп ята икән әле. Насыйр аның исе, тавышы, тәменә кадәр тойды. Бөтен үпкәләрен әлеге һава белән тутырасы килеп, бик озак һәм тирән итеп сулыш алды. Кайтты бит ул, ни булса да, барыбер әйләнеп кайтты!

Авыл, бер караганда, шул ук булып күренсә дә, игътибар белән җентекләп күзәтә башласаң, бөтенләй үзгә шикелле. Кайчандыр шаулап торган урам юлларында хәзер җил генә тузан туздырып йөри, гаскәр төсле тезелеп киткән

йортлар күзләрне камаштыра, капка төбендә бәбкәләренә якын китермәс өчен ыслап торган ата казы да, аны саклап утыручы әбиләр дә юк. Төзек тә, ләкин шул ук вакытта күңел кайтаргыч җимерек тә кебек. Насыйр карт бу күренешкә гаять гаҗәпләнеп, шаккатып карап торды. Аңына килгәч тә, кул сәгатенә күз салып, тиз-тиз авылның түбән очына, зират урнашкан якка юнәлде. Аның йөрәге яңа гына яши башлаган сыман тибәргә тотынды. Карт үзендә җан барлыгына ышанмый да башлаган иде инде, ә хәзер, кара, ничек үзен белдереп, шашынып суга. Менә каршыда капкасы җимерелеп беткән зират. Кызык, бөтен авыл төзек, биниһая зур йортлар белән әйләндереп алынган, ә шушы кечкенә генә зират капкасын рәтләп куючы юк.

Яңа гына барлыкка килгән кабер янында кешеләр басып тора. Аларның ни өчен җыелганын да, җир куенына тапшырылган кешенең кем икәнен дә Насыйр белә, ләкин җаны-тәне белән ризалашырга теләмичә тарткалаша иде. Инде менә җилкәдәге йөкне бераз гына булса да җиңеләйтәм, җаныма тынычлык табам дип уйлаганда, янә соңга калды. Дөньядагы иң газиз кешесенең күзләренә тутырып бер карый һәм соңгы кат аның әйткән сүзләрен ишетми калды. Кабаттан. Ах, моннан да үкенечле нәрсә юктыр. Картның аяклары хәлсезләнеп, тезләре җиргә тиде. Ул куллары белән кара туфракны актара, чокый башлады. Ләкин аның астында яткан гәүдә күпкә тирәнрәк яшерелгән иде шул. Хәле беткәч, кабергә башын куеп, сабый бала шикелле үкси-үкси еларга тотынды. Соңладым, инде менә күрәм дип уйлагач, хатамны төзәтерлек җай чыккач та соңга калдым, дип өзгәләнде ул… Кичер, кичер мине, газиз әнкәем. Синең тугры юлдан язган углың кабереӊ янына яңа гына, ничә еллар үткәч кенә кайтып төште. Хәзер каршыңда баш иеп, тез чүккән килеш гафу сорый, үзе китергән кайгы-хәсрәтләрен, ачы күз яшьләреңне әз генә булса да юмакчы була. Алар юа алмаслык булсалар да, рәнҗемәвеңне, кичерүеңне үтенә, дип, эченнән өзгәләнгән картның күз яшьләре кабер туфрагы өстенә сеңеп, юкка чыгып бара иде. Елый иде, ничә еллар яшереп яткан бу сагышын, мәхәббәтен, юанычын әнкәсе каберенә түгә иде ул.

Нindидер таныш түгел картның кыланмышларыннан авыл кешеләренең исе-акылы китте. Алар аның кем икәнен, нишләп йөргәнен дә белмиләр иде, билгеле. «Акылдан шашкан» дип чигә янында бармак боручы да, «ире кайткан», дип фараз кылучылар да булмады түгел. Насыйр халыкка карамады, эндәшмәде дә. Тамаша кабатланмагач, һәркайсы әкренләп таралыша башлады. Бик тиздән кабер янында картны җентекләп күзәтеп торучы ир-аттан башка берәү дә калмады.

– Аның улы шәһәргә чыгып китте дә әле һаман әйләнеп кайтмады, – диде ул, картны сискәнергә мәҗбүр итеп.

– Ыхы, – дип куйды карт, ул инде бераз тынычланган иде. Ир-ат сүзен дәвам итте:

– Ә бит без анасының вафат икәнен язып җибәрдек, ул гына нишләптер... югалды...

Насыйр карт, ниһаять, баядан бирле үзе белән сөйләшергә тырышучы кешегә күтәрелеп карады. Җыерчыклар барлыкка килсә дә, анда яшь чактагы җилкенчәк егетне танырга була. Тик кара күзләрдә генә сагыш сөреме, җитдилек арткан. Ә болай караганда, нәкъ үзе. Насыйр дустын кабаттан күрүенә шатланды: аны кысып кочаклыйсы, хәлен беләсе, авыл турында сораштырасы, яңалыклар уртаклашасы килде. Тик теге каһәр суккан кагыйдәләр генә искә төшеп, аны бу уеннан кире чигенергә мәҗбүр иттеләр.

Ә кайчандыр бергәләшеп урам буйлап яланаяк йөгереп йөргән ике шук, шаян малай беркайчан аерылмаска сүз куешкан иде. Ул вакытта язмышның нәрсә әзерләп куйганын белми иде шул алар. Кырык яшькә җитеп килүче бу ир-ат яшьлек дустының әйләнеп кайтуы турында уйлап та карамый иде. Һәм нәрсә әйтсен инде ул аңа? «Мин синең якын дустың – Насыйр. Мин киләчәктән кайттым, шуңа синдә караганда өлкәнрәк», дисенме? Аннары, чынлап та, җүләр, дип ябып куярлар. Хәер, озын-озак еллар буе җүләрләр йортыннан ким булмаган җирдә яшәде түгелмени соң инде ул? Иябләшергә авыр булмас.

– Минем исемем Айдар була, – диде ир кеше, барлыкка килгән тынлыкны бозарга тырышып һәм картның сөякчел, кан тамырлары күренеп торган кулларын кысты. – Сез миннән курыкмагыз, начарлык эшләп йөри торганнардан түгелмен, – дип дәвам итте Айдар, аннары кабергә карап торган килеш: – Эх. Сез бу апаның улы урынында булсагыз нишләр идегез? Кайтыр идегезме? – диде.

Насыйр өстенә әйтерсең лә бер чиләк кайнар су койдылар, маңгаеннан тамчы-тамчы тир бөртекләре ага башлады. Кайтмады… Кайтмады шул... Әнисен җирләгәндә, ул башка телдә сөйләшеп, үз туган телен юкка чыгарам, дип йөрде. Әйе, ул көнне Насыйр яхшы хәтерли. Нәкъ телеграмма килгән минутта аларны ашыгыч рәвештә караңгы бүлмәгә җыйдылар да документның юкка чыгуын хәбәр иттеләр. Насыйр ул вакытта, анасының вафаты турында да уйламыйча, көн-төн кәгазь эше белән чапты. Үз анасының, үз ана телен юкка чыгарам, дип... Ах, нинди түбәнлек!

– Сез минем белән сөйләшәсезме? – диде Айдар.

Насыйр карт сагаеп калды. Аннары, сүз әйтмичә генә, башын як-якка борып «юк» дигәнне аңлатты.

– Ә-ә, сез сөйләшә алмыйсыз, – дип аңлап алды Айдар. – Ә төн кунар урыныгыз бармы соң?

Карт янә баш чайкады.

– Әйдәгез алайса, минем йортка. Кунак булырсыз... – дип, серле елмайды ул.

Насыйр карт сәгатенә карап алды. Әле тагын шактый вакыт бар дип күрсәтә. Җитешергә тиеш. Аптыраган кыяфәттә, аякларын өстерәп, Айдар артыннан иярде. Җил, аның адымнарын тапмасыннар, күрмәсеннәр, дигән төсле һәрберсен арттан җуя барды. Дулкынлана иде ул. Кешеләр каршында түгел, ә нәкъ менә авылы, туган нигезе алдында үзен шулкадәр түбән, бурычлы хис итә иде. Моңа сәбәпче дә, гаепле дә – ул үзе. Ә авылның түбән очында кояш «бүгенгә соңгы тапкыр» дип күкне кочаклап алды да үзенең бишегенә кереп ятты. Шуны гына көткән ай күкнең иң биек ноктасына үрмәләргә тотынды. Бик тиздән караңгылык басып алыр да, җан ияләренең бердәнбер яклаучысы булып ай калыр. Ул адашканнарга туры юл күрсәтер, начар юлга басканнарның күзләрен ачар.

Айдар бер караваты гына булган кечкенә бүлмәгә төртеп күрсәтте:

– Бүген монда гына йоклarsыз.

Насыйр карт бу шыксыз ят бүлмәдә ялгызы калды. Тулган ай гына, аның борчуларын бүлешкән төсле, тәрәзәдән елмаеп карап тора иде шикелле. Их, син, адашкан җан, дип әйтә кебек ул. Насыйр айга төбәлде. Аны беренче тапкыр шуның кадәр якыннан күрүе иде бугай, әллә моңарчы айга каралмый яшәгән... Йә ул бөтенләй булмаганмы, кем белсен. Тегендә аңа барысы да бер иде. Көн туса эшли, төнлә йоклый. Ә хәзер бер тамчы йокы килми. Шулай булмыйча, ни гомердән соң әйләнеп кайтты бит. Инде теге дөньяда гына күрермен дип

уйлаган авылын, аның кешеләрен күрде. Тик барыбер кылган гөнаһын юа алмый калды. Анасы аның киләчәктән үк әйләнеп кайтуын көтеп тора алмыйча китеп барган. Ишек ярыгы аша икенче бүлмәдә янган ут яктысы керә. Анда кунакны уятмас өчен пышылдап кына сөйләшергә тырышкан өй хуҗалары, үзләрен тыныч тота алмыйча, ара-тирә кычкырып та куялар иде.

– Ташла, зинһар, шул шөгыленңне, бала хакы өчен булса да үтенеп сорыйм. Ике тапкыр төрмә михнәтен күрү генә җитмәгән аңа, тагын әллә кемне өстерәп кайткан.

– Кызма инде. Беренчедән, бу карт миңа никтер якын тоела. Икенчедән, мин боларның барысын да туачак баламның телле булып үсүен теләгәнгә эшлим.

– Эшлисең, пычагым. Җитте дим мин сиңа. Теле бар инде аның. Ата-анасы нинди телдә сөйләшкән – шул булыр.

– Юк, аның үз туган теле бар. Синеке икенче тел, дип, балама туган телне бирмәскә, син мине кем дип белдең.

– Ярый, кара аны. Берәр нинди куркыныч янаса, барам да донос ясыйм, – дип әйтеп ташлады хатын. Аннары үзе дә нәрсә әйткәнен аңлап, тизрәк аны йомшартырга тырышты. – Айдар, кадерлем, минем турыда да уйла әле әзрәк.

– Донос ясыйм дисең инде алайса, – диде ир кырыс кына.

– Юк инде, шаярттым гына, сине куркытыр өчен генә әйттем, – дип акланды хатын.

– Нинди бәхетсез ир-ат мин, хатыны да сатарга әзер булган... Йа Аллам, үзең ярлыка.

– Нәрсә сөйлисең син, тузга язмаган сүзләрне!..

– Булды, әйдә ятыйк, – диде ир, бу сөйләшүне бүтән дәвам итәсе килмичә.

Тиздән ут сүнеп, йорт та йокыга талды. Бары тик ике кулын баш астына куеп, айны күзәтеп ятучы Насыйр гына йоклый алмый интегә. Туган авылында иде ул, хыялланырга да курыккан үз нигезенә карап кына, кермичә китеп барган иде. Ә хәзер шуннан берничә адым ераклыкта яту аңа тынычлык бирмәде. Карт, караваттан торып, ишекне шыгырдатмыйча гына ачып, урамга юнәлде.

Инде төн. Бары тик бер-ике җирдә эт өргән тавышлар гына ишетелә. Ә һавасы, саф җиле күкрәкне шундый назлы иркәли. Насыйр, ай яктысында үзләренең нигезен танып алып, капканы әкрен генә этеп, ишегалдына үтте. Төнге тынлыкны бозып, йөрәге кагарга тотынды. Дөп-дөп, дөп-дөп... Насыйр йортның баскыч төбенә килеп утырды. Ай баягыча балкый бирә. Менә син үз нигезеңә әйләнеп кайттың, дип елмая сыман. Ә карт, күзләрен йомган килеш, әнисен, үзенең балачагын, киткән вакытын искә төшерә. Шундый гүзәл почмакны үзенең таш бүлмәсенә алыштыруына үкенеп туя алмый.

Соры тынчу бүлмә урынына монда синең карамакта иксез-чиксез болын, урманнар. Аһ, син юләр баш, дип тиргәде карт үзен. 35 ел бил бөккәннән соң да синең кем икәнеңне белми торган адәмнәр белән яшә инде. Үземнең матур татлы телемне шул салкын телгә алмаштыр. Төнге күк сакчылары булган ай һәм йолдызлар аңа нәкъ балачакта ишеткән бишек җырын көйләде:

Әлли-бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу;
Тырышып сабак укыгач,
Галим булып җитәр бу.

Бөек Габдулла Тукай үз халкы өчен нинди генә җырлар чыгармаган. Үз туган телен, милләтен саклап калу өчен, ни генә күрмәгән дә, ни генә ишетмәгән. Ул,

әкияттәге батыр кебек, һәрвакыт яхшылык яклы: кечкенәләрне рәнҗетмәскә, олыларны хөрмәт итәргә, яман гамәлләргә юл куймаска чакыра, шулар өчен көрәшә. Насыйрның да бит шундый бер әкият герое кебек буласы килә иде. Ул кыю, батыр, көчле, имеш. Әнисе аңа төннәрен «Таңбатыр», «Камыр батыр» әкиятләрен сөйләп арып бетә иде. Ә хәзер кем ул? Нәкъ шуларның киресенә әйләнде түгелме соң? Кечкенә Насыйрның хыялларына да хыянәт итте.

Йолдызларга исә картның бу уйлары билгесез. Туган нигезнең күге, җире аңа бу төндә чын мәгънәсендә әнисе кыяфәтендә килеп басты. Алар Насыйрга әкрен генә бишек җыры көйли. Юк, картны түгел, ә үз әнкәсен югалткан, читкә киткән, адашкан бер сабыйны тирбәтә алар. Сабый җаны тынычлансын, юансын өчен, әнкәсен искә төшерәләр.

*9 сәгать*

Иртәгесе көнне Насыйр карт уяну белән, үзенең кайда икәнлеген, нишләгәнен аңламыйча, бермәл айный алмый торды. Авыл һавасына исереп, баскыч төбендә йоклап киткәнен сизми дә калган. Кояшның әле күренеп кенә килүе. Нинди хозурлык! Яңа гына чәчәк атарга җыенган иркә алсу гөл төсле ялындырып кына, үз җаен белеп кенә чыга. Нурлары ишегалдында бөреләнеп ятучы алмагачка тиеп үтә, агач өйнең бүрәнәләрен сыпырып ялтыратып куя, кетәклектәге ярдәмчесен – әтәчне уята. Кик-ри-күүк! Насыйрның тормышында да яңа таң атты. Ул иркен итеп киерелде. Хәзер төнлә күренми калган алмагач та, борын төрткән яшел бәбкә үлән дә күренә. Насыйр карт, өйгә үтәргә теләп, ишекнең тоткасын тартты, ләкин ача алмады. Соңыннан ныклап карагач кына, анда кечкенә йозак бар икәнен күрде. Үз йортына ишек бикле! Нинди яңа тормыш булсын бу, артыңнан үткәннәрең ияреп барып, яшәргә ирек бирмәгәч. «Менә бит алдыңда хуҗаң басып тора, ә син аңа ишегеңне дә ачмыйсың, әдәпсез», дип эндәште ул йортка. Тик җавап кына бирүче булмады.

Насыйр карт Айдарларга кайтып кергәндә, ул яңа торып кына килә иде әле.

– Хәерле иртә! Бигрәк иртә торгансыз. Әйдәгез, чәй эчеп алыйк та, мин сезне бер җиргә алып барам, – диде ул, елмаеп.

Насыйр карт баш какты. Иртән әле томан да таралып бетмәгән вакытта урамда кеше галәмәте бар икәне күренә. Барысы да Айдар белән күрешеп, берике сүз алышалар да, шул аклык эченә кереп югалалар. Юри шулай үзләренең барлыгын белдермәс өчен, томан чыгарган кебек. Аннары Айдар үзе дә артык сүз сөйләми, җитдиләнеп, нәрсә турындадыр уйланып атлый. Насыйр карт, еш-еш сулап, аның эре-эре адымнарына көчкә өлгереп бара.

– Килеп җиттек, – дип, ташландык йортка күрсәтте ул. Аннары койманы сикереп чыгып, капканы эчке яктан ачты да «әйдә, абзый», дип эчкә дәште.

Бу нинди җир булыр икән? Алай-болай кеше йортына рөхсәтсез кермибездер бит, дип шикләнде карт. Аның сүзләрен ишеткән төсле, Айдар да:

– Сез мине әллә кая алып керә дип уйламагыз инде? – диде, ишекне кабат эчтән бикләп куеп. – Без чит йортка кермибез, ә менә башкаларның килеп керүе бик мөмкин, – дип, өй ишеген шакыды. Бер... ике... өч... Нindидер яшерен кодка охшаш бу авазлар эчтә булган кешене уятып җибәрде. «Кем бар анда?» дигән тавыш ишетелде.

– Айдар мин, кунак алып килдем, – диде ир, Насыйрга күз кысып. Ишек ачылып китте. Анда ак күлмәк өстеннән яшел камзул кигән, башына ак яулык бәйләгән бер әби басып тора иде.

– И-ии, бигрәк яхшы булган. Күрше кызы кереп чыккан иде әле, коймаклар китергән. Әйдәгез, үтегез, үт, чәй куйдым, – диде әби.

– Бу безнең барыбызның да дәү анасы – Фәһимә апа була, – диде Айдар Насыйрга. – Ул сөйләшми, аптырамассыз, – дип, ак яулыклы әбигә карады. – Сез чәй эчә торыгыз, ә мин хәзер тагын киләсе кешеләрне каршы ала торам, – дип чыгып китте.

Башта өй эче бик караңгы булып күренсә дә, күз ияләште булса кирәк, җиһазлар да күренә башлады. Артык купшы түгел, гап-гади йорт. Стенада эленеп торган һәм Насыйрга күпме вакыт калганын күрсәтүче күкеле сәгать, өстәл-урындыклар, караватта – кабартып өеп куелган ап-ак чигүле мендәрләр. Насыйрның игътибарын шулар җәлеп итте. Кайчандыр аның да әнисе чигеп биргән шундый мендәре бар иде. Һәр кич ул шул мендәргә ятып китаплар актара иде. Серле, самими, маҗара тулы кичләр...

– Чәй әзерләдем, әйдәгез, утырыгыз, – диде ак яулыклы әби.

Насыйр, чәй эчәсе килмәсә дә, өстәл янына барып утырды.

– Әгүзе билләһи… – дип, әби дога укый башлады. Насыйрның йөзендә курку, аптырау, куану – барысы бергә җыелды. Ул ак яулыклы әбидән күзен ала алмады. Әйтерсең лә аның каршысында үз анасы ак яулыктан дога кылып утыра. Кечкенә чакта Насыйрга да өйрәткән иде бит, ләкин хәзер генә сүзләре хәтердән чыккан.

– Динен җуйган кешегә бу дөньяда яшәп яту да гөнаһтыр ул, анакай? – диде ул, түзеп тора алмыйча. Әби кеше аның кинәт сөйләшеп китүенә аптырады, ләкин тиз генә һушына килеп:

– Юк, улым, бу җирдә яшәвебез белән без бары тик рәхмәтле генә була алабыз. Үз динен җуйганның да Ходай каршында кичерелергә хакы бар. Кылган гамәлләреңдә тап булса да, җаныңның пакь булуы мөмкин, – диде.

Насыйр карт ничә елга беренче тапкыр туган телендә әйтелгән сүзләрне ишетте. Аңламады, ләкин тойды. Менә аның колакларын иркәләгән, күңеленә хуш булган иң изге, газиз, якын тел. Тапты! Күпме еллардан соң үз туган телен тапты! Шушы түгелмени җан рәхәтлеге? Шул түгелме бәхет? Насыйр картның бу кечкенә генә әбине кысып-кысып кочаклыйсы, кулларын үбәсе, аңа меңләгән рәхмәт яудырасы килде. Туган телне саклап калган, башкаларга ана булган бу ак яулыклы әби, һичшиксез, Ходай каршындагы гөнаһсыз бер фәрештә төсле тоелды.

– Сез... Сез онытмагансыз, – диде карт. – Телебезне саклагансыз.

– Онытмадым, мин генә түгел, күбебез онытмады әле, – дип җөпләде әби. Шулчак, берничә кешене ияртеп, Айдар килеп керде.

– Менә без дә, таныш бул. Бу безнең бөек язучы егетебез – Каюм, монысы укымышлы Минтимер, ә бу гүзәл затыбыз мәктәптә балалар укыта торган Асия ханым.

– Исәнмесез. Айдар безгә сезнең турында бик күп сөйләде, – дип, кул биреп күреште Минтимер.

– Исән, улым, – дип кулын кысты Насыйр карт. Аннары шулай ук Асия һәм Каюм белән дә күреште.

– Сез... сөйләшә аласызмыни? – дип аптырады Айдар.

– Әйе, билгеле бер сәбәпләр аркасында сөйли алмадым, гафу. Ә хәзер барысы да үзгәрде. Таныш булыйк, исемем – Насыйр, – диде карт.

– Сез миңа бик тә бер кешене хәтерләтәсез. Аның исеме дә Насыйр иде, – диде Асия.

«Эх, Асия... Мин бит бу, танымадыңмыни?

Бар җиһанны бүләк итәм,
Йолдызларны җиргә сибәм.
Асиякәй, Асия, сине җаны-тәне белән
Тиле бер гашыйк сөя,

– дип язган хатларымны оныттыңмыни? Ә безнең, төнге күккә карап, хуш исле печән өсләрендә ятканыбыз, минем зур бәйләм ромашкалар җыеп бирүем, мәхәббәт аңлашулар, вәгъдәләр...» Аһ, бөтенесе дә Насыйр күз алдына әле яңа гына булган шикелле килеп басты. Йөрәк шашынып һәм тилереп типте. «Үз гомеремдә беренче һәм соңгы мәхәббәтен дә саклап кала алмады бит ул. Ни кызганыч, бәхетле булырга язмагандыр шул минем кебек бәндәгә», дип уйлады.

– Сез кем буласыз, кайдан килдегез, нишләп йөрисез? – дип сорау яудырды Минтимер.

– Мин бу авылда туып үстем, яшәдем дә, аннары ташлап чыгып киттем. Менә шулай...

– Ничек инде? Ник ташлап чыгып киттем дип әйтәсез? – дип сорады Каюм.

– Ә нәрсә дим инде, дөресе шул булгач. Якты киләчәк турында сөйләнгән купшы сүзләргә ышанып, туган нигездән, әти-әнидән, дус-ишләрдән ваз кичеп, читкә китеп бардым. Ә анда минем телне «яраксыз, мәгънәсез, түбән», дип җәберләделәр, мин дәшмәдем, каршыма бөтенләй башка телне китереп куеп, йә шуны өйрәнәсең, йә бу җирдә башка көн күрмәячәксең, диделәр, мин телемне сындыра-сындыра, тешне кысып, шул телне өйрәндем, түздем. Аны өйрәнгән саен, үземнең туган тел онытыла барды. Газиз әнкәемне җир куенына озаткан вакытта да мин шул салкын телдә аралаштым. Менә шундый инде мин – үз телен, милләтен, нигезен саткан бер түбән җан, – дип сөйләде Насыйр карт.

– Алай димәгез инде, Насыйр абый, – дип, Асия утырган җиреннән торып басты, картны кочаклап алды. – Без хәзер бөтенебез дә шул халәттә.

– Ә шулай да ник менә хәзер кире авылга әйләнеп кайтырга уйладыгыз? – дип сорады Каюм.

– Менә нәрсә тартты мине, – дип, карт куеныннан кечкенә генә итеп бөкләнгән кәгазь бите тартып чыгарды.

– Бу нәрсә? – диде Минтимер.

– Бу – әнкәемнең миңа дип язган соңгы хаты. Аннан соң инде дистә еллар узган.

– Нәрсә язылган соң анда? – дип сорады бер читтә тыңлап кына утыручы Айдар.

– Сезнең алда әйтүе дә оят: мин аны укый алмыйм, дөресрәге танымыйм һәм аңламыйм да, – диде Насыйр карт.

– Сез аны Минтимергә укытыгыз. Ул безнең язуны әйбәт таный, – диде Асия.

Насыйр карт өметле күзләрен Минтимергә төбәде. Ул картка ничә еллар яшереп сакланган серен чишеп бирә алучы көчкә ия булган батыр сыман күренде.

– Әйдәгез, укып карыйк, – дип кулын сузды Минтимер.

Насыйр карт калтыраган куллары белән аңа бу дөньядагы иң кадерле нәрсәсен – кәгазь битен тоттырды. Минтимер, күз йөртеп чыкканнан соң, Асиягә эндәшеп:

– Бар әле, чоланнан китапларны алып кер, – диде. Ханым, җитез генә чыгып китеп, искерәк дүрт-биш китап күтәреп керде.

– Менә бу безнең байлыгыбыз инде, – дип елмайды Айдар, картның аптыраулы карашын тоеп.

– Боларны бит яндырып бетерделәр, – диде карт, иске тышлык өстендә сак кына бармакларын уйнатып.

– Күреп торасыз, кайберләрен саклап кала алдык, – дип сөенде Каюм.

– Ул ерткыч җаннар безнең китапларны да, телне дә, милләтне дә тартып алды, – диде Асия. – Һәм минем сөйгән ярымны да... – дип өстәде. Насыйр карт, сүзне башкага күчерергә теләп:

– Ничек, улым, таныйсыңмы? – дип сорау бирде. Ул ничек тә Асиянең күзләренә туры караудан качарга тырыша иде.

– Менә китаплар белән күпкә җиңелрәк һәм дөресрәк тә. Укыйммы, абый?

– Тукта, тукта, хәзер көтеп тор, – диде карт. – Фәһимә апа, зинһар, минем өчен дога кылыгыз әле, – дип, бер читтә утырып торган ак яулыклы әбигә дәште. Әби, кулларын йөз каршына китереп, дога укый башлады, барысы да аның артыннан кабатлады. «Улың тәүбәгә килде», дип, Насыйр күңеленнән әнисе белән сөйләште. Ул аны хәзер ишетәдер, өстән карап торадыр сыман тоелды. «Кичер, рәнҗемә, зинһар, миңа, анам!» дип үтенде, ялварды ул. АннарыМинтимер авызыннан чыккан һәр сүзне ишетеп калыр өчен, каршына ук утырып:

– Дәвам ит, мин әзер, – диде.

– Үз телебездә укыйммы, Насыйр абый? – дип сорады Минтимер.

– Туган телдә укы, улым. Әнкәм сүзләренә салкын тел белән тап төшерәсем килми. Үзем аңламасам да, минем күңелем, рухым аңлар. Укы, балам, укы, мин бу көнне гомерем буена көттем, укы.

*«...Әссәламегаләйкүм, минем газиз вә сөекле улым! Менә сиңа хат язарга булдым. Туган оядан кош шикелле очып чыгып киткән улымның кайчан да булса капка шакуына ышанам һәм шул мизгелне бөтен күңелем илә түземсезлек белән көтәмен. Улым, сиңа гомер юлыңда бирешмәслек таяныч, терәк була алмавым өчен гафу үтенәм. Мин үземне сиңа багышладым. Күкрәк сөтемне, җанымны, язмышыма кадәр сиңа фида кылдым. Сиңа якты тормыш, балачак, тел бүләк иттем. Кем уйлаган син аннан да баш тартырсың, кирәк тапмассың дип. Хәер, бу гөнаһлар барысы да минем өлештә калыр. Ана кеше була торып, газиз баламны туган телне хөрмәт итәргә өйрәтә алмадым. Мин көн саен, сиңа тугры юл күрсәтүен үтенеп, Ходайга ялварам. Кыйбласын югалткан адәм бу җирдә үз урынын да, бәхетен дә таба алмый ул, улым. Сиңа Ходайның игелеге, рәхим-шәфкате насыйп булсын. Һичкайчан сиңа рәнҗемәс вә кире какмас газиз әнкәең...»*

Бу хаттан соң никтер сүз әйтерлек кыюлар табылмады. Гүя, анда язылган сүзләр Насыйр картка түгел, ә монда утырган һәрбер кешегә кагыладыр төсле. Картның күңеле тулды, күз яшен яшерергә тырышты, тамагында барлыкка килгән төерне йотып, ярым ишетелерлек тавыш белән генә:

– Рәхмәт. Мин, балалар, урап керим әле. Сез утырыгыз, – диде дә чыгып китте.

– Миңа шундый аяныч, – диде Асия, ул чыгып киткәннән соң күз яшьләрен сөртеп.

– Алла каршында барыбыз да гөнаһлыбыз, – дип җөпләде Каюм.

Насыйр картның башы әйләнде, ә аяклары үзеннән-үзе әнкәсе кабере янына атлады. Юл буе башындагы уйлар өермәсен тынычландырырга тырышып

барды карт. Меңләгән, миллионлаган хис-кичереш барысы да шушы минутта аның өстенә ябырылды. Кичерде, аны әнкәсе кичерде, ул аңа рәнҗеми! Хаттан шуны гына аңлады Насыйр, ләкин барысы да алда әле. Хәзер ул туган авылына, нигезенә, диненә һәм теленә кире әйләнеп кайтты. Ул бу хатны яттан белер дәрәҗәдә йөз кат укыр, аңлар. Ничек үз телен югалтса, аны шулай кире кайтарыр да. Әйе, һичшиксез, шулай булыр, Алла боерса. Насыйр карт сөенеченнән үзен шундый җиңел хис итте. Әйтерсең лә ул атламый, ә юл буйлап очып кына бара. Үлем якынлашканда, кеше җиңеләеп китә, диләр бит... Әнә, каршыда зират капкасы, кабер, кабер ташы... Карт шул ташны кайчандыр әнкәсен кочаклаган шикелле итеп кочып алды. Ул аңа җылы һәм йомшак булып тоелды. Ирексездән, Габдулла Тукайның:

> Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабрең ташы, –
> Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы!

– дигән сүзләре исенә төште. Ул үз куенында әнкәсенең бәхилләвен саклаган, кичерелгәнен белмичә, җилкәсенә йөк җыеп яшәгән. «Рәхмәт сиңа, изге фәрештәм!» дип пышылдады, ләкин бу сүзләр аның күңелендә бик көчле һәм аермачык булып яңгырады.

*5 сәгать*

*«Кайчандыр ерак үткәндә мәхәббәтемне кире какмаган өчен, сиңа рәхмәт укыйм. Тормышымда сине очратмаган булсам, сөюнең нәрсә икәнен дә белми китеп барган булыр идем. Ә менә хәзер, шул сәгать якынлашкан саен, бу мизгелләрнең никадәр матур, кадерле икәнен аңлыйм. Асия сөйгәнем, мин синең каршыңда чиксез гаеплемен. Үз хисләреннән баш тарткан төсле кыланган булып гомер буе яраткан тиле гашыйк – ул мин булам инде. Шундый инде мин... Кабул итәсеңме-юкмы, ансы синең эш. Ләкин, ни кызганыч, мин синең җавабыңны ишетә алмам. Хатымда сиңа булган барлык мәхәббәтемне ничек кенә сыйдырып бетерергә тырышсам да, булдыра алмыйм. Ул аннан ташып агачак. Бары шушы гади сүзләр белән чикләнергә булдым, ләкин беләм, син мине аларсыз да аңларсың. Мин сине яратам, Асия! Яраттым, яратам һәм яратачакмын, ишетәсеңме. Алла теләсә, оҗмах капкасы төбендә очрашырга насыйп булсын. Мин сине шунда көтәрмен. Хатымны сәер итеп кабул итә аласың, бу чыннан да шулай. Җавап көтмичә, сине күктәге йолдызлар күпме булса, шулкадәр үбеп, Мәҗнүн-Насыйрың».*

Насыйр хатны икесе генә белә торган каенга бәйләп калдырды да үзе, ашыгып, кабаттан шул тәбәнәк кенә иске йортка юнәлде. Ул килеп кергәндә, өйдә формалы кешеләр тентү ясап яталар иде. Бөтен шкафлар ачылып, андагы әйберләр идәнгә ыргытылган, берсенең кулында китаплар.

– Нәрсә булды монда? – дип сорады Насыйр, бу хәлгә гаҗәпләнеп.

– Ник аптыраган кыяфәт чыгарып торасың, син саткансың безне, үзең үк «ваз кичтем», дип сөйләп тордың бит, – диде ачуыннан ярсып беткән Каюм. Аның күзе-башы тонган, чәчләре үрә баскан иде.

– Тик тор, Каюм! Яла якма белми торып! – диде Айдар.

– Карагыз сез аңа, ничек тыныч басып тора. Бик күп сер яшерә ул бездән, ә без тиленләр шикелле аңа барысын да ачып салдык. Афәрин, искиткеч эш! – дип, мыскыллы кул чапты туктарга җыенмаган Каюм.

Аларны берәм-берәм тимер рәшәткәле машиналарга утырта башладылар.

Насыйр монда нәрсә булганын тәгаен генә аңлап җиткерә алмады. Машина кузгалып китеп барды. Насыйр карт аның рәшәткәле тәрәзәсеннән соңгы кат авылына карарга гына өлгерде. «Сау бул инде, авылым! Синдә торырга насыйп булмаган күрәсең, менә тагын китеп барам. Ләкин башка кеше булып», дип сөйләнде ул.

Шактый озак бардылар. Насыйр хәтта төш күреп алырга җитеште бугай. Айныганда, чәнечкеләр белән уратып алынган җиргә кереп баралар иде инде. «Төрмәгә илтәләр» дип уйлады ул. Машиналардан чыгып, як-якка карарга тотынды. Асия кайда? Аны нишләтәләр? Бераздан килеп туктаган машинадан Асия дә чыкты. Аларның барысын да, алдан-арттан сакчылар куеп, камерага озаттылар. Каюм инде тынычланган, Минтимер, кашларын җыерып, нидер уйлый, Айдар исә, киресенчә, хафалана иде. Асияне, аерып, башка җиргә алып киттеләр. Насыйр аның үреп салган толымнарына гына карап калырга җитеште.

Төрмә бүлмәсендә җан өшеткеч салкынлык. Сакчылар китеп барса да, берсе-бер сүз дәшми. Бу бушлыкны тойган саен, Насыйрның күңеле пошына. Каюмның сүзләре тынычлык бирми аңа. Аларда хаклык бар бит. «Сатлык» дип туры бәреп әйткән кеше юк иде әле аңа. Йөрәкне пычак шикелле җәрәхәтли иде бу сүзләр, аларның нахак икәнен исбатлыйсы, дәлиллисе килә иде Насыйрның.

Ниндидер хатын-кыз тавышын ишетеп, «Асия түгелме?» дип карарга тырышса да, беркемне күрмәде Насыйр. Берничә минуттан соң гына алар каршында бер абзый белән Айдарның хатыны пәйда булды.

– Сез бит миңа, аларның кайда җыелуын әйтсәң, иреңне эзәрлекләмәм, дигән идегез... – дип ялынды хатын.

– Синмени ул безне сатучы? – диде Айдар. Аның тавышында ерткычларның куркыныч «ырлавы» ишетелде.

– Айдар, мин сиңа барысын да аңлатырмын, – диде хатын, аны тынычландырырга тырышып. Аннары бер читтә утыручы картны күреп: – Менә бөтенесенә ул гына гаепле, шул котыртып йөри. Аны тотыгыз, – дип кычкырды.

– Бу дөресме? – дип сорады абзый.

Насыйр бер мәлгә ни әйтергә белми торды.

– Дөрес, мин гаепле, – диде ул. – Ә аларны җибәрегез.

– Ха! Шулай җиңел генә җибәрәм ди! Абзый күзләрен ялтыратты.

– Җибәрәсең, – диде Насыйр, катгый гына. Барысы да аңа борылып карадылар. Ул сумкасыннан ышанычлык кенәгәсен тартып чыгарды. Мыскыллы елмаеп торган абзыйның кулыннан тәмәкесе төшеп китте. Ул сакчыларга шундук ишекне ачарга боерды.

– Гафу үтенәм, ниндидер аңлашылмаучанлык килеп чыкты, – дип сөйли-сөйли баш ия башлады. Берсе дә мондый борылыш көтмәгән иде.

– Ха-ха-ха! Әйттем бит мин сезгә шпион ул диеп, – дип мыскыллы көлде Каюм. Айдар аптырап Насыйрга карады:

– Бу әйткәннәр барысы да дөресме?

– Мин барысын да аңлатырмын. Ә хәзергә безгә моннан тизрәк чыгарга кирәк, – дип җавап кайтарды карт.

Аларны, чыннан да, азат иттеләр. Кәеф күтәренкелеге дә кире кайтты. «Яшибез икән әле», дип куйды Минтимер. Насыйр белән Айдарның гына шатланганы сизелмәде. Алар якындагы парк эскәмиясенә барып утырдылар. Көн җилле булса да, кояшның җылысы күңелне кытыклый иде. Бик тиздән бөтен җир йөзе чәчәкләр белән капланыр, зарыгып көткән җәй җитәр.

– Мин сиңа бөтенесен дә сөйләп бетерә алмам, – дип сүз башлады Насыйр. – Әйе, мин телне бетерү оешмасында эшлим, эшләдем, дисәм, дөресрәк булыр. Ләкин...

– Син безне алдадың булып чыга, шулаймы? Ә хәзер чын дөресен күзгә карап әйт! Ни өчен кайттың?

– Җанымны табарга, – диде карт, күзләрен түбән төшереп. – Гомер буе тынычлык, бәхет таба алмый чит җирдә каңгырап йөрдем, ә бит аның өчен бары тик туган якның бер көне җиткән.

– Ник әниеңне җирләргә кайтмадың? – диде ул, усал итеп.

– Мин ялгыштым, хаталандым, аңлыйсыңмы... Һәм шуның өчен түләдем. Син мине кичер, зинһар, Айдар!

– Без бит әлеге көрәш юлында бергә булырга тиеш идек, ә син... – дип кулын селтәде ир-ат.

– Гаепләмә, – диде Насыйр.

– Кичерәм, әлбәттә. Син бит кайттың, безнең белән хәзер.

– Айдар, син бу юлдан читкә тайпылмаска тиешсең, син генә түгел, Каюм, Минтимер, Асия дә... хәтта алар гына да түгел, бөтен халык, милләт тә. Без яшәргә тиеш! – диде Насыйр.

– Яшибез, яшибез! – дип торып басты Айдар.

– Ә миңа китәргә кирәк. Бик мөһим эш көтә, бәлки, шушы гамәлем минем гөнаһларны азга гына булса да киметер, – дип, Насыйр кул сәгатенә карады.

– Мин сине тау битендә көтәм, – диде Айдар.

– Ярар, хәерле юлда, – дип, Насыйр сумкасын артына аскан килеш, асфальт юлдан җил-җил басып китеп югалды.

*1 сәгать*

Кояш яктысында җемелдәп торган биек бина аның эш урыны булырга тиеш. Хәтта шундый биналар да алдап торгач, кеше ничек алдамасын яисә алданмасын ди. Тыштан җемелди, ә эчендә бернәрсә дә юк. Матурлыкны күрә белер өчен, гади күз генә түгел, күңел күзе булырга тиеш. Насыйр карт, сакчылар аркылы үтеп китәр өчен, ышанычлык кенәгәсен чыгарды. Тә-әк, булды, ул инде эчтә. Хәзер бары тик сиздермичә генә иң өске катка менеп җитеп, шул бүлмәгә керергә кирәк.

Насыйр карт бер бүлмәгә кереп, сумкасыннан соры костюмын алды, кара эшләпәне күзләренә батырып диярлек киеп куйды. Лифт төшә... 12 нче кат... 9 нчы кат... 5 нче кат... 1 нче... Ишекләр ачылды. Насыйр һәм аннан кала тагын берничә кеше бу кечкенә генә җайланмага үттеләр. Тынчу, һава җитми. Ярый әле берәр кат үткән саен, бу «бөҗәкләр» коела бара. Насыйр 12 нче катка менеп җиткәндә, ниһаять, үзе генә калды. Монда кеше күп йөрмәгәнлеге салкын һавасыннан ук беленеп тора. Шакылдап торган пыяла идәннәр, гөмбәзгә охшатып ясалган шундый ук түбә, төрле документларның пыялага куелган фотосурәтләре. Менә ул керергә тиешле бүлмә... Кап-кара күзлекле кешеләр кесә актарып, сумкасындагы машинаны тикшереп тә бернинди шикләнерлек сәбәп тапмагач, ишекне ачтылар. Насыйр карт, аякларын шудырып атлап, эчкә үтте.

Бүлмә шундый биек итеп эшләнгән. Уртада пыяла эчендә торган документтан башка берни дә юк. Ул җирдә күптеллелекне бетерү турында искәртеп тора. Насыйрның газиз туган теленең, нигезенең, әнисенең юк икәнен исбатламакчы каһәр суккан кәгазь кисәге... Юк, ул моңа юл куймаска тиеш...

Насыйр эшләпәсеннән шырпы тартмасы чыгарды... Сәгать телләре тагын 5 минут вакыты барлыгын күрсәтә... Менә ул үзенең кылган гөнаһлары, яман гамәлләре белән күзгә-күз очрашачак та Ходай каршында шулар өчен җавап тотачак. Янгын, кәгазьләр белән генә разый булмыйча, яңа корбанга үрелде... Картның бу истән башы әйләнде, уйлары чуалды.

...Авыл киче җиткәндә, мунча яккач, шундый төтен исе тарала иде бит. Шәһәрдә андый ис юк, ул авылга гына хас, үзенә генә. Шундый якын, хуш, рәхәтлек исе. Син шунда, мунча кызурак булсын өчен, утын ыргытып торасың, ә ул шарт-шорт яна бирә. Мунча булып җиткәч, сөлгеңне аласың да шунда чабасың. Аның пары, кайнарлыгы синең көне буена җыелган кереңне юып төшерә. Ә хуш исле пиннек бөтен буыннарыңа көч өсти. Ах, шул чакларда ничек тыныч, рәхәт булып китә! Тагын йөз, мең ел яшисе килә башлый!

...Насыйр җаны авылына таба очты. Ул зәңгәр күк буйлап ак болытлар белән бергә йөзде, өйләрне күзәтте, зираттагы каберлекне карап үтте, ә аннары туган нигезенә тукталды. «Менә хәзер мин инде чынлап та кайттым», диде ул, аннары биеккә, күккә ашты. Анда аны әнисе зарыгып көтеп тора торгандыр. Монсында инде соңламас... Әлбәттә, соңламас.


* * *

*«...Кадерле, хөрмәтле хәзерге Насыйр! – дип башланып китә иде хат. Аңа бүген китерделәр аны, телеграмма белән бергә. Шунда ук җитәкчелек, «янгын булган» дигән хәбәр белән, җыелышка чакырды. Насыйр, соры костюмын кия-кия, адресы да булмаган бу сәер хатны укуын дәвам итте: – Син, ихтимал, бу хатка бик гаҗәпләнерсең яки башка берәүнең шаяртуы дип аңларсың, бик мөмкин. Ләкин аны ахырга кадәр укып бетерерсең дип ышанам.*

*Хәзер син, иртән соры костюмыңны киеп, эш урыныңа ашыга торгансыңдыр. Бер минут та буш вакытың юк сыман, алда сине яхшы, бәхетле киләчәк көтәдер сыман... Кызганыч, мин синең бу буш хыялларыңны чәлпәрәмә китерергә мәҗбүрмен. Ни өченме? Чөнки мин үзем киләчәктә булып караган кеше, һәм ышан, сине анда бернинди сөенеч тә көтми. Бүген сиңа телеграмма килергә тиеш. Әгәр күргән булсаң, тагын да яхшы, чөнки анда синең әнкәеңнең вафат булуы турында язылган. Минем киңәш: кайт! Бернинди кирәкмәгән җыелышларына карамыйча, буш мәшәкатьләреңә төкереп, туган авылыңа кайт! Без бу җирдә бер генә яшибез, ә вакыт ул шундый кызык: юри койрыгын гына күрсәткән булып кылана да башың килеп бәрелгәнче артыннан йөгертә. Син шуңа алданып чабасың да чабасың. Ә борылып карасаң, артыңда берни дә юк, көзгедә исә синең урынга җыерчыклы, саргайган йөзле бер карт карап тора. Шушы минут белән яшәргә кирәк. Бер көн эчендә тормышыңны астын-өскә китереп үзгәртеп була. Мин моңа инандым.*

*Әлбәттә, кайсы юлны сайлау – синең эш. Төшләреңә кереп йөдәтә торган Асия, туган йорт, авыл – болар барысы да чынга ашмый торган хыял түгел. Бу – чынбарлык. Кичерелергә һәркем хаклы, җаның гына туры юлда булсын.*

*Сиңа ышанып һәм бәхет теләп, киләчәктән Насыйр...»*



Әхәт
Гаффар

# КИЛӘЧӘКТӘН КАЙТЫП КИЛЕШЛИ

ХИКӘЯ

Керәшәләр зур бер көтүгә укмашып тузындылар-тузындылар да туган-үскән җирләреннән үзләрен ни көтәсе билгесез тарафларга очып киттеләр. Очынганнары, тузынганнары, канат ныгытулары көне буена күренеп торса да, гаип булуларын һичкем белешми, аңышмый калды: анысы иртән-иртүк – табигать, җиһан, тереклек уяныр-уянмас чагында ук булган иде, күрәсең. Булган да – узган-киткән. Тагын бер елсыз кабатланмас тамаша.

Керәшәләрнең инешнең ачык, биек, текә, нык, көнчыгышы һәм көньягы ярларындагы ипле оялары тәмам суынып өлгергәндер инде. Алар мәңгегә үги калды. Керәшәләр искегә оя кормый.

Резедә беравык кичәге шул манзараны исенә алып торды. Баягынак – иртәнчәк бит-кулларын юып, киенеп алгач, ул үзенең көзгедәге чагылышына күз атып алган иде. Шунда ул үзенең киң, ачык, дулкын-дулкын нечкә, әле болай артык сиздереп тормаган җыерчыклар сырлый башлаган маңгае, кыйгач, көрән кашлары астындагы кучкыл-кара күзләренең дә әлеге күләгәле, караңгы керәшә ояларын хәтерләтеп торганын искәреп алган иде. Ул моңа тәфсилләп дикъкать итеп тормады. Аның һәр елдагыча, шушы көндәгечә кабатлана килгән ифрат зур, һичнигә алыштыргысыз эше бар: ул мәктәпкә җыенды. Кичә мунчасын ягып, төштән соң бер өй аша торган сыер савучы Җәмилә белән иркенләп юынып чыкканнар иде, уртадан ерып тараган, шактый сыкы сарган чәче – ай-һайла! – ыспай гына күпереп тора. Тантаналы күмәк бәйрәм-сәйрәмнәрдә генә сирәк киелә торган ачык-көрән кәчтүм-күлмәге җайлы, зәвыклы, чиккән күн читеге бик таман; вак-төяк кирәк-яраклары салынган букчасы да ипле генә. Инде менә тәмен белеп кенә дөге боткасы ашап, йомшак солы печеньесе каба-каба, сөтле һындыба чәе эчкәч, өстәл яныннан торып, ул капка төбенә чыгып басты.

Көн матур иде. Һава әйбәт. Хәер, көннең матур, һаваның әйбәт икәнлеген

Әхәт ГАФФАР (1949) – *язучы; «Сызылып таңнар атканда», «Энә күзе», «Дәрья башы», дүрттомлык «Сайланма әсәрләр» һ.б. күпсанлы китаплар авторы. М.Горький исемендәге Бөтенсоюз әдәби конкурсы һәм Ф.Хөсни исемендәге әдәби премия лауреаты. Казанда яши.*

уйлап тормыйсың инде. Моны шулай булмаганда гына искә аласың, дөньяга карап торырга һични комачауламаса, һәммәсе дә әйбәт. Ай, һәммәсе дә түгел шул ул. Болай... барысы да бер килеш, көндәгечә, берни дә үзгәрмәгән, бөтенесе кабатланып торган шикелле. Ә юк. Таягына таянган Гыйматдин абзый урам буйлап тыйтак-тыйтак үтмәде. Ул, Резедәләр очындагы соңгы могикан булып, бу тормышның ачысын-төчесен, сугыш фаҗигаләрен, гомер итүләрнең авырлыгын – хәер, байтак сөенеч-куанычларын да ахыргы мыскалынача кичергәннең соңында – яз башында якты дөньядан китеп барды.

Ата каз белән ана казларын, инде канатлары шактый ныгыган каз бәбкәләрен ялгызы гына калган Банат апа су буена төшерә чыккан.

Исәнлек-саулык сорашкач, Банат:

– Болай кая җыендың әле, Резедә? – дип сорады.

Резедә көр итеп, рәхәтлек кичереп:

– Мәктәпкә, мәктәпкә! – диде.

– И, онытып торам икән әле, пәрәми. Бүген мәктәп көнегез ич. Котлы булсын, котлы булсын!

– Рәхмәт яусын, Банат апа! Рәхмәт яусын...

– Сиңа барып тормасаң да гаеп түгелдер инде. Пенсиядәге килеш, диюем.

Бу сүзләргә үпкәләсә дә, Резедә аны-моны сиздермәде.

– Йөрәккә нинди пенсия, Банат апа? Тәкъдиреңә язылгач. Иялэнгәч, күнеккәч.

– Бәлки шулайдыр, – диде Банат. – Алайса соңга кала күрмә. Сафа малае белән кызы баярак ук кузгалды. Быел безнең бөтен очтан шул ике бөртеккә калды.

– Мин аларны куып җитәм әле. Өлгерермен, өлгерермен. Моңарчы соңга калганым булмады, – дигәч, Резедә урам уртасындагы таш юлга күтәрелде. Авыл тып-тын иде әле. Хәзер көпә-көндез дә, кичкырын да шулай. Урамга чыгып басасың икән, карыйсың, күрәсең: әйләнә-тирә дә, әллә кайлар да буп-буш. Инешнең аргы ягындагы болынны узгандагы асфальт юлдан гына ара-тирә машиналар үткәли, ерак басулардагы техника шәйләнә дә, кибет тирәсенә юлга кузгалган чагында гына кешеләргә юлыгасың. Бераз хәл-әхвәл белешеп, бер-береңнең яңалыкларын сорашсаң, уртаклашсаң да, күңелләр тулып китә, җаннар иркенәеп, кинәнеп, җиңеләеп калгандай була. Югыйсә үзара аралашу тәмам тансыкка әйләнде. Резедә кайчакны аптырашта кала, йөдәп бетә: нигә авылда, элеккегерәк вакытлардагыча, кешеләрнең тавышы, көлешкәне ишетелми, көрлек, ихласлык, хөрлек әллә кая киткән дә адашып йөридер кебек. Гармун тавышы юк, төннәрен егет-җиләннең кыз-кыркынны озатулары юк, кычкырып җырлау, ташланып, онытылып бию юк. Ичмасам, этләрнең генә булса да өрүләре нигә шулкадәр дә боек, әйтеп җиткералмастай моңсу соң ул? Сузылыплар аткан алсу таңнарны кыл урталай бүлеп, мәңгелеккә дигәндәй каршылап торган әтәч тавышлары нигә гаярь, горур, армас-талмас түгел? Су буендагы тал төбендә кармак сабын тоткан килеш калкавычка текәлер алдыннан, каршыдагы болын кырыеннан бер укытучы Ильясның гына үтеп киткәләгәне чамаланып кала. Авыл халкының ял көннәрендә, бәйрәмнәрдә кайткалаган бала-чагасы, туган-тумачасы күрешкәне күрешә, белешкәне белешә, ә югыйсә әйбәтләп, мәңге онытылмаслык итеп очрашулары әллә

нидә бер генә диярлек. Дөньяны әзгә канәгатьлек, бөеккә, галилеккә омтылмау басып бетерде.

Шушылар хакында уйланып та, һичнинди уйсыз-нисез дә Резедә үзенчә ашыга-ашыга, тик кабаланмыйча барды да барды. Инде урамның үз очларын, зиратны үтеп, үрдәге мәктәпкә әйдәүче урамга аяк басканда, аңа күбесе хатын-кыз, сирәгрәк ир-ат очраштыргалый башлады. Аның белән башлап исәнләштеләр, ул җавап кайтара барды, әңгәмә кормады: аның барып җитәсе җире бар бит, шунда соңармыйча өлгерәсе. Аңа анда һәр елдагыча сүз әйттерерләр инде. Аны бераз каушатып та җибәрер, тик ул югалып калмас, зарыктырган, сагындырган, башкаларга кирәкле дип санаган түгәрәк-түгәрәк сүзләрен дисбедәй дөрес төзеп, тезеп, ялыктырмый гына әйтеп бирер.

Ә аңарчы барасы җиргә җитәсе бар әле. Әллә кайтасы микән? Әйе-әйе. Барыр җиргә кайтасы. Кайтасы шул, кайтасы.

Әллә кайларга җитеп ирешкәннең соңында үз ояңа әйләнеп-әйләнепләр кайтасы. Нәкъ кичәге керәшәләр кебек. Алар да, вакыты килеп җиткәч, үз ояларына әйләнеп кайтыр өчен китеп бардылар бит.

«Миңа да гел шушы мәктәбемә кайтасы, – дип уйлады Резедә. – Яшәгәндә дә, яшәп бетергәч тә. Бәлки, мин үз өебезгә мәктәптә яшәгәннән соң барып кына йөргәнмендер?»

Ул үз соравына җавап эзләп табуны кирәксенмәде. Яшәүне дәвам иттерер өчен, керәшәләр нибарысы ике ай буена борнап чыгар, үсәр, канат ныгытыр алдыннан озын-озак дистә айның аргы ягыннан кайталар. Яшәр өчен. «Мин – Резедә дә киләчәктә яшәр балаларымның канатларын ныгытырга кайтып барам», дигән уе аның үз җан канатларына да дәрт-дәрман шаукымы биреп куйды да – шундук басылды. Алар күптәннән – кырык өч ел буена үзләре үк әйләнәләр дә кайталар, әйләнәләр дә кайталар лабаса инде. Үз балалары исә, кими, киметә барып санаганда, шул саннан фәкать бер генә елга кайтыш шулай итәләр.

Ике улы, өч кызы. Юк, юк, уллары да кызлары.

Резедә ире Галиәхмәтне, сагышлы исенә алып: «Ансыз ничек булсын!» – дип уйлады. Әлеге сагышы исә иксез-чиксез булып, ул бетмәс-төкәнмәслеге белән аның ярты җанын тутырып, исән-имин тота иде.

Резедәнең, үзе белән Галиәхмәте шикелле үк, эти-әнисе дә йөзләгән бала-чага канатын ныгытып очырды. Үзләренең җиде пар газиз җан канатлары да, шөкер, сөбханалла, өлкәннәре Резедәгә биргесез төстә ару гына очалар да очалар әле.

И-и, бу уйлар, әй! Керәшәләрнең ясканулы, омтылышлы очынулары сыман җитезләр, төгәлләр. Зиһен ияреп өлгермәле түгел.

Шул вакытны Резедә әллә нишләп китте. Йөрәге тынсыз калдырып чәнчегән мәлләрдәгечә. Мәктәп юлындагы койма капкасын ачарга дип кулын күтәргәндә, ул:

– Чү! Бу ни бу? – дип куйды.

Һичнәрсәгә күзе төшмәс борын, аның сак җаны-тәне һава җитмәгәндәй тирән сулкылдап куйды. Дөнья тып-тын иде. Тып-тын.

Бу тынлыкта көтмәгән-нитмәгәндә ишеткән авазга ул сискәнеп китте. Аңа берәү аркан яктан, ягымлы гына итеп:

– Исәнмесез, апа, – дип эндәште.

Ул әлеге тавыш иясен борылып тормастан ук танып алды да:

– Исәнме, Минһаҗева, – диде.

Ә җавап кайтарганына борылып җитәр-җитмәстән үк, әле генә ул «Минһаҗева» дигән зат аңа кочагын тутырган купшы чәчәк бәйләме сузып тора иде. Кибетче Мәдинә икән, Минһаҗева Мәдинә. Ул аның инде өченчегә йөкле икәнен яхшы белә. Ул зирәк, шаян укучы бала иде. Хәзер уңган, булган хатын. Берүк күз тимәсен. Мәдинә тагын:

– Исән-саумы, Резедә апа, – дип кабатлады. – Белем көне мөбарәк булсын!

Резедә йомшак кына, чәчәкләргә җаны-тәне белән омтылып:

– Рәхмәт яусын, наным, – диде.

– Кичә-бүген бөтен чәчәкләремне сатып алып бетерделәр. Боларын сиңа сакладым, Резедә апа. Бар классыбыз исеменнән булсын, яме!

– Рәхмәт, наным, – дигәч, ул әйтергә ярыймы икән, юкмы дигәндәй сынап карап алды да: – Кайда... – дигәч тотлыгып, тынып, уңайсызланып калды.

Мәдинә аңлады. Аркан якка борыла төшеп, әллә кая читкә, еракларга карап, кая икәнлеге билгесез бер тарафка кулы белән җиңелчә генә ишарәләп:

– Әнә, – дип, авылның моннан башта түбәнтен, аннан соң, инеш күперен узгач, үргә таба күтәрелгән урамны чыгып, бераз баргандагы асфальт юл чатына борылган автобусны күрсәтергә теләде. – Баягынак бөтенесен Олы Юлга авылына озаттык. Башлангычлары, башка сыйныфлары белән егерме сигез бала. Икесе – минекеләр. Тагын биш укытучыбыз. Безнең мәктәпне бетерделәр ич. Сине дә көткәниек. Бүген өлгермәдең. Озатышырга өлгермәдең. Онытып җибәргәниеңмени, Резедә апа? Ярар инде, соң булса да, уң булсын, диләр. Менә, килгәнсең бит әле.

– Мин монда килмәдем, Мәдинә наным, – диде Резедә. – Мин монда кайтам.

Мәдинә, аңлап җиткермичә:

– Кайтам? – дип сорады.

Резедә тыйнак кына:

– Кайтам, – диде. – Ә кайтырга беркайчан да соңга калмыйлар. Вакыты җиткәч, барысы да кайта.

Резедә, тагын борылып, бу яктан кояш төшмәгән ике катлы мәктәпнең ак кирпеч диварына карап торды. Аның караңгы тәрәзәләре ярдагы тезелешеп киткән буш ояларны хәтерләтә иде.

– Керәшәләр дә кайта әле ул, Мәдинә наным, кайта, – диде ул. – Киләчәктән әйләнеп кайта.

– Керәшәләр?

# «КЕШЕ БӘЯСЕН ХАЛКЫ БИЛГЕЛИ...»

ОЧЕРК

*Үзенең кем икәнен белмәгән инсан ничаклы хиссез исә, үз милләтенең тарихын белмәгән инсан да шул нисбәттә хиссездер.*

Һади Атласи

Адәм баласы җир йөзенә ни өчен туа, нигә яши, мәңгелеккә үзеннән соң ниләр калдырып китеп бара? Мөгаен, бу сорау турында күпләр уйланадыр, һәркемнең үз җавабы үзенә дөрес тоеладыр...

Гаҗәеп заманда яшибез, хәтер җебе көннән-көн ныграк кыскарган, бар булмышыбызны бүгенге җырчылар, аларның нәрсә ашап, ничә сумлык эчке күлмәк киеп йоклавы, кайда нинди юл һәлакәте булуы турындагы мәгълүмат кыры урап алган тирәлектә көн итәбез. Әйтерсең, Аллаһы Тәгаләнең кодрәте белән барлыкка килгән шушы олы җиһанда кемнәргәдер юл күрсәтерлек, үрнәк булырлык бер генә гамәл дә кылынмый. Әйтерсең, безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы, дип чаң суккан шагыйрь сүзләренә кушылып, дөньяны уятырга, яңартырга омтылган шәхесләребез бөтенләй юк... Хәер, болай дип кистереп әйтүемә үзем үк каршы килеп куям: шөкер, сирәк-мирәк булса да, андый фидакарьләр турында да сөйләп-язып торалар, тик, әллә күңел күзе сукыр, әллә ишетеп тә ишетмәгәнгә салышабыз – колак очыннан үткәрергә гадәтләнеп киләбез.

Ырынбур каласына юлыбыз төшкәч, атаклы татар меценатлары Әхмәт һәм Гани Хөсәеновлардан бүгенгәчә тарихи ядкарь булып сакланып калган «Хөсәения» мәчетен, таш мәдрәсә биналарын күреп, сокланырга да, уфтанырга да өлгергәнемне хәтерлим әле. Нинди шәхесләр! Мәдрәсә утарын төзү өчен үз акчаларына заманына күрә бик кыйммәткә җир алып, нинди комплекс төзеп куялар! Һәр елны, мәдрәсәне уңышлы тәмамлаган берничә шәкерт, миллионер Хөсәеновлар билгеләгән стипендия исәбенә Истанбул, Каһирә, Дәмәшкъ, Бәйрут уку йортларында, Франция, Бельгия университетлары һәм институтларында белем ала!.. Ырынбурның икенче бер мактанычы, алтын приискалары хуҗасы Закир Рәмиевнең – Дәрдемәнд тәхәллүсе алган шагыйрьнең – әле башка өлкәдәге иганәчелеген телгә алмыйча, бөтен чыгымнарны күтәреп, үз наширлегендә «Шура» журналын, «Вакыт» газетасын чыгаруын гына искә төшерсәк тә, милләткә күрсәткән игелеген беркадәр күзалларга мөмкинлек бирер...

– Бүген юк инде, юк. Өстән кушкач, мәҗбүр иткәч ярдәм күрсәтүчеләр күп, тик XXI гасырда татар меценаты дип әйтерлек беркем юк инде, юк, – диешәбез.

– Кулында мал булганы халык өчен дип кыл кыймылдатырга ашыкмый, биш гомерлек яшәр кыланып, үз сандыгына җыя...

– Андыйлар татар тарихында Дәрдемәндләр булу-булмауны түгел, кем икәнен дә белмидер шул...

Ни оят, ул минутта без дә белми идек – милләттәшләребез арасында яңа гасырның игелекле шәхесләре барлыгы хакында белми идек.

***

«Таттелеком» акционерлык җәмгыяте турында бөтенләй бернәрсә белмим дип әйтүем түгел. Хәзер тормышыбызны интернетсыз, кәрәзле элемтәсез, телевизорсыз күз алдына да китерә алмыйбыз, үзебезнең телефоннар да, кабельле телевидение дә бу компаниянең «Летай» операторы «күзенә карап тора». Яңа медиапроектлар да колакка байтак чалына, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте белән уртак булган проектлардан «Ышаныч» телефоны, кәрәзле элемтә өчен «Азан» тарифы планы, «Летай» абонентларының кабель телевидениесендә эфирга чыккан «Азан» радиосы, «Хозур ТВ» мөселман телевидениесе турында да хәбәрдарбыз.

Болар барысы да заман таләбенә буйсынып барлыкка килгән инновацион элемтә

чаралары, компаниянең бөтен филиалларын күздә тотсак, анда эшләүче биш меңләп кешенең уртак тырышлыгы, уртак хезмәте. Әмма укучы мине гафу итсен: бу язмада сүзем җир өстеннән, җир астыннан сузылган чыбыклар аша араларны тоташтырган элемтә хакында түгел, үткәнне һәм бүгенгене, киләчәкне бербөтен итеп ялгаган җепләр турында булыр.

Елларга исем кушу матур бер гадәткә әйләнеп килә: бер-бер артлы Тукай елы, Лобачевский елы узып китте, быел менә Шиһабетдин Мәрҗани елы дип игълан ителде. Шул уңайдан республиканың бөтен район-авылларында әллә никадәр әдәбият-сәнгать чаралары уздырылды, архив материаллары барланды, тарихи һәйкәлләр сафка басты. Бу гамәлләрнең барысы да нәкъ менә «Таттелеком» оешмасы иҗади төркеме, аның җитәкчелеге тарафыннан тормышка ашырылган икәнлеген бик күпләр беләдер дип уйламыйм. «Игелек эшлә дә суга сал, халык белмәсә, балык белер» дигән мәкальне (тәрҗемәче Фатих Кутлу фикеренчә, аның дөрес варианты – игелек эшлә дә суга сал, халык белмәсә, балык белер, балык белмәсә, Халикъ, ягъни Аллаһ белер) күздә тотып микән, компаниянең генераль директоры Лотфулла Нурислам улы Шәфигуллин үзләре башкарган эшләр турында шәрран ярып йөрүчеләрдән түгел. Җитәкченең сүзе бер һәм кыска: «Мин моны мактану өчен эшләмим». Хәер, сүзләргә караганда, җәмәгатьчелек күзе алдында тарихи хәтеребез булып калыккан гамәлләр ачыграк сөйли түгелме?..

Казан каласына килгән күпләрне иң тәүдә Совет мәйданы, борылыштагы тукталышта «Таттелеком» оешмасының өч катлы бинасы һәм әдәбият-сәнгать әһелләренең аны каймалап алган портретлары каршы ала. Әнә, быел үзенең тууына 140 ел тулганын искәртеп, Гаяз Исхакый карап тора, «миңа чыннан да 190 яшьме?» дип, Толстой бераз аптыраулы төбәлгән... Каләм ияләренә мондый игътибарны Баку урамнарында күреп, сокланып кайтканым бар иде: Үзәк китапханәнең, Әдәбият музееның тышкы яктан шундый сурәтләр һәм сыннар белән бизәлүе аһ иттерсә дә, табигый тоелды. Ә менә Казаныбызда элемтә оешмасы урнашкан йортның үзе бер сәнгать учагыдай балкып утыруы гаҗәпкә калдырды: студент елларыбызда санаулы минутка гына булса да авыл белән тоташтырган, әткәй-әнкәйләрнең җанга якын тавышын ишеттереп, күз-керфекләрне чылаткан, телефон трубкасында шул тавышны ишеткән мәлдә тап-тар кабиналары да җиһанның үзе кебек киң тоелган бу бина әллә соң берәр әдәби йә булмаса тарихи үзәккә әйләнгәнме? Май чүлмәге тышыннан билгеле, диләр бит...


Монда чын-чынлап сәнгать җанлы элемтәчеләр эшләгәненә төшенү өчен, ераккарак китеп карарга кирәк икән. Чакрымнар гизеп кенә түгел, чорлар, гасырлар аша үрелеп карарга, милләтебезнең данлы да, зарлы да үткәненә, йөз күрке булырдай шәхесләренә борылып карарга кирәк. Гамил Афзалның: *«Төп астында тирән тамырлар. / Шул тамырдан безне танырлар»*, – дигән шигъри юллары бар. Шигырьдәгечә, тамырларыбызны барларга кирәк.

Компаниянең генераль директоры ярдәмчесе, тарихи-географик фондның башкарма директоры Рөстәм Зәкуанов – үзе дә шагыйрь кеше, аның Тукайлар, Туфаннар белән «җенләнүен» аңлап була, ә менә Лотфулла Нурислам улы – гомеренең күп еллары хәрби хезмәттә үткән җитәкче – ни өчен әле тора салып нәкъ менә тарихи мирас белән кызыксынасы, аны саклау, халкыбызга кайтару турында уйланасы иткән?

Барысы да очраклы рәвештә генә килеп чыкканмы? Әллә, 2010 елда Иске Казан җирлегендә «Сәләт» лагерена җыелган балалар янына килгәч, андагы күптән инде яңарту көткән музейны күргәч, колагына шушы туфракта сөякләре яткан бабаларыбызның сыктау авазы ишетелгәнме? Үзен култыклаган хатыны Венера Абдулловнаның: «Шушы балалар өчен берәр нәрсә эшлә инде, үз халкың алдында оят түгелме?» – дип төрттереп куюы сискәндереп җибәргәнме? Озак та үтми, Камай авылы янындагы яланнарга мари урманнарыннан бүрәнә арты бүрәнә кайтартыла башлый, кирмәнне яңарту буенча эш кайнарга тотына. Бөтен тирә-як ел буе бер генә минутка да тынып тормаган балта тавышына күнегеп беткәндә генә, әйләнә буенча озынлыгы 500 метрдан артып киткән борынгы кирмән пәйда була, музей-тыюлык танымаслык булып үзгәрә.

Үзең тотынган эшнең нәтиҗәсен, аннан да битәр, кешеләргә сөенеч һәм файда китергәнен күрү тагын, тагын игелекле эшләргә этәрә.

Арча ягы – татар халкына берсеннән-берсе асыл ир-егетләр бүләк иткән төбәк.



*«Апуш коесы». Арча районы Яңа Кырлай авылы.*

Үзе дә шуннан, Симетбаш авылыннан булган Лотфулла әфәнденең туган туфракка рәхмәте якташларының затлы исемен мәңгеләштерүдә чагыла. Халыкның хәтере бик озын да, шул ук вакытта, ни кызганыч... бик кыска да. Тарихны оныттырам, дисә, сәясәт кылычының бер селтәнүе җитә: телеңнән, китабыңнан, әдәбиятыңнан, мәктәбеңнән аерылдыңмы, димәк, үткәнеңнән дә, киләчәгеңнән дә аерылдың дигән сүз. Тамырларның кая тоташканын ташка уелган, мәчет манарасы булып калыккан, чишмә булып саркып чыккан истәлекләр саклап калса инде...

Татар халкы – Тукайлы халык. Нибары 27 ел яшәп, гасырларга җитәрлек мирас калдырган, милләтнең бөтен фаҗигасен иҗатында чагылдырырга өлгергән олуг шагыйрьне, үзе үк әйткәнчә, маңгаеннан сыйпап, шул ук милләте үстергән, Арчаның Кушлавычы, Өчилесе, Кырлае, өзелергә торган гомер җебен ялгап, яшәү суты биргән. Кырлайның Сәгъди абый йортында уздырган ике елы булачак шагыйрьнең тамагын ашар икмәккә, ә күңелен җыр-шигырь атлы хикмәткә тиендергән. Әлеге йорт күптәннән музей буларак сакланып калса да, соңгы елларда кунаклар күзенә күрсәтерлек кыяфәттә булмый. Тукайның тууына 130 ел тулу уңаеннан, «Таттелеком» оешмасы киң колачлы эшкә алына. Беренчедән, республикада 2016 елны Тукай елы дип игълан итеп, олысынкечесен шагыйрьнең шәхесенә һәм иҗатына тагын да якынайта. Икенчедән, Сәгъдетдин Салиховның әле кайчан гына боегып, җиргә чүгеп барган йорт тирәсе танымаслык булып яңартыла: биредә теләсә кайсы илдән килгән кунакны көлеп каршы алырлык затлы әдәбиархитектура паркы сафка баса. Шүрәле, Су анасы, Былтыр кебек онытылмас образлар, скульптурага әверелеп, шигъри дөньяга дәшә; әнә, бер-берсе белән җитәкләшкән Апуш һәм Сәгъди абый да, менә-менә телгә килеп, язмышлар хакында бәян итәр кебек... Ишегалдында «Апуш коесы» дип балкып утырган коеның да, йөзьяшәр наратның да нәни Апуш турында үз хатирәләре бардыр... Кайчандыр бәрәңге бакчасында нәни малайның аяк йөзен яралаган көрәк күзгә чалынмаса да, хәзер инде хәтер утарына әйләнгән бакча үзе йөрәк өзгеч бу хәлләрне онытмагандыр әле...

«Үлгәннәрнең каберен бел» дигән гыйбарәне искәртеп, зиратта Сәгъди абзыйның мәңгелек урыны үзе бер һәйкәл булып күренә.

Болар барысы да – «Таттелеком» иҗади төркеменең фидакарь хезмәте, тарихи чыганакларда, архивларда эзләнүләре. Кемдер кушканга, өстән төшкән боерыкка буйсынып эшләнгән гамәлләр түгел бу, күңел таләп иткәнгә, рухи кыйммәтләрнең һәм саваплы эшләрнең асыл бәясен аңлаганга, йөрәк фәрманын ишеткәнгә башкарылган хезмәтләр.

Арча районы Югары Курса авылында туып, татар дөньясында үзен беренче реформатор буларак таныткан мәгърифәтче Габденнасыйр Курсавига багышлап ачылган мемориал комплекс та – игътибарга лаек.

Быелгы елның Шиһабетдин Мәрҗани елы дип игълан ителүенең дә төп «гаеплеләре» – шушы егетләр. Мәгърифәтче, дин галиме, тарихчы, дөньяга карашы белән үз заманында да, хәзер дә торып-торып шаккатырга мәҗбүр иткән Мәрҗанинең туган авылы Ябынчыда аңа багышланган мемориал төзү дә, әткәсе һәм Шиһабетдин үзе мөгаллимлек иткән Ташкичүдә музей, аның исеме белән аталган Мәрҗани чишмәсен ачу да – алар эше.

Шиһабетдин Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвәли Казан вә Болгар» («Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр») дигән хезмәте буенча университетта укыганда имтиханга әзерләнгәнемне хәтерлим әле. Укытучыларыма мең рәхмәт, бу шәхеснең үз бөеклеге турында да, тарихи хезмәтләре турында да әле дә ярый шул чорда төшендереп калганнар. Чөнки аннан соң инде халкыбызның бу олпат заты турында ниндидер мәгълүматларга тап булганымны хәтерләмим. Аның кем икәнен бөтенләй белмәүчеләр дә байтактыр, бу елның Мәрҗани исеме белән аталуы бик күпләргә әллә никадәр ачышлар һәм табышлар алып килер әле. Компаниянең иҗат төркеме тарафыннан күптән түгел генә «Татарский Геродот» дип аталган затлы китапның чыгарылуы, аның мәктәпләргә, китапханәләргә һәм Россиянең 23 өлкәсендә таратылуы да бүген зур әһәмияткә ия – димәк, яңа буын аның тормыш юлы белән дә, эшчәнлеге белән дә танышу мөмкинлегенә ия булачак.

1889 елда вафат булган Шиһаб хәзрәт Казанда Татар зиратында җирләнгән. Лотфулла Нурислам улы аның да, Каюм Насыйриның да кабере тәмам ташландык хәлдә икәнен күргәч, халыкның хәтер җебе хакында уйланды микән? Тарихи шәхесләргә мөнәсәбәт турындамы?.. Югыйсә, төп аллеяда, Тукай янына алып барган сукмак буенда, кеше күзе алдында бит үзләре... Һәртөрле бюрократик киртәләрне җимерер өчен, тиз арада компания егетләренең кайсына – «Мәрҗани оныгына», кайсына «Каюм бабайның ерак туганына» әйләнергә туры килә. Каберләрне тиз арада рәтләп, төзекләндереп куя алар.

Әтнә районы Иске Мәңгәр авылындагы борынгы зиратны – Алтын Урда чорына караган мәңгелек йортны тәртипкә китерү дә эш юктан эш табу гына түгел. Лотфулла әфәнде әле үзенең яшь чагында бу зират өстендә балаларның туп тибүен, кабер ташларын капка итеп тезеп куюларын яхшы хәтерли. Менә, сәгате җиткәч, әлеге урынны төзекләндерүне үз өстенә ала ул. Егетләре җирне металл таяклар белән казый торгач, байтак кына борынгы кабер ташларын эзләп алалар. Шул рәвешле, яңа чардуганнар белән уратылган хәтер сакчылары сафка баса.

ТРның Дәүләт Советы депутаты Лотфулла Шәфигуллин Президиум утырышындагы бер чыгышын: «Бәлки, кайберәүләр минем фикер белән килешмәс, «Ватан каян башлана?» – дигән сорауга мин: «Зираттан», дип җавап бирер идем. Зират ул – ачык һавадагы музей, зират ул – бабалар хәтере, бабайлар рухы сакланган урын...» – дип башлап җибәрә. Болар һич кенә дә ниндидер кызыл сүзләр түгел, киресенчә, сүзе һәм эше тәңгәл килгән ир-егетнең тормыш кыйбласы...

Югалтмыйм, эзлим, саклыйм, дисәң, хәтер ул көл астында калган тарих битеннән дә гөл булып күтәрелергә мөмкин... Әнә бит, татарның тагын бер асыл улы – Кама Тамагы Мәрәтхуҗа авылында туып-үскән Туфан Миңнуллинның туган нигезе, янгыннан соң, туры мәгънәсендә кара күмергә, көлгә кала. Язучының 80 еллыгы якынлашкан мәлдә, Лотфулла Шәфигуллинның үз ярдәмчесе Рөстәм Зәкуановка: «Туфан абыйның авылына барып кайт әле, нигезе ни хәлдә икән?» – дип эндәшүе җитә. Аны аякка бастыру, Туфан аганың үзе төзегән иҗат йортын музейга әверелдерү, гомумән, биредә Туфан Миңнуллин утарын булдыру – «Таттелеком» оешмасы хезмәте.

Азнакай районының Яңа Ташлыяр авылы – ике мәшһүр зат – Татарстанның һәм Россиянең халык артистлары, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатлары Нәҗибә Ихсанова һәм Әзһәр Шакиров туып-үскән авыл. Кызганыч, бик күп авыллар язмышын кабатлап, бүгенге көндә ул картадан гына түгел, җир йөзеннән дә сызылган, юкка чыккан. Ата-бабаларның рухын саклап, зиратта каеннар гына шаулап утыра. Ташландык булуы белән генә туган авыл, туган нигез йөрәк түреннән сызылыр дисезме? Ул халык хәтерендә яшәргә тиеш! Әнә шундый ният белән Яңа Ташлыяр авылы нигезенә истәлек ташы һәм бу авылда ике артист туып-үсүе турында стелла урнаштырылу – «Таттелеком» егетләренең эше.

Татар тарихын өйрәнүгә искиткеч зур хезмәт куйган академик Миркасыйм ага Госмановның Яшел Үзән районы Татар Наратлысы авылындагы йортын төзекләндерү дә, Арча районы Хәтнә авылында Пётр һәм Павел чиркәвен яңарту, Изге чишмә, православие динендәгеләр һәм мөселманнар өчен гыйбадәт кылу урыннары, кайчандыр биредә яшәгән данлыклы Перцовларга багышланган музей да – алар эше. Советлар Союзы Герое, Арча районы Иске Кишет авылы егете Гани Сафиуллинга багышлап ачылган

музей-комплекс та – аларныкы. Бүген мәктәпләрдә пионер, комсомол оешмалары да юк, патриотик тәрбия дигәнебез дә еш кына төче бер сүз булып ишетелә, Ватан сугышы, аның каһарманнары турындагы мәгълүмат та елдан-ел заманга яраклашып бара. Хакыйкать архивларда һәм музейларда саклана: бирегә, элемтәче егетләрнең тырышлыклары нәтиҗәсендә, генералның «Секретное личное дело»сына кадәр табып китерелгән, метрикәсе дә табылган. Кайчандыр авылның бер тыкрыгында ташландык һәм ятим кыяфәттә нәүмизләнеп утырган йорт бүген чын-чынлап патриотик тәрбия бирү үзәгенә әйләнгән, яз-көз айларында армия хезмәтенә чакырылган яшьләрне бирегә зурлап, тантаналы рәвештә озату инде – Арча районындагы күркәм бер традиция.

Чишмә һәм кое казу мәчет төзү, китап бастыру, Коръән уку дәресләре оештыру, мохтаҗларга ярдәм итү кебек, элек-электән иң хәерле, савaплы гамәлләрдән саналган. Бу җәһәттән оешмада элемтәче булып эшләүче егетләр егермедән артык чишмәне казып, чистартып, җырлап кына ага торган хәлгә китергән арада, көмеш суның чылтыр агышын җиде кат җир астыннан да тоярлык «су белгечләре»нә дә әйләнеп беткәннәрдер. Кара әле, Курса авылында бурасы җимерелеп, бөтенләй ташландык хәлдә калган чишмәгә тотынуларын күргәч, авыл халкы ни үгетләде үзләрен: «Суы юк аның, әллә кайчан качты. Интегеп йөрмәгез, барыбер су чыкмый», янәсе. Күз курка, кул эшли – изге ният белән тотынгач, нишләп чыкмасын? Әнә, ике торбадан шаулап ага хәзер. Халык белән киңәшкәч, исемен «Курсави чишмәсе» дип, әллә каян күренеп торырлык итеп язып куйдылар.

Татар әдәбиятына Гариф Ахунов кебек гаярь язучыны биргән, бөтенләй бер йортсыз, бер кешесез, ялан гына булып калган Өчиле авылында «Ахун чишмәсе» дә җырлап утыра бүген. Әле кайчан гына ләмгә, сазлыкка, камышларга күмелгән ташландык чишмә... Казанда Боратынский музеенда очрашкач, шагыйрә Наилә Ахунованың: «Әтинең туган авылында берәр истәлек тактасы куеп булмасмы», – дип, Лотфулла Шәфигуллинга мөрәҗәгать итүе җитә... Кайчандыр Гариф ага үзе: «Дөньяда ике могҗиза бар: берсе – чишмә, икенчесе – әлифба», дип язган иде. Сүзләренең дә, Арча ягының тагын бер горурлыгы булган әдипнең дә үлемсезлеген раслагандай, челтер-челтер килеп чишмә ага...

«Зариф чишмәсе», «Әбиләр чишмәсе», «Кафия чишмәсе», «Нурислам чишмәсе», «Изге чишмә», «Туфан чишмәсе», «Мәрҗани чишмәсе», «Сабантуй чишмәсе»... Аларның һәрберсе суга килгән сыгылмалы билле кызларның, сусап, чишмә буена туктаган юлчыларның рәхмәт хисе белән сугарылып, үзләренә юл ярган игелек ияләренә дога кылгандай, тигез тавыш белән җырлап, челтерәп агып утыра.

Чишмәләр дә – хәтер. Һәркемнең күңелен шифалы суы белән юып агартырга, матур үрнәкләр турында сөйләргә омтылган хәтер ул. Югыйсә, кешеләрнең һәрбарчасы, кулыннан килгәнчә, тары бөртеге кадәр генә яхшылык кылып яшәсә, дөнья бөтенләй башка якка үзгәрер иде. «Илдән берәр җеп җыйсаң да, ятимгә күлмәк була», ди халык мәкале...

Берәм-берәм санап китсәң, «Таттелеком» компаниясе, аның җитәкчесе, иҗат төркеме башкарган хезмәтләрне су буе итеп тезәргә туры килер иде, мөгаен. Әле ул хезмәтләрнең ярты юлда бүленеп калмавын, һәр башлангычның дәвамлы булуын тәэмин итү, карап-тикшереп тору да оешманың язылмаган кануныла әйләнгән. Шимбә-ял көннәрендә җитәкчеләрнең күбесе ауга, балыкка чыгып китәдер, ә «элемтәчеләрнең» үз урманы, үз чишмәсе: барысы да тәртиптәме – барлап, хәл-әхвәлләрен белеп тору зарури бер гамәл кебек...

Чүлмәкчедән күрмәкче, дип, әллә нинди гамәлләргә ияләбез, кемуздан дөнья куабыз, йөгерәбез. Әмма, ни хикмәт, башкалар мәнфәгатен, милләт гамен кайгыртып кылынган изгелекләр турында ишетәбез дә онытабызмы? Чөнки аларны кабатлаучылар күренми... Кулында малы булганнарны тарих, әдәбият, шәхесләр түгел, дөньяның ялтыравык бизәкләре күбрәк кызыксындыра шул.

«Таттелеком» егетләре-кызлары исә, дөньяның йөзен бераз булса да агартырга теләп, хәтеребезне, мүк баскан йөрәкләрне уятабыз дип, күңелләргә элемтә җепләре сузарга омтыла: чөнки үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк икәнне алар инде күптән аңлаган...


**Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА**



*Узган гасырның 60нчы елларында Шигырь бәйрәме Казан үзәгендәге («Кольцо-Боҗра») Тукай һәйкәле янында үткәрелә иде.*



*Республика җитәкчеләре һәм бер төркем язучылар Тукай һәйкәленә килгәннәр. 1995 ел.*



*Шагыйрь Наҗар Нәҗми Тукай бәйрәменә килгән халык алдында «Татар теле» дигән шигырен укый.*



*Тукайның тууына 100 ел тулуга багышланган тантаналар уңаеннан Яңа Кырлайга, музейга килгән кунаклар. 1986 ел.*

# ЯКУТ РИВАЯТЬЛӘРЕ

## Угры, Шайтан һәм Шаман

Оруосун исемле байның тугыз ел тәрбияләгән үгезе булган. Үгез шулхәтле симергән, инде аяклары күтәрә алмый, зур бака шикелле кабарынып, күбрәк ятып тора икән, ди. Караклар шундый сирәк малны урлап китмәсен өчен, көндез аны күздән ычкындырмаганнар, ә төнлә өч катлы абзар эчендә, өч йозак астында тотканнар.

Менә Ходайның боерганы килеп җиткәч, бай карар иткән: үгезне суярга вакыт, тик, ит бозылмасын өчен, көннәр суытканын гына бераз көтәргә кирәк.

Көзге һава төсен койган һәм кашын җыерган, җиргә калын булып көпшәк кар яуган, аннары салкыннар килеп җиткән, кар тыгызланган, инде аяк астында шыгырдый ук башлаган. Оруосун әйткән: иртәгә тәвәккәллибез! Шуның өстенә, иртәгә Оруосунның төп байлыгы – күптән көтелгән, карап күз туймаслык оныгына төп-төгәл өч яшь тула икән. Язмыш үзе бу сабыйга данлыклы токымның лаеклы дәвамчысы булырга насыйп иткән. Үгез турындагы карарны беркеткәч, Оруосуннар иртәгәсе күңелле көн турында татлы хыяллар белән йокларга ятканнар.

Ә төн уртасы узгач, тын ихатада зур гауга күтәрелгән: каравылчы этләрнең абалап өрүе, урыныннан кузгатылган үгезнең үкерүе, куркынган кешеләр ай-вае – барысы бергә кушылган. Оруосуннар йоклаган җирләреннән купкан, караңгыда бер-берсе белән бәрелешеп, кулларына мылтык эләктереп, ишегалдына сикереп чыкканнар.

Этләр, сырт йоннарын торгызып, калын бүрәнәләрдән салынган абзар тирәли бәргәләнгәннәр, ә абзар эчендә кемдер стенага төя-төя котырып кычкыра икән.

– Карак! – дип аһ иткәннәр бай кешеләре, ишеккә ташланганнар, тик аптырап туктап калганнар: тимердән коелган бөтен бикләр исән, авыр йозаклар урыныннан кымшанмаган, аларда артык тырналган төш тә юк. Оруосуннар бер-берсенә карашканнар, абзар тирәли йөгереп узганнар, әмма бернинди казылган урын күрмәгәннәр, хәтта кар өстендә дә һичнинди эз юк, ди. Хәер, тимер балта да үтеп керә алмаслык, туң җирне кем казый алыр икән?!

Бай үзе ачкыч бәйләмен алып килгән, бикләр шалтырап кузгалган, Оруосуннар, коралларын әзер тотып, авыр ишекләрне ачып җибәргәннәр. Абзар эченә төшкән факел яктысында бөтенләй таныш түгел кеше күренгән, ул тилергән сыман кычкыра, йодрыклары белән абзар диварларын кыйнавын дәвам иткән, имеш.

Хуҗаның ым кагуы белән, яшь таза егетләр, Оруосуннарның батраклары, таныш түгел кешегә ташланганнар, исенә-акылына килгәнче, каеш баулар белән аның кул-аякларын богаулап бәйләп тә куйганнар.

Чакырылмаган кунакны өйгә өстерәп керткәч һәм ихата хуҗасы каршына китереп бастыргач:

– Чит кеше абзарына төн уртасында ни эзләп кердең? – дип сораган Оруосуннарның өлкәне.

– Сезнең үгезне урлап китәргә, – дип курыкмыйча җаваплаган теге адәм.

– Нәрсә дидең? – Мондый ачыктан-ачык тануны көтмәгән бай бугазына килеп тыгылган ачудан елап җибәрә язган.

Барысы да – уллары, киленнәре, хуҗабикә карчык һәм батраклар – таныш түгел кешегә, аны нинди хәтәр язмыш көткәнен аңлап, куркып караганнар.

– Бу юньсезнең ни әйткәнен барыгыз да ишеттегезме? – дип сүзен дәвам иткән Оруосуннарның өлкәне. – Ул, күрәсең, кем кулына килеп эләккәнен белми әле.

– Нишләп белмәскә – беләм, – дип, баягыча ук курыкмыйча җавап биргән угры.

– Алайса, син шундый кыю һәм ихлас икәнсең, бәлки, безгә әйтерсең, сиңа абзарны кем ачты? Кем сиңа ярдәм итте? – Бай үз кешеләренә сөзеп караган.

– Беркем дә ярдәм итмәде. Барыгыз да күрде бит, йозаклар үз урынында.

– Шулай да син ничек абзарга керә алдың?

Угры иңнәрен сикерткән.

– Дөреслекне беләсегез килсә – әйтәм... Тик башта минем кул-аякларымны чишегез.

– Бәлки, чынлап та, аны чишәргәдер, – дип тәкъдим иткән байның улы.

– Без күбәү, бу бәндә беркая да качып котыла алмас. Йәле, егетләр, аны чишегез.

Богауларыннан котылганнан соң, угры, берни дә булмагандай, тәнендә кысып бәйләүдән калган эзләрне ышкып алган да учакка якынрак урындыкка күчеп утырган.

– Сөйлә! – дип әмер биргән Оруосуннарның өлкәне.

– Минем сүзем озын.

– Сөйлә! – дип кабат боерган бай.

Төнге кунак, дәрәҗәсен саклап, тагын бераз дәшми торган да сөйли башлаган.

– Көн батышындагы олысларның[1] иң танылган карагы буламын мин. Сезнең инде тугыз ел симерткән үгезегез турында ишетмәгән кеше юк, исемемне тагын да ныграк танытыр өчен, минем нәкъ менә аны урлыйсым килде. Үгезне суярга җыенганыгызны белгәч тә, атымны ерак юлга әзерләдем. Ә мин әйтергә тиешмен: атыма дүрт аяклылар арасында тиңнәр юк. Төнгә каршы юлга чыктым һәм тиздән сезнең утарга барып җитәрмен дип уйладым. Ул шулай булырга тиеш тә иде: малкаем гадәттәгечә шәп кенә юыртып барды, каршы искән җилне күкрәге белән кисеп кенә төшерде, киң аласларны[2] аяк астына салып, тирән сулы елгаларны йөзеп үтте.

Караңгы төндә шулай очып кына бардык без.

Максатыбызга җитәргә инде ерак та калмаган иде, шул чакта аңлашылмый торган нәрсә булды: атым-канатым алга таба бер адым да атлый алмас дәрәҗәдә арыды.

Минем инде, бу юлы угрылык бәхетемне күрергә язмаган икән, Оруосуннарның байлыгы кулымнан ычкынды, дип, күңелем төште.

Угры авыр сулап куйган, үзен тыңлап торучыларга күз салып алган һәм сүзен дәвам иткән.

– Атымның хәл җыйганын көтеп, шактый озак тордым мин, әмма ул башын да күтәрә алмый иде. Кинәт артымда, әле генә үзем узган юлда, бик елдам тоякларның тупылдавын ишеттем. Ә мин, әйтергә тиешмен, теләсә нинди ераклыктан торып, яхшы атны тояк тавышыннан таныйм. Бу тояклар чакылдавы каты суыкларда боз вата торган үткен сөймән авазына охшаган. Кемнеке соң мондый шәп ат, дип уйладым мин. Мондый ат безнең бөтен тирә-якта юк. Юкса белгән булыр идем.

Артыма борылып карыйм. Ай яктысында шундый яхшы, ачык күренә: кара күләгә булып, бер җайдак якынлаша... Килеп җитә дә сорый:

– Кайсы якка юл тоттың, и адәмчек?

Мин җавап бирдем, ә ул әйтә:

– Син Оруосуннарга – атаклы үгезне урларга барасың, шулаймы? – ди.

Шулчакта уйлап алдым: төнлә йөри икән, бу кеше дә, мөгаен, минем кебек карактыр, ә үз ишеңнән нәрсә яшереп маташасың һәм шуңа турыдан-туры җавап бирдем: әйе, урларга барам, тик менә бәла – атым арыды, бу сәфәрем – тирән карны бушка ерып йөрү белән бер, дидем. Үз нәүбәтемдә мин дә сорадым: кем ул һәм кая юл тота.

– Мин кеше түгел, мин – абаасы[3], – дип җавап бирде җайдак, мин шунда гына аның айлы төндәге карт агач күләгәсенә охшап торганын күреп алдым: ул галәмәт зур, зәңгәрсу-кара төстә иде.

Абаасы үзенең дә Оруосуннарга барганын әйтте.

– Нинди максат белән? – дип, түземсезләнеп сүзен бүлдерәләр аның.

– Мин дә абаасыдан, ник барасың, дип сорадым. Ул миңа шунда әйтә, Оруосун байларның оныгы бар, ул малай, үсеп житкәч, кешеләрнең тулы бер ыруы башында торасы көчле зат булачак. Менә ул, абаасы, янәсе, шул баланы юк итәргә бара. Моңа хәтле, үзенең сөйләвенчә, ул инде ике тапкыр шуны эшләргә җыенган, тик

[1] Олыс – Якутиядәге административ берәмлек, нәсел утары.
[2] Алас – еш кына уртасында күл була торган, урман белән уратып алынган үзәнлек, зур алан.
[3] Абаасы – шайтан.

ике талпынуында да кара нияте барып чыкмаган: байларда бик куәтле шаманнар камлап[4] утырган чак туры килгән, абаасы, аларның күзендәге уттан куркып, буш кул белән әйләнеп кайткан. Иртәгә бу малайга өч яшь тула икән, шуңа күрә, бу төннән дә калмый, аны, һичшиксез, юк итәргә кирәк, ди. Шуларны сөйләгәч, абаасы миңа атыма атланырга һәм юлымда булырга кушты.

– Юлым киселде, – дим моңа, – атым ахыр чиккә җитеп хәлсезләнде.

– Ә синең атың минем көчемне сизгәнгә күрә, аякларын минем тышаулавым аркасында бара алмый торды. Хәзер, тынычлап, юлыңда бул, атың минем шаукымымны бүтән тоймаслык итәрмен.

Чынлап та, ияргә утыру белән, атым элеккечә үк гайрәтлегә әйләнде. Без матур гына юыртып киттек. Барабыз, барабыз, ә шайтан әйтә:

– Синең атың, чынлап та, яхшы бугай. Һәрхәлдә минекеннән начаррак түгел. Шуңа күрә сиңа тәкъдим итәм: әйдә, узышабыз. Оруосун байлар аласының көн як чигендә Бөек кэрэһ[5] басып тора. Менә шул агачка кадәр атларыбызны куыйк. – Мәлгуньнең мондый сүзләреннән соң, аркамда кырмыскалар йөгерешкән сыман булды; узышырга очраклы гына тәкъдим итмәде бит инде бу, һичшиксез, явыз нияте бар. Ул җиңсә, йә мине, йә, ким дигәндә, минем атымны тотып ашар. Иблиснең шөгыле шул лабаса. Аңа сер бирмәскә тырышам:

– Узышып тормыйксана, – дим. – Икебез дә хәтәр эшкә барабыз. Шундый чакта үзара ярышуның бер мәгънәсе дә юк.

– Куркасың, димәк, – дип көлеп җибәрде шайтан, ә көлүе шундый шомлы, җир астыннан чыккан кебек иде.

– Ничек курыкмыйсың инде, – дип җавап бирәм абаасыга, ә үземне бер калтырата, бер кара тиргә батыра, – миңа, кеше затына, синең белән ярышырга мөмкинме соң? Минем атымның яңадан хәлен алу сиңа берни дә тормый.

– Юкны сөйләмә, – ди бу, – гаделлек белән узышабыз.

Шайтанда нинди гаделлек булсын инде? Аңлыйм, мәлгунь мине болай гына тынычлыкта калдырмаячак. Менә бәла! Ярышырга риза булырга туры килә. Әмма үзем уйлыйм: моның аты минекен узса, ул чакта миңа яшәү юк, димәк, әлеге карачкы-тилгән сезнең варисны да, яклаучысыз калган үрдәк баласы кебек, тырнакларына эләктереп китәчәк, аңа берәү дә комачаулык итә алмаячак. Чөнки Оруосуннар нәсел дәвамчысына бу дөньяда яшәү өчен нибары шул төн калганын бер мин генә беләм, тик мин генә аны коткарып кала алам. Ярар, дим абаасыга, ни булса, шул булыр, узышабыз, әйдә...

Угры сөйли, ә үзе күз кырые белән тыңлаучыларны күзәтә һәм барысын да күреп тора: хатын-кызлар, балалар, караңгы почмакларга качып, бер-берсенә сыеналар; әнә бер яшь хатын, Оруосун байның килене булса кирәк, шайтанның уй-ниятен ишеткәч, тыныч кына йоклап яткан тук яңаклы сабыен бишектән ала да күкрәгенә кыса. Хатыннар белән балаларның гына түгел, ирләрнең дә сагаеп калуы күренә.

Шуннан соң угры үзенең хикәятен тагын да илһамланыбрак дәвам итә. Тыңлаучыларга аның тавышы әле куркып пышылдау, әле шомлы һәм дәһшәтле күкрәү булып ишетелгән.

– Менә без абаасы белән икәү калкулыкка менеп бастык, атларыбызны колакка-колак тигезләдек, «һайт»ладык һәм чабып киттек. Мин – угры тормышының тәвәккәл кешесе, хәтәр сукмаклардан йөрергә, хәнҗәр йөзеннән үтәргә аз туры килмәде, әмма беркайчан да үз язмышым өчен бу кадәр куркыныч тойганым юк иде.

Бу – атыма үз тормышымны тапшырган узыш булды.

– Бәхетле аткаем, уздырма, караңгы көчләргә хуҗаңны һәлак итәргә ирек куйма, – дип пышылдыйм аңа.

Кырык чакрымны без янәшә юырттык. Шайтанның чуар каен тузы сыман алмачуар аты ай яктысында күренми дә диярлек, әмма мин юл буе аның кайнар сулышын, йөрәгемә басып барган тоякларын тоеп бардым.

Шул мәлдә үзем өчен үлем яки яшәү сәгате сукканын аңладым һәм, кычкырып: «Бәхетле малкаем, дөньяда бер икәнлегеңне расла!» – дип, өчтән үргән камчымны

[4] Камлау – шаман йолаларын үтәү.
[5] Кэрэһ – шаман агачы.

алып, өч тапкыр атыма суктым. Миңа күкләр бүләк иткән атым-лачыным кырларны яңгыратып кешнәде, җәя кебек киерелде, – аның дүрт йомры тоягы җирдән аерылган кебек тоелды. Ул, күрәсең, шулай булгандыр да әле. Колакларым, очып барган чумгалаклар көтүе чыгарган кебек, гүләү белән тулды, ә юл буендагы агачлар тоташ соры чаршау булып кушылды.

Күпме вакыт шулай чабышканны хәтерләмим, менә без сезнең аласның көн як чигенә, Бөек кэрәһ калкып торган тәшкә атылып килеп җиттек, шул изге агач янынннан очып узганда, алмачуар минем атымның койрык очында иде. Шул чакта шайтанга каерылып карадым да кычкырып җибәрдем: «Мин җиңдем!»

...Тынып калган тыңлаучыларның күкрәгеннән җиңел сулыш ургылып чыккан, киеренке йөзләр йомшак елмаю белән яктырган, хатын-кызлар үзара пышылдаша башлаган, ә ирләрдән кемдер, хәзер менә, казанны кертеп, ит пешерергә салсаң да начар булмас иде, дип әйтеп куйган.

Ит турындагысын угры яхшы ишеткән, шуңа күрә хикәятен тагын да рухланыбрак дәвам иткән.

– Оттырганын күрде дә: «Бәхетең бар икән», – дип әйтте шайтан миңа. Шуңа өстәп: «Син, егет, сыек буынлы булып чыкмадың әле», – дип, мине мактап куйды.

Ә мин үзалдыма уйладым: ашыкма, нәгъләт, вакыты килеп җитәр – мине үтерергә маташканың өчен үч алу җаен кулдан ычкындырмам!

– Йә нәрсә, дускай, эшкә керешәбезме? – дип сорый миннән шайтан, атларыбызны киртәләп алынган печән кибәнегез янына куйгач. – Кайсыннан башлыйбыз: башта үгез урлыйбызмы, әллә, мин малайны кабып йотканчы, син чак кына түзеп торасыңмы?

– Менә нәрсә, кеше ашаучы абаасы, – дип җавап бирәм мин аңа, – башта үз эшеңне башкар, ә үгез миннән беркая да качмас.

– Килештек, – ди бу. – Хәзер без икәү өйгә якынлашабыз, кемнеңдер килүен ишетеп, этләр «һау» күтәрер. Эт өргән тавышка кешеләр чыгар. Әмма мин шулай итәрмен, ничек кенә тырышсалар да, алар безне күрмәс, этләр юкка гына тавыш күтәргән, дип, кире өйгә кереп китәрләр. Шулчак син түбәгә менәрсең, ә мин өйгә керәм. Инде менә колагыңны торгызыбрак тыңла. Мин бала йоклаган бишек янына килермен дә әкрен генә сызгырырмын. Мин сызгырган вакытта, син дә мич морҗасына сызгыр. Шуның белән минем эшем бетәр.

Бу хезмәтең өчен мин сиңа үгезне урларга булышырмын.

Барысы да шайтан әйткәнчә булып чыкты. Без өйгә таба атладык, этләр, аяк тавышын ишетеп, өрә башладылар. Өйдән кешеләр йөгерешеп чыкты, тик этләрнең ник өргәнен берничек тә аңлый алмыйлар: күзләренә без күренмибез бит. Югыйсә, аларның янында ук басып торабыз. Менә бу егет, – угры учактагы пүләнне төзәтеп маташучы, күптән чәче алынмаган батракка төртеп күрсәткән, – миңа бәрелә язды, барыбер күрмәде...

– Кара бу каһәр сукканны! Аңгыра тек аңгыра инде. Бервакытта да бернәрсәнең дә рәтен белеп эшли алмый, – дип, гадәтенчә мыгырдап алган хуҗабикә-кортка.

Егет тын тартмаган, бары тик, гаепле сыман, муен чокырын гына кашып алган.

– Ул аны ничек күрсен инде, шайтан каплап торгач, – дип, батракны баланың анасы яклаган.

– Ну, кешеләр этләрне эт итеп сүктеләр дә үз ятакларына кереп киттеләр. Абаасы тагын күпмедер вакыт барысы да йоклап киткәнне көтеп торды, аннары миңа боерды, ә хәзер түбәгә мен, диде.

Мин түбәгә үрмәләп мендем, морҗага ябыштым һәм аңладым, шайтан барысын да дөрес исәпләгән: кешеләр тирән йокыга талгандыр, инде хәтта мичтәге күмерләр дә суынган диярлек. Ишетәм, шайтан баланың бишеге янына килде, – өйгә ничек кергәндер ул, анысын мин сизми дә калдым, – әкрен генә сызгырды. Ул сызгыруга, бала, куркып, кычкырып куйды, аннары каты итеп төчкерде. Аның төчкергәнен өйдәгеләрнең берсе дә ишетмәде микәнни? Бала төчкергәч, мин морҗадан әйттем: «Исән бул!» – дидем.

Икенче тапкыр шайтан инде учактан сызгырды. Бала уянды, елап җибәрде һәм тагын төчкерде. Мин яңадан әйттем: «Исән бул!» Шайтанның өченче сызгыруы

ишектән килде, аның тавышына бала тәмам уянып төчкергәч, мин инде өченче тапкыр: «Исән бул!» – дип әйттем.

Шайтан өйдән чыкты, мин түбәдән шуып төштем дә аңардан сорыйм:

– Йә, эшләр ничек бара?

– Бик шәп ярдәмчем булып чыктың әле син, – ди абаасы, ачуланып. – Нишләп баланың һәр төчкерүенә «исән бул!» дип әйттең? Кем синнән моны сорады?

– Минем гадәтем шундый бит, – дип җавап бирәм шайтанга, – кем төчкерсә дә, шул сүзләрне әйтәм.

– Ә син беләсеңме? – ди шайтан. – Шул алама гадәтең аркасында, мин бу баланы беркайчан да юк итә алмаячакмын. Минем өч сызгыруыма да син өч тапкыр «исән бул!» дидең һәм шуның белән баладан минем сихеремне читкә алдың...

Өйдә тагын, язгы йомшак җилдә яшь яфраклар шыбырдашкан кебек, җиңел сулыш алу ишетелгән, тыңлаучыларның йөзе яктырган, коткарылган бала анасының күзләре рәхмәт һәм шатлык хисе белән очкынланып киткән, ул бетмәс-төкәнмәс назын салып, нәни улын кочакларга-үбәргә керешкән.

Кулларның түземсез хәрәкәтеннән, кешеләрнең үз-үзләрен киеренке тотышыннан күренгән – барысы да бу гаҗәеп тарихның ни белән беткәнен түземсезләнеп көткән. Бары тик олы һәм кече Оруосуннар гына үзләрен башкача тотканнар. Дикъкать белән тыңлап утырган кечесе күзләрен кыскалаган, аның иреннәрендә әледән-әле җиңелчә елмаю чагылып алган. Өлкән Оруосун, йорт хуҗасы, караңгы чырай белән бөкрәеп утырган, кырыс күзләре авыр маңгае астыннан угрыга текәлгән, хикәятнең башыннан ук карт бер сүз дә дәшмәгән, шуңа күрә бу тамашалар турында аның ни уйлаганы билгесез булган.

Ә угры сүзен дәвам иткән:

– Минем эшем барып чыкмады, – дип әйтте миңа шайтан, – бәлки, син уңарсың. Киттек, хәзер үгез урлыйбыз.

– Ничек аны урлыйсың, – димен, – аны өч йозак астында тоталар икән бит.

– Әй, бу – бик җиңел эш! – дип тынычландырды ул мине. – Мин, бер почмагыннан тотып, абзарны күтәрәм, ә син үгезне алып чыгасың.

Шайтан, чынлап та, шундый зур абзарның бер почмагыннан җиңел генә күтәрде. Тик абзарга кереп, үгезнең муенына бау бәйләргә тотынуыма, шайтан абзарны үз урынына куйды, ә мин дөм караңгыда калдым.

– Син миңа баланың канын эчәргә юри юл куймадың, – диде абаасы ачу белән, – шуңа күрә синең дә юлың уңмас. Шунда утыр, куркып һәм газапланып, хуҗалар чыкканны көт, алар синең колакларыңны йолкып алырлар, ә аркаңны каештан үргән камчы белән кашырлар...

Алга таба ни булганын барыгыз да беләсез. Ә хәзер мин, кулларымны тез өстенә куеп, язмышыма буйсынам, – дигән угры һәм йорт хуҗалары – карт белән карчык алдында баш игән.

Кешеләр хикәятнең дәвамын көткәндәге кебек, тагын күпмедер вакытка өй тынып калган, ә аннары барысы дәррәү кузгалган, җанланып-ярсып сөйләшә башлаган, аларның тавышында явыз рухның чиксез мәкереннән курку һәм угрының тәвәккәллеген хуплау ишетелгән.

– Йәле туктагыз, – дип тыйган батракларны хуҗабикә-карчык. – Сезнең лыгырдашуыгыздан колаклар шаулый. – Аннары кортка йорт хуҗасына таба борылган. – Мин, бу кеше безне зур бәладән коткарган, дип уйлыйм. Тик миңа шунысы гына аңлашылмый: нишләп әле син канатларыңны салындырып утырасың? Тор, изге утка ризык бир, яхшы сүзләреңне әйт. Безгә саклаучы фәрештә булып килгән кешегә хөрмәтеңне белгерт.

Карчыкның сүзләреннән соң, угры күзгә күренеп дәртләнгән: барысы да минемчә бара бит дип уйлаган ул. Хәзер нәкъ менә хуҗаларның кайсына да булса бүләк бирү турында сүз әйтергә вакыт җитеп киләдер.

– Мал-туар һәм безнең барлык байлык – нәрсә ул, – дип әкрен генә, ярым төш аралаш сыман әйткән баланың анасы. – Минем кояшкаем гына исән-имин була күрсен. Калган барысы да – табыла торган мал.

– Шулай, шулай, – дип килененең сүзенә кушылган каенана һәм башын еш-еш чайкап куйган. – Ул бит нәселебезнең бердәнбер дәвамчысы, безнең борынгы нигезнең варисы... Менә без чак кына аны кулдан ычкындырмадык, бәхеткә, якында гына шушы кеше булып чыккан, – хуҗабикә кул ишарәсе белән угрыга күрсәткән. – Йәле, егетләр-кызлар, симезрәк итне алып керегез дә казанны ут өстенә куегыз.

Шул мәлдә карт бай да аркасын турайткан һәм башын күтәргән.

– Ашыкмагыз әле, – дип, батракларны туктаткан ул, – ә, бәлки, шайтан, җирәнгеч явыз зат, әле беркая да китмәгәндер, шул тирәдә генә йөридер. Кодрәтле шаманны чакырып, камлавын сорарга түгелме икән безгә: аның барысын да күрә торган күзләреннән бер шайтан да качып кала алмас.

– Менә бу – дөрес, – дип сүз кыстырган яшь Оруосун һәм тагын, ярым елмаю белән, күзләрен сәер кыскалап, угрыга караган. – Адәм баласы явыз рухның сүзләренә ышанмаска тиеш. Шайтан, киттем, дип әйтергә мөмкин, тик үзе, ерак та түгел кайдадыр яшеренеп, сәгате сукканны көтеп ятарга мөмкин.

Учак янында җылы булса да, угрының маңгаена салкын тир бәреп чыккан. Яшь Оруосунның елмаюы аңа хәзер нindидер аерым мәгънә, хәйлә-мәкер белән тулган кебек күренгән. Шаманны алып килерләр, ә тегесе, тотар да, бөтен сөйләгәннәрнең ялган икәнен ачып бирер, ул чакта моннан тере килеш чыгармын, димә! Әмма угры үзенең шикләнүләрен тыштан сиздермәгән.

Таң беленү белән, карт бай кушуы буенча, елгыр бер егет, җиңел чанага утырган да шаман артыннан киткән. Икенче батрак угрының атын, зур гына кочак печән салып, аранга керткән. Угрының үзен исә табын янына утырткannар һәм симез ит белән сыйлый башлаганнар. Тик менә бәла: угры күптән ашамаган булса да, тамагыннан ризык үтмәгән.

Шулчак яшь Оруосун мыек астыннан елмаеп пышылдаган:

– Күрәм, дускай, син, нишләптер, теләр-теләмәс кенә ашыйсың. Әллә ит ошамыймы? Тиздән бөек аксакал килер һәм барысына да ачыклык кертер. Ә син курыкма, сиңа куркасы юк бит, барысы да яхшы булыр. – Үзе тагын елмайган.

Угры берничә тапкыр өйдән чыккан һәм аты торган аран ягына күңелсезләнеп кенә карап алгалаган. Их, менә хәзер, очып китәргә торган атының җылы аркасына сикереп менеп, «һайт!» дип бер кычкырып җибәргәч, колагында җил сызгырганын ишетү өчен күпне бирер иде ул! Һичкем ул чагында аны куып тота алмас иде. Әмма аран ягына бер адым да атлап булмый: әзмәвердәй ике егет, күләгә сыман, аның артыннан ияргән.

Көн урталарына таба, атаклы, халык арасында зур хөрмәткә ия шаманны алырга җибәрелгән егет кайткан, төрле җәнлек тиреләренә төренгән, бөкрәйгән кечкенә картны, күтәреп, сак кына чанадан төшергән. Бусагадан атлап керү белән, шаман, иске танышын күргәндәй, керфек тә какмый торган күзләрен үгез урларга килгән бәндәнең йөзенә текәгән. Бөтенесен үтәли күрә торган бу үткен караш угрыга аның караңгы күңеленең иң тирән төпкелләренә төшеп җиткән кебек тоелган.

– Менә, хөрмәтлем, – дигән өй хуҗасы, дәрәҗәле кунак өс киемен салгач, – без сине бик җитди һәм гади булмаган эш белән борчыдык. Хәер, син инде, атаклы күрәзәче, без сине ник дәшкәнне үзең дә беләсеңдер?

Шаман, учак алдына куелган урындыкка иплэп кенә утырганнан соң, килешеп, вәкарь белән генә баш кагып куйган.

– Бәлки, юлдан соң ял иткәч һәм җылынгач, син безгә камларсың? Әйт әле, бу кешенең хикәяте ялган түгелме? – дип, угрыга күрсәткән карт Оруосун.– Әгәр дөресен сөйләгән булса, аның белән бергә килгән дәһшәтле явыз рухның нинди мәкерле ниятләре булганын, хәзер ул нәгъләтнең кая киткәнен әйтче.

Шаман җавап бирергә ашыкмаган, дәшми-тынмый, төребкәсен тартуын гына белгән. Төребкәсе сүнгәч, ул авыр күз кабакларын күтәргән дә хуҗага караган.

– Мин хөрмәтле кешенең үтенечен кабул итеп килдем һәм сиңа булышырга тырышырмын. Астыма ак мендәр җәяргә, чанадан изге киемнәремне алып керергә куш.

Батрак егет шаманның шылтыравыклар таккан киемен, шактый кыршылган шөлдерле барабанын алып кергән дә аларны, кипшенергә дип, утка якынрак куйган.

Угры пошаманга төшкән. Хәзер аның бөтен язмышы шаман әйтәсе сүзләргә бәйле.

Ишеткәннәрегез – ялган, ди икән, бәладән котылу чарасы юк. Шул ук вакытта угры үз-үзен тынычландырган: хөрмәтле аксакал, караңгы көчләрнең катнашыннан башка, бикле ишектән үтеп, угрының абзарга керә алганын ничек аңлатыр икән? Күзләре никадәр үткен булса да, ул беркем дә күрмәгәнне белми бит инде. Ә беркемнең дә күрмәгәнлеге – бусы чынлап та хак: угры, үгезне караучы батрак егет кибәннән печән алырга барып килгән арада, этләргә мул итеп ит кисәкләре ташлаган да, елт итеп, абзар эченә чумган. Этләр итне ашап бетергәч кенә өрә башлаганнар, әмма ул вакытта инде көне буе эшләп арыган батрак өйгә кереп киткән һәм сәкесенә йокларга ауган була. Шуларны уйлап, угрының күңеле бераз күтәрелгән, шаманга төбәбрәк караган, хәтта, аңа ниндидер ишарә ясаган кебек, бер күзе дерт итеп кысылып алган. Шаманның йөзенә теләктәшлек төсе чыгуын күреп, карак бөтенләй дәртләнеп киткән.

Изге кунак туйганчы ашаган-эчкән, учак янында кипшенгән шөлдерле барабанын алган. Ак мендәргә утырып, үзалдына нәрсәдер мыгырдаган, аннары җырлап җибәргән, ә шөлдерле барабан, саңгырау тавыш белән, аның сүзләренә кушылган. Тыңлаучылар, кодрәтле шаман янында тәбәнәгрәк, тыйнаграк булырга тырышкандай, дәррәү тынып калганнар. Инде угры көнләшеп үк куйган: шаман үзенә игътибарны аңардан күпкә тизрәк, остарак яулап алган, бу кешеләргә ныграк, тирәнрәк курку салган бит.

Җырлап һәм шөлдерле барабанын кагып бетергәч, шаман башын күтәргән дә әйткән:

– Сезгә төнгә каршы явыз көч – кыя таулар һәм Боз океаны утраулары рухы килгән. Аның нияте балагызны харап итү булган, әмма бу эше барып чыкмагач, ул кире үзенең шайтани дөньясына әйләнеп кайткан. Хәзерге мәлдә ул әнә кыялардагы мәгарәсенә якынлашып килә. Абаасы бик ачулы, балагызны юк итүдә өченче тапкыр талпынып та уңышка ирешә алмаганына аның бик нык эче поша. Әйе, үз исемнәрен данга күмгән Оруосуннарга ул моңарчы инде ике тапкыр килгән булган, тик икесендә дә буш кул белән кайтып киткән. Беренче тапкыр ул өч ел элек, мин сездә камлаган, уңыш бүләк итүче Айыысыт алиһәгә рәхмәтләр укыган вакытка туры килгән, шуңа күрә өйгә керергә батырчылык итмәгән. Дәһшәтле абаасы үткән елны да явыз ниятен башкарып чыгарга омтылыш ясаган, әмма минем карашымның уты аны куркыткан: ул кичтә сездән ерак түгел генә күршеләрегездә карт хатынның чирен куып утырган идем. Өченче тапкырында исә сезнең балагызны менә бу изге адәм коткарып калган.

Угры иңнәрен турайткан, өйдәгеләрнең барысына да горур караш ташлаган. Ә шаман дәвам иткән:

– Ул кыя таулар һәм Боз океаны утраулары рухының хәзер ни уйлаганын да беләм. Бүтән беркайчан да монда әйләнеп кайтмам, дип ант эчә, мәлгунь. Әнә очсыз-кырыйсыз бозлык уртасындагы кыя таулардан аның тавышы ишетелә: «Мин кире әйләнеп кайтмаска киттем. Әгәр артыма борылып карасам, минем чукмар сөягем уалсын, җилкә сөякләрем шартлап сынсын».

Угры шаманның хәйләкәрлегенә, елгырлыгына, җилнең кайдан исүен шулкадәр тиз сизеп алуына тагын бер кат шаккаткан: бу картлачның сүзләренчә, алар икесе дә – нәсел дәвамчысын коткарып калучылар булып чыга.

Торак эчендә шатланып тамак кырулар, җиңел сулыш алулар шыбырдашып узган. Бу мәлдә Оруосуннарга ничек сөенмәскә ди, – аларның нәсел учагы мәңге сүнмәячәк, борынгы нигезләре алга таба да сумалалы карагач төбе кебек нык торачак икән бит!

– Безнең малаебыз, әфәндебез, һәрвакыт безнең белән булсын. Явыз рух мәкереннән котылуы хөрмәтенә, аны саклап калучыларга рәхмәт укый-укый, әйдәгез, үгезне хәзер үк суйыйк, – дип әйткән хуҗабикә-кортка, ә хуҗа-карт, аның сүзләре белән килешеп, вәкарь белән генә баш кагып куйган.

Тугыз ел симерткән үгезнең нәкъ ярты түшен Оруосуннар, тирән ихтирам йөзеннән, угрыга биргәннәр, ә калган өлеше тулысынча диярлек шаманга тигән. Хуҗалардан хөрмәт күргән угры инде китәргә торганда, аның янына яшь Оруосун килгән һәм йөзенә элеккечә үксерле елмаю чыгарып сораган:

– Ә син олонхо[6] чыгара белмисеңме? Бәлки, син олонхосуттыр[7]?

[6] Олонхо – якут дастаны.
[7] Олонхосут – олонхоны башкаручы, җырау.

– Юк-юк, – дип ашыгып әйткән угры. – Мин – бары тик олыс карагы гына. Ә син нигә сорадың?

– Болай, беләсем килеп, – дигән яшь бай, тагын бер елмайган һәм угрыга тар учын сузган.

Угрыны шаман да озатышкан. Әмма алар үзара сүз алышмаганнар, бары тик бер-берсенә карап елмайганнар гына. Шулай саубуллашканнар.

Шаман угры белән берни турында да сөйләшмәгән, әмма кайбер иртәләрне, һич уйламаганда, ул үзенең бусагасы алдында яңа суйган ит таба башлаган. Карчыгы мондый табышка һәрвакыт аптырап калган, ә шаман ачулана икән:

– Син аңламыйсыңмыни, болар – минем юмарт улымның бүләкләре. Мин, бөек шаман, мондый бүләккә лаек түгелмени?

## Җыр да җанны саклап кала икән

Халыктан чыккан җыручылар элекке заманнарда күчмә тормыш алып барганнар – аластан аласка күчеп йөргәннәр, шул рәвешле үзләренә ипи-тозлык хезмәт хакы тапканнар. Җыручыны һәркайда күптән көтелгән бәйрәм кебек шатланып каршы алганнар. Ул, чыннан да, халыкның күңелен ачкан, кайгы-хәсрәтен тараткан. Җыручы килеп туктаган бәхетле кешенең өенә бизәнгән-ясанган якын һәм ерак күршеләр җыелган; тантана төсе булып кечкенә учакта иң коры утын гына дөрләгән, табаларда тау-тау майлы коймак чыжлап утырган, казаннарда иң симез ит кайнаган. Ачык чырай, такта чәй белән кабул итүләрен тоеп, җыручының күңеле канатланган, хуҗаларга, аларның кунакларына җыры белән ул бетмәс-төкәнмәс рәхмәтен җиткергән. Ә кайчакта аны тыелгысыз шундый бер дәрт биләп алгалаган: җыручының тавышыннан диварлар калтыранган, әлегәчә тик кенә торган савыт-саба шылтырый башлаган, күктә яшәүчеләрнең исләре китеп хәйран калган тавышлары, сокланулы аһлары учак морҗасы аша ишетелер сыман тоелган.

Җыручылар шулай яшәгәннәр-күченгәннәр, кайчакта моңарчы таныш булмаган, кыргый төбәкләргә дә барып чыккалаганнар, анда исә әлеге бахырларны, хуҗаларның сокланып каршы алуы урынына, хәтәр сынаулар да көткән.

Бервакыт менә шундый йөремсәк җыручыларның берсе кояш батканда гына үзенә таныш түгел утарга килеп җитә. Утарны күрү белән, куркудан, аты пошкырса да, җыручы моңа һичнинди игътибар бирми, матур итеп сырлап бизәлгән баганага малкаен бәйләп, йөрәгеннән тулып ашкан сөенеч белән иркен җылы тирмә бусагасыннан атлый. Анда учак дөрләп яна, шуңа күрә якты, җылы була, әмма бер адәм заты күренми. Җыручы, хуҗалар абзарга сыерларын ашатырга һәм саварга чыкканнардыр дип уйлый, тыныч кына чишенә дә ут янына җылынырга утыра.

Аны әкренләп йокы баса, өйгә берәү дә кайтып кермәгәч, җыручы, әлбәттә, күңелсезләнә, ялыктыргыч-зарыктыргыч көтеп торуыннан бизәр өчен, учлары белән яңагына таянып, әкрен генә җыр суза башлый. Шаман озак камламый торса, үзендәниндидер тынычсызлык сизә, авырый, диләр бит. Җыручы да шулай – озак дәшми тора алмый, җыр сузып җибәрә. Ул инде ут янында җылынган, аның җаны рәхәтләнеп ойый, шуңа күрә беренче җыры дә яшь атның җирән ялына охшаган күңелле ут яши торган уйнак учак турында булуы бик табигый. Җыр учак иясен – утны саклаучы рухны данлый, аны иң ягымлы, ихтирамлы сүзләр белән илһамланып мактый.

Шулчак кинәт учак чатыр-чотыр итә башлый, – әйтерсең лә пүләннәрдән кызган күмерләр оча. Әмма карап торышка ут тигез, тыныч яна. Җыручы моның кадәр гадәти булмаган чатырдауга гаҗәпсенә, хәтта, бу юкка гына түгелдер, дип уйлап куя, шулай да сер бирми, җырын тыныч кына дәвам итә. Ә инде егет ут иясен атасының атасы дип атагач һәм: «Мине дикъкать белән тыңла да минем ягыма күз сал», дигән сүзләрне җырлагач, учак янә шарт-шорт итә, бу юлы инде ул тагын да катырак була.

Шунда җыручы аңлап ала – учактагы чатырдау очраклы гына булмаган, аның, һичшиксез, берәр мәгънәсе бардыр. Бер җырын җырлап бетерүгә, ул икенчесен башлый, үзе исә күзен уттан алмый. Ул болай дип җырлый:

*Урман, картаеп, агачлары ава-сирәкләнә торган,*
*Саф сулы елгалар корылыктан сусап кибә торган,*
*Көзендә үләннәр саргаеп корый-шиңә торган,*
*Таң күзендә салкын чыклар тибә торган*
*Гүзәл Урта Дөньяда*
*Яшәгән-булган, ди, сөлек кебек бер егет.*
*Табаннары белән үбеп,*
*Ул аңа җиңел генә кагылган,*
*Ягымлы карашы белән йөрәкләргә ягылган.*
*Гомере буе көчен саклап калыр өчен,*
*Кеше булып атала алган иргә*
*Кайчак тал чыбыгыдай үрелергә,*
*Кайчак тимер сөймәндәй үткенләнергә туры килгән.*

Шуннан соң учакта яңадан колак тондыргыч шартлау ишетелә. Яна торган пүләннәр кинәт таралып китә дә алар арасыннан кызыл чырайлы, утлы-җирән чәчле, комач тузгак сакаллы баш күренә һәм утлы күмер кебек күзләрен җыручыга теки. Гаҗәпләнүдән, куркудан егет коелып төшә, авызын ачып өнсез кала. Учактагы утлы кисәүбаш исә күкләр күкрәтеп кычкыра:

– Ай-яй, таң калырлык тавышлы бу уранхай[8] безгә кайдан килде икән?!

Утлы чырай, көтмәгәндә пәйда булган кебек, көтмәгәндә юкка да чыга, ә учакта, элеккечә тигез гүләп, гадәти коры утыннар яна. Җыручы, көтелмәгән очрашудан баягыча шүрләп калса да, аңа әле генә Ут Рухы Быржа Бытык үзе күренгәнен төшенә.

Егетне шәп тавышы өчен һәрвакыт мактаганнар, ул инде мондый юмарт мактауларга күнеккән, әмма аның бу кадәр шатланганы әле беркайчан да булмаган – бар кешенең котын алган Ут Иясе үзе соклануын белдергәч, җыручының күңеле күккә аша, ул, үзендә илаһи көч тоеп, дөньяны яңгыратып, тагын бер җыр суза.

Җыр тынуга, учакта нәрсәдер шарт та шорт килә, шул арада яңадан утлы чырай күренә, күмер-күзләре белән егеткә хуплап карый һәм:

– Гаҗәеп тавышлы уранхай-җыручы, син кая килеп эләккәнеңне беләсеңме соң? – дип сорый.

Бу юлы җыручы Ут Иясенең туп-туры үзенә эндәшүеннән каушамый, күптәнге танышы белән сөйләшкәндәй җавап бирә:

– Кайдан белим? Белмим.

– Шул-шул, белмәвең күренеп тора. Ә син тирә-юньдәге шактый адәмнең башына җиткән убыр-дэрэтик өненә килеп кергәнсең.

Җыручы, дэрэтиктан аңа рәхим-шәфкать булмасын аңлап, бик курка һәм, тормышын саклап калырга соңгы өмет белән, Ут Иясенә ялварып дәшә:

– Әфәндем минем, атам һәм атамның атасы! Ничек исән калыйм – киңәшеңне бир! Минем өчен Кояшка һәм Айга әйлән. Син бит ул озын кышларда кешеләрне зәмһәрир суыклардан коткарасың, якутлар ыруын яман күзләрдән, хәтәр хәлләрдән яклыйсың. Халкыбыз бик борынгы заманнардан алып бүгенге көнгәчә синең сулышың белән җылытылганга гына исән бит. Бу юлы да ялгыз уранхайга ярдәм итче, җеннәр нәселеннән булган каһәр суккыры шайтан токымына улыңны харап итәргә бирмә.

Җыручы учакка туп-туры карап шулай дигән, ә үзе эченнән калтырый икән: ул бит теләсә кем белән түгел, галиҗәнап Ут Иясе белән сөйләшә!

Ут Рухы тыңлый-тыңлый да, зәңгәр ут агымына җилле сулышын өреп әйтә:

– Гаҗәеп тавышлы уранхай! Тавышың, җырларың өчен мин, мөгаен, сине коткарырлык киңәш бирермен. Дикъкать белән тыңла һәм исеңдә калдыр. Дэрэтик кайткач, – ә ул бик тиздән кайтачак, – бөтен кыюлыгыңны, тапкырлыгыңны, тел тегермәнеңне эшкә җик, әмма дэрэтикны алдый ал. Кыска гына вакытка булса да ишегалдына чык. Шуны булдыра алмасаң – сине әҗәлең көтә. Әгәр инде чыксаң, чанаңда яткан спиртны алып кер дә учакка сип. Аннары ни булганын күрерсең.

– Алайса, мин спиртка хәзер үк йөгерәм, – дип кычкыра җыручы.

[8] Уранхай – якутларның борынгы үзатамасы.

– Соң инде, – ди Ут Иясе һәм күздән югала.

Шул ук мизгелдә дөбердәп ишек ачылып китә, өйгә тимер тешле кап-кара убырлы ишелеп керә.

– Хорр! Хорр! – дип ырылдый дэрэтик. – Хуп! Хуп бит, әй! Миңа кунакка уранхай-якут килеп чыккан. Тозакларым әлегәчә буш тормаган иде, бүген дә мине күчтәнәчсез калдырмаганнар. Мин шәп аучы шул!

Җыручының, моны күреп, бер дә исе китми.

– Җылы торакка юлыгуыма мин дә бик шат.

Убырның әле беркайчан да үзенең корбаныннан мондый сүз ишеткәне булмый, шуңа күрә ул чиксез гаҗәпләнә.

– Хорр! Хорр! Син хәтта шат кебек, ә?!

– Ничек шатланмыйсың, ди? Тышта шундый суык, ә мин үземә бөтенләй таныш түгел җирләрдә җылыга килеп юлыктым. Юлчы өчен уңыш түгелмени бу?

– Уңыш? – дип кычкырып көлә дэрэтик, ботларын чабып. Әмма шунда ук кашларын җыера, йөзе караңгылана. – Менә нәрсә, уранхай! Үзеңне кулга ал һәм ир-егет булып кал. Мин хәзер синең яшь, кайнар каныңны эчәм дә арык тәнеңне кабымлык итеп йотам.

Җыручы бу юлы да бернинди куркуын сиздермәгән, әле убырга бармак янап әйтә:

– Син, шайтан алгыры, башта, әдәп йөзеннән, мине табын янына утыртып бер сыйлар идең. Чакырылмаган булсам да, мин бит – синең кунагың!

Дэрэтик, кеше болай да миннән беркая китә алмас, дип уйлап, җиңел генә ризалаша.

– Йә, синеңчә булсын, – ди ул һәм, коточкыч зур кара күләгә булып, торакның сул ягына кереп китә, шунда ук өстәлгә төрле-төрле нигъмәтләр алып чыгып тезә.

Җыручы инде табынга утырырга теләгән кебек була, ләкин, кинәт кенә нәрсәдер исенә төшкәндәй, сикереп тора:

– Бу – минем соңгы туй, шулай булгач, инде туйганчы ашарга тырышырмын. Минем дә чанада тәмле әйберләрем бар. Бәлки, алып керергәдер, ә? Икәү бергә сыйланыр идек.

– Алып кер, әйдә, – дип баш кага убыр, шулай да кисәтеп куюны кирәк таба: – Качарга уйлама, үзеңне һәм атыңны азаплама. Мин алас уртасыннан очып үтүче көртлекне, урманга хәтле очып барырга бирмичә, сузылып кына алам.

– Нәрсәгә моны сөйләп торасың? Мин кая, кемгә килеп юлыкканымны аңламыйммыни?

Бу сүзләр убырның күңеленә хуш килә, егетне:

– Ярар, бар-бар, – дип ашыктыра.

Җыручы чанасындагы күн капчыктан ике шешә спирт ала. Өйгә керү белән, учакка якынрак килә һәм спиртны җылыткан кыяфәт ясый. Хәлиткеч мизгел җиткәч, җыручы бер шешәне икенчесенә бәреп вата да утка ташлап кычкыра:

– Бырджа Бытык, бабакаем, мин сине сыйлыйм, елмаеп кабул ит!

Учактан дәррәү «ух!» иткән тавыш килә, учакның корымланган авызыннан кибән хәтле зур ялкын, чыгып, убырны әйләндереп ала. Дэрэтикның коточарлык үкерүе өйне дер селкетә, аннары төтен һәм ялкын эчендә барысы да юкка чыга.

Җыручы һушына килгәндә, үзенең ярым җимерек, салкыннан бозланып каткан, ишеге каерылган, тәрәзә уемы буш тирмәдә басып торганын күрә. Кичергәннәреннән тетрәнеп, ул купшы баганага түгел, ә менә-менә аварга торган черек казыкка бәйләнгән аты янына чыга да бу хәтәр урыннан тиз генә тая.

Менә шулай җыр адәм баласын үлемнән коткарып калган.

*Якут теленнән* **Мөдәррис ВӘЛИЕВ** *тәрҗемәсе.*

# ГАФУР КОЛӘХМӘТОВКА ИКЕ ТӨРЛЕ КАРАШ

## ГАЗИЗ ГОБӘЙДУЛЛИН ҺӘМ ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫҢ МАТБУГАТТАГЫ ЧЫГЫШЛАРЫ УҢАЕ БЕЛӘН

Галимҗан Ибраһимовның инкыйлабтан соңгы чынбарлыкта суллар тарафын һич каршылыксыз кабул итүе – билгеле факт. Бу аның каләм әһелләрен сыйнфый чыгышлары ягыннан төрле катламнарга аеруы һәм аларның арасын үзара якынайту мөмкин түгеллегенә ышануында да күренә. Җитешле тормышта яшәп күнеккән кешенең яңа шартларга бәрабәр каләм тибрәтү хокукын ул еш кына кире кагарга да мөмкин. Бу аның Газиз Гобәйдуллин тарафыннан язып бастырылган «Гафур турында истәлекләрем» дип исемләнгән язмаларга булган мөнәсәбәтендә бөтен ачыклыгы белән күренә *(Яңалиф. – 1930. – №6. – Б.49-61).*

Газиз – Салих исемле Казан сәүдәгәре малае. Ул үз тырышлыгы белән Казан университетында хокук белгечлеге алган, М.Вахитов, Ф.Әмирханнар белән яшьләрнең яшерен оешкан «Шимбә» түгәрәгендә аралашкан. «Әл-ислах» газетасы тирәсендә аралашып йөргәндә, мәктәп мөгаллиме һәм драматург Гафур Коләхмәтов белән танышкан, Троицкига укытырга киткәнче, аның белән дуслашып яшәгән. Газиз хәтта Гафурның сеңлесе Суфияга гыйшык та тота. Әтисе бу кызга өйләнергә рөхсәт итмәгәч, соңыннанрак, булачак хатыны Рабига Казакова белән танышуында һәм аңа өйләнүендә дә Гафурның йогынтысы була. Менә шуңа күрә, егерменче еллар уртасында Бакуга күчеп киткәч, Газиз дустына мөнәсәбәтле хатирәләрне күңелендә яңарта һәм, аларны бер рәвешкә китереп, алдарак искә алынган хатирәләрен бастыра. Бу язмаларны укыган кеше Г.Коләхмәтовның ун еллык гомерен шактый эзлекле итеп күздән кичерә, аны шәхес буларак бәяләү мөмкинлеге ала.

Шунысы мөһим: Г.Гобәйдуллин үзенең дусты Гафурны идеаллаштырмыйча, бизәмичә-матурламыйча, мөмкин кадәр булганынча сурәтли. Дөресрәге, аны үзе белгән кадәр генә тасвирлый, тулысынча белүгә дәгъва кылмаганы сизелеп тора. Истәлекнең икенче бүлегенең «Гафурны мин беләм шикелле», дип башлануы да очраклы түгел. Чөнки кешене белеп бетерү мөмкинме?! Г.Гобәйдуллин болай дәвам иттерә: «Бу бик серле кеше, серен беркемгә дә чишми торган адәм иде. Гафурның сәяси, иҗтимагый, фәнни фикерләрен белергә мөмкин, әмма аның үз тормышындагы фикер һәм тойгыларын белү ансат эш түгел». Шуңа карамастан, Г.Гобәйдуллин менә болай расларга җөрьәт итә: «Шулай да мин әйтә алам: аны бүген минем хәтле күп белгән бар микән?»


Иң әүвәл ул үзләренең беренче очрашуларын тәфсилләп сөйли. «Әле бу заман «Ислах»ның Фатих (Фатих Әмирхан. – *Ф.Г.*) кулындагы чагы иде бугай. Бу тирәдә җыела торган яшьләрдә 1905 елның тәэсире бетеп җитмәгән. Ләкин боларның эчендә бер төркем халык инде бөтенләй җәмәгать эшләреннән бизгән. Бәгъзе вакытта сыйныфны, милләтне, җәмәгатьне, партияләрне, революцияне, сәясәтне, һәрнәрсәне,



*Галимҗан Ибраһимов*



*Гафур Коләхмәтов*



*Фәхрелислам Агиев*



*Газиз Гобәйдуллин*

һәрбер кешене сүгәләр... «Ислах» янына Фатих заманның мәгълүм шагыйрьләрен җыя алган». Мәсәлән, ул Г.Тукай белән С.Рәмиевнең биредә үз кешеләр булуы, бер-берсенә җылы мөнәсәбәтләре хакында бик матур итеп телгә ала. Г.Гобәйдуллин әлеге истәлекләренең герое Гафур Коләхмәтов белән дә шушында очрашкан. «Менә көннәрдән бер көн, май аеның башларында иде бугай, мин «Ислах» идарәсенә кердем. Гадәттәгечә, Фатих Әмирхан янына килеп утырдым. Кәбир Бәкер беләнме шунда Фатих бик гайрәтләнеп әллә нәрсә турында сөйләшә иде. Дума чакырылуы, куылуы хакында иде бугай.

Озын, кара йөзле, кулына таяк тоткан, пальтосын култыгына аскан, аксыл косоворотканы, кара ефәк зинар белән бәйләп, өстеннән иске генә, әмма бик чистарткан пиджак кигән бер кеше, ачык тәрәзә янына килеп, бик ачык йөз белән:

– Исәнме, Фатих? – диде.

Шул вакытта Фатих:

– Менә таныш булыгыз, безнең инде бу социал-демократларыбыздан Гафур Коләхмәтов! – дип күрештерде. Менә шунда бу кеше белән таныш булып киттек. Бу кеше минем күңелемә бик ошады. Укымышлы булганы да күренә. Без сөйләшеп киттек; мин моны чәй эчәргә алып кердем; шул көнне үк мин бу кеше белән циркка киттем. Шуннан соң бер җомга көн – Хөсәен Ямашевларга, икенчесендә миңа килә һәм кунып каладыр иде. Шул рәвешчә, мин бу кеше белән 1916 елда мөгаллим булып Троицкига киткәнгә кадәр аерылмадым. Бу кеше Габделгафур Йосыф улы Коләхмәтов иде».

Шуннан соң Г.Гобәйдуллин «бу кеше», ягъни Гафурның нәсел-нәсәбе белән таныштыра. Ата-анасы вафат булгач, яшь туганнарының аның тәрбиясендә калганлыкларын әйтә. Пороховойда мөгаллимлектән алган акчасына барысын да тәрбияләп торырга тырышуын, туган җанлы булуын искәртә. Өендә җиһазлары бик ярлы булса да, китаплары күп булуын тасвирлый.

Без бу язмада Г.Гобәйдуллинның үзенең дә эчке дөньясын, омтылышларын, аңа заман ясаган тәэсирне күрәбез. Ул, ару тормышлы гаиләдә үссә дә, Х.Ямашев, Г.Коләхмәтов, Ф.Әмирханнарга тартыла. Аларның үзеннән өлкәнрәк булуы да комачаулык итми. Дөньяны, анда бара торган вакыйгаларны аңларга тырыша. Язмадан күренгәнчә, Гафур үзенең дуслары Хөсәен белән Газизләргә арадашчы була. Газиз сорагач, Х.Ямашевтан үзендә булмаган әдәбиятны алып кайтып бирә. Газиз үзе дә Гафурга кирәкле китапларны табарга булыша. Әйтик, Г.Коләхмәтов «Әбү Җаһил» әсәрен иҗат итәргә ниятләгәч, дин тарихын төплерәк белсен өчен, Газиз аңа «Рәбгузи», «Алтын бармак» исемле китапларны, ә инде «Тарих сәхифәләре» дип аталган хезмәтне язганда, кирәк булырдай башка чыганакларны китерә. Моның белән горурлануын да яшерми, «шуларны укып язды ул», дип, кинәнеп әйтеп тә куя.

Әлеге язмада Г.Гобәйдуллин замана, шул чор кешеләре хакында шактый мәгълүматлар бирсә дә, аның төп игътибары – Гафурда. Ул аның шәхес буларак эволюциясен ача. 1905-1907 елларда, ягъни инкыйлабый хәрәкәтләр нык күтәрелгән

вакытта, Гафур – кулына револьвер тоткан көрәшче, коллективның көчен үзендә тойган шәхес. Инкыйлаб җиңелеп, хөкүмәт тарафдарлары өстенлек алгач, сабырланып калган бер зыялы. Алай гына да түгел, аның күзәтүләренә караганда, «буржулаша да төшкән, либераль байлар янында йөрергә, яхшы киемнәр кияргә ярата иде». Ләкин асылда ул – элеккеге Гафур. Тышкы яктан күпмедер үзгәргән кебек тоелса да, «язган нәрсәләре революция рухында буладыр иде», диюе шуны аңлата. Шуңа күрә Г.Гобәйдуллин өстен катлауларның аңа булган мөнәсәбәтен дә белдереп куя: «Тормышта никадәр буржуалашмасын, аны мулла-мунтагай яратмый, бер ят кеше итеп карыйдыр иде». Аның каравы ул үзе дә аларны өнәмәгән.

Язмадан Гафурның сәламәтлеге елдан-ел катлаулана баруы да күренә. «Соңгы елларда, – ди язма авторы, – Гафурның чахоткасы көчәйгән, шуның белән бергә рухы сүнгән, җәмәгать эшләренә әһәмияте беткән». Моңа тагын бер сәбәпне күрсәтә: «Гафурның рухы Хөсәен үлгәч сүнде». Димәк, бу – 1912 ел. Х.Ямашевның вафаты Гафурга үз гомеренең дә санаулы булуын, зур эшләр майтару өчен, көченең көннән-көн кими баруын искәртүче сигнал буларак та кабул ителә. Г.Гобәйдуллин, сизгер һәм зыялы кеше буларак, моны яхшы күреп тора. Ул этисеннән дустын Кырымга җибәреп дәвалау өчен ярдәм сорый, бу эш тормышка да ашырыла. Ләкин авыруы инде дәвалаудан узган дәрәҗәдә була, шуңа күрә әллә ни файдасы да тими. Г.Гобәйдуллин менә шулар турында да яза. Күрәбез, язма авторы үзалдына Г.Коләхмәтовны пьедесталга бастырып тасвирлау бурычын куймаган, аны җанлы кеше, катлаулы язмышлы шәхес итеп күрсәтү максатында, булганынча тасвирлаган. Шулай әйтергә яраса, үзеннән советчыл рәсми матбугат органнары көткәнчә түгел, бәлки хакыйкатькә тугры калып эш итә.

Г.Ибраһимовка әлеге язма нәкъ шуның өчен ошамый да инде. Классик әдибебез, билгеле булганча, бу елларда Ялтада яши. Үпкә авыруы аны Татарстаннан – җанлы әдәби мохиттән – читтә торырга мәҗбүр итә. Совет хакимияте еллары әдәбият тарихында әйтелеп киленгәнчә, бездә социалистик реализм иҗат методының беренче яралгыларын биргән Г.Коләхмәтов шәхесенең укучыларга бу рәвешле тәкъдим ителүе аңа бөтенләй ошамый, ул ел буе шуңа борчыла. Һәм, ниһаять, бер ел үткәч, шул ук «Яңалиф» журналында *(1931. – №5/6. – Б.96-103)* аның «Әдәби тарихыбызның кадерле битләре болай тапталмасын иде» исемле репликасы (мөнәсәбәте) игълан ителә. Шактый күләмле бу язма тулысы белән «өстен катлау вәкиле» Г.Гобәйдуллинның үзен, Гафур Коләхмәтов исемен файдаланып, яңа шартларга җайлашырга тырышучы буларак күрсәтүгә багышланган. Алай гына да түгел, биредә тагын бер «фаш итү» объекты бар, ул да булса – Фәхрелислам Агиев. Ул – татар мәдәнияте тарихында билгеле шәхес, язучы, журналист. Бигрәк тә 1913-1914 елларда балалар өчен «Ак юл» дигән журналның нашире һәм редакторы буларак та танылa. Гафурның сеңлесе Суфияның ире дә. Билгеле булганча, Гафур 1918 елда үлеп китә. Аның язу-сызулары, ягъни архивы шушы гаиләдә кала. Мондый мирасның кадерен белгән Ф.Агиев аларны дөньяга чыгару чараларын күрә. Мәсәлән, кульязма хәлендә калган «Ике фикер» әсәрен әзерләп бастырып чыгара *(Коләхмәтов Гафур мәҗмугасы. – М.: СССР халыклары үзәк нәшрияты, 1925. – 152 б.).* Шушы ук китапта Ф.Агиев драматургның тәрҗемәи хәле турында үзенең тикшеренүен бастыра һәм әлеге «Ике фикер» дигән пьесаны урнаштыра. Бер урында Ф.Агиев мондый искәрмә бирә: «Гафурның өслүбен һәм телендә булган кайбер авырлыкларын төзәтү минем тарафтан булды» *(8 б.).* Менә шушы сүзләр Г.Ибраһимовның ачуын китерә дә инде. «Бу әдипнең барлык әдәби мирасы Ф.Агиев кебек пролетариат революциясенең дошманы кулында ята. Аның иске заманда басыла алмаган «Ике фикер» кебек кадерле драмасын шул ук Агиев кульязмадан дөньяга чыгарды. Бу бик уңайсыз эш булып төште». Әдәбият мәнфәгатьләреннән караганда, моңа шатланырга гына кирәк иде, «уңайсыз эш булып төште», дип хафаланырга һич тә урын юк. Әмма Г.Ибраһимовның үз үлчәме – сыйнфый герләр салынганы». Большевик әдипкә редактор Агиев булса, җитмәсә бу редактор «төзәтә» башласа, «кабереңдә яткан җирдә чыдаша алмый әйләнерсең» ич!», дип ачына. Югыйсә, ул Ф.Агиевка рәхмәтле

булырга тиеш иде кебек. Чөнки ул әлеге «большевик» әдипнең «Ике фикер» әсәрен сандык төбендә генә саклый ала иде бит. Ул аны, тәртипкә китереп, әдәби кысаларга кертеп, укучыларга җиткерә. «Яшь гомер» әсәре янәшәсенә «Ике фикер»не китереп куя. Шуның белән Г.Ибраһимов әйткән «большевик әдип»нең иҗатын халыкка тулырак итеп җиткерүгә өлеш кертә. Әмма һәрнәрсәгә сыйнфыйлык җирлегеннән генә карау мәсьәләне киң аңлауга комачаулык итә. Г.Ибраһимов Г.Гобәйдуллинны да, Ф.Агиевны да бер үк төрле тамгалый. «Г.Гобәйдуллин бөтенләй шул Агиев сызган юлдан бара. Икесендә дә бер үк «дипломатия», бер үк тактика. Икесендә дә Гафурның үзләренә бик «якынлыгы»н, үзләренең һәркайда аңа җитәкче, ярдәмче булуларын сөйләп, аның исемен вак исәпләргә корал итү дәрте ялтырап бара». Моннан күренгәнчә, Г.Ибраһимов ул әйткән тактиканы куллануда Ф.Агиевка җитәкчелек ролен бирә. Г.Ибраһимов бу истәлекләрнең язылуында шулай ук Ф.Агиевны төп гаепле кеше итеп саный. «Гафур өчен Агиев кулыннан «төзәтелеп» үтү аңа әлегә беренче зур бәхетсезлек булса, икенче иң авыр бәхетсезлек, үзе үлгәч, эре капиталистларның реакция чорындагы «тарих»ларын акларга, «буярга» маташучы Гобәйдуллин тарафыннан көчләп хезмәт иттерүе булды. Агиев белән Гобәйдуллин икәүләп Гафурга үлүеннән соң да килеп ябышалар». Күрәбез ки, Г.Ибраһимов уйлавынча, имеш, бу «Истәлекләр» дә Ф.Агиев кушуы буенча язылган икән. Әлеге язманың Баку шәһәрендә яшәгәндә язылганлыгын искә алсак, ай-һай, Г.Гобәйдуллинның шәхси характердагы истәлекләрне кемдер кушуы буенча кәгазьгә төшереп утыруын күз алдына китерү кыен. Әлеге язманың туган Казанны, Татарстанны, яшьлек дусларын сагынудан барлыкка килүендә шөбһә юк. Бу вакытта Кырымда яшәргә мәҗбүр Г.Ибраһимовның үзенә дә әлеге хисләр таныш булгандыр. Әмма ул бу очракта үзен барысы өстеннән дә хөкем йөртергә бурычлы һәм шуңа хокукы бар кеше итеп саный. Хәтта шундый чакыру ташлый: «Кадерле әдип Гафурны бу ике кешедән коткарып калырга кирәк! Бу сүзне уйнап түгел, чынлап әйтәм!»

Г.Ибраһимовның замандаш каләм әһелләренә булган төрлечә мөнәсәбәте яңалык түгел. Әйтик, аның Г.Тукайга карата үзенчәлекле һәм дәвамлы карашы барыбызга да мәгълүм. Әмма шунысы бар: бу мөнәсәбәт, нигездә, иҗатның эстетик ягына карый иде, биредә Г.Ибраһимовны аңларга да мөмкин иде әле. Ә инде аның Г.Гобәйдулин, К.Бәкер, Г.Рәхим, Г.Исхакый, М.Бигиев, Ф.Туктаров, Һ.Атласи кебек каләм әһелләренә мөнәсәбәте сыйнфыйлык карашлары белән билгеләнде. Ягъни егерменче елларның ахыры – утызынчы елларның башында илдә ныгып урнашкан пролетариат идеологиясе Г.Ибраһимов кебек гаять киң карашлы, бөтен нәрсәгә үз фикере һәм мөнәсәбәте булган шәхесне дә тулысы белән үзенең мәнфәгатьләренә хезмәт итүчеләр мохитенә алды. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр ул моңа тугрылыклы булды.

Бу мәкаләләргә М.Мәһдиев әле туксанынчы еллар башында ук игътибар иткән иде. Әйе, әдәбиятыбыз тарихындагы мондый күренешләргә битараф калырга ярамый. Алар теге яки бу шәхеснең аерым чорлардагы карашларын билгеләүгә генә түгел, бәлки сүз сәнгатебез тарихында булган катлаулылыкларны бөтен ачыклыгы белән күз алдына китереп бастыру өчен кирәк. Г.Гобәйдуллин истәлекләре һәм Г.Ибраһимовның аңа җавап итеп язган мәкаләсе хәзерге укучыларга шул чордагы иҗат мохите турында гыйбрәтле сабак бирүләре белән әһәмиятле.

**Фоат ГАЛИМУЛЛИН,**
*КФУ профессоры*

# ӘДӘБИЯТЫБЫЗНЫҢ ӘМИР-ХАННАРЫННАН БЕРСЕ

## МАРАТ ӘМИРХАНОВКА 85 ЯШЬ

Халкыбыз, нинди генә кыен шартлар булуга да карамастан, талантлы угыл-кызларын тудырып, үстереп торган. Кол Гали һәм Сәйф Сараи, Мөхәммәдьяр һәм Мәүла Колый, Габдерәхим Утыз Имәни һәм Кандалый, Исхакый һәм Тукай, Такташ һәм Җәлил... – болар һәм аларның күпләгән чордашлары сүз сәнгатебезне тудырган һәм алга җибәргән, баеткан һәм дөньяга таныткан. Шөкер Ходайга, гасырлардан гасырларга килүче әдәби эстафетаны, традицияләрне уңышлы дәвам иттерүчеләр хәзер дә бар. Шундыйларның иң күренеклеләреннән берсе – Марат Әмирхан улы Әмирханов.

Чын татар мохитендә үсү, кечкенәдән үк туган телне, кызыклы китапларны ярату, җыр-моңнарга мөкиббәнлек «өлгергәнлек аттестаты» алган Сөн егетен Казан педагогика институтының атаклы «татар теле һәм әдәбияты бүлеге»нә китерә. Биредә ул 1951-1955 елларда тырышып белем ала, башкала тормышы, мәдәнияте белән таныша. Югары уку йортын уңышлы тәмамлаган яшь белгечне Питрәч районының җырларга кергән Күн авылына мөгаллим итеп җибәрәләр. Әмма биредә озак эшләргә туры килми – аны хәрби хезмәткә алалар. Офицер погоннары таккан Марат ике елдан соң элеккеге укытучылык хезмәтенә кайта. Дистә елдан артык ул хәзерге Бөгелмә районы Карабаш бистәсендәге урта мәктәптә директор урынбасары вазифаларын башкара, татар теле һәм тарих фәннәрен укыта. Аның биредәге (һәм өлешчә моңа кадәрге, шулай ук аннан соңгы) тормышы, эшчәнлеге «Тәкъдир» романында (1998), аеруча бу әсәрнең каһарманы Мансур Әмирҗанов образында да билгеле бер дәрәҗәдә гәүдәләнеш тапкан.

Яшьтән үк каләм тибрәтеп торган Сөн егете мәктәптә эшләү елларында нефтьчеләр төбәгенең актив хәбәрчесе буларак танышла. Бу шөгыле аны ахыр чиктә 1970 елда «Социалистик Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») гәҗитенә даими эшкә китерә. Биредә ул әүвәл мәктәпләр һәм югары уку йортлары бүлеген, аннан сәнәгать, төзелеш һәм транспорт тармагын җитәкли. Аның төрле темаларны яктырткан язмалары, очерклары матбугат битләрендә еш күренә. Аларның кайберләре авторның «Безнең лауреатлар» (1980), «Чулманның ак йолдызы» (1988) китапларында да туплап бирелгән. Бу басмалардагы очеркларда Дамир Нуретдинов, Марат Бибишев... кебек хезмәт кешеләре, җитәкчеләр, галимнәрнең эшчәнлеге, ныклап өйрәнелеп, шактый үтемле тел-стиль белән бәян ителә. Аларда кызыклы факт-мәгълүматлар, драматик вакыйга-хәлләр дә еш очрый. Әмма әле бу очерклар, нигездә, совет чорына хас идеология, бәйнәлмиләллек кысаларында язылган, милли як шактый тоныкландырылган яисә бөтенләй читтә калган, «производство» ягы артык калкуландырыла.

Мәгълүм ки, «Сөембикә» («Азат хатын») соңгы ярты гасырда татарча гәҗит-журналлар арасында алдынгы урыннарның берсен били. Аның мондый дәрәҗәгә күтәрелүендә Марат Әмирхановның да роле зур. Ул бу журналда 1987 елдан алып шактый вакыт баш мөхәррир урынбасары буларак эшләде. Хәтерем ялгышмаса, ул бу коллективта «Арабызда бер егет бар, җеннәр иялөнмәскә» җырындагы кебек, ир-атлардан берүзе генә иде бугай. Авторның шактый гына китапларында хатын-кыз образлары үзәктә тора. Хәтта кайберләре (Гөлнәзирә, Мөкәррәмә, Гәүһәршад, Үрбәт ханәкә...) әсәр исемнәренә дә чыгарылган. Мәхәббәт темасы да төп урыннарның берсен били. М.Әмирхановның хатын-кыз табигатен, психологиясен тирәнтен белүе, тоюы да сокландыра. Мин авторны шәхсән якыннан белмим, бу зат белән бик аралашкан

кеше түгел. Әмма әсәрләре аркылы аның яшьтән үк хатын-кызлар даирәсендә сөйкемле сөяк булуы тоемлана.

Мәкалә-очеркларын исәпкә алмаганда, М.Әмирханов, күп кенә каләм әһелләреннән үзгә буларак, матур әдәбиятка чагыштырмача соңрак – илленең аръягына чыккач кына керә башлады. Анысы да әле кинәт түгел, ә әкренлек белән генә. «Алаяк» дип исемләнгән беренче басма әсәре (хикәясе) 1978 елда «Социалистик Татарстан» гәҗите битләрендә дөнья күрә. Аннан, бик озак көттереп кенә (дистә елдан соң), «Таш һәйкәл» исемле китабы (1987) басылып чыкты. Мәктәп укучыларына адресланган бу җыентыкта авторның ике повесть-бәяны («Юл буенда таш һәйкәл», «Төтенле самолёт») һәм бер хикәясе («Кичке яшен») урнаштырылган. Биредә сугыш чоры балаларының тормышындагы аерым гыйбрәтле хәлләр, укучыларның тарихи үткән белән кызыксынулары, үзара мөнәсәбәтләре тасвирлана. Китапта экология проблемалары да кузгатыла. Гомумән, табигатьне саклау мәсьәләләре М.Әмирхановның кайбер башка әсәрләрендә дә мөһим урынны били. Автор карашынча, табигать – кеше яшәешенең нигезе, аерылгысыз өлеше. Мөгаен, шуңадыр аның иҗатында пейзаж күренешләре еш очрый; елга-сулар, болын-урманнар, кар-яңгырлар, җил-давыллар, кош сайраулары адәм баласының рухи дөньясы, эш-гамәлләре белән табигый рәвештә үреп бирелә.

Еш кына әдәбиятка өлкәнәеп килгән каләм әһелләре үзләренең тәүге әсәрләре белән үк укучылар арасында бик тиз популярлык казана. Моның ачык бер мисалы – М.Мәһдиев һәм аның «Без – кырык беренче ел балалары» повесте. М.Әмирхановка исә язучы буларак танылу озаклап килде. «Таш һәйкәл» җыентыгыннан соң ун еллап вакыт узгач, аның «Сөн моңы» исемле китабы (1995) нәшер ителде. Биредә инде автор каләменең тагын да ныгый төшүе, сәнгати якның камилләшүе күзгә ташлана. Бу аеруча әлеге җыентыкта урнаштырылган хикәяләрендә («Кое», «Алтын каптырма», «Ир хатыны», «Саба җиле», «Тәүбә» һ.б.) ачык күренә. Алар өчен кыскалык, жанр төзеклеге, гыйбрәтлелек хас.

Узган йөзнең ахыры – XXI гасыр башлары – М.Әмирхановның иҗади сулышы ныклап ачылган чор. Моңа, әлбәттә, җәмгыятьтәге үзгәрешләр, милли хәрәкәтнең көчәюе дә уңай йогынты ясагандыр. Ике гасыр аралыгында әдип укучыларга дистәләгән роман-повестьларын бүләк итте. Аларның исем-атамалары гына да шактый үзгә, мәгънәле: «Каргыш», «Дөя муены», «Тояк эзе», «Тәкъдир», «И кылган догам минем», «Гөлнәзирә» һ.б. Боларда зур урынны сугыш һәм сугыштан соңгы чордагы авыл кешеләренең яшәеше-тереклеген тасвирлау алып тора. Гадәттән тыш кыенлыкларга, афәт-җәфаларга да карамастан, тормыш дәвам итә: адәм балалары яши, эшли, сөя-сөелә, алдый-алдана, нәселен дәвам иттерә, җырлый-моңая... Гөлнәзирә, Заһит, Мөкәррәмә һ.б. бик күп персонажларның язмышлары укучыны дулкынландыра, уйландыра.

Мәгълүм ки, нигездә, сугыш белән бәйләнешле әсирлек, тоткынлык үткән тормышыбызда шактый тирән эз калдырган. М.Әмирханов та бу гаять фаҗигале, катлаулы мәсьәләне урап узмый. «И кылган догам минем» повесть-бәянының төп каһарманы Хисам Сабиров гомеренең унбер елын әсирлектә уздыра: «өч елы – немец ягында, сигез елы – Совет ягында». Ул үзенең күргән-кичергәннәрен, башыннан үткәннәрне оныгы Гүзәлия үтенече белән магнитофонга яздыра. Үткән һәм бүгенге вакытның бу рәвешле ялганышы сәнгати якны көчәйтүгә ярдәм иткән. Әсәр тукымасына милли тарихның аерым факт-мәгълүматлары, реаль затлары да кереп китә. (Шулар исәбендә – Сара Садыйкова, Камил Кәримов... образлары.) Әсирлектәге татар егетенең немец кызы Эрнага мәхәббәте дә повестька үзгә бер яңгыраш бирә. Әсәр героена әсирлектә сират күперләрен күп мәртәбәләр узарга туры килә. Аның үлем-афәтләрдән исән-имин котылуында кечкенәдән үк күңеленә сеңеп калган иман-ышанычы, «кылган догалары» да мөһим роль уйный.

Мәгълүм булганча, соңгы вакытта туган телебезгә (бер үк вакытта милләтебезгә) дә аеруча күп кыенлыклар кичерергә туры килде; ул рәсми тикшерү органнары, хакимият тарафыннан төрле кимсетелүләргә дучар ителде. Заманында милли мәгариф мәсьәләләренә М.Әмирханов та җитди игътибар бирә. Аның «Тәкъдир» романында, мәсәлән, узган гасырның 60-70нче еллар аралыгында ук татар мәктәпләренең ябыла баруы, телебезнең үгиләштерелүе, урыс теленә генә гадәттән тыш игътибар ителү

ачынып бәян итеlә... «Саба җиле» хикәясендә райком вәкиле авызыннан татарның гореф-гадәтләре «сасып беткән», «теле ярым-йорты», дип бәяләнә. Имеш, «халык үзе болардан ваз кичә». Чөнки «татар теленең Минзәлә күперен узгач кирәге калмый».

Әдәби тәнкыйтьтә, укучылар арасында М.Әмирхановның әдәбиятта юмор-сатира үсешенә дә билгеле бер өлеш кертүе еш искәртелә. Әмма автор ак-кара принцибы белән генә эш итми. Аның еш кына тискәре дип әйтерлек герой-каһарманнары да билгеле бер уңай сыйфатлары белән бирелә. Әдип, ничектер, ярамаган, әхлаксыз эш-гамәлләрнең дә асылын, сәбәпләрен ачарга тырыша. М.Әмирханов тормышыбызда эчүчелек, гайбәтчелек, үчләшү кебек начар сыйфатларның киң тарала башлавына тирән борчылуын белдерә, бу төр эш-гамәлләрнең аяныч нәтиҗәләргә, фаҗигага китерүен искәртә. Бу типтагы аерым хикәяләре сәхнәләрдән, эфирдан да ишетелгәләп тора. Авторның тулысы белән диярлек сатирик нигезгә корылган «Дөя муены» исемле повесте да бар. Анда узган гасырның 90нчы елларында илдә башланган иҗтимагый, сәяси, әхлакый күз буяулар, бозыклыклар, алдашу, үчлек җанлы күренешләрдә, кабатланмас холык-характерлар аркылы гәүдәләндерелә. Намуслы, үз хезмәте белән көн күрүчеләргә яшәү тагын да авырая.

М.Әмирхановның «Дөя муены» повесте мактауларга бик юмарт булмаган Аяз Гыйлаҗевне дә каләм алып, мәкалә язарга этәрә. «Бәрәкалла, Әмирхан!» дип исемләнгән язмасында *(Мәдәни җомга. – 4.04.1997)* ул болай ди: «Автор үткен сүз белән җитәкче бюрократлар вертикален астын-өскә кадәр бәяләп чыга. Теле – бритва авторның, турый гына. Күзе – прожектор, без күрмәгәннәрне күрә. Фикере – ачык, максаты бер: ул халкыбызны, һәр җан иясен коллыктан коткарырга ашкына». (Ни кызганыч, тормыштагы гаделсезлекләр, бозыклыклар әсәр иҗат ителгәннән соңгы дәвердә тагын да ныграк «чәчәк атты».)

Кагыйдә буларак, каләм әһелләре, сигезенче дистәне ваклый башлагач, үзләренең иҗади активлыкларын киметәләр яисә язудан бөтенләй дә туктап калалар. Марат Әмирхан исә бу яктан да безне шаккатырды: әйтерсең, әдәби иҗатсыз узган гомеренең беренче яртысына «үч» иткән кебек, 75нең югары ягына чыккач, ягъни соңгы берничә елда ул дистәләгән күләмле әсәрен бастырып чыгарды: «Үрбәт ханәкә гыйшкы», «Гәүһәршад» (2009), «Әлвидаг» (2011), «Ир-Мамай» (2013), «Тәхетсез патша» (2017) һ.б. Болар инде әдиптән хыял-фантазияне генә түгел, ә тирән гыйлем-мәгълүматны да таләп иткән тарихи жанрдагы әсәрләр. Алар һәм эчтәлекләре, һәм образ-вакыйгалары, һәм төзелеш-композицияләре белән роман исеменә тулысынча лаек.

Мәгълүм ки, совет җирлегендә халкыбызның милли тарихын, аеруча ханнар дәверен, татарларның дәүләтле чорын әдәбиятта гәүдәләндерү хупланмады. Шулай да бу юнәлештә, бигрәк тә соңгы ярты гасырда тарихи тематикага Н.Фәттах, М.Хәбибуллин романнары иҗат ителде. Бераздан боларга Р.Батулла, В.Имамов, Ф.Латыйфи һәм кайбер башка авторларның язмалары килеп кушылды.

Сорау туа: ә ни өчен соң моңа кадәр, нигездә, заман тематикасы, үз чоры тормышы белән шөгыльләнгән Марат Әмирхан үзенең төп игътибарын милли тарихка, ханнар дәверенә юнәлтә? Бу сорауга төгәл генә, бертөрле генә җавап бирү авыр. Моңа, әлбәттә, ике гасыр аралыгында көчәйгән милли хәрәкәт, милли үзаң йогынты ясагандыр. Әдипне кайчандыр үз дәүләтләрен тоткан халыкның мескен хәлгә калуы, милләт язмышы киң, глобаль планда борчыгандыр.

Гадәттә, йорт-бинаны төзү алдыннан аның проектын, корылма булачак урынның мәйданчыгын әзерлиләр. Шуның кебек, Марат абзабыз да язылачак романнары өчен күпләгән тарихи чыганакларны, язма һәм фольклор ядкярләрен өйрәнә, хан чорларының халкыбыз һәм дөнья тарихындагы урынын, ролен гомуми рәвештә, әйтергә яраса, методологик программа планында билгели. Бу юнәлештә әдәби тәҗрибәләр дә ясап карый. «Тояк эзе» (2001) – шундыйларның берсе. Бу роман зыялыларыбыз, галим-голамә арасында заманында зур кызыксыну, бәхәсләр дә тудырды. Андагы образ-персонажларда чорыбызның аерым шәхес-прототипларын да абайлау кыен түгел. Кайберләре (мәсәлән, Президент М.Шәймиев) үз исемнәре белән дә бирелгән. Романда узган гасырның азакларындагы катлаулы һәм каршылыклы тормыш, кыргый базар мөнәсәбәтләре урнаша бару, мафиячелек тормышчан образлар, шәхси

язмышлар аркылы шактый оста сурәтләнгән. Әмма анда төп проблема – милли, этник тарихка хәзерге мөнәсәбәт. Ничәмә-ничә буын килгән, киткән, күпләгән хөкемдарлар алышынып торган. Шулай да татарның тарихта эзе, сүзе калган. Юкка гына роман авторы «толпарның эзе бетмәс, тоягы китмәс», дип язмый.

Романда, чынбарлыкка нисбәтән, соңгы дәвер галим-голамәнең зур өлеше (шул исәптән элеккеге рәсми хакимият тә) татарның этник тарихын болгарлар белән генә бәйли, Алтын Урданы бөтенләй читкә кага. Моның башында Фәнни-тикшеренү институты директоры Сәүбан Галимов тора. Икенче төркем исә болгарны, кыпчак, хәзәр, татар кавемнәре белән бергә, халкыбызның оешу-шәкелләшүендә мөһим бер компонент рәвешендә карый, Алтын Урданың, нигездә, татар дәүләте булуын, аның этник һәм дәүләтчелек тарихыбызда төп һәм хәлиткеч роль уйнавын искәртә. Бу юнәлешнең төп әйдаманы – чагыштырмача яшь галим Кәшшаф Хәмитов. Әсәрдә әлеге ике капма-каршы юнәлеш тарафдарлары арасындагы көрәш-каршылыклар гәүдәләнеш таба. Автор исә үзе «алтынурдачы»лар белән теләктәш һәм фикердәш. Ул да Алтын Урданы фәнни өйрәнү предметы буларак кына түгел, ә татар халкының этник тарихындагы мөһим бер чор рәвешендә карау тарафдары.

Югарыда телгә алынган «Үрбәт ханәкә гыйшкы», «Гәүһәршад», «Әлвидаг» романнары инде укучыларга яхшы таныш. Матбугатта да алар хакында сүзләр булды. «Казан утлары»ның 2009, 2010, 2011 еллардагы саннарына күзәтү рәвешендә язылган мәкаләләрдә без дә бу әсәрләргә шактый урын биргән идек. *(Мәдәни җомга. – 19.02.2010; 18.02.2011; 3.02.2012).* Болар безнең «Иҗади гамәлле шәхесләр» китабында да *(К., 2014. – 178-210 б.)* урнаштырылган. Шуңа күрә биредә бу романнар хакында гомуми фикер әйтү белән генә чикләнәбез.

М.Әмирхановның бу өч әсәре һәм эчтәлеге, һәм төп образ-персонажлары белән үзара тыгыз бәйләнешле. Заманында мин аларны трилогия дип тә билгеләгән идем. Һәм бу атама инде гавам тарафыннан да кабул ителде. Әлеге трилогиядә, нигездә, XVI йөзнең беренче яртысындагы татар тарихының Казан ханлыгы белән бәйләнешле катлаулы вакыйга-хәлләре сурәтләнә. Үзәктә – Чыңгыз токымы, аталы нәселләр белән бәйләнешле Мөхәммәдәмин, аның хатыны Үрбәт ханәкә, Гәүһәршад (Ибраһим хан белән Нурсолтан бикәнең кызы), Сөембикә һәм кайбер башка билгеле тарихи шәхесләр, аларның драматик, хәтта фаҗигале дә язмышлары. Авторның үткен һәм тәҗрибәле каләме белән тудырылган әдәби-сәнгати дөнья үзенең тормышчанлыгы, офыкларының киңлеге, образларның җанлылыгы, бүгенге көнгә дә аваздашлыгы белән укучыны сокландыра. Бу трилогия тарихи үткәнебез турындагы күзаллауларны шактый баетты, тарих белән бүгенге заман арасындагы бәйләнешләрне сизелерлек якынайтты. Авторның әлеге циклдагы әсәрләре рухи тормышыбызда мөһим бер вакыйга рәвешендә кабул ителде.

М.Әмирханов ике гасыр аралыгында язылган «Тояк эзе» романында, Алтын Урда тарихы, аның хөкемдарлары хакында уйланып, болай дигән иде: «Мамай – татар тарихына кереп калган олы шәхес. Әле аны өйрәнәсе бар». Автор чын егет икән: объектив, милли ихтыяҗны башкалар сыртына салмыйча, үзе тәвәккәлләп башкарды: 80 яшен тутырган көннәрендә укучылар хозурына «Ир-Мамай» исемле шактый күләмле романын тапшырды. *(Казан утлары. – 2013. – №5-7)*.

М.Әмирханов үз иҗатында, аеруча тарихи романнарында катлаулы язмышлы, каршылыклы шәхесләрне сурәтләргә ярата. «Гәүһәршад, Симеон Бикбулатович, Явыз Иван, Туктамыш һ.б. – әнә шундыйлардан... Болар арасында аеруча әмир Мамай мөһим урынны били. 1330-1381 елларда яшәгән бу затны татар тарихчылары да, урысның каләм әһелләре дә еш кына тәнкыйтьли, аның эшчәнлеген тискәре бәяли. Чынлыкта исә әмир Мамай Алтын Урданың, бәкләрбәге буларак, чирек гасырга якын сузылган «болганчык», катлаулы дәверендә төп һәм хәлиткеч рольне уйный, Литва һәм урыс князьлекләренә дә билгеле бер йогынты ясый; Евразиянең кайбер башка илләре белән сохбәт-мөнәсәбәтләргә дә керә, күп мәртәбәләр җиңә, уңышсыз походлары да җитәрлек. Тарихи нигезе тәмам ачыкланып җитмәгән «Куликово сугышы»нда үзе тәрбияләгән князь Дмитрий тарафыннан җиңелә дә. Ахыр чиктә Алтын Урданың законлы ханы Туктамыш аны һәлакәт упкынына этәрә.

Әсәрдә Мамайның катлаулы язмышы драматик, киеренке ситуацияләрдә

гәүдәләндерелә, бу көчле шәхеснең уңай һәм кимчелекле яклары шактый үтемле итеп сурәтләнә. Аның Җанибәк һәи Бирдебәк ханнарның сеңлесе Толымбикәгә романтик мәхәббәте, аларның гомер юллары әсәргә үзгә бер җылылык өсти. Романның башлангычы бик тә үзенчәлекле, хәтта символик та: тышта давыл, җил бөтен табигатьне туздырырдай котырына; киез тирмә эчендә Тутыя бикә тулгак тотып ята, газаплана, бәргәләнә. Ахыр чиктә күптән көтелгән ир бала дөньяга килә, әнисе шул чагында ук җан тәслим кыла. Бу эпизод үзе үк төп каһарманның катлаулы язмышына ишарә ясый. Әсәрдә аның «үлеп» кабат терелү күренешләре үзләре генә дә күп нәрсә хакында сөйли.

Романда төп герой белән курыкмыйча бәхәс-әңгәмәгә керүче, аның уй-ниятләрен «фаш итүче» шартлы Юзекәй образы да сюжет үстерелешенә билгеле бер йогынты ясый, әсәргә серлелек төсмере дә өсти. «Тәхетсез патша» романындагы Шамакай образы да, Юзекәй кебек, сарай тормышында сизелерлек роль уйный.

М.Әмирханов әсәрләрендә төш күрү, саташу, төрле әверелү-метаморфозалар шактый еш очрый. «Ир-Мамай»да соңгы дәвер модернистик әдәбиятта аеруча көчәеп киткән бу сәнгати алымнар вакыйга-хәлләрне бәян итүдә, сюжет коруда, геройларның табигатен һәм рухи халәтен яктыртуда аеруча мул кулланыла.

М.Әмирханов әдипнең төп коралы булган тел, сүз белән бик оста эш итә. Әсәрләрендә, шул исәптән «Ир-Мамай»да да кызыклы һәм оригиналь чагыштырулар, әдәби детальләр күпләп очрый. Автор, вазгыять-ситуациягә, герой-каһарманнарның рухи халәтенә туры китереп, текст тукымасына мәкаль-әйтемнәр, канатлы сүзләр, җырлар кертеп җибәрә. Тарихи романнарында дастаннардан, элеккеге язма әдәби ядкярләрдән алынган өзекләр дә әсәрләрнең эмоциональ, фикри тәэсир көчен арттыруга булыша.

Татар һәм урыс тарихы элек-электән үзара тыгыз бәйләнешле. Ике арада хезмәттәшлеге дә, сугышлары да булып торган. Урта гасырлар өчен урыс-татар икетеллелеге дә чит түгел. Күпләгән татар кешеләренең урыслашып китүе, мондыйлар арасыннан меңәрләгән мәшһүр затларның чыгуы (Карамзин, Державин, Чаадаев, Тургенев, Куприн...) үзләре генә дә күп нәрсә хакында сөйли. Наполеонга нисбәт ителүче «Урысны чокысаң – татар чыгар» гыйбарәсе тирән тарихи хакыйкатьне чагылдыра. Урысның шактый гына ил башлыклары да нәселе белән теге яки бу дәрәҗәдә татарга барып тоташа. Мәсәлән, Явыз Иванның әнисе Елена Литваның атаклы Глинскийлар нәселеннән, аның бабасының бабасы – әмир Мамайның улы Мансур. Урыс иле хөкемдарларының берсе Борис Годунов нәселе дә Алтын Урда чоры татар аксөякләренә барып тоташа. Мәскәү тәхетендә хәтта татарча сөйләшкән, мөселманлыгыннан аерылып бетмәгән, христианлыкка тәмам күчеп җитмәгән зат та патша булып тора. Чыңгыз нәселенә тоташкан бу шәхес – Әхмәд ханның оныгы. Берничә ел Касыйм мәмләкәтенең дә хөкемдары булып тора. Рәсәй патшасына хезмәткә күчә, Мәскәү ягыннан «воевода» (гаскәр башлыгы) сыйфатында бик күп сугышларда катнаша, тәвәккәллеге, батырлыгы белән абруй казана. Явыз Иван таләбе белән 1573 елда чукынып, Симеон исемен ала, бояр И.Ф.Мстиславскийның кызы Анастасиягә өйләнә, 1575-1576 еллар аралыгында «Русьнең бөек кенәзе» булып ала. «Халиф на час» кына түгел, ә елга якын! Иван IV тәхетне үзенә кабат кайтаргач, унбиш ел буена – «Тверьнең бөек кенәзе». Фёдор Иванович үлгәч, бер төркем боярлар аны янә патша итәргә телиләр. Әмма Симеон Бикбулатовичка Борис Годунов каршы төшә: аның әмере белән Русьның бер еллык патшасы сукырайтыла, монастырьга сөрелә. М.Әмирхановның «Тәхетсез патша» исемле «кыйсса»-романында *(Казан утлары. – 2017. – №4)* шушы катлаулы һәм каршылыклы затның сикәлтәле тормыш юлы үзәккә куелган. Ул тарихи контекстта, Мәскәүнең югары идарәчеләре белән тыгыз мөнәсәбәтләрдә яктыртыла. Автор сәяси интригаларны, хакимияттәге мәкер-хыянәтне, кансызлыкны, икейөзлелекне шактый оста гәүдәләндерә. Симеон Бикбулатовичның, ягъни Саин Булат ханның хатыны Анастасия белән сөю-мәхәббәтләре укучының игътибарын җәлеп итә, әсәргә җылылык өсти.

Бикбулатовичның чукынуы, марҗага өйләнеп гаилә коруы, урысларга хезмәт итүе татар күзлегеннән караганда мактауга лаек түгел. Аның мондый эш-гамәлләренә әбисе Шаһ-Солтан да үзенең ризасызлыгын белдереп тора. Әмма татарлыкның,

мөселманлыкның бер символы (архетибы) – 80 яшьлек бу карчык та бераздан урыс-христиан хакимиятенең фаҗигале корбаны була. Әмма Бикбулат улы – ни генә әйтсәң дә, безнең халыктан чыккан кеше, елга якын Мәскәүнең олуг патшасы булган зат. Явыз Иванның да тәхеткә утырту өчен бик күпләр арасыннан аны сайлавы очраклы хәл түгел. Димәк, Бикбулатович үзе дә олуг шәхес булган. Марат Әмирханның мондый затны әсәр герое итүе хуплауга лаек.

«Үрбәт ханәкә гыйшкы», «Гәүһәршад», «Әлвидаг» романнарын үз эченә алган трилогиягә М.Әмирхановның «Ир-Мамай», «Тәхетсез патша» әсәрләре дә билгеле бер дәрәҗәдә ялганып китә. Аларның барысының да үзәгендә – XIV-XVI йөзләргә мөнәсәбәтле вакыйга-хәлләр, тарихи шәхесләр. Образларның зур күпчелеген татар хөкемдарлары, өлешчә урысның югары даирә вәкилләре тәшкил итә. Татар-урыс мөнәсәбәтләрен тасвирлау да бар. Шуңа күрә бу биш романны бер цикл рәвешендә карарга мөмкин. Урта гасыр Шәрык сүз сәнгатендә тезмә рәвештә язылган биш роман-поэманы «хәмсә» (ягъни «бишлек») дип йөрткәннәр. Аның классик үрнәкләрен Низами (1141-1209), Әмир Хөсрәү Дәһләви (1253-1325), Нәваи (1441-1501) һәм кайбер башка бөек шагыйрьләр тудырган.

Заман темасын гәүдәләндерүдә шактый зур уңышларга ирешкән М.Әмирханов соңгы дистә елда татар әдәбиятын тарихи романнар өлкәсендә дә яңа баскычка күтәрде. Әмма шунысы гаҗәп: ул соңгырак чор мәүзугыннан да тәмам аерылмады. Аның 2016 елда нәшер ителгән «Бибимәмдүдә» бәяны *(Казан утлары. – №4)* – шуның ачык бер мисалы. Анда мондый мәгънәле юллар бар: «Балага тән биргән дә ана, сөт биргән дә ана, кой биргән дә ана. Моннан да дәрәҗәлерәк, моннан да игелеклерәк вазифа юк бу җиһанда, һәм була да алмый. Шулай булмаса, Пәйгамбәребез дә, җәннәт аналар аяк астында, дип тәкрарлап калдырмас иде». Тукай, аның әнисе хакында безнең әдәбиятта күп язылган. Әмма Марат Әмирхан бу изге һәм җаваплы темага үзенчә якын килгән, үзенең сурәтләү аспектын тапкан. Нәтиҗәдә, Бибимәмдүдә ханымның гаять күркәм, җанлы, игелекле образы тудырылган.

Күргәнебезчә, Марат Әмирхановның иҗат мирасы гаять бай, күпкырлы. Ул тудырган әдәби дөнья гаять киң, зур. Анда нинди генә образ-персонажлар, хөкемдарлар хәрәкәт итми. Болар арасында ханнар, патшалар белән бергә, галимнәр, әдип-шагыйрьләр, каләм әһелләре дә бар. Әмма әле әдип иҗаты, аерым мәкалә-рецензияләрне исәпкә алмаганда, җентекләп өйрәнелмәгән. Бу әдәби мирас махсус диссертацияләр, монографияләр язуга соралып тора. Без әлеге мәкаләдә бары тик аның кайбер якларына гына тукталып киттек.

М.Әмирханов иҗаты хакында сүз барганда, күңелне борчып килгән бер мәсьәләне дә кузгатмыйча булмый. Әдипнең күптәннән җитлеккән, тәҗрибәле, бай иҗат мирасына ия булуы – бәхәссез хакыйкать. Аның әсәрләре укыла, мавыктыра, уйландыра, милли әхлакый, инсани, эстетик яктан тәрбияли. Әмма ниндидер сәбәпләр, аңлашылмаучанлыклар (бәлкем, авторның артык тыйнаклыгы) аркасындадыр, М.Әмирханов иҗаты рәсми яктан тиешенчә бәяләнми киленә. Сөйләүләренә караганда, М.Мәһдиев Тукай премиясенә тәкъдим ителгәч, «мин Әмирхан Еникидән алда бу бүләкне ала алмыйм», дип үз кандидатурасын кире ала. Билгеле булганча, М.Әмирхановтан шактый кайтыш яисә иҗатлары аның дәрәҗәсенә күтәрелеп җитмәгән аерым авторлар инде күптәннән Тукай бүләге иясе, «халык язучылары (шагыйрьләре)» булып беттеләр. Әмма аларның берсеннән дә М.Мәһдиев авызыннан чыккан сүзләр ишетелмәде. Минем инануымча, М.Әмирханов иҗаты, һичшиксез һәм тиз арада, рәсми рәвештә дә югары бәяләнергә тиеш. Аның әсәрләре урыс, төрек һәм кайбер башка телләргә дә тәрҗемә итүне көтеп тора.

Марат ага Әмирханов – үзенең яше белән генә түгел, ә кабатланмас, бай иҗаты белән дә әдәбиятыбызда ханлык, әмирлек дәрәҗәсенә ирешкән олпат зат. Ул сүз сәнгатендә тирән эз калдырган адашлары Фатих Әмирхан, Әмирхан Еники традицияләрен уңышлы дәвам иттерә.

**Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ,**
*профессор*

# ТОРМЫШЫМА ТУКАЙ КИЛЕП КЕРДЕ...

Үз чорында хәзерге кебек теләсә кем үрелергә җөрьәт итмәгән Тукай премиясе лауреатлары арасында татар әдәбияты, бигрәк тә прозасында һәм тәнкыйтендә зур эз калдырган Ибрай Гази (Ибраһим Зариф улы Мингазиев; 1907-1971) да бар. Ибраһим аганың иҗатта үтә кызыллыгы, совет иле төзелүгә күп еллар узгач та, инде ленинчыл идеяләрне баш бәрә-бәрә яклауның артык кирәклеге калмагач та, Сталин башында торган хакимиятнең кешелексезлеге фаш ителгәч тә, бу кызыллыкның кимемәү сәбәпләре турында күп уйландым, үз-үземә төрле сәбәп-шартлар белән аңлатырга тырыштым. Ахырда шундый нәтиҗәгә килдем: әдипнең аңлы гомере һәр этапта иҗтимагый тирәлектә узган, шул тирәлекнең йогынтысы аңа биниһая зур булган, һәм ул ил сәясәтен, партия күрсәтмәләрен әти-әни боерык-үтенечләре, әманәтләре дәрәҗәсендә кабул иткән.

Ибраһим Гази 1907 елның 4 февралендә Кама Тамагы районының Иске (Олы) Карамалы авылында шактый авыр тормышлы крестьян гаиләсендә туа, иртә ятим кала һәм биш ел дәвамында Тәтеш балалар йортында тәрбияләнә. Шушы чорда аның иҗтимагый тормышка ныклы карашлары формалаша, ул комсомол активистына әверелә. Беләбез, балалар йортыннан кеше йә деградацияләнеп, йә анда алып барылган тәрбияне Коръәннеке дәрәҗәсендә кабул итеп чыга. Ибраһим Гази белән дә шулай була. Социалистик киләчәкне төзү хыялларына бирелгән егетне 1924 елда Казанга – өлкә партия мәктәбенә укырга җибәрәләр, аны тәмамлауга ук, Кукмара өяз комитеты сәркатибе итеп куялар. Ике елдан Ибраһим Гази инде Мамадыш кантон комитетын җитәкли. 1929-1931 елларда ныклап каләмгә тотынган яшь әдип комсомолның Татарстан өлкә комитетында пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире вазифаларын үти. Хәзерге укучы, һичшиксез, тиз арада «баш әйләндергеч карьера ясаган», дип әйтер. Әле бит бер үк вакытта «Авыл яшьләре» журналына һәм «Кызыл яшьләр» газетасына мөхәррир булып та урнаша. Әдипнең 1967-1971 елларда Татарстан язучылар оешмасын җитәкләвен дә, ике ел РСФСР Язучылар берлегенең сәркатибе булып торуын да онытмыйк.

20 яшьтә үк (!) Коммунистлар партиясенә кергән Ибраһим Газиның иҗаты шәхси тормышы белән шактый тыгыз бәйләнгән. Кайда гына хезмәт итмәсен, ул язачак прозасына материал туплый. Әйтик, туган җирем Кукмара аңа «Көмеш сулы Нурминкә» (1930) әсәрен иҗат итү идеясе бирә. Чәчмә әсәрләр белән генә танылуына карамастан, каләменең Тукай йогынтысында формалашуы хакында үзе язганнарны укыганнан соң, аңладым: икесе дә, искелекне җимереп, яңаны төзү өчен көрәшкән, яңа кешенең әхлагы нинди булырга тиешлек хакында уйланган, үз карашларын ышанып раслаган, дошманнарга үткен сүз әйтүчән булган. Җитмәсә, бары тик күргәннәрен, үзләре яхшы белгәнне генә язганнар.

Бигрәк тә эсерларга симпатия белдерүенә, татарның киләчәген алдан фаразлаган, шул киләчәкне матур итү өчен гомерен багышлаган шәхесләрен зурлавына карамастан, теге яки бу партияләрдә тормаган Тукай иҗатының актуальлеге, озын гомерлелеге аның, кемнәрнедер потка әвереЛдермичә, үзенә бер кыйбла булдырып, милләттәшләребезнең уртак язмышын кайгыртуы, ә түбән катламнарының хәсрәт-аһларын җырлавы белән бәйле. Ә менә Ибраһим Гази белән эш башкачарак тора. 1931-1942 елларда Татарстан язучылар оешмасында һәм Мәскәүдә марксистик-ленинчыл классиканы тәрҗемә итү курсларын тәмамлаган әдип, әлбәттә, дөньяга инде большевик-коммунист күзе белән карый. Ул тәрҗемә иткән әдәбият, фронтта «Сталин байрагы», «Кызыл Армия» газеталарында хәрби мөхбир булып хезмәт итү һәм башка вазифа-гамәлләре Ибраһим Газины чын коммунист буларак тәрбияләвен дәвам итә, һәм бу аның бөтен иҗатында чагылыш таба.

Кызыклы сюжетларга корылган әсәрләр иҗат итеп калдырган И.Газины бүгенге көн укучысы бик начар белә. Бердән, аны пропагандалау җитми, икенчедән, әлеге дә баягы кызыллыгы да заман кешесенә инде беркатлылык, марксизм-ленинизмга сукырларча табыну булып күренәдер. Алайса бөтенләй башка шартларда формалашкан әдипне Тукайга тагын нәрсәләр якынайта соң? Икесенең дә тормыш хроникасын бөтен тулылыгы белән әдәбиятка кертеп калдырырга тырышуы дип әйтер идем. Сугышта катнашканда илләр гизгән, үз гомерендә төрле шәһәрләрдә яшәгән И.Газиның кулланган материалы, Тукайныкыннан аермалы буларак, татар мохитеннән читкә чыкса да, дөнья кысасыныкына күчсә дә, прозасы татар кешесенең зур ил эчендә узган тормышын тулы тудыра.

Ибраһим Газиның беренче әсәрләре совет илен төзүче яшьләрнең хезмәт дәртен, әхлагын, борынгыдан килгән ямьсез күренешләргә каршы торуын сурәтләсә, сугыштан соңгы прозасы совет кешеләренең – сугыштагы һәм хезмәттәге батырлыгын тасвирлый, әйтерсең, боларны янәшә куя. Бераздан ул нефтьчеләр тормышын яктыртырга алына. Ул бу вакытта ил тарихын киң полотноларда ачкан «Онытылмас еллар» трилогиясен тәмамлый.

И.Гази тәнкыйтендә әдәби бәйләнешләрне яктырткан берничә мәкалә бар. Бу проблема белән кызыксыну анда бигрәк тә тәрҗемә эшчәнлеге белән шөгыльләнә башлагач көчәя. Әдип, Габдулла Тукайның үлеменә 25 ел тулу уңаеннан, «Рус поэзиясе һәм Тукай» (1938) мәкаләсен яза. Анда әйтелгән күпсанлы фикерләр эчендә аеруча мөһимнәре бар. Ибраһим Гази Пушкин һәм Лермонтовның, башка рус шагыйрьләренең Тукай поэзиясенә йогынтысы булуын таныган, ачкан хәлдә, татар шагыйренең дә зур, аларныкына тиң талантка иялеген әйтә: «Тукай үзе турында: әгәр Пушкин, Лермонтов кояш булса, мин аларның нурлары белән яктыручы ай, ди. Тукайча матур итеп, образлы итеп әйтелгән бу чагыштыру бик үк төгәл түгел, әлбәттә: чөнки Тукайның гүзәл поэзиясен җансыз, салкын «ай нурлары»на гына кайтарып калдыру ялгыш булыр иде. Аның поэзиясендә шул ук кояш нурлары балкый, шул ук кайнар, дәртле ялкын уйный». Моннан тыш, И.Гази татар әдәбиятын рус поэзиясе белән рухландыруда Тукайның роле бик зур дигән карашта тора.

Үзе дә тәрҗемә белән шөгыльләнгән Ибраһим ага Тукайның бу өлкәдә Жуковскийдан өйрәнгәнлеген шагыйрьнең үз сүзләре белән үк дәлилли, һәм Тукайның остазлыкта ни өчен аны сайлавын, тәрҗемә итүдә аныкына охшаш принципларга таянуын шушы рәвешчә аңлатып уза: «Жуковский – шигырь тәрҗемәсе өлкәсендә көндәше булмаган зур мастер; икенчедән, аның тәрҗемә принципларында үзенә генә хас нәрсәләр күп.

Жуковский шигырьне сүзен-сүзгә, юлын юлга тәрҗемә итми; ул оригиналны бик нык үзгәртә, үзеннән күп өсти, кайвакыт кеше шигырендәге идеяне нигез итеп алып, бөтенләй яңа, оригиналь шигырьләр дә яза.

Тукай да, үзенең остазы шикелле үк, рус шигыренең төп идеясен, построениесен ала да оригиналны, хәтта строфа тәртипләрен дә сакламый. Ул үзеннән дә өсти, төшереп тә калдыра, хәтта укылган рус шигыре тәэсирендә бөтенләй яңа, оригиналь шигырь дә яза».

Чорына күрә Тукай принципларын мактасак та, И.Газиның бер фикере белән килешми мөмкин түгел: «Тукай принциплары безнең бүгенге тәрҗемәчеләребезгә үрнәк була алмый». Хәер, галимнәр Тукайның тәрҗемәләре рәвешендә өйрәнгән, аңлаткан күп нәрсәләр – асылда тәрҗемә булмыйча, ияреп язылган, мотив биргән йә булмаса ярышып язган әсәрләрдер. Көнчыгыш традицияләре буларак, XX гасыр башында да үз позицияләрен югалтмаган һәм Тукайда да сакланган назыйрәчелекнең, бер уйласаң, хәзер дә яшәргә хакы бар. Бу очракта шуны онытырга ярамый: үзенә идея, образ биргән авторны ияреп язучы һәрвакытта искә алырга, әсәрләре янәшәсендә махсус күрсәтеп узарга тиеш. Авторлык хокукы һәм әхлак принциплары әнә шуны таләп итә. Назыйрәчелекне бер тәҗрибә рәвешендә яңадан җанландырып алу үзенең бик кызыклы нәтиҗәләрен бирергә мөмкин.

Тукайның әдәби бәйләнешләренә мөнәсәбәттә И.Гази әйткән фикерләр Казан артында яшәгән «җирле» тәнкыйтьченең Кандалый белән Пушкинны бик ямьсез, фәнни нигезсез чагыштырган мәкаләсен искә төшерде. Аның колагына да киртләү өчен, язмадан шушы юлларны китереп узарга телим: «Тарихи параллель үткәрү һәрвакыт бик шартлы була; бу очракта бигрәк тә: чөнки бөтенләй башка тарихи шартларда,

бөтенләй башка масштабта эшләгән Пушкин белән Тукай арасындагы параллель урынсыз булырга мөмкин. Шулкадәресе дөрес: рус поэзиясендә Пушкин эшләгән эшне бездә – татар поэзиясендә – Тукай башкарып чыкты».

И.Гази «Рус поэзиясе һәм Тукай» мәкаләсендә, әдәби бәйләнешләр һәм тәрҗемә проблемаларыннан этәрелеп китеп, Тукайның татар поэзиясенә керткән өлеше темасына килеп чыга, аның халыкчанлыгы, халык әдәбияты белән бәйләнешләре, көрәш рухы турында сөйли. Ул аны «халык арасыннан чыккан һәм бөек шагыйрь булып күтәрелгән Тукай», дип атый.

Ибраһим Гази үз чыгышларында Тукай исемен еш телгә ала торган була. Туган тел турында сүз алып барамы («Туган тел»), әдәбиятта форма эзләүләргә бәйле фикер йөртәме («Яңаны эзләгәндә искегә юлыкма!»), иҗатта формальлеккә, автор стилен исәпкә алмауга каршы көрәшәме («Тәрҗемәдә формализмга каршы», «Тәрҗемә һәм тәрҗемәчеләр»), ул һаман Тукайга килеп чыга. Әйтик, әдип Муса Җәлил, бик отышлы русчалаштырылып та, Тукайның чит телгә күчерелгән әсәрләрендә автор иҗеге чагылмауны бик хаклы рәвештә алар кулланган калыплар белән бәйли, «Тукай өчен рус шигыреннән яраклы форма табу кыен булган», дип белдерә («Тәрҗемә һәм тәрҗемәчеләр»).

1969 елны «Илле ел эчендә татар әдәбиятының уңышлары нидән гыйбарәт?» соравына җавап эзләгән «Бер күз ташлау» мәкаләсендә И.Гази сүз сәнгатебезнең, беренче чиратта, романнар белән горурланырга хаклыгы, аларның исә буш урында барлыкка килмәүләре турында яза. Роман жанрының үсешен башка күптөрле сәбәпләр белән бәйләсә дә, ахырда сүзне Тукайга илтеп җиткерүе тәнкыйтьченең яңа заманда һәр жанр үсешенең башкасына да тәэсир итүен аңлаганлыгын күрсәтә. Икенче яктан, прозабызның уңышларын сөйләгәндә, әдипнең аңа озын тарихлы поэзиябезне нигә янәшә куюы да аңлашыла: аның әдәбият тарихында һәм чәчмә, һәм тезмә әдәбиятны үстерүче, сизелерлек алга җибәрүче талантлы шәхесләр булуын күрсәтәсе килә. Билгеле, татар поэзиясен сизелерлек үстерүчеләр арасында И.Гази әдәби телне халыкныкына якынайтуда зур өлеш керткән Г.Кандалый, К.Насыйри, Г.Тукайларны атамый кала алмый. Шул ук вакытта әдипнең бар кешедән дә югарырак күтәргәне – Тукай.

И.Гази карашынча, шагыйрь әдәбияттагы заман уңышларының башында тора: «Габдулла Тукае булган әдәбиятның Һади Такташы, Хәсән Туфаны, Муса Җәлиле, Әхмәт Фәйзие яисә Сибгат Хәкиме булу бер дә гаҗәп түгел». Язучы традицияләрдән үсеп чыккан Тукайның алга таба үз мәктәбен булдыруын күрә: «Тукайдан соң килеп тә, Тукай кебек, халык мәнфәгате белән яши алмаган шагыйрь инде чын шагыйрь була алмый. Тукай сабагы ул – инде барлык киләчәк шагыйрьләр өчен сабак. Ягъни матур традиция». И.Гази «Бер күз ташлау» язмасында, Тукай әдәбиятка килеп китмәсә, Бабич, Сәйфи Кудаш, Туфан һәм башка зур талантлар була алыр идеме икән, дигән сорау куя һәм аларның ничек язуында, ни хакында язуында Тукай тәэсире дә бар, дип нәтиҗә ясый.

Әлбәттә, үзе хакындагы кайбер язмаларга теркәгәнчә, нигездә, русча китаплар укыган, рус мәдәниятендә тәрбияләнгән И.Газиның үзенә дә Тукайның йогынтысы зур була. Ул аның иҗаты аша татар сүз сәнгатенең шулай ук бөеклеген, башка алдынгы халыкларныкыннан ким түгеллеген аңлый. Шагыйрь исемен ул җәдид мәдрәсәдә укуының тәүге елында ишетә. Остазының Тукай үлеме хакындагы хәбәре сабыйны сискәндереп җибәрә, үлем турындагы уйларын җанландыра: «Мин тик шуны аңлыйм: үлгәч инде мин беркайчан да бу дөньяга кайтып, тау башында язын сарык көтеп, ут ягып, көлгә бәрәңге күмеп ашый алачак түгел; Олы күлдә дә, балык кебек, чума-коеначак түгел; юл тузанын туздыра-туздыра, Ыргылмага балык тотарга да чабачак түгел...» Бала Тукай абыйсын нәкъ менә «шул дөнья рәхәтләреннән мәхрүм булган өчен кызгана».

Ибраһим моңарчы да Тукай әсәрләрен белгән, шуның тасвирларын күз алдыннан уздырган, әмма үзенең ничек яшәгәнлегеннән хәбәрсез булган лабаса! Мөгаллим абыйсы сөйләгәндә, шәкерт үзен яланаяклы Апуш янәшәсенә куеп карый. Тукай вафаты хакында ишетү аңа сабыйларга гына була торган тәэсир ясый: «Өйгә кайтып керүгә, мин, сөенеч хәбәр алып кайткан кебек, кинәт кычкырып җибәрәм:

– Әти, Тукай абый үлгән!

/.../ Әти, ясый торган чабатасын сәке өстенә атып, киштәгә сузылды.

– Менә, – диде ул, юка гына бер китапны минем кулыма тоттырды.

Тукай минем тормышыма менә шулай килеп керде».

И.Гази бала вакытында Тукайны тормышчан язганы, ягъни ул белгән авылны, урамны, күлне, малайның үзен... тасвирлаганы өчен ярата, әкиятләре, Шүрәлегә, Су анасына бәйле хыяллар белән саташа. Шагыйрь әсәрләре аның күңелен нечкәртә, сафландыра. Озакламый Тукай ятимлегенә охшаган ятимлек Ибраһимның үзенә дә килә.

Еллар уза. Үсмерлек, аннан егетлек чоры җитә. Инде Тукай Ибраһимны мәхәббәт шигырьләре белән әсир итә. Әз генә яшәргә өлгергән шагыйрьнең мәхәббәт турында озак дөнья көткән, ачыны да, төчене дә күп татыган кеше кебек язуы аны таң калдыра. Гашыйкның һәр ике халәтен – янган һәм сүнгән чагын – ничек оста тасвирлый алган, ди үзе дә әдип булып танылган Ибраһим Гази. Ул моны Тукайның шагыйрь буларак иртә өлгерүе белән бәйли.

Ибраһим Гази, әтиләре үлгәч, сабыйларын ялгыз калдырып, карт кешегә кияүгә китеп барган әнисенә үпкәләгән була. Аның ачлык елны юлда катып үлгәнлеген ишеткәч, егет шунда ук Тукай шигырьләрен исенә төшерә, аларда сөйләгәнне үз язмышына салып карый. Авыр хәсрәт килгән көнне Тукай әсәрләрен исенә төшерү аңа әнисе фаҗигасен ача, күңелендә кайчандыр аңа карата туган, әмма инде тонykланган үпкәсен бөтенләй сыпырып ата: «Үлгәнен ишеткәч, мин аны бик кызгандым. Мин белгәннән бирле ул бер рәхәт күрмәде, өстенә рәтле нәрсә кия алмады. Утыз алты яшендә килеш алтмыштан узган картка да ул инде үзе теләп китмәде.

*Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабрең ташы,*
*Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы!»*

Тукай гомер буе, әйтерсең, И.Газиның янәшәсендә атлый. «Кеше буларак кечкенә генә, зәгыйфь кенә, ә шагыйрь буларак, шундый бөек, минем аңа һич буем җитми. Мин аның гүзәл таланты каршында башымны иям», – дип белдерә ул үзенең узган гомерен тасвирлаган һәм алда безнең тарафтан мисаллар да алынган «Минем тормышымда Тукай поэзиясе» (1957) язмасында.

И.Газины кеше күңелендә бөек бер зат булып яшәгән Тукайның сәнгатьтә ничек тудырылуы проблемасы һәрвакыт борчый. Ул шагыйрь тууга 75 ел тулу уңаеннан иҗат ителгән «Аның рәсеме» мәкаләсен нәкъ менә шул проблеманы ачуга, чишүгә багышлый да. Язма Тукайның, Толстой, Горький, Пушкин һәм башкалар кебек, үлгәч тә исәннәр арасында калуын хәбәр итүдән башлана. Аннан язучы рәсемнәргә күчкән Тукайның халык күңелендә ни рәвешле саклануы турында үз фикерләре белән уртаклаша.

Зәгыйфь тәнле, көчле рухлы Тукайны ничек иҗат итәргә һәм тудырган сурәтең белән халык күңелендә аңа карата яшәгән хисләрне сүндермәскә соң? Шактый четерекле мәсьәлә. И.Гази җавапны Хаҗиморат Казаковның «Тукайның сабый чагы» әсәренә таянып бирергә омтылыш ясый, һәм рәссам бу образны иҗат итүдә дөрес юл сайлаган, дигән нәтиҗәгә килә. Әдип уенча, Казаков рәсеменнән безгә балаларча булмаган җитди карашлы, дәү башлы чандыр гына бер малай йомры маңгае астыннан кара җимеш күзләре белән текәлеп карап тора.

Ибраһим аганы бөтен тормыш юлы буйлап озата йөргән Тукай. Һәр язганына ышандырган Тукай. Аһ, юк! Сугышның иң кызган көннәрендә хәрәкәттәге армиягә китәр алдыннан әдип көндәлегенә болай дип язып куйган икән: «Газап тойгыларны сафландыра, күңелне сафландыра. Вак-төяк җәнҗаллар бик әһәмиятсез булып, мәгънәсез булып калалар. «Тәнгә – мунча, җанга – юк», дигюе белән Тукай хаталанган булса кирәк. Җанга да мунча бар: газап!»

Бер ел элек кенә ул шул ук көндәлекләренә: «Йокларга комачаулаганы өчен, немецлар имчәк баласын үтерәләр», дип язган булган. Тукай каләменә хас дәрәҗәдәге ак һәм караны каршы куйган юллар бу.

**Рифә РАХМАН**

# ШАГЫЙРЬНЕҢ КОРЪӘНГӘ МӨНӘСӘБӘТЕ

Аллаһ Хак Тәгалә «Бәкарә» сүрәсендә: **«Кәнән-нәсү үммәтәү вә хидәтәң фәбәгасә Аллаһүн нәбийинә мүбәшширинә вә мүнзиринә үә әнзәлә мәгәһүмүл – китәбә бил-хаккый»**, ягъни, әүвәл кешеләр һәммәсе дә ислам динендә иде, соңрак төрле диннәргә бүленде. Аллаһ һәммә кавемнәргә пәйгамбәрләр күндерде. Аллаһуга баш игәннәрне җәннәтләр белән сөендерүче итеп. Янә аларга китап иңдерде, хаклык, кешеләр арасын гаделлек белән хөкем итсеннәр өчен, – ди.

Аллаһуның Коръән-Кәрим белән тәсдыйкъ ителгән барлык пәйгамбәрләренең дине ислам булган. Алар барысы да Җәбраил фәрештә аркылы Аллаһуның барлыгы, берлеге, мәңгелеге турында бер тәгълимат, бер вәхи, бертөрле хәбәр, бертөрле китаплар алганнар: **«Күллүн әмәнә билләһи вә мәләәәә-икәтиһии вә кү-түбиһии вә рүсүлиһ»**, ягъни мөселман шул булыр, кем Аллаһуның берлегенә, Аның фәрештәләренә, китапларына, пәйгамбәрләренә иман китерсә. Чын мөселман шул булыр, кем Мөхәммәдкә кадәр килгән пәйгамбәрләргә вә аларга иңгән Изге Китапларга ышанса. Димәк, Мусага (г.м.) иңдерелгән Библиягә («Иске гаһеднамә»), Даудка иңдерелгән Псаломга, Иисуска иңдерелгән Евангелиегә (Яңа Гаһеднамә) ышанган кеше генә мөселман була.

Вә ләкин ошбу хакыйкатьне күңелебезнең иң мөкатдәс түрендә саклыйк. Мөселман, санап киткән Изге Китапларның беренче нөсхәләренә генә ышана. Әйе, мөселманнар Мусага (Моисей) иңдерелгән Тәүратның, Даудка (Давид) иңдерелгән Зәбүрнең, Гайсәгә (Иисус) иңдерелгән Инҗилнең беренче нөсхәләренең хаклыгына ышана. Ни кызганыч, бу китапларның Раббымыз тарафыннан иңдерелгән беренче нөсхәләре безгә килеп җитмәгән. Тәүратның, Зәбүрнең, Инҗилнең асыл нөсхәләре безнең эрага кадәр VI-V гасырларда Иерусалимга – Якын Көнчыгыш мөселман халыкларына каршы булган Вавилон варварлары тарафыннан яндырылган. Бүгенге Изге Китаплар соңыннан килгән апостоллар (Пётр, Иоанн, Павел, Матфей) – тарафыннан язылган, үзгәртелгән.

Раббымызның беркем тарафыннан да үзгәртелмәгән, пәйгамбәребез Мөхәммәдкә 23 ел дәвамында (610-632 еллар) иңдерелгән олуг нигъмәте – Коръән-Кәрим тулысы белән саф көенчә саклаган. Ошбу хакыйкать турында Тукай беренче мәртәбә Мотыйгулла хәзрәттән ишетә. Схоластика белән томаланган Уральскида Тукай үзенә яктылык эзли. «Мотыйгия» мәдрәсәсендә Коръән графикасын, тәҗвид хөкемнәрен үзләштерә. Шәкертнең күңелендә әдәби, иҗтимагый фикерләр белән сугарылган илаһи вә Аллаһу Тәгаләнең олуг нигъмәте – Коръән-Кәримгә мәхәббәте уяна. Коръән-Кәримнең ни дәрәҗәдә иксез-чиксез нур икәнлеген, аңа безнең дә мәхәббәтебезнең иксез-чиксезлеген тасвир кылып, изгелеккә өндәгән китапларга олуг хөрмәт белән карап, газиз Тукай «Китап» дигән шигырен яза:

*Һич тә күңлем ачылмаслык эчем пошса,*
*Үз-үземне күрәлмичә, рухым төшсә,*
*Җәфа чиксәм, йөдәп бетсәм, бу башымны*
*Куялмыйча җанга җылы һичбер төшкә;*

*Хәсрәт соңра хәсрәт килеп алмаш-алмаш,*
*Күңелсез уй белән тәмам әйләнсә баш,*
*Күзләремдә кибеп тә җитмәгән булса*
*Хәзер генә сыгълып-сыгълып елаган яшь, –*

*Шул вакытта мин кулыма китап алам,*
*Аның изге сәхифәләрен актарам;*

*Рәхәтләнеп китә шунда җаным, тәнем,*
*Шуннан гына дәртләремә дәрман табам.*

Шулай, Хак Сүбхәнәһү Тәгаләнең: **«Зәә-ликәл китабүләә райбә фиһ һүдәл лил-мүттәкыйн»**, ягъни «үз бурычларына тугры кешеләргә – мөттәкыйннәргә иңдерелгән, хак юлны күрсәтүче китап Коръән-Кәрим икәнлегенә һич шик юк», – дигән кәлимәсенә таянып, Тукай:

*Укып барган һәрбер юлым, һәрбер сүзем*
*Була минем юл күрсәтүче йолдызым;*
*Сөйми башлыйм бу дөньяның ваклыкларын,*
*Ачыладыр, нурланадыр күңлем, күзем.*

*Җиңелләнәм, мәгъсумләнәм мин шул чакта,*
*Рәхмәт әйтәм укыганым шул китапка;*
*Ышанычым арта минем үз-үземә,*
*Өмид берлән карый башлыйм булачакка, –*

дип яза. Бу шигъри юллар белән шагыйрь, «хәсрәт соңра хәсрәт килеп», тәмам башы әйләнгән бәндәнең күңелен кайгыдан арындыру өчен, Изге Китаптан дәрман эзли.

Татар поэзиясендә иң беренчеләрдән булып Г.Тукай, ислам тәгълиматы вә шәригате таләп иткәнчә, балаларны сабый чактан ук изгелеккә өндәүдә, дуслыкка, миһербанлылыкка үгетләүдә, әле үзе дә яшь булуга карамастан, үрнәк иде.

Пәйгамбәребезнең: «Кечкенәләребезгә мәрхәмәт итмәүчеләр вә олыларыбызның хакларын белмәүчеләр бездән түгел», – дигән хәдисенә мөкиббән булган әдип:

*Әй баһале, әй кадерле, әй гөнаһсыз яшь бала!*
*Рәхмәте бик киң аның, һәрдәм таян син Аллага!*

*Йа Ходай, күрсәт, диген, ушбу җиһанда якты юл;*
*Ул – рәхимле; әткәң-әнкәңнән дә күп шәфкатьле ул!*

*...Кыйл дога, ихлас белән тезлән дә кыйбла каршына;*
*Бел аны: керсез күңелдән тугры юл бар гаршенә! –*

дип сабыйларны Раббымыз кыйбласына өнди.

Балалар язмышы турында уйга калганда, Тукай нәниләрнең үзләренә генә хас сөйләү теленә якын булган җөмләләр белән эндәшә: *«Тәти читек, тәти күлмәк-штаннарны / Баш астыма өеп куеп яткан чагым».* («Бәйрәм вә сабыйлык вакыты»). *«Хозурыңда гәүһәр яшем түгеп телим, / Кабул әйлә, Раббым, әле мин бик «нәни».* («Йокы алдыннан»).

*«Коръән-Кәримдәге мөбарәк аять белән Хак Тәгалә: / «Вә идәә сәәләкә гыйбади ганнии фәин-ни кариибө...»* – диде. Ягъни, әгәр бәндәм Миннән сорар булса... Мин аның догасын кабул итәчәкмен, – дигән Раббымыз вәгъдәсенә бинаән Тукай*: «Тамадыр мискинәмнең тамчы-тамчы күзләреннән яшь; / Карагыз: шул догамы инде Тәңре каршына бармас?»* – җөмләсе белән Раббымыз кәлимәсен куәтли.

Дөньяда иң ләззәтле икмәк – адәм баласының үз кәсебе, үз тырышлыгы белән табылган икмәк икәнлеген фәһемләгән Тукай, «Бай баласы» дип аталган шигъри юлларында «егылмасын» дигән сүз урынына, сабыйларга «түп итмәсен» кәлимәсен куллана. Нәтиҗәдә, шигырь комик рәвештә формалаша:

*Тот, җаным, тот, аумасын – түп итмәсен, тот баскычын,*
*Шунда ядыңнан чыгарма кассаның да ачкычын.*
*Җәнабел Хак сүбхәнәһү вә Тәгалә:*
*«Үә каалә раббикүмү дугуниии әстәҗиб ләкүм», –*

ягъни, хаҗәтләрегезне сорап, «Миңа дога кылыгыз, – аны кабул итеп, сезгә җавап бирермен», – диде.

Раббымызга җан-тән ихлас тугры булган Тукай ошбу аятьне «Ана догасы» дип исемләнгән шигыре белән мәгънәви тәфсиргә салды.

*Менә кич. Зур авыл өстендә чыкты нурлы ай калкып,*
*Көмешләнгән бөтен өйләр вә сахралар тора балкып.*

*Авыл тын; иртәдән кичкә кадәр хезмәт итеп арган*
*Халык йоклый – каты, тәмле вә рәхәт уйкуга талган.*

*Урамда өрми этләр дә, авыл үлгән, тавыш-тын юк;*
*Авыл кыръенда бер өйдә фәкать сүнми тора бер ут.*

*Әнә шул өй эчендә ястүеннән соңра бер карчык*
*Намазлыкка утырган, бар җиһаннан күңлене арчып;*

*Күтәргән кул догага, яд итә ул шунда үз углын:*
*Ходаем, ди, бәхетле булсайде сөйгән, газиз углым!*

Шагыйрьнең эчке фикер дөньясы ни дәрәҗә Аллаһу Раббымыздан иңгән илһам байлыгы белән сугарылган булса, ул шул дәрәҗә үзенең әйтергә теләгән сүзен-нәсыйхәтен укучы бәгъренә җиткерү сәгадәтенә ирешә ала. Нәсыйхәт ул – өндәү, чакыру, үгетләү. Коръән – Аллаһ сүзе. Аллаһ сүзен аңлап уку – ул үзе барлык мөселманча, ислами тәгълиматка итагать кылган бәндәгә – нәсыйхәт!

Нәсыйхәт кылучы кешенең гыйлеме камил, холкы гүзәл, сүзе төгәл, гамәле хак, үзе саф булу Пәйгамбәрнең өммәтенә сөннәте икәнлеге мөселманга мәгълүм. Холкы дорфа, гамәле бозык, надан кешенең Коръән эчтәлегендәге Аллаһ шәригатен бәндәгә ирештермичә, аңлатмыйча, томана укуы һичкайчан да нәсыйхәт булмый. Шулай булгач, укучыга да, тыңлаучыга да савап юк. Г.Тукай:

*Күп яттык без мәдрәсәдә,*
*Аңламадык бернәрсә дә;*
*Селкенмәдек, таш төсле без,*
*Җилбер-җилбер җил бәрсә дә...*

*...Хуш! Хуш! Хәзрәтләр, без киттек,*
*Сездән изгелекләр көттек, –*

дип, хәзрәтләрнең наданлыгына, намуслы, сабыр, мәгърифәткә омтылган шәкертләрнең авыр язмышына чын күңелдән газаплана, борчыла. Тукай үзе дә шәкерт иде. Әдипне аңлау ниятендә, без дә бүген бер мизгелгә XIX гасыр ахыры татар шәкертләре язмышы заманына кайтыйк.

...Мәдрәсә. Стенадагы дүрт почмаклы ак агач тактага буяу белән хәзрәт хәлфә 29 хәреф язган. Шул хәреф исемнәрен «әлиф», «би», «ти», «си»... – дип шәкертләр көйләп, шаулап укыйлар, ятлыйлар. Укып, ятлап арып туйгач, тактага язылган хәрефләрне пычак, пыяла кыйпылчыгы белән кыралар. Чөнки, кадим хәлфәнең уйлавынча, «кара тактага акбур белән Коръән хәрефләрен язу – хәрам». Шул хәрефләрне шәкертләр яңадан чиратлашып тактага язалар. Аст, өст хәрәкәләрне куеп, иҗекләп укый-укый, күңелләренә биклиләр. Бикләнгән аяти кәлимәләрнең «мәгънәсен белү, тәрҗемәсен өйрәнү, уку, кәгазьгә язу – олуг гөнаһ!» Фәкать шәригатьне, догаларны ятлау – «савап». Шәригать хөкемнәре турында кешеләрнең мөстәкыйль фикер йөртүләре «хәрам, мөһмәлат-мәгънәсезлек». Шулай кадимчеләр, патша чиновникларының булышлыгында татарлар арасында искелектә, наданлыкта черегән, схоластика белән сугарылган фанатизм тамыр җәя.

*Чәйниләр монда җирәнгеч әллә нинди мөһмәлат,*
*Яшь гомерләр мөнмәлат чәйнәп була монда һәлак.*

*Мәдрәсә, дип, нәрсәдер асрый агайлар җилкәсе,*
*Нәкъ эче азган мөрит[1], мәҗнүн[2] ишаннар хилкасе[3]».*

Шулай «Авыл мәдрәсәсе» дигән әсәре белән Тукай XIX гасырның икенче яртысында халык аңы, мәгърифәте өчен зур афәт килгәнлеген, кадимчеләрнең наданлыкның бер оясы булган схоластик мәдрәсәләрнең мәгънәсез тормышын үзенә генә хас сарказм белән искәртеп кенә калмый, татар мөселман зыялыларына, Коръәнгә бинаэн хәлдә, нишләргә кирәклеген ассызыклый. «Гыймран сүрәсенең 104нче аяте белән Аллаһу Хак Тәгалә Коръәндә»: **«Вәлтәкүм миңкүм үммәтүийәдегүүнә иләл-хайри вә йәэмүрүүнә бил-мәгруфи вә йәнһәүнә гэнил-мүңкәри вә үләәә-икә һүмүл – мүфлихүүн»**, – диде. Мәгънәви тәфсире: «Үз арагыздан шәригатьне яхшы белгән кешеләр булсын. Алар сезне хәерле эшләргә чакырырлар. Бидгать гамәлләрдән тыярлар. Ошбу җәмәгать сезне һәлак булудан коткарыр».

Әһле исламны наданлык фанатизмы баткагыннан коткару максатында, XIX гасыр азагында Русия мөселманнары җирлегендә «ысулы җәдид» исеме белән ислам тарихына кергән дини педагогик юнәлеш барлыкка килә. Җәдидчелек ул мөселманнарның алгарыш рухияте булып, аның башында Шиһаб Мәрҗани, Исмәгыйл Гаспралы, Ризаэтдин Фәхретдин, Фатих Кәрими, Һади Максуди, Шәмсетдин Күлтәси, Галимҗан Баруди, Муса Биги, Һади Атласи, Әхмәт Габәши, Гобәйдулла вә Габдулла Бубилар, Нурзада Насихиләр кебек «милләт өчен бәһа җитмәс кыйбат булган» имамнар торган. Җәдидчеләрнең тырышлыгы нәтиҗәсендә, татар телендә дини тәгълимат белән бергә физика, география, биология, арифметика, медицина, логика фәннәренең нигезләре мәдрәсәләрдә укытыла. Ысулы җәдид укытуның хәерле нәтиҗәсе булып, «меңнәрчә ислами галим-голамә вә әдипләр, хакимнәр вә табиблар, йөзләрчә инженер вә астрономнар, географлар вә тарихчылар, хәзерлекле сәясәтчеләр, игенчелек вә сәнәгать белгечләре җитеште», – диде Ш.Күлтәси.

Балаларны нинди ысул белән укыту мәсьәләсендә кадимчеләр һәм җәдидчеләр арасында аяусыз тартышлар булган. Кадимчеләр укытуда иске тәртипне яклап җан аткан. Җәдидчеләр, мөселманлыкны саклап, дин вә фән гыйлемнәрен бергә үзләштерү ысулына гади, аңлаешлы туры юнәлеш, якты юл тапкан.

*Читтәге бик күп өяздә, күп авыллар яктыра,*
*Пар тату йолдыз кеби школ белән мәктәп тора.*

*Бу ике дус, берсенә чөнки аларның берсе тиң,*
*Бертигез тәгълимнәре дә: берсе – дөнья, берсе – дин, –*

кәлимәләре белән Тукай, диннең вә фәннең бергәлек алгарыш ысулын тапкан җәдидчеләргә ихлас күңел, югары пафос белән мәдхиясен-одасын багышлый. Бу җөмләдән, Г.Тукайның замандашы, ислам голамәләре тарафыннан XX гасырның иң зур ислам галиме дип табылган, төрек милләтенең горурлыгы булып саналган шәхес – Бәдиуззаман Сәид Нурсиның: «Акылның нуры фән гыйлемнәре, вөҗданның зыялылыгы дин гыйлемнәре белән яктыртылыр. Икесенең берләшүе белән акылларда һәм күңелләрдә хакыйкать барлыкка килер», – дип әйткән сүзе искә төшә дә калебне гафиллектән уята, күңелне уйга сала.

– Әгәр дин гыйлемнәре үзләре генә укытылса, – ди әдип, – фанатизм барлыкка килә; фән гыйлемнәре диннән аерым укытылса, Аллаһу Тәгаләне инкяр итү, иман хакыйкатьләреннән шикләнү һәм атеизм туа.

Инсаннарның узган XX гасырда һәм бүген дә дини фанатизмда баглануы, базар икътисадында диннән аерылган фән, дәүләттән аерылган дин, диннән аерылган мәктәп яшь буынга әхлакый тәрбия бирә алмас хәлгә килде. Хәзерге көн җәмгыятьтә матди

[1] Мөрит – наданлыкка юлыккан кеше.
[2] Мәҗнүн – юләр.
[3] Хилка – түгәрәкләнеп утыру.

байлык чагыштырмача үсте, ә халыкта әхлак түбәнгә тәгәрәде. Моның асыл сәбәбен, башка җитешсезлекләр белән бергә, мәктәпләрдә фән гыйлемнәре генә укытылып, дин гыйлемнәренең кире кагылуыннан икәнлеге күренеп тора. Соңгы елларда «татар исламы» дигән атама барлыкка килде. Җәдидчелек ул татар исламы түгел. Ислам ул һичкайчан да татарныкы булмады, булмый, булмаячак! Ислам ул – Раббымыз дине. Алай булгач, җәдидчеләр ислам динен «татарчалаштырганнар», дигән сүзләр – ахмаклык, мәгънәсезлек белән сугарылган уйдырма-ялган.

Габдулла Тукай XX гасыр башында ислам диненең безнең җирдә үсеш алу сәбәбен XIX гасыр җәдид мәгърифәтчеләре – дин галимнәре Шиһабетдин Мәрҗани (1818-1889), Каюм Насыйри (1825-1902), Ризаэтдин Фәхретдин (1859-1936) хәзрәтләренең фидакарь хезмәтләре белән бәйли.

Ул вакыттагы кадимнәр үзләреннән галимлектә өстен бер генә кешене дә күрергә теләмәделәр. Ш.Мәрҗанинең китапларын хәрам дип игълан кылып, әйткән нәсыйхәтенә, кылган гамәленә, иҗатына каршы төштеләр. Фанатик муллалар, схоластик ахуннар, надан ишаннар хәсәд-хөседче байлар бергәлегендә, Мәрҗанине галим итеп танырга теләмәделәр. Хак сүзләрен кирегә юрадылар. Донослар яздылар. Ике мәртәбә имамлыктан алдылар. «Динне фән белән берләштерә, исламга инануы зәгыйфь», – дип коткы тараттылар. Шушы гаять аяныч, куркыныч шартларда Ш.Мәрҗани үзенең иҗаты, сүзе, куәте, нәсыйхәте белән халыкны җәдид ысулына өндәүче иң беренче галим булды. Бөек әдипнең хаклыгына җан-тән итагать илән иҗтиһад кылган Тукай, «Шиһаб хәзрәт» исемле шигыренең юлларында:

*Һәрбер имам бездә койрык булган чакта,*
*«Койрык» сүзе безгә бойрык булган чакта,*
*– Фәлән сәләф[4] фәлән әйткән, фәлән бул, – дип,*
*Җаһил[5] мулла әмер боерып торган чакта, –*

*Чыкты ахры бездән дә бер бөтен кеше,*
*Яхшы аңлап, тәкъдир итү читен кеше;*
*Татарда да гыйрфан[6] уты кабынганны*
*Күрсәтергә күтәрелгән төтен кеше.*

*Кирәк булса, әйтеп бирәм: ул шәп хәзрәт,*
*Тулган ай күк балкып чыккан Шиһаб хәзрәт,*
*Мәгарифкә әүвәл башлап адым салган,*
*Милләт өчен бәһа җитмәс кыйбат хәзрәт.*

*...Чыкты, әлбәт, бу даһигә сәфил[7] дошман;*
*Чыккан дошман мәгълүб[8] булып чыкты эштән,*
*Олуглыкта, өстенлектә Шиһаб хәзрәт*
*Этләр буе җиталмаслык җиргә кичкән.*

*Бер җан белән тиздән милләт итә бәйрәм,*
*Шәрафәтләп[9] , туган көнне бу мөхтәрәм;*

*Җисме үлек, исме терек бул хәзрәтне*
*Мәхшәргәчә[10] телләр сөйләр, язар каләм! –*

дип, безгә һәм бездән соң киләсе буыннарга нәсыйхәт кылуы.

[4] Сәләф – борынгы галимнәр.
[5] Җаһил – надан.
[6] Гыйрфан – аң-белем.
[7] Сәфил – түбән, әшәке.
[8] Мәгълүб булып – җиңелеп.
[9] Шәрафәтләп – олылап, дан-хөрмәткә күмеп.
[10] Мәхшәргәчә – кыяматкә чаклы.

Шиһаб Мәрҗани хәзрәтләре – милләтебезнең дини тарихын, әүвәл заманнардан алып, мөселман мәгърифәтен безнең җирдә тасвир кылган галимебез. Бу мөхтәрәм имамыбызны Тукайның олуглавы тикмәгә генә түгел. Бүген дә ислам дөньясында Мәрҗани фикере мөселманнарны гафиллектән уяту, башка милләтләр, диннәр, дин әһелләре арасында Раббымызның чын бәндәсе булып яшәр өчен олы хезмәт куйган үрнәк хәзрәткә Тукаебыз үз бәһасен, шулай итеп, «мәхшәргәчә телләр сөйләр, язар каләм», кәлимәсе белән бирә. Шул ук вакытта газиз Тукаебызның: *«Фәлән сәләф фәлән әйткән, фәлән бул», – дип, / Җаһил мулла әмер боерып торган чакта»*, – дигән җөмләсе әле бүген дә дин дәрьясындагы кимчелекләрне төзәтергә тырышканлык ниятендә туган тәнкыйть дип аңлау хак булыр.

Тукайның аерым сүзләрен ялгыш аңлаучыларга карата әдипнең «Кыйтга» шигырен искә төшереп үтәсе килә:

*Көчләремне мин кара көннәргә саклый алмадым,*
*Көннәремнең һичберен дә чөнки ак ди алмадым.*

*Булды юлда киртәләр, эттән күбәйде дошманым,*
*Чөнки залимнәрне, өстеннәрне яклый алмадым.*

*Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч – шул булды эш:*
*Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым, –*

дисә дә, мәдрәсәдә алган гыйлемен Габдулла Тукай (шагыйрьнең әтисе Мөхәммәтгариф хәзрәт тә имам, мулла, галим иде) гомере буена милләтенә ирештерергә тырышты. Шулай булса да, өметен өзмичә, «керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым», дигән вакытында да, шигырьләре белән үзеннән соң булган буыннарга дөрес үгет-нәсихәт биреп, бу эшне дәвам иттерүне киңәш кылды. **«Бисмилләәһир-рахмәнир-рәхим. Иәәәә әййәтүһәннәфсүл мүтмәзинәһ»**, ягъни, тик Аллаһуның барлыгына, Пәйгамбәрнең хаклыгына изге нәфес белән инанган мөселманның рухына: «Синең дөньяда өлешең бетте һәм бурычың үтәлде. Инде син Аллаһудан разый булган хәлдә һәм Аллаһ синнән разый булган хәлдә Раббыңа кайт!» – дигән Коръән кәлимәсен исебезгә төшереп, әдип:

*Кайт, и нәфсе мөтмәиннәм! Бар, юнәл, кит тәңреңә:*
*Бирдең арканңны моңарчы, инде бир бит әмренә,*

*Дустларым, кардәшләрем, сез муллаларга әйтегез:*
*Бу ике юлны, мине күмгәч, укырлар кабремә.*

*Әһле тәкфир бер гаҗәпләнсен, күреп актык сүзем:*
*Күр, нә рәсмә тулган иман берлә Коръән садремә!*

Бу шигъри тәфсир шагыйребезнең ахыр сулышында безгә мирас итеп калдырган васыяте булды. Шуның өчен дә без – гомер дәвам иманлы кешеләр – Тукай шигырьләреннән калебемезгә илһам алабыз, тормышыбызда бәндәчелек белән булган хата һәм гөнаһларыбызны төзәтергә ашыгабыз.

**Харис хәзрәт САЛИХҖАН,**
*Бөек Ватан сугышы ветераны,*
*Татарстанның Г.Тукай исемендәге*
*Дәүләт премиясе лауреаты*

# АЙРАТ АРСЛАНОВ

*(1928-2010)*



Борын-борыннан татар халкында сүз сәнгатенә үзгә бер хөрмәт, игътибар яшәп килгән. Көйләп бәет-мөнәҗәтләр әйтүнең, хикәя-дастаннар укуның үз осталары булган. Татар шигъриятендә шигъри сүзне бөтен нечкәлекләре, тирәнлеге, аһәңе белән яңгырата алучыларны тикмәгә генәме «нәфис сүз осталары», дип атаганнар. Г.Кариев, М.Мутин, Ш.Шамильский, Х.Сәлимҗанов, Ф.Йосыпов, Ә.Яһудин, И.Әхмәтҗанов, А.Арсланов, И.Сафин, Р.Сабиров, Р.Садриевлар – татар шигъри сүз сәнгатенең осталары дип аталырга чын мәгънәсендә лаеклы затлар.

Татар сүзен дөньяның төрле кыйтгаларына тараткан, чит ил һәм рус классик әсәрләрен дә үз туган теле дәрәҗәсендә яңгырата алган халкыбызның асыл улларының берсе Айрат Арсланов 1928 елның 10 апрелендә Башкортстанның Бүздәк районы Ахун авылында туа. Сәхнәгә юлны булачак артист мәктәпне тәмамлауга ук таба. Ул башта Татар дәүләт театр училищесын, аннан соң Мәскәүнең Луначарский исемендәге Мәскәү театр сәнгать институтының актёрлык факультетын тәмамлый. Билгеле, башка күп кенә иҗат әһелләре кебек, әдәбиятка мәхәббәт, иҗатка омтылыш аңа гаиләсендә үк салына. Бала вакытта ук сәхнәдән Тукай, Такташ шигырьләрен сөйли, радио тыңларга бик ярата. «Әтием авыл зыялысы иде. Без аның белән кичләрен рус һәм татар әдәбиятын укый идек. Тукайны, Такташны, Мәҗит Гафурины... Бу да әдәбият белән кызыксынуга нииндидер этәргеч биргәндер», – дип искә ала ул үзенең бер язмасында.

Радио-телевидениедә диктор, Камал театрында актёр, Татар дәүләт филармониясендә артист һәм халык коллективлары бүлеге режиссёры... Ә менә Айрат Арслановның татар эстрадасына хәер-фатыйханы мәшһүр композиторыбыз Салих Сәйдәшевтан алуы – чын мәгънәсендә сокланырлык вакыйга. Сәйдәш үзенең юбилей кичәсен алып баруны радиода диктор булып эшләүче, Тукайны һәм башка шагыйрьләрне оста итеп укуы белән таң калдырган егеттән үзе сорый! Әнә шулай итеп, Сәйдәш фатихасы белән эстрадага аяк баскан егет кырык елдан артык татар әдәбиятына-сәнгатенә хезмәт итә, ул гына да түгел, татар тамашачысына да, чит ил сәхнәләреннән башка халыкларга да рус әдәбияты әсәрләрен ана теле дәрәҗәсендә камил итеп башкара алу осталыгын күрсәтә. Пушкин да, Маяковский да, Есенин да, Гамзатов та була аның репертуарында. Сибгат Хәким иҗатын аеруча якын итә ул, башкару осталыгын үстерүдә аның иҗаты үзе бер мәктәп булды, дип саный Айрат Арсланов. Гаяз Исхакый, Шәехзадә Бабич, Сәгыйть Рәмиев, Муса Җәлил, Һади Такташ, Хәсән Туфан иҗатлары аша татар язмышын югары сәхнәләрдән ишеттерә ала ул. Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Айрат Арсланов башкаруындагы татар һәм рус шагыйрьләренең күп кенә әсәрләре радио һәм телевидениенең Алтын фондына кергән. Татар әдәбияты һәм сәнгатенә бай мирас калдырып, мәшһүр артист, зыялы шәхес 2010 елның апрель аенда бакыйлыкка күчә.

# Вакыйф Нуриев

## Мостаев җыры

Казандагы Чехов базары янында «У Марселя» дигән бер кафе бар. Заман рухындагы, күңелгә ятышлы, җыйнак бер кафе. Монда ризык мулдан: токмачлы аш, чүлмәктә пешерелгән шулпалы ит, кыздырылган тавык, бәлеш, өчпочмак, кыстыбый, пәрәмәч... Барысы да тәмле, йөрәккә ята. Шулай да кафеның «бренды» – кыздырылган балык. Әллә нинди ят балык ул. Үзе карпка охшаган, әмма карп түгел. Диңгез балыгы. Кабыгы тоташ куба. Ите кучкыл, бик майлы, йомшак. Сезнең андый балыкны беркайда ашаганыгыз юк. Шәһәрнең бер генә кафесында да, бер генә ресторанында да аны тапмыйсың. Бу кафега каян китереп торганнардыр?! Күпме ашап, тәки шуны белә алмадык. «У Марселя»да эшләүче кызлар да чибәр, ягымлы. Гүзәл-Наташалар җаның теләгән ризыкны җәт кенә салып бирәләр, синең белән бер дулкында сөйләшәләр.

Кафеда еш кына элеккеге түрәләрне, партноменклатураны очратырга була. Алар барысы да диярлек шушы тирәдә тора. Якында гына – халык телендә «обкомская» дип йөртелгән «спецбүлнис». Өлкән кеше анда бармый торамы?! Башта алар бүлнискә килә. Табибка күренә, шунда ук дару-мазар ала. Очрашалар, сөйләшәләр. Заманында җир җимертеп йөргән, күз өстендә каш булган, хәзер инде өй саклап ятучы картларга әңгәмә тансык. Сораулар күп. Кемнең кай җире авырта? Кем ничек йоклый? Йоклый аламы? Кичен саф һава суларга чыгамы? Сүзләре бүлнистән чыккач та бетми. Ә нигә юл өстендәге шушы кафега кереп утырмаска, әңгәмәне дәвам итмәскә?! Пенсияләре әйбәт, акча бар. Очрашу хөрмәтенә нигә бер йөз грамм коры шәраб тотмаска?! Җәйге эссе көннәрдә салкын сырадан да баш тартмыйлар. Анысын чикләвек белән уртлап утырырга яраталар.

Берсендә шулай җәйнең бер эссе көнендә, кафега шагыйрь Илдар Юзеев белән кердек. Кояш рәхимсез кыздыра. Исәбебез, берәр бокал салкын сыра алып, сөйләшеп утыру. Керсәк, «яшьтиләр» түгәрәкләнгәннәр. Үзләре бер «дәүләт» булып утыралар. Нишләп «дәүләт» булмасын?! Аны саклаучы бар – өстәлнең сул ягында утырган абзый заманында обкомның оборона бүлеге мөдире булган. Киендерүче бар – җиңел промышленностьның экс-министры. Гүзәл белән Наташа ашаталар. Өстәлнең түрендә исә башын артка ташлап, ара-тирә горурлык белән як-ягына карап алучы, чама белән генә елмаеп куючы шәхес – бу дәүләтнең закон чыгаручысы. Аны президент дисәң дә була. Ул – бер ун ел тирәсе элек Татарстан Республикасы Верховный Советы Президиумы председателе булып эшләгән Шамил Әсгать улы Мостаев. Бу «дәүләт»нең дөньясы түгәрәк – бөтен шартлар бар. Бер итекче генә кирәк бу «дәүләткә». Шулай дип уйлап кына куйдык, «Спартак» аяк киемнәре фабрикасының элекке директоры (хәтерем ялгышмаса, Кыямов бугай) килеп керде кафега һәм шушы табынга килеп утырды. Болай булгач, бүреләре улый инде, дип көлешәбез. Уласын! Бу «дәүләт»нең килер җирен киң кыл, Ходаем.

Күңелләре дә киң икән. Кафеда очрашырга туры килсә, алар безне үзләре янына утырырга кодалый башлыйлар. Күңеле тоташ шигърияттән торган, шаян-тапкыр

сүзне бик урынлы әйтә белгән Илдар Юзеевны тагын каян табасың?! Ханнар да бит үз сарайларында шагыйрьләр, мәзәкчеләр тоткан. Башка язучылар һәм сәнгать әһелләренең дә бу «дәүләт»нең хозурында булганы бар. Табында беркем дә казна кесәсенә керми. Һәркем жаны теләгән ризыкны үзе ала. Дөрес, читтән кергәннәр «дәүләт»нең үзен сыйларга кыҗрап тора.

Өлкәннәр табында ни турында сөйләшәләр? Хәлбуки, сүз үткәннәрне сагыну тирәсендә бара. Мостаев күптән түгел генә үлеп киткән хәләл җефетен сагына. Кайчан гына очрашсак та, ул аны искә алмыйча калмый. Аны искә алганда, Шамил аганың күзләре дымлана, яшь тибеп чыгарга тора. Ул беравык сүзсез тора һәм үзен бик тиз кулга ала һәм сөйли башлый: «Мәскәүдә һәр сессиядән соң подвалда табын әзерләнә иде. Мәҗлескә кадәр Воротников (РСФСР Верховный Советы Президиумы председателе, Мостаев аның урынбасары иде. – *В.Н.*) минем янга килер иде дә: «Шамил Әсгатович, мәҗлесне син алып барырсың, яме», – дип әйтер иде».

Хәлбуки, мондый сүзләрдән соң Мостаев – безнең табынның да (табын ук түгел инде, өстәл) тамадасы. Күбрәк ул сөйли. Сүзнең мәгънәсен югалттырмыйча, сөйләшү агымын бер көйгә агыза белә.

Үткәннәрне сагыну дигәннән, Шамил Мостаев Апаста да эшләде. Партия райкомының беренче секретаре иде. Димәк, районның хуҗасы. Берсендә шулай аз-маз сыра йоткалап, кафеның харчаларын капкалап утырганда, Апас районында булган бер вакыйганы сөйләде ул: «Урак өсте. Дәүләткә ашлык чыгару планын үтәр өчен, кылны кырыкка ярырдай булып йөргән чак. Бер авыл икмәкне бирми генә бит. Председатель дә, районнан килгән кешеләр дә бернишли алмыйлар. Кич белән тоттым да үзем киттем бу авылга. Китәр алдыннан, өйгә кереп, гармунымны алдым. Авылга килеп җитүгә, туп-туры ындырга. Караңгы төшеп килә иде. Ындырда эш гөрли. Уборкада төн уртасына кадәр эшләү бит инде. Барысы белән дә исәнләштем. Бу авылның холкын беләм, боларны сүксәң дә, үгетләсәң дә, баш бирмиләр, үзләренчә эшлиләр. Татарлар да, чувашлар да яши анда. Мин нишләдем, гармунымны алдым да көшел, көшел генә түгел, икмәк тавы түбәсенә менеп утырдым. Гармун уйный-уйный җырладым. Чувашча да, татарча да. Шул төнне үк элеваторга олау-олау икмәк озаттылар».

Бүген аларның күбесе, шул исәптән Шамил Әсгать улы Мостаев та мәрхүм инде. «У Марселя»ның үзенә «Марсель» гастрономын китереп тыктылар һәм кафены бер почмакка кысрыкладылар. «Марсель кибетен «Пятёрочка» басып алды. Бүген мин ул кафега кермим. Шәхесләр юк анда хәзер. Иң аянычы – «дәүләт» юк. Дәүләт булмагач, кызык түгел.

## Мин Рейганны күрдем

Мәскәүдә эш белән йөрим. Калинин проспекты буйлап бара торгач, Кремльгә килеп чыктым. Монда халык, халык... Кремльгә керә торган юлны ике яктан камап алганнар бүген. Бүген Америка Президенты Рональд Рейганның Мәскәүгә сәфәре башлана бит!.. Аның аэропорттан Кремльгә килүен көтәләр. Эшем күп булса да, Рейган кадәр Рейганны күрмичә китеп буламы?! Америка Президентлары көн саен килеп тормый лабаса! Казанга кайткач та, авылга кайткач та: «Мин Рейганны күрдем!» – дип сөйләрмен.

Ул елны майның соңгы көннәре эссе булды. Карашын җәйгә төбәгән кояш астында халык Рейганны янып-пешеп көтте. Кунак та, ул утырган затлы машина да, аны озатып баручы кортеж да күренмәде. Тукта әле!.. Ни булды?.. Күземә күренәме соң?.. Халык ташкыны мәтәлә-кадала Кызыл Мәйданга таба чаба башлады. Рейган Кремльгә Спасс манарасы астыннан керәчәк икән. ГУМ тирәсендә мәхшәр купты. Этеш-төртеш китте. Һәркем алга чыгарга, Америка Президентын күреп калырга тырышты. Маңгайлардан тагын күпме тир аккандыр, хәбәр таралды: «Рейган Кремльдә икән бит инде!!!» Халык армиясе, Кызыл Мәйданны тутырып, дәррәү атакага күтәрелде. Спасс манарасына ябырылдылар. Бу һөҗүмнең ахыры ни белән беткән булыр иде, ярый әле, сакчылар, солдатлар, хәрбиләр манараның ике якка ачылып торган, фашистлар Мәскәүгә һөҗүм иткәндә дә ябылмаган алагаем авыр капкасын ябып өлгерделәр.

Булмады Америка Президентын күреп!..

Хәер, кич белән күрдем. Майның озын көне кичкә якынлашып, караңгы төшә башлаганда, Россияне «явызлык империясе» дип атаган Рональд Рейган Кызыл Мәйданда халык белән аралашып-сөйләшеп йөрде.

Күрдем!..

Кунакханәдә. Телевизордан...

## Хамматов куган чебен

Узган гасырның 70нче елларында, без мәктәптә укыганда, район газеталарында укучыларның мәкаләләрен чыгармыйлар иде. Безнең, азмы-күпме каләм кыштырдатучы малайларның, чыгарасы килә. Мин әмәлен таптым. Мәкаләне язам. Астына «В.Нуриев» дип кенә куям. Исемемне дә, ничәнче класста укыганымны да язмыйм. Мәкаләмне җибәрүем була, өч-дүрт көннән басылып та чыга.

Шулай дәртләнеп иҗат итеп йөргән көннәремнең берсендә хат алдым. Арчадан, «Коммунизмга» газетасы редакциясеннән. Конвертны ачып укыйм. «Иптәш Нуриев! Сезне журналистларның һәм хәбәрчеләрнең зона киңәшмәсенә чакырабыз. Киңәшмә районның Мәдәният йортында үтә», диелгән хатта. Көне һәм сәгате күрсәтелгән.

Шатлыгым эчемә сыймады. Авылдашларым – рәссам, хәбәрче, укытучым Үзбәк Яхин белән шулай ук рәссам Әнәс Исламовның Арчага район хәбәрчеләре слётына барып, ресторанда сыйланып, бүләкләр алып кайтуларын ишетеп, кызыгып калган идем. Үземә дә форсат чыкты.

Киттем Арчага. Барып җиттем. Район Мәдәният йорты кырмыска күче кебек кайный. Зур-зур абзыйлар, дәү-дәү кешеләр. Барысында да шәп кәчтүм, галстук. Кулларында йә портфель, йә папка. Минем кебек малай-шалайның исе-косы юк. Тукай әйтмешли, күгәрченнәр арасында үземне бер чәүкә кебек хис иттем. Чәүкә баласы. Шулай да, залга кереп, бер почмакка чүмәштем.

Башланды киңәшмә. Президиумда Хамматов (аның «Социалистик Татарстан» газетасының редакторы икәнен беләм), Пушкарёв (аның Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе дәүләт комитеты председателе икәнен соңыннан гына белдем) һәм обкомнан бер кеше. Чыгышларның эчтәлеге болайрак: газета-журналларда басылган һәр мәкалә марксистик-ленинчыл идеология белән сугарылган һәм тирән философик анализга ия булырга тиеш. Мин беттем генә инде. Мәктәптә көл, тимер-томыр, макулатура җыю турындагы мәкаләләремне мин ничек марксистик-ленинчыл идеология белән сугарыйм да ничек тирән философик анализ ясыйм? Ник килдем?

Ул арада президиум тирәсендә бер чебен пәйда булды. Өстәлдә лампалар янып тора, шуларның җылысына килгәндер инде. Хамматов ул чебенне газета белән куа башлады. Чебен Пушкарёвның маңгаена кунды. Ул таза, түгәрәк, кызыл битле иде, аның керфеге дә селкенмәде. Чебен обком кешесенә тимәде, курыкты. Яңадан Хамматовка очып килде. Тагын чебенгә һөҗүм. Бу минутларда мин үзем дә нәкъ шул чебен хәлендә идем. Хамматов аңа суккан саен, мин урындыкка сеңә барам, гүя, редактор, шушы киңәшмәне алып баручы, газета белән минем башка кундыра. Күрше абзый әйтә торган иде аны: «Газета сүзе белән кешене үстерергә дә, үтерергә дә була», – дип. Газетаның үзе белән – чебенне, сүзе белән кешене үтерергә була. Түзә алмадым, киңәшмәдән чыгып качтым. Чыгып барганда, район газетасы корреспонденты Ильяс абый Фәттахов очрады. Аның белән танышкан идек.

– Син моннан рухланып кайтып, тагын да шәбрәк язарга тиеш инде, – ди.

– Ильяс абый, мин бүтән бернәрсә дә язмыйм. Яза да алмыйм, – дип җавап бирдем.

Әмирхан Еники әйтмешли, озын сүзнең кыскасы: Мәскәүдә, Союзлар йортының Колонналы залында СССР журналистларының соңгы алтынчы съездында мин, Татарстаннан сайланган җиде делегатның берсе булып, Шәмси Хәбибулла улы Хамматов белән янәшә утырдым.

# «АФӘРИН, ТАГЫН ӘЙТ!»

РАВИЛ ШӘРӘФИЕВКӘ 80 ЯШЬ

## Шәрәфи шаяруы

Равил Шәрәфи Хәким Сәлимҗан булып сөйләшә торган була. Ул Хәким абый тавышына шулкадәр нык охшата икән, хәтта бер тапкыр Хәким ага Сәлимҗанның хатыны Галия апа Нигъмәтулла да буталып кала. Ул болай була. Галия апаның бизәнү бүлмәсе турыннан Шәрәфи, Хәким абыйга охшатып:

– Каяле минем Галиямнең бүлмәсе? Ничәнче гримёрныйда әле ул? – дип узып китә.

– И-и, Хәким Тбилисидән кайтып та төште микәнни? – дип, Галия апа коридорга чыга да:

– Хәким, Хәким! – дип кычкыра.

Артистлар бу шаярудан көләләр һәм әйтәләр:

– Галия апа, Хәким абый түгел ул, Шәрәфи шаяра! – диләр.

– Мине тилегә саныйсызмы соң әллә сез? Үз иремнең тавышын Шәрәфинең булыр-булмас тавышы белән бутарга мине сез әллә теге юләр дип белдегезме?

Берничә тапкыр шулай кабатлангач кына, Галия апа Шәрәфинең бу сәләтенә ышана.

**Равил ШӘРӘФИ** *сөйләгәннәрдән.*
*1986. 11 февраль.*

## Шәрә башлы Шәрәфи

Артист Шәрәфи, чыннан да, мәзәкләр уйлап табучы бер җор кеше ул. «Айдын» спектаклен уйнаганда, иске йортлар янында аны ике бандит кыйнарга тиеш була. Сәхнәдәшләренә әйтмичә, Шәрәфи чәчен пәке белән кырдырып, өстән эшләпә киеп сәхнәгә чыга. Кыйнау күренешендә Шәрәфинең эшләпәсе «ялгыш төшеп китә». Шәрәфинең ялт иттереп кырылган шәрә башын күреп, кыйнаучыны уйнаучы артистлар тыела алмыйча көлә башлыйлар. Бу көлү шаукымы шулкадәр куәтле була ки, артистлар Шәрәфине кыйный алмыйча, бөгелеп төшәләр. Шәрәфи исә, озын буе белән алар каршына басып:

– Кыйнагыз, нигә кыйнамыйсыз! – дигәч, артистларны тагын көлү шаукымы буып ала.

Шәрәфи үзе, тамчы да көлмичә, теге ике бандитны кыйный-кыйный да сәхнәдән чыгып китә.

*Хатирәләр дәфтәреннән.*
*1983. 4 октябрь.*

## Охшашлык

Бервакыт артист Рәшит Шамкай, Шәрәфи янына килеп:

– Равил абый, карале миңа! Мин Жан Марэга охшаганмы? – дип сораган.

– Җанын белмим,– дигән Шәрәфи. – Әмма марига бик тә охшагансың!

**Илдар ХӘЙРУЛЛИН** *авызыннан.*
*1983. 8 декабрь.*

## Дәү ли?

– Гариф Ахун Батулланы язучылар арасындагы артист, дип атый, минә сезне, Равил ага, артистлар арасындагы язучы, диләр! Берәр әсәрегезне укып күрсәтә алмассызмы?

Шәрәфи ялындырмый, мизгелдән әйтә:

*Нәби абый инде ул – Дәүли!*
*Только менә вопрос бар:*
*Дәү ли?*

Тирә-якны алкышлар күмеп китә. «Афәрин, тагын әйт», дигән авазлар яңгырый. Шәрәфи тагын әйтә:

*Буең озын, аркаң да киң,*
*Көчең дә бардыр, Зәки;*
*Шигырь язма, урман кис син,*
*Файдасы булыр бәлки.*

*Г.Камал исемендәге театр.*
*1983. 8 декабрь.*

## Мәрхәбә!

Артист Шәрәфи, авылларга чыккан саен, колхоздан ит-сөт, һич югында бер-ике кило бәрәңге алып китә икән. Акчага сатып ала, әлбәттә. Бушка түгел.

Саба төбәгенең Тимершык авылына автобус белән килгән артистларны каршы алырга колхоз җитәкчесе үзе чыга. Артистлар автобустан төшүгә үк, колхоз рәисе:

– Хуш киләсез! Хуш киләсез! – дип алкышлый.

Шәрәфи, олы буш капчыгын баш очында болгап:

– Хуш киләбез! Буш киләбез, буш киләбез! – дип кычкыра.

*Саба төбәге, Кызыл Мишә кешесе*
**Гыйндулла ГАФИЯТУЛЛА** *сөйләгәннәрдән.*
*1991. 9 гыйнвар.*

## Вакыт белән бәһа

Радио дикторы Камал ханым Саттар, иртән эшкә килеп, хезмәттәшләре белән базар бәһаләре турында сөйләшеп тора икән. Карбызның килосы утыз тиен, итнең килосы биш сум, йөзем ике сум илле тиен, диләр. Ул арада эфирга чыгар вакыт та җитә. Камал ханым иртәнге тапшыруларны болай башлап җибәрә:

– Казан сөйли. Иртәнге радиотапшыруларыбызны башлыйбыз. Мәскәү вакыты белән җиде сум кырык биш тиен!

**Рәшит ӘХМӘТҖАН** *авызыннан.*
*1983. 3 октябрь.*

## Тешле Фәйзи

Җитмештән узган булса да, сүз остасы Фәйзи Йосыпов ара-тирә авылларга чыгып йөри икән. Шулай бер чыгышында бу таныш-якын якларга – Цильна, Шәйморза авылларына кайта. Иске танышы бер мишәр моны танып дәшә:

– Нихәл, Фәйзи! – ди.

– Әйбәт кенә, кордаш! – ди артист.

– Сәламәтлегең ничек, Фәйзи? –ди танышы.

– Яхшы! – ди Фәйзи.

– Әле һаман авылдан-авылга йөрисеңме?

– Йөрим әле, кордаш, һаман йөрим!

– Ничә ел йөрисең инде син, Фәйзи?

– Кырык ел, кордаш, кырык ел!

– Тешләрең ничек, Фәйзи?

– Тешләрем дә бик һәйбәт, кордаш!

– Вата кана, – ди Фәйзинең кордашы. – Кырык ел чүбек чәйнәп тә теш исән булыр икән!

**Рәдиф ГАТАШ** *авызыннан.*
*1986. 23 гыйнвар.*

**Рабит БАТУЛЛА** *тупламасыннан*

# ӘЙТКӘН СҮЗ...

## ИСЛАМ ӘХМӘТҖАНОВКА 70 ЯШЬ

### Кайтып та кермәс идек

Сәгать кичке ун ягына авышкан иде инде, һич көтмәгәндә телефон шалтырады. Гөлдерәп торган тавышыннан, ара-тирә тамак кырып куюыннан ук төшендем – Туфан абый Миңнуллин:

– Братук, ничәгә эшкә йөрисең син?!

– Күптәнге гадәт: җиде тулыр-тулмаста цехта инде, Туфан абый.

– Һе, иртә йөрисең икән. Вакытлы юлаучы гына сигез-тугызга йөри ул. Өйләгә кадәр күрешеп булмасмы дигән идем. Сүзем дә барые сиңа.

– Һич карусыз, Туфан абый, җаена карап килә күр.

Килде, күрештек. Сүзгә-сүз ялганды. Кыска-кыска җөмләләр белән сөйләшәбез. Дөресрәге, Туфан абыйдан – сорау, мин фәкыйрегездән – җавап.

Беравыктан Туфан абый килүенең төп сәбәбен дә әйтеп бирде: ун китаплык сайланма әсәрләрен чыгарырга йөри икән. Һәм бик тиз! Абзыебыз биргән вакыт – ике-өч ай. Килешмәскә ымсынып карыйм: җыясы бар, бизисе бар, калыпка саласы бар, тагын әллә ниләр саныйм, көн-төн эшләсәк тә, өлгерүебез бик икеле, дим! Кая анда, Туфан абзыйның үз туксаны туксан!

– Чабаксарга йә булмаса Нижгарга кит, диюеңмени инде бу?! Үзебездә бастырырмын, дип йөргән идем. Мин түгел, вакыт пуезды ашыга, энем, вакыт пуезды...

...Туфан абыйга каршы килеп буламыни?

Яңа елның (2003 ел турында сүз бара) гыйнвары бетәргә берничә көн кала Туфан абый күптомлыгының сигнал данәләрен кертеп өстәлгә тезделәр. Бүлмә тулып китте. Шалтыратуга, Туфан абый сәгате-минуты белән килеп тә җитте. Әле бу китапны ала, әле икенчесен. Капшап карый, йөзенә китерә, тышлыгына күз сала.

Ил агасы беравыктан: «Киен әйдә, көн уртасы да җитеп килә, киттек!» – дип, мине кай тарафкадыр кыстый башлады. Ун-унбиш минуттан мәркәзебезнең Себер трактындагы «Кама Тамагы» дигән кафесында утыра идек инде. Гөбәдия белән чәй эчтек, әзрәк мәе дә эләкте. Туфан абый, саубуллашканда:

– Һе, ел саен күптомлыклар чыгарсак, Ислам энем, без бу кафедан кайтып та кермәс идек. Юк бит, китап бастырулары авыр шул, – дип куйды.

### Вәгъдә – иман

Узган гасырның туксанынчы еллар башында чыга башлаган «Татарстан хәбәрләре» гәҗите тәүге саннарыннан ук халкыбызның вөҗдан-намусы булган каләм ияләренең, сәхнә йолдызларының, кыю фикерле галимнәр, гаярь хәрбиләр, дәүләт башлыкларының милләттәшләренә атап язган кыска, әмма тыгыз фикри җегәр белән сугарылган ихлас сүзләрен бирә башлады. Беренче булып Гомәр ага Бәширов белән элемтәгә кердек. Олуг әдибебез берсүзсез ризалашты. Ике-өч көн үткәндерме-юктырмы, Гомәр ага, үзе шалтыратып, «Ихлас сүз»нең (язмалар шундый рубрика белән басылды) әзер икәнлеген әйтте.

– Рәхмәт, Гомәр ага, өйлә вакытларында килеп чыгармын, – дип ышандырдым олуг язучыны. Язманы танышу санына, бүтәнчәләтеп дә әйтсәк, гәҗитнең беренче санына бирәчәгебезне дә белдердем. Һәм ул 1991 елның февралендә дөнья да күрде.

Әллә инде гәҗитнең бюджеты каралачак мөһим җыелышка җибәрделәр, әллә башка сәбәп килеп чыкты – тәгаенләп кенә әйтә алмыйм, ләкин Гомәр агадан ул язманы редакциянең башка бер хезмәткәре алып кайтты. Аны күргәч, Гомәр ага, гаҗәпләнүен белдереп:

– Әхмәтҗанов үзе киләм дигән иде бит, – дип куйган.

Каләмдәш нәрсәдер әйткәндер, әлбәттә. Гомәр ага саубуллашканда:

– Менә вәгъдә иткән язма, җибәргән кешегез беренче абзацны кат-кат укысын әле.

Укыйм: «Вәгъдә – иман, дигәннәр борынгы бабаларыбыз. Әйткән сүзең каккан казык шикелле нык, ышанычлы булырга тиешлеген дә искәрткәннәр. «Вәгъдә иттеңме – үтә!», дип васыять итеп тә калдырганнар. Бу әйтем гомер-гомергә әдәп-әхлак кагыйдәләренең нигез ташларыннан саналган...»

Олуг язучының сүзе искә төшкән саен, бүгенгәчә ояла-кызарына башлыйм.

**Ислам ӘХМӘТҖАНОВ**

## СИНЕҢ ЯЗМЫШ ЯЗГА ОХШАГАН

*(Ислам Әхмәтҗановка)*

Сине котлап шаулый татар иле,
Гөр киләдер Буа яклары.
Шәрабләргә куәт өсти сыман
Шагыйрьләрнең татлы такмагы.

Еллар белән бергә ага-ага,
Ил агасы булып җиткәнсең.
Без Исламсыз – синсез нишләр идек? –
Димәк, туып дөрес иткәнсең!

Туып кына түгел, дөнья куып,
Түрләр яулап дөрес иткәнсең.
Түрәләрнең чабатасы түрдә,
Ә син һаман гади икәнсең.

Какканны да күрдең, сукканны да,
Тик какмадың үзең, сукмадың…
Карурманнар аша, адашмыйча,
Алып чыкты тормыш сукмагың.

Мәҗлесләрдә халык эреп төште
Синең баллы, татлы телеңнән…
Белми алар, телгә бал төшкәнче,
Ничә кабат җаның теленгән.

Татар һәрчак китап язуына,
Ташка баскан сүзгә инанган.
Димәк, Ислам, синең бар гамәлең
Изгелектән тора, иманнан.

Иделләрдә бүген бозлар китә,
Хисләр бүген бәйдән ычкынган…
«Синең язмыш язга охшаган!» – дип,
Яр буена басып кычкырам.

Иделләргә чыгып аваз салам,
Кайтавазы килә Осланнан:
«Аермасын Ходай дусларыңнан,
Аермасын безне Исламнан!»

**Разил ВӘЛИЕВ**




*Ислам Әхмәтҗанов Владимир Жириновскийга: «Үзең кит Монголиягә!!!»*
*Мәскәү. Март, 2002 ел.*

**Ислам ӘХМӘТҖАНОВ** *архивыннан.*

## Зәй – Азнакай арасы

Татарстанның Халык язучысы Рабит Батуллага 80 яшь тулу уңаеннан, Зәй һәм Азнакай районнарында әдәби-музыкаль кичәләр булып узды.

Казаннан килгән язучыларны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Илнар Хафизов каршы алды. Соңрак Зәй китапханәчеләре белән иҗади очрашу үтте. Көндез – Мәдәният йортында юбилярны зурлап котлау тантанасы, ә кичен Батулла укыган Түбән Биш авылында якташлары белән күрешү йоласы булып узды.

Икенче көнне очрашулар Азнакай районының 1нче урта мәктәбендә, гимназиядә һәм Кәкре Елга мәктәбендә дәвам итте.

Кунакларны Азнакай районы башлыгы Марсель Шәйдуллин кабул итте.

Юбилей чараларында Батулла үзе, шулай ук Татарстанның Халык язучысы Марсель Галиев, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире, язучы Рөстәм Галиуллин, бүлек мөхәррирләре: язучы Камил Кәримов һәм шагыйрь Фәнил Гыйләҗев, «Чын мирас» журналы баш мөхәррире Ләбиб Лерон, язучы, сәхнә остасы Алмаз Хәмзин катнашты.








2008 елда



# Очрашулар дәвам итә...



*Татарстанның Халык шагыйре Равил Фәйзуллинның туган ягы - Балык Бистәсе районы Балтач авылында очрашу. Яшь шагыйрьләр Фәнил Гыйләҗев һәм Сиринә Мөхәммәтҗанова шигырьләрен дә укучылар яратып кабул итте.*




*Казандагы Альберт Камалиев исемендәге 178нче мәгариф үзәгендә «Казан утлары»н иң күп алдыручы укучылар белем ала. Журнал редакциясе коллективы белән очрашкан укучылардан бер төркем.*



*«Язучы дәрес бирә» проекты дәвам итә. Яшел Үзән шәһәренең 16нчы мәктәбендә без һәрвакыт көтеп алынган кунак. Бу юлы «күчтәнәч»кә Рабит агалары Батулланы алып бардык.*



*Фәнис Яруллинның тууына 80 ел тулу вакыйгасы Казанның 103нче мәктәбендә дә гөрләп узды.*



*Казан шәһәренең 6нчы гимназиясе коллективы «Казан утлары» журналын һәрвакыт көтеп ала. Очрашуда - Алмаз Хәмзин һәм Гөлзадә Бәйрәмова. Уртада - оештыручы, милли мәсьәләләр буенча директор урынбасары Энҗе Гыйззәтуллина.*




*Казандагы чит телләр тирәнтен өйрәтелә торган 132нче мәктәптә дә туган телләрен яратучы татар балалары күп. Камил абыйлары Кәримов аларга әдәбият серләрен ачты.*

**Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ** *фотолары.*



*Ак җилкән*

Балачак белән яшьлек арасындагы
гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу – безнең сәхифә!

Казан федераль университетының Алабуга институты татар филологиясе факультетында башлыча авыллардан килгән кызлар һәм егетләр белем ала. Алар арасында әдәби иҗат белән шөгыльләнүчеләр дә күп. Лилия Сәлимҗанова, Ризәлә Сәйфетдинова, Резедә Сәетгәрәевалар «Татнефть» ААҖ һәм «Рухият» фонды тарафыннан булдырылган Саҗидә Сөләйманова исемендәге стипендия алуга ирештеләр.

Талантлы егет һәм кызларның шигырьләре, хикәяләре төрле район, республика басмаларында дөнья күрә, иҗат конкурсларында призлы урыннар яулый. «Казан утлары» белән дә алар күптәннән дус, язучы-шагыйрьләрне очрашуларга еш чакыралар. «Ак җилкән» белән танышканнан бирле, Алабуга студентлары әлеге сәхифәдә бик теләп катнаша. Бу санда да аларның кайбер шигырьләрен тәкъдим итәбез.

## Төш

Мин төшемдә күрдем: имеш, минем
Яшьлек белән картлык очрашты.
Яшьлек балкып тора, сөйли-көйли,
Картлык тыныч кына сорашты:
«Беләсеңме кая барасыңны?
Бу дөньяда ниләр аласыңны?
Ни югалтып, ниләр табасыңны?
Эш башларга иртәрәкме, соңмы?
Сабый чагың инде үтеп киткән,
Җан сөярлек ярың кайда икән?
Һөнәреңне сайлар чак та җиткән,
Уйланырга вакыт инде күптән».
Яшьлек көлеп кенә җавап бирде:
«Бу дөньяда бәхет кирәк, – диде, –
Бәхетемне тапсам мин юлымда,
Саклар идем аны үз кулымда».

Картлык сорый: «Нәрсә соң ул бәхет?
Кирәкме соң сиңа биек тәхет?»
Яшьлек әйтә: «Хыялларым булсын,
Алар һәрчак чынга ашып торсын.
Яшәр өчен максатларым булсын,
Маяк сыман алга дәшеп торсын.
Дөнья киңлегендә очар өчен,
Пар канатым – сөйгән ярым булсын».

Картлык елмайды да җавап бирде:
«Синдә, миндә бер үк язмыш, – диде, –
Синең хыялларың, максатларың,
Тырышлыгың миңа бәхет бирде».

**Ләйсән САФИНА**

## Күңел түре

Күңел түре бигрәк нәфис җеп шул,
Көтмәгәндә кинәт өзелә,
Юктан гына кайчак ялгана ул,
Гөлчәчәктән кинәт үрелә.

Күңел була, кояш көлеп торса,
Күңел була, кошлар сайраса,
Күңел була, өзелеп сөйгән ярың
Гомерлеккә сине сайласа.

Күңел була, дустың сәлам бирсә,
Хәлне белсә ерак танышың,
Күңел була, әгәр туганнарың
Уртаклашса кайгы-сагышың.

...Күңел түре бигрәк нәфис җеп шул...

**Резедә СӘЕТГӘРӘЕВА**

***

Тулышып түгелсә күңелең,
Җибәрмә,
Йөзләгән йөгәнгә йөгәнлә,
Ни гаҗәп: меңләгән хаталар кылырга
Бары тик бер гомер бирелә.

Җир тырмап елардай булганда,
Бел икән шаркылдап көлә дә,
Тик күңел ялганга бирешми,
Челлә җәй чорында күшегә.

Тартыша күңелем, бирешми,
Һаман да йөгәнләп маташам.
Мин түгел, челлә җәй чорында
Күшеккән күңелем саташкан.

Бер гомер җитәрме икән соң
Һәр кылган ялгышны акларга?
...Күшекмә, күңелем, бирешмә –
Мин сине моннан соң тапламам.

**Рима ФӘРРАХОВА**

# БЕЛӘЗЕК

ХИКӘЯ

Әллә язмышым, әллә ялгышым – юлларымда янә Гамилне очраттым. Аны күрүгә шатландым дип әйтә алмыйм, мине шул мизгелдә бик авыр хисләр өермәсе урап алды. Нинди хис иде ул? Үземне гаепле тоюмы, әллә куркумы… Күзләренә багарга курка идем, ә бит аның матур яшел күзләренә кайчандыр карап туя алмый идем. Ник? Җавапны балачактан, яшьлектән эзләргә туры килер.

Бу кеше – минем иң якыным, иң кадерлем иде, ул янымда булганда, бөтен сагышлар тарала, башыма төшкән бөтен мәшәкатьләремне ул хәл итә иде. Ә балалар йортында мәшәкатьләр аз түгел…

Гамил белән без миңа унике яшьләр тирәсендә, корт оясына яңа ташланган чагымда таныштык. Анда эләгүемнең бик авыр тарихы бар, мин исемә төшермәскә тырышам, ләкин хәтер сандыгына нинди генә бик куйсаң да, тамчылап, кайвакыт исә ургылып ташып чыга шул.

Беренче көннәрдән үк мине караңгылык чолгап алды. Яшәү шартлары коточкыч, начар мөнәсәбәтләргә дә урын күп иде. Яңа кешене беркайда да җылы каршы алмыйлар, мондагы каршылауны әйтәсе дә түгел… Юк, юк… Начарны уйлыйсым да килми. Күңелемә яхшыны гына сеңдерергә тырыштым. Бөтен яманлыкны хәтердән алып атарга. Яхшыны гына искә алырга… Мине артык ачуланмыйлар да, тәрбияче апалар да ягымлылар… Ләкин монда һәрбер кеше ялгыз иде… Юк, кеше дигәнең синең тирәңдә мыж итә, әмма ялгызлык өметсезлеге һәрберсенең күзендә чагыла.

Янымда өемнән килгән ике нәрсә бар иде: әнкәемнең алтын беләзеге – ул аны миңа үлем түшәгендә тапшырды, һәм иске генә телефон. Телефон икенче көнне үк юкка чыкты, үзе аякландымы, аяк куйдылармы… Аның өчен бик кайгырып тормадым, чөнки ул миңа кыйммәт түгел иде, әтиемнең үги кызының искесе иде. Хәтта ничектер җиңел сулап та куйдым. Тик беләзекне мин ике күзем кебек саклый идем, мондагы шартны аңлап, аны ераграк яшердем. Һәрхәлдә, шулай дип уйладым. Тик соңрак аңлашылды: бу козгын оясында яшереп кую, гомумән, мөмкин нәрсә түгел икән. Һәр ялтыраган нәрсәгә күзләре төшкән саескандай, әниемнең изге истәлеген дә юкка чыгардылар. Минем хәлем бик яман, сагышлы, зарлы, йөрәгем яралы чак. Бөтен дөньяны җимерәсе килде, бөтен бүлмәне, бу сөйкемсез балалар йортын ватасы, җимерәсе… Әмма көчем мендәрне кыйнарга һәм акырып еларга гына җитте. Шул көннәрне бик ямансу йөрдем, бернәрсәгә дә игътибар итмәдем. Ул беләзек әниемнең җылысын саклаган хәтерем иде, ялтыравы – киләчәккә өметем, рухым, җаным иде… Әйтерсең, канатларым сынды, яшәвемнең мәгънәсе югалды, тормышымның әһәмияте бетте.

Менә шул караңгы көннәрдә тормышымда Гамил барлыкка килде. Аңа унбиш яшь иде, озын буйлы, тузгыган коңгырт чәчле, зөбәрҗәт тамчылары кебек күзле малаймы, әллә егетме… Аның кыяфәте баштарак миңа бер дә ошамады. Эчке дөньясы да салкын кебек тоела иде. Буш куык булып, янымда саруны кайнатып чуала кебек. Тик хаталанганмын икән. Сизми дә калдым, аның белән аралашу мине тормышка кайтарды. Ул күңелгә хуш килерлек, ярдәм итәрлек сүзләр таба белә. Үткәннәребез дә охшаш, безне шул берләштерде дә инде. Гамил мине аңлый, төрле хәтәр хәлләрдән коткара. Сөенечле мизгелләребез дә байтак булды. Мәсәлән, һәр бәйрәмдә дустым миңа төрле үсемлек яфракларын бүләк итә, мин исә аларны гербарийга җыям. Беләм, кемдер аларны бүләк дип тә санамас… Ә ул шундый матур, гаҗәеп яфраклар алып килә!

Аңа гашыйк булганымны аңышмаганмын да, чөнки мин аны беркайчан да булмаган, ә булуын бик-бик теләгән абыем, дип кабул итә идем. Вакыт шулай кайчак әкрен генә өстерәлеп, кайчак бик тиз, шаулап уза бирде. Минем унбишенче туган көнем җитеп килә иде. Дусларым күбәйде, бер бүлмәдә торган кызлар да миңа якынайдылар. Алар мине иртүк котлады, берсе тумбочкасыннан торт та чыгарды. Бәхетем – чиксез, чөнки өч ел авызыма бер кисәк тә торт капканым юк, аның тәме шундый татлы, шундый баллы иде! Шулай да... минем күңел яфрак көтә иде. Гадәти яфрак. Мин аның белән гербариемның битен бизәр идем...

Әйе, гаҗәеп бер яфрак көттем.

Инде төшке ашны ашап, серле китабымны тотып, Гамилне көтәм, юк, күбрәк ул алып киләсе яфракны көтәм бугай. Әллә үзенме?..

Менә ул керде. Кулларын яшереп, матур, ягымлы сүзләр әйтте. Аннан, кулын алга сузып, учыма нәзек кенә, ялтырап торган беләзек куйды. Әнием беләзеге... Сулышым кысылды, күзләрем яшь белән тулды, кулымнан шуып төшкән гербарийның яфраклары төрле якларга сибелде, минем хәтерем кебек очты, таралды. Тавышым югалды, сүзләр, хисләр буталды. Каршымда басып торган иң якын кешем кинәт явыз, усал бер бәндәгә әверелде, аны бүтән күрәсем дә, беләсем дә килмәде.

Көн-төн уйланып, елап чыктым. Ышанычым, өметем югалды, дөньяга карашым алышынды. Ул көннәр караңгы томан эчендә генә узды. Тагын бер яраткан кешем... Ялгыз калдым. Шулай булса да, мин үзем өчен бик күп нәрсә аңладым, беркатлылыгым юкка чыкты. Гамил иң яман дошманыма әйләнде, дошман гына түгел, хыянәтче иде ул. Йөрәгемдә – нәфрәт, уйларымда – үч алу. Йөрәгемнән ташып чыккан сүзләрне әйтеп кенә тынычлана алмадым. Үзем дә аңа явызлык, начарлык эшләргә теләдем. Ләкин уйлаганнарымны тормышка ашыра алмадым... өлгермәдем. Сүз белән кыйналган Гамил җавап биреп тормыйча, әллә нинди җан әрнүле караш ташлап, ишектән һәм минем тормышымнан чыгып китте.

Сигез ел үтте. Мин аны бик еш исемә төшердем.

Элекке бүлмәдәшләрем беләзекнең Гамил тарафыннан нинди авырлык белән табылуын сөйләгәч, дөньяның бер читеннән булса да аны эзләп табып гафу үтенәсем килде. Аның каршында үземне бик гаепле сизә идем. Бәлки, ул мине күптән оныткандыр инде, мин аның тормышында зур югалту түгелмендер. Ә үзем бик күпне югалттым. Сигез ел дәвамында мин аны табар да идем, тик оялуым һәм киребеткәнлегем янына килеп «гафу ит», дияргә ирек бирми иде. Ничек тә онытырга, онытырга кирәк...

Теләк – теләк белән, ә менә язмыштан качып булмый икән.

...Мин эшләгән кафега бер егет килеп керде. Аның күзләрен һәм елмаюын беркайчан да, беркемнеке белән дә бутап булмый! Ләкин ниндидер кирелек «Танытмаска!» дип этәрә. Ул утырган өстәл янына гамьсез генә килеп бастым. «Нәрсәгә заказ бирәсез?» – дигән җөмлә авызымнан чыгарга өлгермәде, колагым үз исемемне танып алды. Йөрәгем дөп-дөп сикерергә тотынды, тавышын ишеткәч үк, уйларым чуалды, бергә булган чаклар кылт итеп искә төште. Мин аның янында басып тора алмадым, атылып урамга чыктым. Утыргычка чүмәштем дә күз яшьләренә буылдым. Тик аңламыйм: ник елыйм? Бу яшьләр ник болай тамчы-тамчы тама?.. Бу – мин түгел, бу – минем йөрәгем елый.

Кемдер яныма килеп басты, башымнан сыйпады, күзләремә тутырып карады. Аның кулында көзге яфраклар бәйләме иде...

**Юлия ДӘҮЛИКАМОВА,**
*Пенза өлкәсе Каменка районы*
*Кикин урта мәктәбе укучысы*

## Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
## Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### РОССИЯ ПРЕЗИДЕНТЫН САЙЛАУ

Татарстан Республикасында Россия Федерациясе Президентын сайлау зур сәяси активлык һәм күтәренкелек белән узды. Анда барлык сайлаучыларның 77,45 проценты катнашты. Аларның 82,09 проценты Владимир Путинны яклап тавыш бирде.

Россия Федерациясендә кандидатлар тавышны түбәндәге күләмдә (процентларда) җыйды: Владимир Путин – 76,69; Павел Грудинин – 11,77; Владимир Жириновский – 5,65; Ксения Собчак – 1,68; Григорий Явлинский – 1,05; Борис Титов, Максим Сурайкин, Сергей Бабуриннарныкы – 1 проценттан кимрәк.

### ПРЕЗИДЕНТ – ГОРЬКИЙ ҺӘМ ШАЛЯПИН МУЗЕЕНДА

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов Казанда Горький һәм Шаляпинның яңартылган музеенда булды, экспозицияләр белән танышты. Бүгенге көндә Горький коллекциясендә – кырык мең, Шаляпиннықында дүрт мең экспонат исәпләнә. Экспозицияләр белән танышканнан соң, Р.Миңнеханов «Трактир у Горького» кафесында балалар өчен оештырылган икмәк пешерү буенча осталык дәресендә катнашты. Аннары ТР Президенты республиканың иҗат интеллигенциясе вәкилләре белән очрашты.

### ТУКАЙ БҮЛӘГЕН ДӘГЪВАЛАУЧЫЛАР

Татарстан Президенты карамагындагы Габдулла Тукай исемендәге Татарстан Республикасы Дәүләт премияләре буенча комиссиясе утырышында Премиягә тугыз кандидатураны күрсәтү турында карар кабул ителде.

1. Т.Миңнуллин исемендәге Түбән Кама дәүләт татар драма театры иҗат коллективы: Галиев Рөстәм Вәлиәхмәт улы (директор һәм баш режиссёр), Нәсихов Булат Вакыйф улы (баш рәссам), Шәмәрдәнова Гүзәл Фазыл кызы (артист) – Чыңгыз Айтматовның «Анам кыры» повесте буенча куелган спектакль өчен.

2. Гаффаров Габделәхәт Габдрахман улы – «Олы юлның тузаны» романы һәм «Дәрья башы: повесть, романнар, хикәяләр» (Казан, Татар.кит.нәшр., 2013) һәм «Әхәт Гаффар: балалар өчен әкиятләр, хикәяләр, пьесалар» (Казан, Татар.кит.нәшр., 2016) китаплары өчен.

3. Дубин Абдулла Ибраһим улы – «Казань на старинных открытках» (Казан, «Светлячок» нәшрияты, 1994), «Казань историческая: альбом» (Казан, Татар.кит.нәшр., 2004), «Старая Казань и её окрестности» / автор проекта, сост. А.И.Дубин» (Казан, Татар.кит.нәшр., 2011), «Две Казани: альбом» / автор проекта, сост. А.И.Дубин» (Казан, Заман – Татар.кит. нәшр., 2011), «Старая Волга: её люди, её суда, её судьба...» (Казан, «Идел-Пресс» нәшрияты, 2012), «Астрахань историческая» (Казан, «Идел-Пресс» нәшрияты, 2005) китаплары, тупланмалары өчен.

4. Кәримов Камил Әдһәм улы – «Карурманда кара песи: повестьлар һәм хикәяләр» (Казан, Татар.кит.нәшр., 2015), «Игезәкләр йолдызлыгы: романнар» (Казан, Татар.кит. нәшр., 2016).

5. Кузнецов Михаил Иванович – «Белые холсты. Народы Поволжья» эшләре сериясе өчен (33 эш).

6. Петров Александр Александрович – «На стихи Г.Тукая» (10 эш), «Памяти Булгар» (19 эш), «Из детства» (21 эш) серияләре өчен.

7. Хаҗиев Мәдияр Шәрип улы – «Татар хатын-кызлары» эшләре сериясе өчен (25 эш).

8. Хөснетдинов Зиннур Зыятдинович (Зиннур Хөснияр) – «Кичү: хикәяләр, повестьлар, роман-дилогия» (Казан, Татар.кит.нәшр., 2012), «Гарасат: роман-дилогия» (Казан, «Хозур» нәшрияты, 2014) һәм «Көмеш чыбыркы: повестьлар һәм романнар» (Казан, Татар.кит. нәшр., 2016) китаплары өчен.

9. «Таттелеком» гаммәви акционерлык җәмгыяте иҗат төркеме: Шәфигуллин Лотфулла Нурислам улы һәм Зәкуанов Рөстәм Газизҗан улы – Татарстан Республикасында яши торган халыкларның милли байлыкларын, тарихи мирасын, мәдәниятен үстерү һәм саклап калуга керткән зур өлешләре өчен.

### ИСКӘ АЛУ КИЧӘСЕ

Чистай районы Яуширмә авылы Мәдәният йортында татар әдәбияты классигы, публицист, җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакыйның тууына 140 ел тулу уңаеннан, «Сүнә белми торган ялкын» дип аталган әдәби-музыкаль кичә булды. Анда Чистай муниципаль районы башлыгының беренче урынбасары Рөстәм Хамматов, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, берлек әгъзалары Рабит Батулла, Марсель Галиев, Фоат Галимуллин,

Фәүзия Бәйрәмова, Вахит Имамов, Ләбиб Лерон, Факил Сафин, галимә Лена Гайнанова чыгыш ясады.

### ИСХАКЫЙНЫ МӘСКӘҮ ДӘ ОНЫТМЫЙ

Гаяз Исхакыйның тууына 140 ел тулу уңаеннан, Мәскәүдәге М.Җәлил исемендәге мәктәптә әдәби кичә булды, Татар җәмәгатьчелеге клубы әдип хөрмәтенә махсус утырыш үткәрде. Бу чараларда КФУ профессоры Хатыйп Миңнегулов катнашты һәм чыгыш ясады.

Мәгълүм булганча, Г.Исхакый Мәскәү белән тыгыз элемтәдә була. Монда ул «Ил» («Сүз», «Безнең ил») газетасын чыгара. «Сәйяр» труппасы аның «Зөләйха» трагедиясен күрсәтә. Биредә язучының әсәрләре басыла.

### ӘДИПНЕ ЯКТАШЛАРЫ ДА ЗУРЛАДЫ

Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗевнең тууына 90 ел тулу уңаеннан, Сарман районы (әдипнең нәсел-нәсәбе, әти-әнисе чыгышлары белән шушы төбәктән) Җәлил бистәсендәге 2нче мәктәптә искә алу чаралары (доклад-чыгышлар, мастер-класслар, А.Гыйләҗевнең әсәрләренә иллюстрацияләр күргәзмәсе, язучы пьесалары буенча куелган спектакльләрдән өзекләр күрсәтү) үткәрелде. Аларда әдәбият галимнәре Хатыйп Миңнегулов, Әнвәр Шәрипов, Миләүшә Хәбетдинова, Дания Сибгатуллина, шагыйрә, галимә Рәзинә Мөхияр, әдипнең хатыны, Сарман кызы Нәкыя Гыйләҗева, җирле хакимият, җәмәгатьчелек вәкилләре, республикабызның төрле төбәкләреннән килгән укытучылар, укучылар, яшь иҗат әһелләре катнашты.

### «ЕЛ КИТАБЫ – 2016» БӘЙГЕСЕ

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе Мәдәният министрлыгы, Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы белән берлектә үткәрелә торган «Ел китабы – 2016» бәйгесенә йомгак ясады.

Конкурста 381 китап катнашты, шуларның: 51е – проза, 75е – шигърият, 44е – балалар әдәбияты, 49ы – рус телендә чыккан матур әдәбият, 92се – татар телендәге публицистика һәм фәнни-популяр әдәбият, 70е – рус телендәге публицистика һәм фәнни-популяр әдәбият китаплары.

Татарстан нәшриятларында 2016 елда басылып чыккан, 2017 ел дәвамында иң күп укылган китапны билгеләүдә республикабызның 1510 китапханәсе катнашты.

Татарстанның халык язучысы Гәрәй Рәхим җитәкчелегендәге жюри җиңүчеләрне билгеләде.

Проза

I урын – Нәбирә Гыйматдинова. «Сөйлим, тыңла...»; II урын – Айгөл Әхмәтгалиева. «Таллыкүлдә былбыл бар»; III урын – Сәйдә Зыялы. «Яралы кош авазы». Кызыксындыру бүләге – Камил Кәримов. «Игезәкләр йолдызлыгы», Гөлсинә Галимуллина. «Алтын ачкыч», Равилә Шәйдуллина-Мурат. «Ялантауга ай кунган».

Шигърият

I урын – Муса Җәлил. «Моабит дәфтәрләре=Моабитские тетради»; II урын – Роберт Миңнуллин. «Монда без дә бар әле!»; III урын – Клара Булатова. «Гасыр белән гасыр арасында». Кызыксындыру бүләге – Рәмис Аймәт. «Бозлы җилкәннәр», Рәдиф Гаташ. «Ихласнамә».

Балалар әдәбияты

I урын – Габдулла Тукай. «Әтәч илә Энҗе бөртеге»; II урын – Лиана Әмирханова. «Китап яратучы малай»; III урын – Йолдыз. «Аппак белән Шапшак=Аппак и Шапшак». Кызыксындыру бүләге – Факил Сафин. «Керпенең шәһәргә сәяхәте».

Рус телендә чыккан матур әдәбият

I урын – Габдрахман Әпсәләмов. «Белые цветы»; II урын – Әхәт Мушинский. «Чёрный индюк, красные штаны...=Кара күркә, кызыл ыштан...»; III урын – Рафис Корбан. «Куда уходит ночь?». Кызыксындыру бүләге – Рөстәм Кутуй. «Сердитый трамвай», Борис Вайнер. «О дырках в зонтике и о других важных вещах».

Татар телендәге публицистика һәм фәнни-популяр әдәбият

I урын – Әзһәр Шакиров. «Язмыш»; II урын – Индус Таһиров. «Без тарихта эзлебез»; III урын – Алла Сальникова, Диләрә Галиуллина. «Татар «Әлифба»сы: үткәне һәм бүгенгесе=Татарская «Алифба»: история и современность». Кызыксындыру бүләге – Альберт Гадел. «Фокуслар энциклопедиясе», Әхәт Гаффар. «Сайланма әсәрләр». 4нче том.

Рус телендәге публицистика һәм фәнни-популяр әдәбият

I урын – Юныс Әхмәтҗанов. «Татарские национальные блюда»; II урын – Роман Почекаев. «Чингизово право: правовое наследие Монгольской империи в тюркско-татарских ханствах и государствах Центральной Азии»; III урын – Фәндәс Сафиуллин. «За свободу и равноправие». Кызыксындыру бүләге – Нияз Халит. «Стили и формы татарской архитектуры Казани 1920 гг.»

2018 елның 18 мартында 73нче яшендә шагыйрь, Һ.Такташ исемендәге әдәби премия лауреаты **Илдус Сабир улы Гыйләҗев** вафат булды.

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: повесть М.АМИРХАНОВА «Зиннатулла хазрат», философская повесть К.КАРА «Депрессия», повесть Д.БУЛАТОВОЙ «Ещё не поздно!»; рассказ А.ХАЛИМА «В чужбине»; поэма Р.ШАРИПОВА; стихи Р.НИЗАМИ, Х.МУДАРРИСОВОЙ, Р.ГАРИФУЛЛИНОЙ.*
*«Актуальная критика»: рубрику ведёт Д.ЗАГИДУЛЛИНА.*
*«100-я страница»: Р.АХУНЗЯНОВА. «Родной язык» Тукая».*
*«Новые имена»: фантастический рассказ А.ГАЛИЕВОЙ с предисловием М.ЗАКИРА.*
*«Кандидаты на Государственную премию имени Г.Тукая»: рассказ А.ГАФФАРА «Возвращаясь из будущего»; очерк А.АХМЕТГАЛИЕВОЙ «Нет цены доброте…».*
*«Литература родственных народов»: «Якутские прибаутки». Перевод М.ВАЛИЕВА.*
*«Литературная критика»: статья Ф.ГАЛИМУЛЛИНА о творчестве Гафура Кулахметова.*
*«Наши юбиляры»: статья Х.МИННЕГУЛОВА, посвящённая 85-летию М.Амирханова.*
*«Тукай и татарская литература»: рубрику ведёт Р.РАХМАН.*
*«Религия и жизнь»: Харис хазрат САЛИХЗЯН. «Отношение поэта к Корану».*
*Рассказы из жизни В.НУРИЕВА.*
*«Юмор и сатира»: юморески, посвящённые Р.Шарафиеву из сборника Р.БАТУЛЛЫ; юморески И.АХМЕТЗЯНОВА; стихотворение Р.ВАЛИЕВА, посвящённое И.Ахметзянову.*
*«Поездки, встречи, впечатления».*
*«Белый парус»: стихи Л.САФИНОЙ, Р.САЕТГАРАЕВОЙ, Р.ФАРРАХОВОЙ; рассказ Ю.ДАВЛИКАМОВОЙ «Браслет».*
*Из фотоархива журнала.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: «Портрет Тукая». Работа Файзрахмана Аминова. 1976 год; литературно-скульптурный парк, созданный компанией «Таттелеком» в деревне Новый Кырлай Арского района. Фото Андрея Титова.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: novel by M.AMIRKHANOV «Hazrat Zinnatulla», philosophical novel by K.KARA «Depression», novel by D.BULATOV «It's not too late!»; story by A.KHALIM «In exile»; poem by R.SHARIPOV; poems by R.NIZAMI, H.MUDARISOVA, R.GARIFULLINA.*
*«Actual criticism»: section is conducted by D.ZAGIDULLINA.*
*«100th page»: R.AKHUNZYANOV. «Tukay's mother tongue».*
*«New Names»: fantastic story by A.GALIEVA with preface by M.ZAKIR.*
*«Candidates for the G.Tukay State Prize»: story by A.GAFFAR «Coming back from the Future». Sketch by A.AHMETGALIEVA «There is no price to kindness…»*
*«Literature of peoples of the world»: «Yakut humourous catchphrases». Translation by M.Valiev.*
*«Literary criticism»: article by F.GALIMULLIN on the work of Gafur Kulakhmetov.*
*«Our heroes of anniversary»: article by H.MINNEGULOV dedicated to the 85th anniversary of M.Amirkhanov.*
*«Tukay and Tatar literature»: heading is conducted by R.RAHMAN. «Religion and Life»: Hazrat Haris SALIHZYAN. «The attitude of the poet to the Koran».*
*Stories from life of V.NURIEV.*
*«Trips, meetings, impressions».*
*«Humor and satire»: humoresques by I.AKHMETZYANOV; poem by R.VALIEV; dedicated to I.Akhmetzyanov; humoresques dedicated to R.Sharafiev from the collection by R.BATULLA.*
*«White Sail»: poems by L.SAFINA, R.SETGARAEVA, R.FARRAKHOVA;*
*story by Yu. DAVLIKAMOVA «Bracelet».*
*From the magazine photoarchive.*
*Diary of public and cultural life.*
*On our covers: «Portrait of Tukay». The work of Faizrakhman Aminov. 1976 year; literary and sculptural park created by «Tattelecom» in the village of Novy Kirlay in the Arsky district. Photo by Andrey Titov.*

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Тукай портреты». *Фәйзрахман Әминов эше. 1976 ел. «Казан утлары» журналының проза бүлеге мөхәррире Камил Кәримов тарафыннан 2017 елда Тукай музеена бүләк ителде.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* Арча районы Яңа Кырлай авылында «Таттелеком» компаниясе тарафыннан булдырылган әдәбият-скульптура паркы.
*Андрей Титов фотосы.*